www.kazanutlary.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

*ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ*

*1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА*

## Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Рашат НИЗАМИ. Хәтер үзәнендә тора сакта. *Шигырьләр*. ....3
Нәфикъ ЯҺУДИН. Атлы казаклар. *Роман*. ....8
Равил РАХМАНИ. Күкрәк тулы моң калган... *Шигырьләр*. ....86
Рөстәм ГАЛИУЛЛИН. Әдрән. *Бәян*. ....90
Фәйрүзә МӨСЛИМОВА. Дөнья шундый тиз үзгәрә. *Шигырьләр*. ....136
Гөлнур ВАСЫЙЛОВА. *Нәсерләр*. ....140
Фәнәвис ДӘҮЛӘТБАЕВ. Сагындырганы — яшьлек еллары. *Робагыйлар*. ....143

*100нче бит:* Гарифҗан МӨХӘММӘТШИН. Татар моңы. ....100

«ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛ»

XX гасырның иң зур тарихи вакыйгасы... Иртәгә безне ни көтә? *(И.Таһиров, Р.Хәкимов, И.Ибраһимов, И.Заһидуллин, Л.Гобәйдуллин катнашында.)* ....*147*

ЯҢА ИСЕМНӘР

Миләүшә ЗАКИРОВА. Күпсенмәсен күкләр генә... *Шигырьләр*. ....161

КОЯШ ТИМБИКОВАНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Мәдинә МАЛИКОВА. Күңелем яктырткычы. ....166

ЗИННУР НАСЫЙБУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Зиннур НАСЫЙБУЛЛИН. Моңнар белән шуңа чигелгән. *Шигырьләр*. ....168

ЮБИЛЕЙЛАР

Дания ЗАҺИДУЛЛИНА. Галимә ачкан дөньялар. ....171
Зиннур МАНСУРОВ. Рухият югарылыгына чакыру. *(Лирон Хәмидуллинга 85 яшь)*. ....177

ЮМОР-САТИРА

Мөхәммәт МИРЗА. Ант эчкәндәге ысылдаулар... ....187
Рөстәм АРИФУЛЛИН. Колхоз кассиры Кәүсәрия һәм банкомат. ....188

«Казан утлары» архивыннан. ....164
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....189

Гамәлгә куючы –
«Татмедиа»
акционерлык
җәмгыяте

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Илфак Мирза улы**
**ИБРАҺИМОВ**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Рәдиф Җамалетдинов**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Дамир Исхаков**
**Зиннур Мансуров**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Вакыйф Нуриев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Данил Салихов**
**Айрат Сибагатуллин**
**Энгель Фәттахов**
**Равил Фәйзуллин**
**Рамил Ханнанов**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Рәфикъ Юныс**

---

*Мөхәррирләр:* **Айгөл Әхмәтгалиева, Гөлзадә Бәйрәмова, Фәнил Гыйләҗев, Камил Кәримов, Ләйсән Солтанова, Рәфикъ Юныс.**
*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Наил Кадыйров.**
*Сайт мөхәррире:* **Рәзилә Хәйретдинова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Люция Сөләйманова** (баш бухгалтер)**.**

---

✉✉: Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир – 222-05-50 (өст. 1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1266).*
➁: **Факс** – (843) *222-09-83 (өст.1612).*

💻: **E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.


---

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 31.10.2017, график буенча 31.10.2017.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 $^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ А-2778. Тираж 4050.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекслар: 73210 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен), П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), 16262 (Татарстаннан читтәге юридик затлар өчен), П2368 (Татарстандагы юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2017 ел



Рашат
Низами

# ХӘТЕР ҮЗӘНЕНДӘ ТОРА САКТА

## Тукай кайтып төшсә...

Әгәр Тукай кайтып төшсә
Бүгенге көнебезгә, –
Кулын куеп каш өстенә
Ни әйтер иде безгә?..
Терелеп кайтсамы Тукай
Бүгенге Казанына,
Азык тапмый калмас иде
Үзенең язарына.
Дияр иде: татарымның
Рухы-җисме тазамы?
Ничекләр соң дәвам итә
Алу-сату базары?..
Кай патша идарә итә
Сез яшәгән чорларда:
«Әллүки»ләр калды микән
Сез җырлаган җырларда?
...Туган тел язмышын күреп,
Кабатлар иде шуны:
«Әй син, Дума, Дума, Дума,
Эшләгән эшең бумы?»
Карәхмәтләр урынына
Бур Әхмәтләр ишәйде.
Урлашуда, гөрләшүдә
Мафияләр көчәйде!
Шүрәле каргаган авыл
Юк, дисеңме, һаман да, –
Өр-яңадан кайтып төштек
«Крепостной» заманга!

Рашат НИЗАМИ (1950) – *шагыйрь, прозаик, публицист; «Кызыл җәй», «Ут һәм Җыр», «Татар моңының өч йолдызы» һ. б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Һ.Такташ исемендәге әдәби премия лауреаты. Казанда яши.*

Ит белән сөт һаман әле
Крәстиан җилкәсендә.
Үзгәреш күренми хәтта
Мәхәббәт өлкәсендә:
Кайда – Таһир-Зөһрә кебек
Сөюдә янган утлар;
Китап битләренә чумып
Ләззәт эчкән минутлар?
«Интернет» белән «инкыйраз»
Рифмалашкан заманда, –
Вәсвәсәче иблис токым
Уен уйный һаман да.
Харап була яшь-җилкенчәк –
Капты «афәт» базына:
Эшен ташлап, берөзлексез
«Портал»ларда казына.
Әдәп-әхлак, сәясәтнең
Саекты чишмәләре.
Хәтта классик әсәрләрнең
Чүплеккә киткән мәле!
Рухы түгел, акча өчен
Ил эчендә дау бара.
Монафикълар, балта тотып,
Кабер ташын аудара...
Кешелеккә ябырыла
Супер глобальләшү, –
Ходай нигъмәтләре белән
Мәңгегә бәхилләшү.
Яшәеш – ватык куласа,
Бер әйләнә, бер баса.
Сугыш-сугыш уйный илләр,
Дөнья – канлы тамаша.
...Әй, Тукайҗан!
Кайта күрмә
Безнең бүгенге көнгә, –
Дучар буласыбыз килми
Синең усал хөкемгә!
Уттан алып, суга салып
«Пешекләр» идең безне!
Зарыбызны аңлаучы юк,
Белүче хәлебезне...
Шигырьчеләр бик күп хәзер,
Сатирада
Юк шул синдәй маһирлар.
«Дефицит» бездә – шагыйрьләр,
Синең кебек шаһ ирләр!..

## Дөреслек

Метеордай чабып узды еллар...
Таш ватылды. Үлде патшалар.
Ә хакыйкать барыбер үлми икән –
Арка терәп хәтта атсалар!

## Теләк

Дәрвиш сыман, әй, кичәсе килә
Урман белән урман арасын, –
Күрәсе һәм иркәлисе килә
Яңа туган поши баласын!

## Бүген

Черки җилдән һәм кояштан курка,
Кыргый адәм уттан курыккан.
Йолдызларны, күкне айкый кеше,
Бүген аңа – галәм тубыктан!

## Таң

Һәр көн саен таңны каршы алам –
Булсын, диеп, илдә бәрәкәт.
Ничә илнең куенында – бомба,
Тәүлек саен
Көтми микән безне һәлакәт?..

## Хәтерләү

Басуларга тагын чыгып китәм,
Табанымда – камыл эзләре.
Юл читендә күзен кысып кала
Күкчәчәкнең зәңгәр күзләре.

## Көнләшү

Казакъ якта милли университет
Ачтылар бит – әттәгенәсе!
Татаргамы? Шушы горурлыкның
Калды бары мескен «көлтәсе»...

## Комсызлык

Америка гарәп илләренә,
Көчли-көчли,
«Демократик» калҗа өләшә.
Кыйтгаларны кабып йотар иде –
Рөхсәт биреп, Ходай теләсә!..

## Җанисәп

Империя ганимәтен барлый:
Кешеләр дә,
Җир һәм сулар – бар да исәптә.
Сугышларны туктатмаган Илаһ,
Күпме генә корбан бирсәк тә...

## Күчеш

Дәште кыпчак далаларга дәшкән, –
Җир тетрәгән. Таулар авышкан.
Бөек күчеш! Дәверләрне кичеп,
Кыйтга белән кыйтга кавышкан...

## Тартыш

Дошманыммы? Бары берәү генә!
Гаҗәпләнмә, ул бит – мин үзем.
Төртеп егам, тартып торгызам да
Чакма-чакма киләм көнозын...

## Биеклек

Бөркет оча торган, һай, киңлекләр
Канатсызга мәңге тәтемәс.
Йөрәгендә иман булган затлар
Кылыч каршында да баш имәс!

## Ачы!

«Күңелем ачы тели», – дисең –
Гәрчичме, әллә суган?
Тормыштагы «ачы»лыклар
Җитмиме сиңа, туган?

## Кырым

Тарихчылар һаман бәхәсләшә:
Кемнеке бу утрау китеге?
Ничәнче кат Кырым буйлап атлый
Рәсәй солдатының итеге?

## Мәскәү

Такташ сыман күчим микән әллә
«Аһ... анасын сатыйм»га?!
Рекламалар... Неон утлар яна –
Мәскәү үзе
Әллә кайчан күчкән латинга!

## Алма исе

Агачларны ап-ак сыкы баскан,
Гыйнвар ае тәмам бозланган.
Ни могҗиза: карлар яуган чакта,
Алма исе килә кызлардан...

## Ветеран

Ветераннар нигә картаймасын:
Айлар, еллар бара авышып.
Мәйданнарга чыксам – ишетәмен
Култык таяклары тавышын.

## Яхшылык

Картаймый – таң саен һаман да
Яшәргә ашкына бу күңел.
Гомернең өч көне калса да,
Яхшылык эшләргә соң түгел!

## Тар-мар

Минем кулда – мылтык-фәлән түгел,
Үткен каләм, куен дәфтәрем.
Ямьсезлекне тар-мар итү өчен –
Мин чакырам шигырь гаскәрен!

## Шәҗәрә

Ага-ага Идел тирләп чыккан,
Күбекләнеп ярга бәрелә.
Идел-йортның газиз бер тамчысы
Кушылгандыр минем тәнемә.

## Кисәтү

Әдип сүзен, китап сүзен әгәр
Кыса барсак шулай без тагын, –
Бернинди дә текә икътисадлар
Коткаралмас Илнең әхлагын!..

## Мәгыйшәт

Мәгыйшәтнең менә шундый чагыдыр:
Ярлы мескен совет чорын сагыныр.
Урта хәлле – тыпырчыныр уртада,
Байлар исә акчасына табыныр...

## Балбал

Бернәрсә дә тоймый, ишетмидер,
Хәтер үзәнендә тора сакта.
Миллион гасыр кичкән таш кисәге
Елый белә – яңгыр яуган чакта...



Нәфикъ
Яһудин

# АТЛЫ КАЗАКЛАР

РОМАН

**1**

Хисамый Җәләй белән сөйләшеп алырга ашыкты. Хисамыйда бүген иртә белән ничектер кинәт кенә шундый теләк кабынып куйды. Әле йокыдан торган вакытта да ул мондый фикердә түгел иде. Әмма, уяну белән үк, аның күңелен нәрсәдер тынычсызлый, ул нәрсә турындадыр борчылып уйлана башлады. Иренең шундый уйчан хәлдә булуын күреп, Мәгузә дә аңа һичбер сүз әйтмәде. Ул, әгәр дә иренә берәр сүз кушса, аның карышып һәм киреләнеп китүеннән курка иде. Әйе, иренең комганына җылы су салганда да, аның өс киемнәрен киендергән һәм кулына чалмасын тоттырган вакытларда да, Мәгузә аңа бер сүз дә әйтмәде. Бу хәл Хисамыйга, чыннан да, Мәгузә уйлаганча уңай тәэсир итте. Үзалдына борчылып уйлаган саен, Хисамыйның Җәләйне күреп сөйләшү теләге көчәя генә барды. Ә өеннән урамга чыккач, ул инде үз-үзенә тәмам ышанып: «Кешеләр азрак вакытта барыйм да картны аулакта гына күреп әйтим, миңа рәнҗеп йөри күрмәсен», – дип уйланды. Ләкин Хисамый соңгарак калды. Ул килгәндә, мәчеткә байтак кеше җыелган иде инде.

Хисамый, үз теләгенә ирешү өчен, ничек тә Җәләйгә якынрак булырга тырышты. Ләкин алдан килеп утырган кешеләрне аралый-аралый үтәргә уңайсызланып калды һәм ишек янындагы мич буена гына барып урнашты. Хәзер Хисамыйда башка теләк – ерактан булса да, Җәләйнең күз карашларын тотып алырга һәм ул карашларның мәгънәсен аңларга тырышу теләге туды: нишли икән, Сабан туенда көрәшкә чыгарга җыенуым өчен карт миңа рәнҗеп йөрмиме икән, дип борчыла иде Хисамый. Ләкин ул Җәләйнең күз карашларын да тота алмады. Чөнки Җәләй һич тә кузгалмый һәм як-ягына каранмый гына утыра. Ул хәтта янындагы кешеләр белән дә сөйләшми иде бүген. Хисамый, кичә кичтән үк Җәләй картның өенә кереп, аның белән барысы турында

Нәфикъ ЯҺУДИН (1910-1977) – *Ватан сугышы ветераны. Күпсанлы хикәяләре һәм очерклары «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналында дөнья күргән. Башкортстанның атказанган укытучысы. Әлеге романны аерым китап итеп чыгару турында Татарстан Язучылар берлеге 1941 елның 21 июнендә карар кабул итә. Сугыш башлану сәбәпле, карар үтәлми кала. Кулъязманы авторның улы – Россиянең Язучылар һәм Татарстанның Журналистлар берлекләре әгъзасы Марс Яһудин тапшырды. Автор хакындагы тулырак мәгълүматны роман ахырындагы искәрмәдән укыгыз.*

да ачыктан-ачык сөйләшеп куймавына үкенә башлады. Кичә аны бу эшкә ниндидер горурлык, турысын гына әйткәндә, үзен тәкәбберрәк тотарга теләве җибәрмәде. Хатыны Мәгузә дә әйтеп-әйтеп караган иде юкса:

– Әтисе, сиңа әйтәм, көрәшкә чыгам дип йөрисең йөрүен дә, Җәләй абзыйның моңар хәтере калмасмы? Ничә әйтсәң дә, байтак еллардан бирле мәйдан тотып килгән кеше бит. Безнең Яңа Чиркас авылында гына түгел, бөтен әйләнә-тирәдә йөзәр чакрымга аның даны таралган. Оренбург кадәр Оренбургның үзендә ел саен батыр булып килде. Җитмәсә тагын, гомер-гомергә күрше булып, тату гына көн кичереп киләбез үзебез. Егылсаң – үзеңә хурлык, ексаң – Җәләй абзый кызганыч.

Аңа каршы Хисамый җитди генә бер тавыш белән үзенең гадәттәге җавабын кайтарды:

– Сөйләмә әле, әнисе, дөньяда мин дә казачи исемен күтәреп йөрим ләбаса! Чын-чынлап казачи булу өчен нәрсә кирәк? Көмеш кашлы ияре, җиз саплы камчысы, чуклы йөгәннәре белән яхшы ат, бүресен дә, куянын да тота торган озын танаулы эт, шулар өстенә тормыш итүеңнең рәте-башы булырга тиеш. Ә мин нәрсә? Мин боларның берсе белән дә мактана алмыйм. Андый бәхетләр безгә бала-баладан ук насыйп булмады. Мин үземнең бер-бер артлы туган өч ир бала үстерүем белән генә мактана алам. Әйе, менә дигән яшь казачилар үстерәм мин! Ходай аларга күп-күп бәхетләр бирсен.

Мондый сүзләрдән Мәгузә дә кәефләнеп куйды. Ул, иркәләнеп кенә:

– Шул җиткән инде, тагын нәрсә кирәк сиңа! – диде. – Улларың үз бәхетләре артыннан үзләре куарлар.

– Юк, әнисе, җитмәгән шул әле! Дөрес, атын да, башкаларын да булдыру – анысы байлыкка бәйләнгән. Ул безнең кулдан гына килә торган эш түгел. Белмим, аны безнең улларыбыз да булдыра алыр микән. Ә менә үзең казачи исемен күтәреп йөреп, гомереңбуенча бер мәртәбә дә мәйданга чыгып көрәшмәү – бу инде бик зур хурлык. Чын казачи өчен оят эш бу.

– Ә егылып куйсаң?

Хисамый кызып китте:

– Егылып куйсаң да, егылып куйсаң, сиңа тагын! Егылып куйсаң – җир күтәрә, җир астына берәүнең дә төшеп киткәне юк бит әле.

Мәгузә, иренең азрак тынычлана төшүен көтеп торды да:

– Әтисе, шушы гомер түзеп килгәнсең икән, тагын берәр елга гына түзәсеңме әллә? Киләсе елга көрәшер идең, – диде.

– Куйсана, әнисе, башымны катырма әле син минем! Хәзер инде минем көрәшкә чыгарга җыенуымны бөтен кеше белә. Хәтта чит авыл кешеләре дә ишеткән инде бу хәбәрне. Шуның өстенә, эти мәрхүм үлгән вакытта васыять итеп әйтте бит: улым, Сабан туйларында көрәш мәйданына чык, кеше арасына кереп, үзеңне кешеләргә күрсәтеп йөр, диде. Әтине беләсең, мин гомерем буена көрәшеп килдем, мәче шикелле булдым, дип әйтим инде, берәү дә сыртымны җиргә тидерә алмады, диде мәрхүм.

– Белмим инде, әтисе, ул якларын үзең беләсең тагын. Җәләй абзый рәнҗи күрмәсә ярар иде, дип кенә әйтүем. Әтеки мәрхүм вафат булганнан соң, ел саен Җәләй абзый батыр булып килде бит... Үзе белән сөйләшеп алсаң да яхшы булыр иде, бәлкем...

Мәгузәнең тел төбендә әйтелеп бетмәгән башка уйлар да бар. Ул үзе бер нәрсә турында сөйли, ә бөтенләй башка нәрсәләр турында фикер йөртә иде.

Җәләй гаиләсе белән Хисамыйныкылар күптәннән аралашып, байтак

еллар буенча аерылмас дуслар булып яшиләр. Ә соңгы елларда, Миңлебай белән Мәрьям якты дөньяга килгәч, бу ике гаилә арасындагы якынлык тагын да ныгый һәм беркетелә төште. Әйе, бервакыт шулай Хисамый белән Мәгузә Җәләйләргә кунакка керделәр. Аларның уллары Миңлебайга өч яшь иде. Аны да үзләреннән калдырмадылар. Җәләйнең Мәрьяменә бер яшь тулып, аның да күңелле генә итеп тәпи йөрергә өйрәнеп килгән чагы. Кунаклардан берсе, идәндә уйнап йөргән балаларга карап:

– Болар икесе дә бик матурлар, бер-берсенә бик пар киләләр икән, – диде.

Икенче берәү:

– Чынлап та, бу балаларны колак тешләтеп куйсагыз, пар күгәрчен шикелле гөрләшеп гомер итәрләр иде, – дип, тегенең башлаган фикерен куәтләде.

Җәләй белән Мөршидә дә бу уйга каршы түгелләр иде. Җәләй, Хисамыйның «кылын» тартып карау теләге белән:

– Колак тешләтү безнең татарларда бик кулланылмый инде үзе. Ул, асылда, казакълар гадәте бит, – диде.

Хисамый исә, үзенең бу эшкә һич тә каршы түгеллеген белдереп:

– Асылда казакълардан кергән гадәт булса да, безнең авылда хәзер күп кеше шулай итә бит, – дип куйды. Күңелле генә елмаеп хатынына таба ымлады да: – Мин үзем дә Мәгузәнең колагын шушы улым кадәр вакытта тешләп куйган идем. Болай, яхшы гына гомер итеп киләбез бугай, – дип өстәде.

Нәтиҗәдә Мөршидә кызы Мәрьямне үз янына сәкегә чакырып алып утыртты. Мәгузә улы Миңлебайны, җитәкләп алып барып, Мәрьямнең каршысына бастырды да:

– Йә әле, улым, әнә шул матур сеңлеңнең колагын тешләп ал әле, – диде.

Миңлебай шунда ук Мәрьямнең сул колак яфрагын нык кына итеп тешләп тә алды. Һәм аның «матур сеңлесе» кычкырып елап җибәрде. Кунаклар исә кызарып пешкән пар алма шикелле чибәр балаларның озын гомерле булуларын, үсеп җиткәч, тигез һәм бәхетле тормыш итүләрен теләп, озак-озак дога кылдылар.

Әнә шул көннән алып Миңлебай белән Мәрьямне ике гаиләдә дә үз балалары итеп күрә башладылар. Бу вакыйгадан соң, берсе артыннан икенчесе агып, унбер ел вакыт үтте. Шул гомер буенча Хисамый белән Җәләй дә, шулай ук Мәгузә белән Мөршидә дә бер-берсенә караңгы чырай күрсәткәннәре, берсе икенчесе белән авыр һәм күңелсез сүзгә килгәннәре булмады.

Ә менә быел, шушы Сабан туе аркасында, Мәгузәнең күңеле борчылып тора. Хисамый белән Җәләйнең көрәш вакытында сүзгә килүләреннән, кешеләр алдында ызгышып, моңарчы саклап килгән дуслыкларын югалтып куюларыннан курка иде ул. Ә халык телендә хәзердән үк төрле-төрле сүзләр сөйләнә. Хисамый белән Җәләйне ничек тә сугыштырырга җыенып йөрүчеләр дә юк түгел...

Моны Хисамый үзе дә яхшы аңлый...

Мәчет эчендә тирән тынлык. Кешеләр акрын гына пышылдап намаз укый. Ләкин Хисамыйның уйлары башка нәрсәдә, аның фикере хатыны Мәгузә әйткән сүзләр тирәсендә чуала. Дөрес, Хисамый да кешеләр торган вакытта торды, башкалар белән бергә утырып, алар яткан чагында ул да ятты. Хәлләф мулла белән Габделхалик мәзиннең нәрсәләрдер укыганын, ниләрдер сөйләгәнен тыңлады. Ләкин үзе бернәрсә дә аңламады, бер хәрәкәтен дә уйлап һәм шулай кирәк булган өчен дип эшләмәде. Аның күзләре һәрвакыт Җәләй картта булды.

Җәләй карт үзен гадәттән тыш җитди, тирә-янындагы эш һәм хәрәкәтләргә бөтенләй игътибарсыз тота. Күрәсең, ул намазын бик нык бирелеп укый һәм үзен көрәштә өстен чыгаруны Аллаһыдан ялынып-ялварып үтенә. Моны күргәч, Хисамый тагын да шомлана төшә, үзенең быелгы Сабан туенда көрәшергә уйлавына үкенә башлый. Җәләй карт аңа тагын да олырак булып, Алла ярдәме белән бөтен кешене егып йөрүче бер изге җан булып аңлашыла.

Кешеләр шау-гөр килеп мәчеттән чыга башлады. Хисамый монда да Җәләйнең үзен генә аулакта туры китерә алмады. Мәчет капкасыннан урамга чыккач кына, аларга аулаклап сөйләшергә мөмкинлек туды. Әнә, Җәләй карт Хисамыйдан биш-алты адым гына алдан бара: кулында намаз таягы, башында зур ак чалма, өстендә кап-кара җилән. Аның җиләне кояш нурларында елкылдап-елкылдап күренә. Җәләй карт бу җиләнгә аерым бер хикмәтле мәгънә биреп йөри. Кешеләр арасында аны «серле җилән» дип тә, «сихерле җилән» дип тә атап йөртәләр. Җәләй карт ул җиләнне нәкъ ун елдан бирле һәм елына ике мәртәбә генә кия: беренчесе – менә бүгенге шикелле, Сабан туе көнне иртәнге намазга барганда; икенчесе – көрәш мәйданына чыккан вакытта. Хисамый, Җәләй картның әнә шул җиләненә карап, эченнән генә көлемсерәп куйды. Әмма адымын кызулатмады. «Сөйләшәсе килә икән, ул үзе адымын акрынайтсын. Ашык-пошык аны куып җитәргә мин дә бит инде бала-чага түгел, дип уйлады ул. Ә куып җиткәч нәрсә дип әйтер? Абзый, мин сине быел көрәштә егам икән, моның өчен миңа ачуланма инде, дип әйтерме? Әгәр дә ул үзе мине әйләндереп салса?..

Мәгәр Җәләй карт та үзен эре тотарга яратучан кеше иде. Ул, артыннан Хисамый килүен белә торып, аңар әйләнеп тә карамады, адымын да акрынайта төшмәде. Моңар ачуы тәмам кабарган Хисамый: алайга калса, Җәләй картта булган тәкәбберлек бездә дә табылыр, дип, уң яктагы тыкрыкка борылып китте. Аларның өйләре бер-берсенә киртәдәш һәм озын гына тар тыкрык аша иде.

Тыкрык эчендә Хисамыйны Котырык Муллагали куып җитте. Ул, сүз башлап җибәрү өчен генә әйткән шикелле итеп, башта Хисамыйга сәлам бирде һәм аның хәлен сорашты. Аннан соң:

– Шулай, Хисаметдин кордаш, бүген көрәшкә чыгасың икән. Ярый-ярый, бик хуп, бик мәслихәт эш. Җәләй картны әйтәм әле, дөньяда аннан башка кеше юк шикелле итеп, бик кәпрәеп йөргән була бит. Синең хакта көрәшкә чыга икән дип ишеткәч тә, әһә, мин әйтәм, Җәләй картның борынын җиргә бәреп янечә икән инде бу, мин әйтәм, килбәтсез борынын бик югарыга чөеп йөри иде, дим.

Хисамый, уйламаганда гына тәнен кигәвен чаккан шикелле, чыраен сытып һәм җилкәсен куырып куйды. Аңарда, кинәт кенә борылып, кулындагы юан намаз таягы белән Котырык Муллагалинең башын сугып яру теләге туды. Ләкин ул моны эшләмәде: салмак кына адымнар белән эре-эре атлап баруын дәвам итте, Котырык Муллагалигә җавап итеп бер генә авыз сүз дә әйтмәде. Әгәр дә Хисамый аңа каты-каты сүзләр әйтеп ташласа, шау-шу зурга китәчәк, хәтта бу эш Хисамыйның олы улы Миңлебайның хәле мәсьәләсенә дә барып кагылачак иде.

Ә Миңлебайның хәле бу соңгы көннәрдә нәкъ кыл өстендә тирбәлә иде.

Закон буенча, һәрбер казак үзенең улын кече яшьтән үк патша хезмәтенә әзерләргә тиеш. Әгәр дә ул моны берьюлы гына булдыра алмый икән, улы ун яшькә җиткәннән алып егерме дүрт яшенә җиткәнче елына ун сум хисабыннан казна банкына акча сала барырга бурычлы санала. Бу акчалар, хезмәт итәргә барачак яшь казак егетенә ат, ияр, камчы, хезмәткә бару өчен атап тегелгән яңа чикмән, итек һәм башкалар сатып алу өчен тотыла. Әнә шул билгеле сумманы

да үз вакытында түләп бара алмаучы була икән, аның улын берәр бай казакка эшкә бирәләр. Патшага хезмәт итү өчен кирәк булган акчаны бай үзе турыдан-туры казна банкына кертә бара.

Хисамыйның Миңлебае хәзер ундүрт яшендә. Хисамый аның өчен казнага бары тик ун сум гына акча кертә алды. Узган еллар өчен тагын утыз сум бирәсе бар. Хисамый, өен һәм каралтыларын сатып бетерсә дә, бу акчаны түләп чыга алмаячак. Шуның өстенә алдагы ун ел өчен йөз сум бирәсе кала әле.

Авылның уряднигы Миңлебайны Котырык Муллагалигә малайлыкка бирергә тели. Урядникның шундый фикердә булуын да, Котырык Муллагалинең аңа риза булып, хәтта Миңлебайны үзенә бирүләрен сорап йөрүен дә Хисамый яхшы белә. Урядник, Хисамыйны берничә мәртәбә чакыртып, аңа улының хәле турында ачыктан-ачык әйтте. Алай гына да түгел, улын Котырык Муллагалигә илтеп бирергә кушты. Ләкин Хисамый моңа һаман карышып килә. Ул, үзе җитәкләп алып барып, улын Котырык Муллагалинең кулына тоттырырга һич тә җыенмый иде...

Хисамый боларны гаять авыр борчылып искә алды. Ул, үзенең урамда икәнен дә онытып, каты гына тавыш белән:

– Менә сиңа кирәк булса! Кешеләргә Сабан туе, ә миңа җәфа өстенә җәфа, – дип көрсенеп куйды.

Шуннан соң гына ул, янында Котырык Муллагали булырга тиешлеген хәтерләп, артына әйләнеп карады. Ләкин Котырык Муллагали күренмәде.

## 2

Көрәш яланаяклы, ялангач башлы, кайберләренең әле ботлары да капланмаган кечкенә балалардан башланып китте. Аларны, шаяртып, уен-көлке сүзләр әйтеп һәм мактаган булып, нечкә генә beləкләреннән җитәкләп яки җилкәләреннән этәргәләп, берсе артыннан икенчесен мәйдан уртасына чыгара тордылар. Екканына да, егылганына да батыр исеме биреп, чыккан берсен арзанлы сабын, чигелмәгән кулъяулык, агач саплы пәке һәм конфет кебек әйберләр белән бүләкләделәр. Кешеләр беркадәр көлешеп күңел ачып алганнан соң, мәйданга һаман зурракларны чыгара бардылар. Чират Хисамыйның уртанчы улы Гатауга да килеп җитте. Бу сигез яшьлек бала, үзен бик олысыман тотып һәм матур гына елмаеп, бер халыкка, бер исә үзе белән көрәшкә чыккан ачык изүле юан гына малайга карап торды да кулындагы сөлгене тиз-тиз генә беләгенә чорный башлады. Кешеләр аңар кызыксынып карап торалар иде. Кемдер:

– Йә әле, энекәш! – диде дә Гатауның аркасына төртеп куйды.

Гатау тиз генә иелде дә каршысында басып торган баланың биленнән эләктереп алды. Алар, бер-берсен нык кочаклап, мәйдан уртасында эткәләшеп йөри башладылар. Озакламый Гатау тегене күтәреп тә ташлады. Гатау тын алырга да өлгермәде, каршысында икенче малай әзер тора иде инде...

Гатау үз тиңнәреннән һәм үзеннән олырак булганнардан да әле барысы биш малайны екты. Алтынчы булып Котырык Муллагалинең Гарифҗаны Гатауның каршысына килеп басты. Бу хәл кешеләр арасында зур ризасызлык һәм көчле шау-шу тудырды. Алар, төрлесе төрле яктан торып, кулларын селтәнгәләп кычкыра башладылар:

– Аз гына оят кирәк, күсәктәй балагызны бер сабыйга каршы чыгармакчы буласыз!

– Баланың өметен кисәсез бит!

– Чыкмасын!

Икенче бер төркем боларга каршы кабынып китте:

– Чыксын, көрәшсеннәр!

– Батыр егет көрәшүчене сайлап алмый ул.

– Ха-ха-ха, каршы төшмәгез!

Мыскыл итеп көлүчеләрнең шау-шуны зурайта барулары Котырык Муллагалинең күңелен күтәреп җибәрде. Ул, мыек чолгыйларын бөтергәләп һәм гаять зур кара эчлелек белән көлемсерәп, кешеләрнең ачуларын китереп торды. Котырык Муллагали янында авылның кибетче бае Тәбәнәк Хәмчки тора иде. Ул, зур корсагын киереп баскан килеш, үзеннән башкаларның барысын да җиңәргә, һәммәсенең дә тавышын юкка чыгарырга тырышып:

– Җәмәга-ать, – дип кычкырды, – тыныч булыгыз! Әйдә, көрәшә бирсеннәр! Көннең-көн буенча шул көзге әтәчләрне сугыштырып утырырбызмыни? Зурракларга күчәргә вакыт!

Хисамый, башта тыныч кына утырса да, Котырык Муллагали белән Тәбәнәк Хәмчкинең канатлануларына түзә алмады: ашыкмыйча гына урыныннан кузгалды, йодрыкларын нык кысып йомарлады да салмак кына адым белән мәйдан уртасына чыга башлады. Моны күреп, бөтен мәйдан халкы кинәт кенә тынып калды. Бу тынлык эчендә кайберәүләрнең ара-тирә пышылдашулары һәм түзә алмыйча пырхылдап көлеп җибәрүләре генә ишетелгәләде.

– Бу, туганкай, бер бирсә дә берәгәйле итеп, зеңкелдәтеп бирер.

– Тәбәнәк Хәмчкине бер сугуда сытып ташлар.

– Суга алмас, дисеңме? Әле син Хисамыйның холкын белмисең икән: дисбителни дә әписәрне сугып еккан кеше бит ул...

Сабан туен карау өчен чит авыллардан килүчеләр дә күп иде. Алар арасыннан берсе:

– Яңа Чиркаска килсәң, шул булыр инде, сугышмыйча калмаслар, – дип, ризасызлык белдереп куйды.

Миңлебай энесе Барыйны уйнатып утыра иде. Ул кинәт кенә сикереп торды да әтисе янына йөгереп килде.

– Әти, көрәшә бирсеннәр. Гатауны екса, Гарифҗанны мин аны үзем атып бәрәм, – диде.

Хисамый азрак тынычлана төште. Аскы иренен тешләре арасына кысып һәм кулын нык кына селтәп, яңадан үз урынына – хатыны Мәгузә янына барып утырды.

Гатау белән Гарифҗан бер-берсенең биленнән сөлге белән эләктереп алдылар. Гатау, үз хәлен үзе сизеп булырга кирәк, Гарифҗанны күтәреп алырга уйламады да. Ул аңа нык кына асылынып, үзен күтәреп алырга ирек бирмичә йөри башлады. Гатауның бу кадәр тырышлыгы, һич тә көтелмәгән хәл буларак, бая гына аны яклап чыгучыларга дәрт кертеп җибәрде. Алар:

– Ныкябыш, Гатау!

– Шулай, энекәш, махы бирергә тырышма! – диешкәләп тордылар.

Байтак кына вакытлар эткәләшеп йөргәннән соң, аякларына ак әрем чорналып, Гатау егылып китте, һәм шул уңайга Гарифҗан аның өстенә авып төште. Ләкин, Гатауның күкрәгенә таянган сул кулы таеп китте дә, Гарифҗан йөзе белән җиргә капланды. Кешеләр шау-гөр килеп көлешә башлады. Юри шаяртып, каршы якны котырту өчен генә:

– Булмады бу, алай аяк чалып екмыйлар аны, – дигән булды берсе. Башкалары аны куәтләп куйды:

– Әйе, аяк чалып екты, эт егышы булды бу.

– Яңадан көрәштерергә кирәк, егетләр, яңадан! Гатау ега аны барыбер.

Котырык Муллагали һәм аның тирәсендәгеләр тынып калды. Гатау белән Гарифҗан, бер-берсенең каршысына басып, нәрсә эшләргә дә белмичә аптырап торалар иде. Хисамый Гатауны үз янына чакырып алды. Йомшак кына итеп аркасыннан сөйде дә, Гатауның кулындагы сөлгене алып, олы улы Миңлебайга тоттырды.

Миңлебай куян шикелле җиңел генә сикереп торды да як-ягына карангалап аптыраган Гарифҗанның каршысына ук барып басты. Бу хәл Котырык Муллагалигә ошамады. Ул, тынычсызлык белән кашларын җыергалап, иләмсез озын мыекларын селкеткәләп куйды. Тәбәнәк Хәмчки дә, нәрсәдер әйтергә теләп, торган урынында тыпырчынгалап алды. Ләкин Миңлебайның Гарифҗанга каршы көрәшкә чыгуына алар һич тә тоткарлык итә алмый иде. Күп еллар буенча сакланып килгән гадәт шулай: энесе егылган икән, аның урынына агасы чыгарга тиеш. Бу урында Миңлебай, бертуган энесе егылганнан соң, үз нәселенең дәрәҗәсен саклау өчен дип мәйданга чыкты. Шуның өстенә Миңлебай белән Гарифҗанның яшьләре дә бертигез. Алар икесе дә бер елны, урак өстендә туган. Аерма фәкать шунда гына: Гарифҗанның анасы йөкле килеш авыр эшләр эшләп йөрмәгән, баласын үзенең өендә, һәрьяктан да яхшы тәрбияләр күреп тапкан. Мәгузә исә, Котырык Муллагалигә урак урган вакытта, көлтәләр бәйләп йөргәндә авырып, шунда ук, бодай көлтәләре төбендә, улы Миңлебайны дөньяга китергән. Ире Хисамый аңа «кендек әбисе» булган.

Миңлебай белән Гарифҗан арасында көрәш башланды. Миңлебайның тыны шактый иркен иде. Озак та үтмәде, Гарифҗанның күкрәк челтәре аның күкрәгенә менеп утырды, аяклары югары күтәрелде, арт саны аның уң аягы өстенә салынды. Миңлебай үзенең бөтен гәүдәсе белән селкенеп алды, уң аягын кинәт кенә күтәреп, сул кулын сөлгедән ычкындырып җибәрде. Гарифҗан очып киткәндәй булды, әйләнгәләп-әйләнгәләп барып, йөзе белән җиргә капланды.

Миңлебай, масаюлы гына бер кыяфәт белән елмаеп, мәйдан уртасында басып калды. Мәйдан читендә атасы Хисамый белән көрәшче Җәләй сөйләшеп торалар. Аларның йөзендә шатлыклы елмаю сизелә, күзләре белән Миңлебайны иркәләүләре, аның тулы тәнле таза гәүдәсенә канәгатьләнеп караулары аңлашыла.

Мәрьямнең кечкенә йөрәге Миңлебай белән үзе арасында нindidер бер якынлык барлыгын сизенеп тибә. Нәрсә өчен шулай икәнен ул үзе дә аңлап җиткермәстән, Миңлебайның үзен, аның һәрбер хәрәкәтен ярата, аның һәрбер кыланышына сокланып карый, аның ата-анасын һәм туганнарын үзе өчен якын кешеләр итеп, нәкъ үз туганнары шикелле итеп хис кыла. Миңлебайның менә бу көрәш мәйданында туган шатлыгы кечкенә Мәрьямнең дә шатлыгына әверелде. Ул, ата-аналарының гына түгел, хәтта барлык кешеләрнең дә Миңлебайны мактауларын, аның турында һаман яхшы сүз генә сөйләп торуларын тели. Миңлебай да, аерым нык дикъкать биреп, Мәрьямгә карый, аның шатлыктан нишләргә дә белмәвен күреп сөенә иде. Менә аларның күз карашлары бер-берсе белән очрашты...

Шулвакыт Сабан туен алып бару өчен куелган кешеләрдән берсе Миңлебайның иңбашына баш-башы кызыл белән чигелгән зур сөлге салды. Миңлебай, зурларча эре генә кыяфәт белән кулын изәп, энесе Гатауны үз янына чакырып алды һәм, батырлыгы өчен бирелгән бүләк сөлгене аңа тоттырып:

– Мә, әнигә алып барып бир! – диде.

...Ниһаять, халыкның көткәне – Хисамый белән Җәләйгә дә чират килеп җитте. Мәйдан уртасына Җәләй чыгып, рәттән алты кешене екты. Шуннан соң аны ял итәргә утырттылар да, кулына сөлге тоттырып, көрәш мәйданына Хисамыйны алып чыктылар. Ул, үзе көрәш өчен әзерләнеп килгән булса да, ни өчендер башта каршылык күрсәткәндәй итеп торды. Мәйдан алып баручылардан ике кеше аны ике ягыннан култыклап, төрлечә уен-көлке сүзләр сөйләп, ирексезләп чыгарган шикелле иттеләр... Хисамый да, Җәләй кебек үк, алты кешене һичбер кыенлыксыз гына ыргыткалады...

Батырларны шул рәвешчә ял иттерә-иттерә көрәштерү берничә мәртәбә кабатланды...

Оренбург кадәрле Оренбургның үзеннән килгән Җаппар батыр белән көрәшәсе булгач, Хисамыйның кашлары җыерылып, сакал һәм мыеклары селкенгәләп куйды. Җаппар батыр үткән ел Җәләйне дә ега язган иде. Җәләй, әнә шул үткән елгы хәлләрне исендә тотып булса кирәк, быел Җаппар белән очрашмаска тырышты һәм аны Хисамыйга калдырды. Тәҗрибәле мәйданчылар моны ачыктан-ачык сизенеп торалар иде. Кешеләр арасында тирән тынлык урнашты. Шул тынлыкны бозып:

– Хисамыйны ял иттереп алырга кирәк.

– Әйе, Хисамыйга авыргарак туры килә, – дигән тавышлар ишетелде.

Ләкин мәйдан алып баручылар моңа артык игътибар итмәде. Бу Яңа Чиркас кешеләренең Хисамыйны яклап һәм аңа дәрт бирү өчен генә әйткән сүзләре иде. Шулай ук Хисамый үзе дә ял итеп алуны кирәксенмәде. Ә инде Җаппар белән көрәшә башлагач, Хисамый үзенең аңардан көчлерәк булуын бик тиз сизеп алды...

Җаппар батыр да егылгач, мәйдан хуҗалары булып Җәләй белән Хисамый торып калды... Арттан караганда, аларның кайсысы Хисамый, кайсысы Җәләй икәнен дә аеру кыен. Икесе дә бертигез урта буйлы, юан гәүдәле, киң җилкәле булып, икесенең дә өстендә кара җилән иде. Аерма фәкать шунда гына: Хисамыйның җиләне, яшь вакытында ук тегелгәнлектән, аз гына кыскарак та, Җәләйнекенә караганда искерәк тә – шомарып, терсәк турылары тишелгәләп беткән. Җәләйнең җиләне яңарак булганлыктан, кояш яктысында елкылдап, җентекләп караучы күзләргә беленер-беленмәс кенә яшькелт төс чагылгалап үтә.

Әмма алдан караган вакытта бу ике батырның бер-берсеннән аермасы бик зур. Беренче караштa ук Җәләйнең олылыгы, Хисамыйның яшьрәк кеше булуы күзгә бәрелә. Дөрес, икесенең дә күзләре соргылт, сакаллары куе һәм түгәрәк булып үскән. Ләкин Хисамыйның сакалы кара һәм кыскарак булып, күзләре үткенрәк карый, маңгаенда һәм колак яфракларында тап-тап чуарлар бар. Үзеннән-үзе өйрәнелгән гадәт буенча булырга кирәк, Хисамыйның, тик кенә торганда да, ияк асты кузгалгалап, сакалы селкенгәләп куя. Җәләйнең исә куе һәм озын сакалы күкрәк челтәрен тулысы белән каплап алган. Шул ук вакытта аның сакалы соргылт, күзләре юаш һәм сабыр карый.

Менә шул ике кеше, сөлге белән бер-берсенең биленнән кысып тоттылар да, сөзешкән вакытта сак һәм акыллы кыланучан карт үгезләр шикелле, мәйданның бер читеннән икенче читенә этәрешеп йөри башладылар. Хисамый үзен-үзе аерата сак тотарга, һәрбер адымына кадәр уйлап атларга тырышты. Моңарчы Җәләй белән көрәшеп караганы булмаса да, Хисамый аның кайбер гадәтләрен белә иде инде. Көче һәм сәләте белән хисаплашырга туры килгәнрәк кеше

булганда, Җәләй аны һич тә башлап үзе күтәрми. Ул, зур хәйләкәрлек белән, элек тегенең күтәрүен көтеп йөри. Әлбәттә, яңа кеше гадәттән тыш озак түзә алмый. Чыдамы бетеп, тиздән ул Җәләйне күтәрә башлый. Ләкин ул моны булдыра алмый. Моңар Җәләйнең авыр булуы да, хәйләкәрлеге дә, аркасында шуып йөри торган кара җиләне дә уңайсызлый. Кеше аны биленнән тотып күтәрә башласа, кулы шуып, ул аны муеныннан кочаклап кала. Шулвакыт теге кешенең гәүдәсе турылана төшә һәм ул: «Мә, мине күтәреп ал да олактыр инде!» – дигән шикелле, үзе дә сизмәстән, Җәләйнең кочагына барып керә. Нәкъ шулвакыт Җәләй аны бик нык итеп кыса һәм күтәреп ала да сырты белән капландырып җиргә сала.

Хисамый әнә шуларны исәпкә алды һәм үзе башлап Җәләйне күтәреп карарга һич тә җыенмады. Ләкин Җәләй дә, аны күтәреп карап, үзенең чамасын белергә ашыкмады. Шулай итеп, шактый гына минутлар буенча егучы да, егылучы да булмады. Батырларның икесе дә тәмам арып, тирләп беткәннән соң, аларга биш-алты минут чамасы утырып ял итәргә ирек бирелде.

Ял итеп алгач, икесе дә, җиләннәрен салып, күлмәк җиңнәрен терсәк өстенә кадәр сызганып, янә көрәшкә керештеләр. Икесе дә ярсып һәм кызурак хәрәкәт итә башлады. Йөри торгач, Хисамый Җәләйне шулкадәр нык көч белән кызу этәреп алып китте ки, алар мәйдан кырыенда утыручыларның өстенә менә яздылар. Кешеләр тиз-тиз торып, көчкә-көчкә генә артка чигенеп өлгерделәр. Үзенә бер күңелле шау-шу күтәрелеп алды. Әнә шул арада, бөтен гәүдәсе белән селкенеп куйды да, Хисамый, Җәләйне күтәрергә чамалап карады, һәм ул карт көрәшченең тагын бер хәйләсен ачты. Күтәрә башлауга, бөтен авырлыгын салып, Җәләй кешенең уң беләгенә ята һәм күтәреп алырга ирек бирми икән.

Шулай да Хисамыйның моңа ачуы килмәде. Киресенчә, Җәләйнең һаман хәйләгә сабышып кына йөрүен белгәннән соң, Хисамыйга дәрт һәм көч өстәлгәндәй булды. Аның үз-үзенә ышанычы артты. Ул, димәк, Җәләйне егарга телисең икән, аны кинәт кенә күтәреп алырга һәм шул ук уңайга бөтен эшне дә бетереп куярга кирәк, дигән фикергә килде. Менә хәзер, кешеләрне чыр-чу китереп, мәйдан читенә барып чыкканнан соң, Хисамый Җәләйгә үзен этәреп барырга ирек куйды һәм мәйдан уртасына кадәр кире чигенде. Шуннан соң, тагын бик нык этәреп алып китәргә җыенгандай итте дә, тик үзе моны эшләмәде, ул Җәләйне кинәт кенә күтәреп алды һәм, аның чуен шикелле авыр гәүдәсен үзенең югары чөелгән уң аягы өстенә утыртып, тиз генә сулга борылды да җиргә салды.

Халык, бөтен мәйданны көчле яшен бәреп үткән шикелле, тын булып калды.

Атасының көрәш мәйданында егылуын беренче мәртәбә күргән Мәрьямне ниндидер курку һәм рәнҗү тойгылары чорнап алды. Аның кечкенә йөрәге ашкынып һәм өсте-өстенә «лепелдәп» тибә башлады. Нәрсә булыр? Әгәр дә аның атасы белән Миңлебайның атасы арасында талаш-кычкырыш чыкса?..

Бераздан халык айнып киткәндәй итте. Кешеләр арасыннан:

– Ялгышрак булмадымы икән соң бу?

– Яңадан көрәштереп карарга кирәк иде.

– Чынлап та, картның күңелендә калырлык булмасын, – дигән сүзләр ишетелә башлады.

Җәләй егылган урыныннан акрын гына кузгалып торды да ничәмә еллар буенча тарап-сыйпап кына үстерелгән сакалындагы чүп-чарларны һәм өстендәге тузан-туфракларны какты. Янына ук килеп баскан кызы Мәрьям белән хатыны Мөршидәгә карады. Аларның куркудан йөзләре агарган һәм

тәннәре калтырана иде. Җәләй, мәйдан әйләнәсендәге барлык кешеләр өстеннән күз йөртеп чыкты да, уң кулын салмак кына югары күтәреп:

– Кардәшләр, барыгыз да тыныч булыгыз! Хисамый күрше мине дөрес екты, бик һәйбәт итеп екты, – диде.

Ул, әнә шул сүзләрне әйткәннән соң, үзенең сул ягындарак басып торган Хисамыйга кулын сузды; чын дуслык һәм татулык билгесен белдереп, аны кочаклап ук алды. Баш-башлары бик киң итеп чигелгән зур мәйдан сөлгесен Хисамыйның иңбашына салды да:

– Бүгеннән соң Җаек һәм Сакмар буйларының батыр көрәшчесе булып син калырсың, энем. Көчеңнең һәм сәләтеңнең игелеген күр! – диде.

## 3

Җәләй егылганнан соң, Сабан туеның көрәш өлеше бетте. Аякка капчык киеп йөгерү, катык тутырылган зур табакка башны тыгып, табак төбендәге көмеш акчаны авыз белән алу шикелле кызыклы уеннар башланды. Бу уеннарның нәкъ кызган вакытында гына мәйдан әйләнәсендә уйнап йөргән бала-чага:

– Атлар килә, атлар килә! – дип шаулаша башлады.

Авылдан ике-өч чакрым ераклыкта гына җәелеп яткан бер тау булып, бу якта аны Карбыз тавы дип атыйлар. Карбыз-кавын бакчалары ел саен шул тау өстендә булганга күрә, аңа шундый исем кушылып калган. Чабышкы атларның килүләре турындагы хәбәрне ишеткәч тә, кешеләр арасында буталыш һәм шау-шу туды; берсен-берсе этколәшеп, алар барысы да әнә шул Карбыз тавы ягына таба агыла башладылар. Атлар чыннан да килә иде. Бу әле беренче әйләнү генә. Сабан белән сөреп чыгылган зур әйләнмә буенча атларның тагын ике мәртәбә ярышып киләселәре бар...

Атлар көрәш мәйданына тәмам якынлашты. Кешеләр хәзер кемнең аты алдан, кемнеке арттан килүен дә аера башлады. Иң алдан нечкә-озын торыклы ябык кына күк ат, Оренбург аты килә иде. Икенче урында – Герьял чабышкысы, өченче – Котырык Муллагалинең аты, дүртенче булып Җәләйнеке. Котырык Муллагалинең атына – улы Гарифҗан, Җәләйнекенә Миңлебай атланган.

Халык алдыннан атлар әнә шулай үтеп китте. Җәләй картның чиксез дә борчылуын күреп, аның өчен Хисамый кычкырып калды:

– Улым, ныграк куа төш!

Миңлебай, аяклары белән тибенгәләп, камчысын селтәп җибәрде.

Атлар икенче тапкыр әйләнеп килгән вакытта Герьял чабышкысы, алтынчы урынга ук калып, икенчелекне алу өчен, Котырык Муллагалинең туры кашкасы белән Җәләйнең җирәне тарткалашып килә иде. Менә атлар көрәш мәйданы турысына килеп тә җитте. Кешеләр, үзләре тапталу куркынычыннан сакланып һәм атларга юл ачып, берсен-берсе этәргәли-төрткәли чигенә башлады. Шулчак һичбер вакытта да булмаган һәм аны шулай булыр дип һичкем дә уена китерә алмаган бер хәл, гадәттән тыш вакыйга булып алды: Гарифҗан, уң кулындагы җиз башлы юан камчысын югары күтәреп селтәде дә алга чыгу өчен тарткалашып килгән Җәләй атының башына нык кына итеп сукты.

Халык арасында көчле шау-шу һәм куркудан буталулар туды. Хатын-кыз һәм бала-чаганың чырыйлап кычкыруы, кемнәрнеңдер ачулы тавыш һәм оятсыз сүзләр белән сүгенүе, йодрыкларын һавада селтәп җикеренүләре ишетелде. Кешеләр атлар чаба торган әйләнмә тирәсеннән тагын да ераккарак кача һәм көрәш мәйданы уртасына җыелып өелә башлады. Моның белән алар тагын да

начаррак эшлиләр, тапталудан котылабыз дип уйлап, ат юлына үзләре барып керәләр иде. Менә хәзер, берничә секунд эчендә, башына камчы белән сугудан нык ярсыган ат халык төркеменең нәкъ уртасына кереп китәчәк тә кешеләрне таптап-изеп ташлаячак иде. Ләкин ат өстендә оста утыра белүе белән электән үк танылган Миңлебай бу урында да үзенең үткенлеген һәм булдыклы егет икәнен күрсәтте. Ул, гаять зур җитезлек белән, атының уң як тезгенен тартып өлгерде. Ул атны аямыйча бик каты итеп тартты. Ачулы ярсу белән бөтен гәүдәсе калтыранып торган, тагын да сузыла һәм нечкәрә төшкән җирән ат, кисәктән генә уңга борылып, халык төркемен еработан ук әйләнеп чаба башлады. Юк, аңа халык төркемен генә түгел, башка авыллардан килгән кунакларның арбаларын да, аларның тышаулап җибәрелгән төркем-төркем атларын да әйләнеп узарга туры килде. Шул арада Миңлебай кешеләргә дә күз төшереп алды. Көрәш мәйданында шау-шу куптарып буталучылар, томан эчендә селкенгәләгән шәүләләр шикелле, Миңлебайга тоташ бер кара күләгә булып күренделәр. Шулар эченнән Җәләйнең куллары белән һавада нәрсәдер капшавы, Миңлебайга нәрсәләрдер кычкырган шикелле итеп авызын ачуы, кечкенә Мәрьямнең исә куркудан агарынып катканы хәлдә атасы янында тыпырчынгалап торуы – болар Миңлебайның күзләренә аермачык чалынып үттеләр. Ләкин атасы Хисамый белән Җәләйнең:

– Атны харап итәсең!

– Миңлебай!

– Тукта-а! – дип кычкыруларын ул ишетмәде. Ул һаман «һай-һу»лап кычкыра, сул кулындагы тезгенне тарткалап, уң кулындагы камчысын һавада өзлексез селеккәли иде.

Миңлебай яңадан атлар чаба торган әйләнмәгә барып төшкәндә, аның аты тугызынчы урынга калган иде инде. Үзеннән алда баручы сигез атны күреп, Миңлебайның күзләреннән яшь бөртекләре тәгәрәп төште. Аның ярсу йөрәген әрнү, миен үч алу, Гарифҗаннан ничек тә булса өстен чыгу теләге чорнап алды. Аның, үзе атланган ат белән бербөтен булып, киң канат җәеп очасы һәм бик нык очасы килә иде.

Озак та үтмәде, Миңлебай дүртенче, аннан соң өченче урынга чыкты. Әйләнмәнең уртасына җиткән вакытта, икенче урынны алу өчен, ул тагын Гарифҗан белән тарткалаша башлады. Бу юлы инде Миңлебай үзе дә хәйләгә кереште. Күп еллар буенча сакланып килгән Сабан туе тәртибен бозу булса да, ул, атының сул як тезгенен тартып, әйләнмәнең эчке ягыннан, Гарифҗанның камчысыз сул кулы астыннан юл алды. Шуның аркасында тегесе Миңлебайның узып китүен сизми дә калды.

Беренче урынны һаман да шул шәһәрдән килгән ябык күк биләп бара иде. Миңлебай аның белән ярты әйләнмә чамасы тарткалашып барды. Шәһәр аты әйләнмәнең эчке ягында булып, уза торган ат өчен юл ераклаша төшә, һәм ул ара-тирә артка да калгалап куя иде. Миңлебай, тагын да алгарак иелеп, бөтен гәүдәсе белән атының муены өстенә сузыла, атын тагын да ныграк куа башлый һәм шәһәр малаен яңадан куып җитә...

Кешеләр, нәкъ ике төркемгә бүленеп, бер төркеме атларның әйләнмә буенча китә торган юлын каплап, авыл ягына таба юл ачты. Атлар, соңгы кабат әйләнеп, бу яңа юлга килеп кергәндә, Миңлебай атланган ат иң алдан килә иде.

Җәләй берникадәр вакыт кешеләрнең әйткәннәренә һәм үзенең күзләренә үзе ышана алмыйча торды. Ә инде, чыннан да, аның аты беренче булып килүенә тәмам ышангач, куанычыннан нәрсә эшләргә һәм кая барырга да белмичә сикергәләп, балалар шатлыгы белән шатланып йөри башлады. Йөгереп барып,

атының муенына асылынмакчы, атын да, Миңлебайны да кочаклап алып сөймәкче һәм иркәләмәкче булды. Ләкин атның нинди хәлдә булуын, хәзер аны ярты гына минутка да туктатып торырга ярамаганлыгын Миңлебай яхшы белә иде. Ул, Җәләйнең нинди теләк белән үзенә таба ашкынып килүен, юлын буып торган кешеләрне ян-якка этkәләүләренең мәгънәсен тиз генә аңлап алып, халык төркемен узгач та, сулга борылып китте. Җәләй исә: «Һай үткен, һай акыллы да бала соң бу Миңлебай! Кара син аны, күрсә дә, күрмәмешкә сабышып үтеп китте бит, каһәр!» – дип уйланып калды. Аның йөрәгендә Миңлебайга карата якынлык хисе шулкадәр көчле, шулкадәр көчле иде ки, моны берничек тә сөйләп һәм язып аңлатырга мөмкин булмас иде.

Миңлебай, башта атын җилдереп, соңгарак юырттырып, һәм юргалатып, татар зираты ягына таба юл алды. Ул, атын җилгә каршы тотуы белән мавыгып бара торгач, Карбыз тавына кадәр сизми дә калган. Кирегә борылып, яңадан Сабан туе мәйданына таба китте.

Аның мәйданга якынлашуын бөтен кеше көтеп тора иде. Ләкин Җәләй, атына күз-фәлән тиюдән куркып, аны кешеләргә якын ук китереп җиткермәскә тырышты. Ул аты өчен бирелгән бүләкләрне кочаклап алды да, йөгерә-атлый, Миңлебайның каршысына бара башлады. Мәрьям дә атасы артыннан иярмәкче иде, анасы аны үз яныннан җибәрмәде.

Миңлебай, тезгенен дә тартмыйча, муеныннан сөеп кенә атын туктатты. Җәләй исә, егеткә күп-күп рәхмәтләр әйтеп сөйләнә-сөйләнә, атның муен астындагы тир күбекләрен сыпыргалады, әле һаман да дерелдәп-калтыранып торган арт санын сөйде. Миңлебай, картның кулындагы әйберләргә карап:

– Бәйгегә яхшы нәрсәләр биргәннәр икән, – дип куйды.

Җәләй, берөзлексез атын сөя-сөя:

– Әйе, бәйге бик яхшы булды: бер сарык, җиде аршынлы ефәк күлмәклек, сөлге, – диде.

Кулындагы ефәкнең бер очын – атның муенына, икенче яртысын Миңлебайның муены һәм гәүдәсе тирәли чорнады; ике башы да кызыл белән чигелгән зур сөлгене егетнең уң як иңбашына салды да, сул култык астыннан алып, баш-башларын бәйләп куйды.

– Болары сиңа миннән бүләк, – диде.

Ул, нәрсәдәндер уңайсызланган шикелле булып, сөйләүдән тукталып калды. Миңлебай, аның йөзенә һәм күзләренә карап, картның тагын нәрсәдер әйтергә теләвен, ләкин моңар кыюлыгы җитеп бетмәвен аңлады. Карт, атының алгы тоягындагы кечкенә генә балчык кисәген аягы белән төртеп төшерде дә:

– Ефәге аның хатын-кыз күлмәгенә яхшы инде. Син әле егет буласы кеше, кирәге чыгар, – дип өстәде.

Миңлебайның кабарынкы йөзенә куе кызыллык йөгерде. Ул, үзенә бирелгән бүләкләр өчен картка рәхмәт әйтерлек тә хәлдә түгел иде. Җәләй карт:

– Бар, улым, бар! Атны тәмам суынганчы йөртеп кайт. Авылның һәрбер урамыннан йөреп, бәйгене кешеләргә күрсәтеп чык, – диде дә егетнең аркасыннан сөеп куйды.

Миңлебай, аякларын тиз-тиз тибенеп, атын кузгатып алып китте. Ул башта болын ягына таба юл тотты. Берникадәр барганнан соң, олы юл буендагы казна ындырлары яныннан узып, авылдан өч-дүрт чакрым ераклыктагы Якты Күл башына барып чыкты.

Кызгылт кояш ерактан ук ялтырап күренгән Якты Күлнең аргы башына таба тәгәрәп, көн кичкә авышып бара иде инде. Күл өстеннән килгән салкынча дымсу

җил, күл буендагы камышларның, тал яфракларының акрын гына селкенгәләп, үзара пышан-пышан сөйләшкән сыман тавыш чыгарып утырулары – болар Миңлебайның бик яшь һәм кечкенә йөрәген җилкендереп җибәрделәр. Көрәш мәйданында Гарифҗанны ансат кына алып ыргытуы, ат чаптыру вакытында аны икенче мәртәбә көлкегә калдыруы, шул хәлләрнең барысын да Мәрьямнең карап, үз күзләре белән күреп һәм шатланып торуы – болар һәммәсе дә Миңлебайның күз алдына кабат-кабат килеп басты. Җәләй картның ягымлы сүзләре тагын ишетелгәндәй булды: «Ефәге аның хатын-кыз күлмәгенә яхшы инде... кайчан да булса кирәге чыгар». Җәләй аңа, нәкъ үзенең атасы шикелле, олы да, акыллы да, шулар өстенә, ни өчендер, кешенең йөрәгендә нәрсә барын белә торган бер серле кеше дә булып аңлашылды. Аның күз алдына тагын Мәрьям, әле бик кечкенә, ләкин искиткеч матур һәм акыллы Мәрьям килеп басты. Бу тау кадәр шатлыкның барысы да аның эченә сыеп торырлык түгел иде. Ул үзенең күңелен тагын да күтәрергә, эчендәге әллә нәрсәләрне бушатып ташларга, бугазындагы нindидер буып торган әйберне алып ыргытырга, аны патша хезмәтенә әзерләү мәсьәләсе буенча ата-анасының көн-төн кайгырып кан-яшь түгүләрен онытырга, әйе, берничә минутка гына булса да онытып торырга теләде. Һәм ул, аларның мәгънәсен үзе чын-чыннан аңлапмы, әллә егетләрнең урамда җырлауларыннан ишетү буенча гынамы, түбәндәге юлларны җырлап җибәрде: «Атымның дагасы алтын, сынмаса алдырмамын. Үлмәсәм, гүргә кермәсәм, ятларга калдырмамын».

**4**

Миңлебайның кайтышына Җәләй карт капкасын ачып ук куйган, үзе өйдә тәрәзәдән карап утыра иде. Егет ишегалдына килеп керешкә, Җәләй үзе дә, хатыны Мөршидә һәм кызы Мәрьям дә йөгерешеп каршы чыктылар. Миңлебай, җирән чабышкыны ишегалды уртасында туктатты да аның муенына чорнап бәйләнгән ефәкне чишә башлады. Җәләй карт турыдан-туры атының тезгененә барыпябышты, аның маңгаен һәм колак артларын сыйпаштыргалап торды. Мөршидә дә чабышкыны яратып һәм иркәләп сөйде. Аның арт санын учы белән кага-кага:

– Һай, малкаем, зур эшләр эшләдең син бүген. Кешеләр арасында йөзебезне ак иттең, – диде.

Миңлебай, ат өстеннән төшүгә, Җәләй карт чабышкыны лапаска таба җитәкләп алып китте. Миңлебай ефәк белән сөлгене яхшылап төрә башлады. Мөршидә кеткелдәп кенә көлә-көлә егет янына килде, симез генә йомшак кулы белән аның аркасыннан кага-кага сөеп:

– Сиңа да бик зур рәхмәт, балакаем, уңган егет икәнсең! Син булмасаң, без бу куанычларны күрмәгән дә булыр идек. Җаның-тәнең сау, кул-аягың сызлаусыз булсын, – диде.

Лапас эченнән Җәләй картның тавышы ишетелде:

– Карчык, синең анда барысы да әзерме?

– Әзер, әтисе, әзер! – диде Мөршидә. Үзе, тагын егетнең аркасыннан сөеп:

– Җәләй абзыең белән чәй эчәргә керерсең, улым. Мин тиз генә самавырның утын яңартып җибәрим әле, – диде дә, симез үрдәк шикелле әвеш-тәвеш атлап, акрын гына өйгә кереп китте.

Миңлебай Мөршидәгә сүз дә әйтә алмыйча калды. Шул арада Җәләй карт та лапастан чыкты. Ул, ипләп кенә егетнең беләгеннән тотып:

– Әйдә, энем, өйгә керик, – диде.

– Юк, Җәләй абзый, рәхмәт, мин үзебезгә кайтыйм инде, – дип, егет читкәрәк тайпылды.

– Кайтырсың әле, менә чәй эчеп алыйк башта. Син бүген иртәдән бирле ашамагансыңдыр бит?

– Өйдә ашармын әле, Җәләй абзый, тизрәк үзебезгә кайтасым килә.

Җәләй карт, тәрәзәдән карап утырган чагында, урядник белән Котырык Муллагалинең Хисамый өенә таба китүләрен күреп калган иде. Шул вакытта ук картның башына нindидер хәвефле уйлар килде. Шунлыктан, өйләрендә андый-мондый хәл булса, тизрәк кайтуы яхшырак булыр дип уйлап, хәзер ул Миңлебайны артык кыстамады. Янында басып торган Мәрьямнең чәч толымыннан сыйпады:

– Бар әле, кызым, әниеңә әйт, Миңлебай абзый чәй эчәргә керми, диген. Әти, диген, күчтәнәчкә бирәр нәрсәсе юк микән, дип әйтте, диген.

Мәрьям, «куштан итәкле» ак күлмәген бөтерелдереп әйләнде дә очарга җыенган кош шикелле сикергәләп һәм кулларын һавада җилпендерә-җилпендерә өйгә кереп китте. Күп тә үтми әйләнеп тә чыкты. Аның кулында җиде-сигез коймак һәм күлмәк кесәсендә берничә кәнфит иде...

Энесе Гатау белән күрше малае Габдрахман Миңлебайны каршы алырга килгәннәр һәм Җәләйнең капка төбендә көтеп утыралар иде. Урамга чыккач та, Миңлебай аларның урталарына кереп алды. Кулындагы кәләпүшеннән алып, аларга берәр коймак белән берәр кәнфит тоттырды.

Караңгы төшеп җитмәгән иде әле. Ләкин алар барган тар гына озын тыкрык эчендә бер кеше дә юк, шуның өстенә бу тыкрык ягына берәүнең дә өй тәрәзәсе карамый иде. Шунлыктан, караңгы төшкәннән соң, урамга чыгучы егетләр гадәтенә туры китереп, Миңлебай җырлап җибәрде:

Өй артында кәкре тал,
Кәкре талда кәккүк бар.
Безнең сөйгән җаныйларның
Кесәсендә кәнфит бар.

Тыкрык чатыннан борылып, үзләренең капкалары турысына җитүгә, Миңлебайның җыры бүленеп калды.

Ишегалдында Котырык Муллагали белән урядник басып тора иде. Әнисе өй баскычы янында. Ул вакыт-вакыт яулык почмагы белән күз яшьләрен сөртеп ала. Әтисе, ялынулы һәм кызганыч тавыш белән урядникка нәрсәләрдер сөйли, аңардан ниләрдер үтенә. Күпереп торган кып-кызыл йөзле урядник Хисамыйның сүзләрен ишетергә дә теләми: итек шпорларын челтерәтеп, сул кулы белән билендәге кылычының ап-ак көмеш сабына таянып, ишегалды буенча йөргәләштерә, уң кулы белән бертуктаусыз мыек чолгыйларын бөтерә, сирәк-сирәк кенә тамак кыргалап куя.

Миңлебай капканы кинәт кенә ачып җибәрде дә, йөгереп барып, анасына сыенды.

Коргаксыган буш мичкә эченә кычкырган вакыттагы шикелле, урядникның саңгырау һәм калын гына тонык тавышы яңгырады:

– Бөек патша хезмәте! Станица атаманының үзеннән язу. Бүген, дигән, иң соңгы срок, дигән, Гомәров Миңлебайны, дигән, Яфаров Муллагалигә эшкә бирергә кушам, дигән. Аңлыйсызмы? Моңарчы ул, кемгә булса да эшкә бирергә тәкъдим итәм, дип кенә яза иде. Ә хәзер? Кушам, дип кырт кисеп әйткән, Яфаров Муллагалигә бирергә, дигән.

Мәгузә, хәзер инде яулык почмагы белән бөтен йөзен каплап, үксеп үк елый башлады. Анасының елавы Миңлебайның күңелен тагын да боза, кайгы-хәсрәт күреп өйрәнмәгән йөрәген телгәли һәм әрнетә иде.

Әүвәлге шикелле үк тонык һәм саңгырау тавыш белән:

– Киттек. Гомәров безнең белән бара! – диде урядник. Үзе, тау шикелле кабарып торган корсагын киереп кенә, капкага таба атлады.

Баштан ахырга кадәр сүзсез торган Котырык Муллагали, иләмсез озын мыек чолгыйларын ике кулы белән дә бөтереп җибәреп, бик нык итеп тамагын кырып алды да урядник артыннан китте. Аның бу кыланышы: «Менә, мә! Шулай була ул! Бүген бигрәк артыгын очынып җибәргән идегез», – дигән мәгънәне аңлата иде.

Хисамый, капканы ипләп кенә ябып, улы артыннан карап калды.

– Иртәдән бирле күңелем чуарланып, үземне-үзем кая куярга да белмичә йөргән идем аны, шушыңар булган икән, – диде ул.

Мәгузә ире янына килде. Ул:

– Бала алдында әйтәсем килмәде инде, әтисе, күңеленнән безгә үпкәләп йөрер дип. Үзеңә генә әйтүем: азрак җир сатарга да уйламадык инде, үзебез дә. Ул баланың үз өлешенә тигән җирне генә сатсак та, азрагын түләгән булыр идек.

Хисамый тавышын үзгәртеп һәм хатынын үчекләп сөйләргә кереште:

– Ә-ә, шулаймыни? Мин ул җир барын онытып та йөрим икән әле. Хатынның озын чәче уйлап тапмаса, искә дә төшә торган түгел икән. – Ул кинәт кенә чынлап һәм җитди сөйләүгә күчте: – Ә Гатау белән Барый турында нәрсә уйлыйсың?

**5**

Кышкы ачы җил котырына. Ишегалларын әйләндереп алган читәннәр яки такта коймалар селкенгәләп, үзләренең хәлләре өчен кемнәргәдер ләгънәтләр укыган шикелле итеп, рәнҗеп һәм калтыранып утыралар. Бик нык тузгытып җибәрелгән карлар, берсен-берсе узарга теләгән шикелле, очсыз-кырыйсыз киң дала буенча себерелеп йөриләр-йөриләр дә авыл ярлыларының кечкенә өйләрен һәм читән алачыкларын – Котырык Муллагалинең дала уртасында кышлап калган печән һәм ашлык кибәннәрен күмгән шикелле үк итеп – күмеп китәләр. Муллагалинең сары буяулы биек агач өе күл буе урамына урнашкан. Урам буенча бөтерелеп килгән карлар ташкыны ул өйнең һәм өй янындагы яшел буяулы карагай капканың түбәсенә менеп җитә алмый. Өй алдындагы биек такта коймага бәрелә дә, дулап килгән җилнең гайрәте кайта, ул кинәт кенә юашланып кала, һәм, Миңлебай өчен артык эш ясап, капка алдында зур кар тавы өелә.

Башка вакытлардагы шикелле үк, бүген дә буран күтәрелүгә чаң кага башладылар. Печәнчеләр җилнең түбән ягында иде. Алар, чаң тавышын аермачык ишетеп, шуның буенча авылга кайтып керә алдылар. Печәнгә дүрт чана белән барганнар иде. Алдагы ике үгезне Акмырза, арттагы үгезләрне Миңлебай куып кайтты. Миңлебай, чана тәртәсенә нык ябышып, кечкенәрәк өй зурлыгы кызыл үгезгә ышыкланып барды. Шулай итеп, аңа җил-буран тими. Ләкин ул аякларын көчкә-көчкә генә сөйрәп атлый. Аның чабаталарына кар тулган, киндер чалбар балаклары башта җепшек кар белән юешләнеп, юлга чыккач катканнар да, аяк атлаган саен, «кыштыр-кыштыр» килеп баралар. Кар астындагы кибәнне казып алу, буран башлангач, азаплана-азаплана печән төяү, кар күмеп киткән юлдан кайтулар Миңлебайны тәмам хәлдән тайдырды. Ул тизрәк кайтып җитү, Муллагалинең ишегалдындагы кирпеч алачыкка кереп ял итү турында уйланып барды. Әйе, нинди генә җил һәм бураннар булуга карамастан, кирпеч алачыкның эче һәрвакыт җылы була. Дөрес, байның бу тәбәнәк кенә алачыгы анда Акмырза белән Миңлебай торган өчен түгел, илледән артык сарык бәрәне асрагач, үзе

шулай җылына ул. Яшь бәрәннәр туңмасын өчен, хуҗаның олы хатыны Хәят бу алачыкка суык көннәрдә өч күтәрәм камыш яки бер зур күтәрәм тал ягарга рөхсәт итә. Монда ягар өчен тизәк бирелми. Тизәк яхшы ягулыклардан санала һәм аны хуҗалар тора торган зур өйгә генә ягалар...

Миңлебай әнә шулар турында уйланып килгәндә, Акмырза үзенең үгезләрен туктатты. Мөгезләре белән алдагы чананың печәнен сөзеп, Миңлебайның үгезләре дә туктады.

– Энекәш, көрәгеңне алып кил әле, – дип кычкырды Акмырза. Егет, бастырык бавына кыстырып куелган киң генә агач көрәкне алды да, алдагы чаналар кырыеннан карга бата-бата Акмырза янына барды. Ул, кар-буран эченнән беленер-беленмәс кенә күренеп торган зур өйгә карап:

– Ә-ә, кайтып җиткәнбез икән, – дип куйды.

– Кайтып җиттек тә җитүен, ишегалдына кереп булырлык түгел әле, – диде Акмырза. Капка алдындагы кар тавына таба башы белән ымлап күрсәтеп һәм шундый артык эш килеп чыккан өчен ул үзен гаепле санаган шикелле, юаш кына тавыш белән: – Кая, энекәш, тиз генә көрәп ташлыйк инде, – дип өстәде.

Кар тавын икесе ике урыннан кискәләп ыргыта-ыргыта, капка ачылырлык юл салдылар. Акмырза:

– Энекәш, чаналарны ишегалдына кертеп, үгезләрне мин үзем тугарырмын, син алачыкка яга торсаң яхшы булыр, – диде.

Бүген аларның тал кисеп куярлык вакытлары булмады. Акмырза, Миңлебай үгезләр җигеп азапланган арада гына, йөгерә-йөгерә чоланга ике күтәрәм камыш кертеп калдырган иде. Миңлебай, көрәген чолан почмагына сөяп куйды да, алачык ишеген ачып, камышларны тиз-тиз генә эчкә кертә башлады. Акмырзаның ике күтәрәмен аңа дүрт мәртәбә кертергә туры килде. Сарык бәрәннәре уянып бетте һәм, бәрәнлек рәшәткәсенә сикерешә-сикерешә, колак тондыргыч ямьсез тавышлар белән бакырыша башладылар.

Миңлебай, камышны кертеп бетереп, алачык ишеген япкач, кинәт кенә үзенең чиктән тыш арыганлыгын сизде. Аның аяклары авырта, куллары сызлый, бөтен тәне, барлык сөяк-санаклары ватылып-уалып беткән шикелле булып тора иде. Идән уртасындагы камыш өеме аша үтеп, түр як шүрлектәге шырпыны алырга һәм мичкә ут кабызып җибәрергә үзенең көче дә, куәте дә җитмәс кебек тоелды. Һәм ул, кулларын җәеп, йөзе белән камыш өеменә капланды... Аз гына, бары тик бер генә минут ятып алыйм да... Ах, менә шулай. Сарык бәрәннәренең әчкелтем тирес исен җиңеп таралган яшькелт камыш исен сулый-сулый, бик озак итеп йокласаң икән... Тукта, тагын бер генә, ике генә минут...

Аны иртә белән Акмырза уятты:

– Тор, энекәш, тор! – дип йомшак кына эндәште дә иркәләп кенә аркасыннан кагып алды. Миңлебай, акрын гына ыңгырашып, аякларын сузып куйды, өстенә япкан сырма бишмәтен аяк очына таба шудырып, ашыкмыйча гына урыныннан кузгалды. Ул, йокысын ача алмыйча, берничә минут як-ягына карангалап утырды. Акмырза күптән торган һәм киенеп тә өлгергән иде инде. Миңлебай: «Бәлки, ул әле йокларга да ятмагандыр? – дип уйлады: – Тукта, мин ничек болай сәкегә менеп яттым икән соң?»

Акмырза алачыкның җир идәне уртасында басып тора. Иске генә саргылт чикмәне өстеннән билен бозау муенчагы шикеллерәк юкә бау белән бәйләп куйган. Бер кулында чит-читләре тузгып-өзгәләнеп беткән кама бүрек, икенчесе белән ап-ак итеп кырылган такыр башын сыйпаштыра. Ул бер-берсе белән кушылып торган киң кара кашларын сикертеп алды да:

– Йә, энекәш, йокың туйдымы инде? – дип сорап куйды.

Миңлебайның йокысы туймаган иде, һәм ул Акмырзаның соравын җавапсыз калдырды. Ул, үзенең оек һәм чабаталары мич алдына кибәргә куелуын күреп:

– Акмырза агай, мин кичә идәндә йоклап калган идем түгелме соң? – дип сорады.

Акмырза, башын аз гына кыйшайта төшеп һәм зур кара күзләрен уйнатып:

– Шулай, эшне бетереп керсәм, камыш өстендә йоклап ятасың, – диде. – Үзеңне күтәреп сәкегә салганны да, киемнәреңне чишендергәнне дә – берсен дә тоймадың.

– Ай-һай, бик нык арылды шул, арка-җилкәләр бүген дә авыртып тора әле – тоташтан катып калган шикелле.

Акмырзаның йөзендәге уенчак елмаю юкка чыкты. Ул, ачы әйбер капкандагы шикелле, чыраен сытып һәм моңсу гына юаш тавыш белән:

– Шулай инде, энекәш, язмыштан узмыш юк, дигәннәр бит. Бәхетең булмагач, әллә кая барып булмый, – диде.

Миңлебай Акмырзаның Алла һәм язмыш турында сөйләгән сүзләрен бик үк аңлап җиткерә алмый. Ләкин, аны олылап каршы да дәшми. «Менә ул, Акмырза, ничек армый икән? Ничек соң аның озак итеп, бик тәмле һәм ләззәтле итеп йоклыйсы килми икән? Әгәр дә Аллага Акмырза агай эшләгән кебек авыр эшләр эшләтсәң, шулай аз гына йокыга да түзә алыр идеме икән?..» Ләкин, шуннан соң ук, үзенең уйларыннан үзе куркып киткәндәй була. Тәүбәгә килгәндәй, авыз эченнән генә «бисмилла»сын әйтеп һәм ишеткән-белгән догаларын укыштыргалап ала, аягына чолгавын чорнарга һәм чабатасын киярге керешә. Әйтерсең лә Алла дигәннәре, ниндидер канатлы зур күләгә булып, аның баш очында гына басып тора. Һәм ул, начар уйлары өчен, Миңлебайны үлгәннән соң җәһәннәм утында яначак «начар», «гөнаһлы» кешеләр исемлегенә язып куячак иде. Ә инде «бисмилла»ны әйтеп, догаларны укыганнан соң, әйтерсең лә Алланың күңеле булып китә: «Әй, шайтан малай икәнсең, бер юлга калдырып торыйм инде үзеңне», – дип әйтә дә үлгәннән соң җәһәннәм утында яначак кешеләр дәфтәреннән Миңлебайның исемен бозып ташлый...

Миңлебай, ишегалдына чыккач, иреннәр кибеп сусаган вакытта салкын чишмә суын эчкәндәге шикелле рәхәтләнеп, бераз гына саф һава сулап торды. Буран кичәге кебек үк көчле иде. Ялкау гына кагылган чаң тавышы бүген дә ишетелеп тора. Акмырза кыштыр-кыштыр лапас тирәсендә чуала. Миңлебай да аның янына барды.

Бер чана печәнне, буран тынгач лапас эченә тарату өчен дип, бушатмый калдырдылар. Ике чананы лапас түбәсенә ыргыттылар. Калган бер чана печәнне исә, үгез җигеп, Акмырза «аргы ишегалдындагы» мал-туарларга алып китте.

Акмырза киткәч, Миңлебай мондагы карларны көрәде, лапас эчендәге хайван тиресләрен чыгарды. Шуннан соң гына тузгып торган кар өермәсе эченә таң яктылыгы сирпелә барганлыгы сизелә башлады.

Миңлебай лапастан үгез алып чыкты һәм аны мичкәле чанага җигәргә кереште. Шулвакыт өй ишеге шыгырдап ачылды, һәм аннан байның олы хатыны Хәят чыкты. Аның өстендә озын һәм киң җиңле, җирдән сөйрәлеп йөри торган итәкле борынгы күлмәк. Эш арасында кия торган кара хәтфә бишмәтен җилкәсенә генә салып алган. Ире кыйнаганнан соң, Хәятның маңгае берничә урыннан күбеп, чигәләре күгәреп-күгәреп калган иде, алары кешегә күренмәсен өчен, яулыгын күзенә кадәр төшереп бәйләгән. Сул кулында зур җиз комган булып, комган борыныннан җылы суның пары чыгып тора. Хәят

ачулы иде. Ул, кызу-кызу атлап, Миңлебайга таба килә башлады. Миңлебай, сыңар камытка гына җигелгән зур гәүдәле ялкау үгезне куып ишегалдыннан чыгып китәргә өлгермәде, Хәят аның каршысына барып чыкты. Ул:

– Һи-и, чукынчык урыс! Хәерче танау! Гарифҗанга нигә кагылдың? Кичәдән бирле авырып ята. Муллагали абзаң кирәгеңне бирер әле! – диде дә комганы белән Миңлебайның аркасына сугып калды.

Миңлебай мичкә өстенә атланып утырган иде. Җил алгы яктан исә. Миңлебай, муенын һәм битләрен чикмән якасына тыгып, җилгә аркасы белән әйләнеп утырды. Карт үгез үзенең һәр көнге юлын яхшы белә. Ул, башын селеккәләп һәм күзләрен йомгалап, Миңлебайның кууын да көтмичә, акрын гына атлап бара бирә. Миңлебай урамның як-ягындагы йортларга карап ала. Аларның кайберләренә ут алынган, морҗаларыннан төтен дә чыга; ә кайсы кешеләр исә, «үгезем юк урамда, кайгым юк буранда» дигән шикелле итеп, тыныч кына йоклыйлар иде әле. Челтәрләнеп тузган чикмән һәм аның эчендәге иске бишмәт аркылы салкын җил үтеп, Миңлебайның кар көрәгән вакытта тирләгән тәне буенча суык йөгерә. Һәм ул, арка-җилкәләрен куырып, утырган җиреннән кузгалгалап куя. Ара-тирә генә булса да, үзенең әле яшәвен, дөньяда бар булуын белдерергә теләгән шикелле итеп:

– Са-ап! Һай-й, са-ап! – дип, үгезгә тавыш биргәләп ала.

Аның аркасы, Хәят комган белән суккан урыны, тәненә суык үткән саен ныграк авырта. Аркасы авырткан саен, ул кичәге хәлне исенә төшерә.

Акмырза печәнгә бару өчен чаналар рәтләп, Миңлебай мичкәдән су бушатып йөргән вакытта, муеннарына зур букчаларын асып, Гарифҗан белән сеңлесе Сабира абыстай сабагыннан кайттылар. Алар капканы япмыйча керделәр дә, ишегалдындагы ике яшь үгез урамга чыгып китте. Акмырзаның моңа чиктән тыш ачуы килде. Ләкин ул, ачуын үз эченә йотып, сабыр гына тавыш белән:

– Энекәш, капканы ябып йөрергә кирәк! Әнә үгезләр чыгып китте, – диде.

Моңа каршы Гарифҗанның күзләре ачу очкыннары белән зәһәрләнде. Аның авызыннан, чукаеп алга чыккан иреннәре арасыннан, селәгәе агып төште. Ул, Акмырзаның ипләп кенә әйткән сүзләренә каршы:

– Әй, башкырт, үзең дә ябарсың әле, – дип җавап кайтарды. Аның янындагы Сабира исә, агасын яклап, Акмырзаны мыскыл итәргә кереште:

– Ак чук, зәңгәр чук,
Акмырзага чукынса да хатын юк.

Сабирага кушылып, Гарифҗан да такмакларга кереште:

– Башкырт-башкырт барана,
Кермә безнең арага;
Керсәң безнең арага,
Утыртырбыз бүкәнгә.

Алар тагын, бөтен ишегалдын яңгыратып һәм һәрбер сүзгә аерым-аерым басым ясап:

– Ак чук, зәңгәр чук,
Акмырзага чукынса да хатын юк,

– дип кычкырдылар.

Миңлебай, кашларын җыерып һәм ачулы күзләрен Гарифҗанга туп-туры текәп:

– Син нәрсә, үзеңнән олы кешене үчекләгән буласыңмы?! – диде.

Гарифҗан аңа каршы:

– Әй, хәерче! – дип җавап кайтарды.

– Хәерче, хәерче! Башкыртны яклаган була бит әле, – дип кушылды Сабира да.

Миңлебай Сабирага бөтенләй игътибар итмәскә тырышты. Ул, тагын Гарифҗанга карап:

– Син үзең кем, ә? Үрдәк авыз, селәгәй бит әле син! Селәгәеңне җыя белмисең, үзеңнән олы кешене үчекләп маташкан буласың, – диде.

Гарифҗан:

– Ах, с-син, хәерче! Ирәкә хәерчесе! Син әле мине мыскыл итәсеңме? – диде дә, аяк астындагы туң ат тизәген алып, Миңлебайга бәрде. Миңлебай мичкәдән чиләк белән су алып азаплана иде. Ат тизәге аның нәкъ маңгаена килеп тиде. Миңлебай, сулы чиләген тиз генә чана кырыена утыртты да, башын түбән иеп, маңгаен кулы белән тотып торды. Маңгае күбеп чыккан иде. Ләкин ул маңгаеның авыртуын тоеп җиткермәде. Аның хурлануы барысыннан да, хәтта тәненең әрнеп-әрнеп авыртуыннан да өстенлек алды. Аның йөрәге ачудан ярсып тибә башлады. Аның күзләренә яшь агымы килеп тыгылды. Ләкин ул: «Мин нәрсә, шул җебекиләр алдында елап тораммы?» – дип уйлады.

Гарифҗан, өр-яңа кара киез итегендәге карларны каккалый-каккалый, өйалды баскычыннан менеп бара иде.

Миңлебай аңа:

– Их-х, с-син! Нигә качасың, куян йөрәк? – дип кычкырды.

Гарифҗан яңадан Миңлебайга таба килә башлады:

– Кем кача? Кем куян йөрәк? Син миңа исем кушасыңмы, күпкән маңгай!

Миңлебай, чиләк белән суны тиз генә күтәреп алды да Гарифҗанның өстенә сибеп җибәрде:

– Менә, мә!

Миңлебай әнә шулар турында уйлады. Ул, үзен борчып килгән шул уйлардан арыну теләге белән:

– Са-ап, һай-й, са-ап! – дип, үгезгә һаман тавыш биргәләп барды.

Җаек сулары өзлексез агып торган кебек, Миңлебайның көннәре һәм еллары да, бер-берсенә үрелеп, әнә шулай акрын гына үтә тордылар.

**6**

Бер башы белән Җаек елгасына килеп төртелә торган озын гына күл бар. Аны Үле Җаек дип атыйлар. Ул, чыннан да үлеп калган шикелле, өстендә кыл да кыймылдатмыйча тын гына ята бирә. Саерак җирләрендә аны аксыл үги ана яфрагы каплап үскән дә, күлнең өсте үлгән кешенең көлсыман йөзен хәтерләтә. Аны урыны-урыны белән Җаекка караганда да киң һәм тирәнрәк дип исәплиләр. Аның ике як кырые да буйдан-буйга куе камыш һәм исәпсез-хисапсыз таллар белән каеп алынган.

Җәләй картның печәнлеге әнә шул Үле Җаек буена туры килде. Башка елларны ул печәнне кем белән булса да кушылып эшли иде. Күбрәк ул атлы кешеләр белән печәндәш булып килде. Быел ул эшне башкачарак итеп, болын печәнен үзе чалгы белән чабып, кызы Мәрьям җыеп бара торган итеп көйләде. Кыр печәнен кемгә булса да уртагыннан биреп эшләтергә булды. Бодай һәм

солы саламы, ара-тирә кибәк-фәлән кушкаласа, аның бер аты, бер сыеры, бер пар үгезе һәм унлап сарыгына шул печән дә җитәчәк иде.

Җәләй карт чалгысын салмак кына селтәп печән чаба һәм акрын-акрын гына алга бара. Аның артында буй-буй тезелеп ямь-яшел печән покослары кала. Аның киң ак күлмәге һәм төбе капчык сыман салынып төшкән соргылт ыштаны, суга манып алган шикелле булып, тир белән чыланган. Кояш җыерчыклы муенын кыздыра. Тамагы тәмам кипкән һәм бер генә йотым булса да су эчеп җибәрәсе килә. Ләкин ул: «Тукта, шушы буйны гына алып чыгыйм инде», – дип уйлый һәм чабуын дәвам итә.

Шушы буйның башына барып чыккач, Җәләй карт, туктап, тын алып торды. Башта чалгысын янап куймакчы булган иде, ул уеннан ни өчендер кире кайтып, чалгысын иңбашына салды да, зур-зур атлап, кызы Мәрьям янына китте.

Мәрьям, акрын гына җырлый-җырлый, кипкән покосларны күбәләп йөри иде. Атасын күргәч, тырма сабына таянып, аның килеп җитүен көтеп торды. Җәләй карт кызының Җаек буенда гына очравы мөмкин булган нәфис сыек тал шикелле зифа буй-сынына сокланып карап куйды. Бу секундта аны әчке бер канәгатьләнү һәм горурлык тойгылары чорнап алгандай булды. Мәрьямнең кояшта янган бит урталары, өлгереп пешкән пар алма шикелле, кып-кызыл булып янып торалар иде. Ап-ак яулыгын артка каерып бәйләгән. Чит-читләре зәңгәр белән каелган кесәле, гармун итәкле ак алъяпкычы Мәрьямнең нечкә гәүдәсен килешле генә тулыландырып тора. Җәләй карт: «Сөбханалла, сөбханалла! Инде үсеп җитте, кызыма күз генә тия күрмәсен», – дип сөйләнә-сөйләнә, як-ягына төкеренгәләп куйды. Чал керә башлаган куе зур сакалы буенча агып төшкән тир тамчыларын сул кулы белән сыйпап алды да:

– Әйдә, кызым, арттан бай куып тормый әле. Рәхәтләнеп ял итеп алыйк, – диде. Мәрьям, анасы юк вакытларда атасының иркенрәк ял итәргә яратуын искә алып:

– Әти, әле берәү дә туктамый бит, иртәрәк түгелме соң? – дип сорады һәм иркәләнеп кенә елмаеп куйды. Җәләй, Мәрьямнең сүзләрен бөтенләй ишетмәгән шикелле итеп, бераз вакыт кояшка карап торды. Аннан соң: – Ай-һай, эссе! Бүген һава бигрәк бөркү булып тора, – дип өстәде. – Әйдә, төш авышканчы Җаекта су коенып, ашап-эчеп алыйк.

Мәрьям атасы артыннан иярде. Берәр минут алар сөйләшми генә бардылар. Тынлыкны Мәрьям бозды. Ул:

– Әти, кайчан кибән куябыз инде? – дип сорады.

Җәләй, кызына әйләнеп карамыйча гына баруын дәвам итте һәм:

– Алдагы атнаның башы белән керешербез, – диде. – Хисамый күршеләр белән кушылып өяргә булдык. Аларның Гатавы ат йөртер, син чүмәлә җибәреп торырсың.

– Аларның печәннәре бик күп түгелме соң? Алар дүрт пай, без бер генә пай алабыз бит.

– Юк инде, кызым, алар җиде-сигез елдан бирле бер генә пай чабалар. Өч пайның җирен Миңлебайларын Котырыкка биргән елны ук саттылар бит.

Аларның куышлары Үле Җаек буенда иде. Куыш бик гади генә эшләнгән: тал куагы янына куелган арбаның тәртәләре югары күтәреп бәйләнгән дә, аның өстенә эре-эре таллар салып, кояш кызуы һәм яңгыр-фәлән үтмәсен өчен, тал өстеннән калын гына итеп печән капланган.

Җәләй карт чалгысын арба күләгәсенә куйды.

– Кызым, син хәзер Җаек буена төш, коенып ал, – диде ул. – Шул уңайдан бер чиләк су да алып мен.

Мәрьямнең шомарган чабата табаны куыш алдындагы тапталып беткән үлән өстендә таеп китте.

– Әтекәем! – дип кычкырып җибәрде ул.

Җәләй карт, кызын елан-фәлән чакты микән әллә дип куркып, куыш эченә кереп барган җиреннән тукталып калды. Эшнең нәрсәдә икәнен күргәч, иркәләүле генә елмаеп:

– Ипләбрәк йөри күр, кызым! Бер-бер җиреңне авырттырып ала күрмә тагын, – диде.

– Юк-юк, әти, бернәрсә дә булмады, – диде Мәрьям.

Кызы су буена төшеп киткәч, Җәләй карт, кояш эссесенә чыгып, чалгы чүкергә утырды.

Менә ул чалгының бер ягын чүкеп чыкты. Баш бармагының битен чалгы йөзеннән йөртеп, чүкүнең нәтиҗәсен карап алды. Сандал өстенә чалгының икенче ягын әйләндереп салды һәм чүкүен дәвам итте. Өч корычның (сандал, чүкеч һәм чалгы) бер-берсенә сугылуларыннан чыккан саф һәм яңгыравык чыңлау авазлары Җаек буена, якындагы таллар арасына җәелеп торды. Моңардан үзенә бер матур көй хасил була, һәм Җәләй карт әнә шул көйне өзмәскә тырышып чүки иде.

## 7

Миңлебай, әле генә салып бетергән чүмәләсе янына биш япьле зур тимер сәнәген кадап куйды да, киң маңгаеннан агып төшкән тир тамчыларын кул аркасы белән сөртеп:

– Фу-у, бу Гарифҗан батып калдымы әллә? Бозлы әйрән китерәм дип киткән иде бит! – диде.

Акмырза, барлык авырлыгы белән сәнәгенә таянган хәлдә, чүмәләсенә салып бетерәсе печән күбәләренә карап нәрсәдер уйланып тора иде. Ул, күзләрен печән күбәләреннән акрын гына алды да таллык буендагы куышка таба карап куйды. Шуннан соң гына, егетнең сүзләренә җавап итеп:

– Китерәме соң ул! – диде.

– Китермәсә, үзебез барыйк, нигә аны көтеп торырга ди монда!

– Барырга ярамый шул, энекәш. Баягынак, син чокырда өеп йөргәндә, Котырык үзе килеп китте. Шушы покосларны өйләгә кадәр чүмәләгә өеп бетерегез, диде.

Миңлебай кызып китте. Ул, киң кырыйлы киез эшләпәсен тиз генә башыннан салды да, аны яңадан киеп һәм җиргә кадаулы сәнәген әйләнеп чыгып:

– Өйлә дә өйлә! Биш өйлә җитеп үткәндер инде! Безнең дә җаныбыз бар ла! – диде. – Әйдә, тотабыз да кайтабыз куышка.

– Ярамый, энекәш, алай ачуланып булмый ул. Ничек тә түзәрбез әле. Көндәгечә, Миңлекамал апай тәртә башына чикмән элеп күтәргәч кайтырбыз. Анда кайтып, Котырыкның эт урынына өреп торуын ишетәсем килеп тормый әле: ач тамагым, тыныч колагым.

Миңлебай аның белән килешмичә булдыра алмады. Ул, инде юашлана башлап:

– Алайса, Җаекка төшеп су эчеп меник. Башларны юып алыйк, – диде.

– Менә монысы ярый. Тик икебез дә берьюлы китмик, бар, башта син барып кил.

Миңлебай, якындагы эт шомырты һәм зелпе куакларын аралап үтеп,

Җаек буендагы таллыкка таба китте. Таллык белән әрәмә арасында печәне чабылмаган ачыклык иде. Миңлебай, кураларны, чабыр үләннәрен чытырдатып изгәләп, үзенең буе кадәр булып үскән әнә шул печәнлекне үтеп чыга башлады... Кинәт аның йөрәге тибүдән тукталган шикелле булып калды, тын алуы бөтенләй диярлек кысылды, бәхет очкыннары белән дәртләнеп янган кара күзләре алга, таллык буендагы сукмактан Җаекка таба баручы ап-ак күләгәгә карап текәлде. Әйе, ап-ак күләгә, ләкин күбәләк түгел иде ул үзе. Юк, андый зур күбәләкнең булуы һич тә мөмкин түгел... Миңлебайның:

– Мәрьям! – дип кычкырасы килде.

Ләкин аның тавышы чыкмый калды. Муенына елан чорналган шикелле булып, тыны бугазына тыгылды. Мәрьямнең артыннан куып җитәргә тырышып, шул ук сукмактан Гарифҗан бара иде. Миңлебай, аларга күренмәскә теләп, тиз генә җиргә, үлән арасына чүкте. Тегеләр икесе дә Җаек буена төшеп киттеләр.

Миңлебай яшеренеп утырган җиреннән торды. Аңардагы чиксез сөю, көчле мәхәббәт тойгылары көнчелек һәм ачу тойгылары белән бергә кушылып буталдылар. Ул:

– Менә сиңа кирәк булса! Ә соң Мәрьямнең миңа биргән меңнәрчә вәгъдәләре кайда?! Мәрьям булып Мәрьям дә алдар микәнни? – дип уйлады.

Мәче җитезлеге белән алга, Җаек буена таба ташланды. Менә ул, бер минут эчендә, яр буендагы зур гына агач янына барып тукталды. Бу агач яныннан яр астындагы кешеләрнең сөйләшүләре генә түгел, йөгерек агышлы Җаек суының шаулавы да ишетелеп тора. Һәм менә Миңлебай тыңлый.

– Мәрьям, син нигә минем хатларыма бер генә дә җавап кайтармыйсың?

– Нинди хатлар? Мин синең хатларыңны күргәнем дә, алганым да юк.

– Эх, син, кызый! Күрәләтә ялган сөйләп торасың бит... Миңлебайга дигәндә иренмисең син.

– Анда синең эшең юк! Минем кемгә хат язганымны тикшереп торырга дип сиңа кушмаганнардыр бит. Кит моннан, яман кеше юл бөяр, дигән шикелле, юлыма аркылы төшеп торма!

– Кайда ул хәтле ашыгасың, җитез кыз, ә?!

– Бар, җитез булганнарны эзлә! Нәрсәмә миңа бәйләнеп йөдәтәсең? Китче моннан! Хатларың белән аптыратып бетүең җитмәгән, инде артымнан карауллап йөри башладыңмы?

– Мәрьям! Шул хәерче Миңлебайны әллә кемгә куясыңмы? Кара аны!

– Акырма да, куркытма да мине! Бар, Хәмчки Хәдичәсенә җикерен, син аның колагын тешләгән бит.

– Ә-ә, син әле Миңлебай колагыңны тешләде дип йөрисеңме? Колак тешләү нәрсә инде ул?! Миңлебай үткән ел Сабираны суга баткан җиреннән коткарды. Хатын итеп аласы килмәгәч, нигә коткарган ул аны? Суга бату колак тешләү генә түгел. Шулай булгач, Миңлебай сиңа түгел, Сабирага өйләнергә тиеш.

– Китче моннан, әллә нәрсәләр лыгырдап торма минем каршымда!

– Җитезләнми генә тор!.. Әгәр дә Миңлебай безнең Сабирага өйләнми икән, эти аңа хезмәткә киткәнгә кадәр өйләнергә ирек бирмәячәк. Менә син көтеп утыр аның хезмәттән кайчан кайтканын. Әбигә әйләнеп бетәрсең. Хәзер дә син бик яшь түгел бит инде. Синең кебек чибәр кызлар унбиш яшьтән кияүгә чыга. Хәзер инде сиңа өч-дүрт бала анасы булырга кирәк иде.

Мәрьям Гарифҗанның битенә төкерде. Гарифҗан учы белән битен сөрткән арада тиз генә үтеп китмәкче иде, теге яңадан кызның каршысына төште:

– Юк, мин сине җибәрмим! Әле мин сине!

– Китче әле! Суымны түктерәсең бит! Кагылма миңа кулың белән! Ә-ти-и!

Мәрьямдәге ныклык Миңлебайның күңелен үстереп җибәрде. Көн буенча эшләп арыган булуы да, салкын су эчәсе килүе дә онытылды. Ул үзеннән бер генә адым ераклыктагы текә ярдан аска сикереп төште. Яр бик биек һәм текә иде. Миңлебайның аяклары ком өеменнән генә торган җиргә батып керде, каталарының эченә, оекларының тишек-тошыкларына ком тулды. Авыр эш белән хәлсезләнгән аякларының тез буыннары бөгелеп китте; һәм ул, егылып йөзе белән җиргә капланмас өчен, куллары белән эссе комга таянды...

Яр башыннан Миңлебай сикереп төшкәч тә, Гарифҗан Мәрьям яныннан читкәрәк тайпылды. Аннан соң, үзенең куркып, каушап калуын сиздермәс өчен, ясалма бер кыланыш белән шаркылдап көлгән булды да:

– Син өтеккә монда ни калган тагын?! Кара, чалбар аламаларыңа ком тулган бит! Үзең кызлар артыннан йөргән буласың тагын, – диде.

Миңлебай исә, җиргә төшкән эшләпәсен алып киде дә, Гарифҗанның янына ук барып һәм аның яшькелт зәңгәр күзләренә туп-туры карап:

– Ә син селәгәйгә монда нәрсә калган? – диде. – Үзең эшләүчеләргә салкын әйрән алып киләм дип киттең, ә үзең әллә кайларда югалып йөрисең, тинтәк малай!

Миңлебайның бу сүзләре Гарифҗанның йөрәгенә агулы ук булып кадалды. Ул, чиктән тыш хурланып һәм ачуыннан еларга җитешеп:

– Сиңа әйрән ташып йөрергә мине хатыннар дип белдеңме әллә? Әнә, теге йолкышны хатын итеп алгач, әйрән китерергә аңа кушарсың. Тик ул вакытта әйрәнегез генә булмас, – диде.

– Анысын синнән сорамаслар!

Гарифҗан, йодрыгын Миңлебайның борын төбенә үк куеп:

– Анысын сорамасаң, менә монысын сорарсың! Эшләми йөрергә сиңа кем кушты? Менә мин этигә әйтим әле.

Миңлебай аның йодрыгын читкә этәрде.

– Кулыңны җыебрак тот! – диде ул. – Синең ул кулың авызыңнан аккан селәгәеңне сөртү өчен генә ярый бит. Бүгеннән башлап, син түгел, атаң да миңа кагыла алмас, менә күр дә тор!

Гарифҗанны «үрдәк авыз» дип тә, «селәгәй Гарифҗан» дип яки «Котырыкның селәгәе» дип тә атап, мыскыл итеп йөртәләр иде. Яшьләр арасында әйтелеп йөри торган шул сүзләрнең монда, Мәрьям бар урында кабат-кабат искә алынуы Гарифҗанның түзәр хәлен калдырмады. Ул:

– Ай-һай, гайрәтләнгәнсең икән, – диде дә, күзләренә килеп тыгылган яшь бөртекләрен Миңлебай белән Мәрьямгә күрсәтмәс өчен, тиз генә читкә борылды. Текә ярны кисеп эшләнгән тар сукмакның баскычларыннан сөрлегә-сөрлегә атлап, югарыга менеп китте...

Мәрьямнең шатлыгы эченә сыймый иде. Ул, Гарифҗан бөтенләй китеп күздән югалу белән үк, кулындагы сулы чиләген җиргә утыртты. Кыюсыз гына адымнар белән Миңлебай янына килде. Аңа нәрсәдер әйтергә теләде, ләкин һичбер сүз таба алмады һәм җайсызланып калды. Ә Миңлебай, барысын да аңлыйм, сүзнең кирәге дә юк инде хәзер, дигән шикелле елмайды да аның алъяпкыч бавы кысып торган нечкә биленнән иплән кенә кочаклап алды. Бу – ничәмә еллар буенча сөешеп, хатлар аша һәм төннәрен тәрәзә пыяласы аркылы гына вәгъдәләр бирешеп йөргәннең соңында – беренче мәртәбә шулай бер-берсенә якын килү, беренче мәртәбә шулай тиңе булмаган ләззәт һәм рәхәтлекләр табу иде. Мәрьям, Миңлебайның муеныннан кочаклап

алып, башын аз гына арткарак чөйде. Миңлебайның башы түбән иелде. Тәмам кипкән, сусызлыктан хәлсезләнгән иреннәре Мәрьямнең кайнар, дәртле иреннәре белән бергә кушылды. Берничә секундка, бары тик берничә секундка гына алар икесе дә тынсыз калды һәм бөтен дөньяларын онытты... Беренче башлап Мәрьям айныды һәм иреннәрен читкәрәк алды, аннан соң гына Миңлебай башын күтәрде. Ул Мәрьямгә текәлде:

– Су сорасаң, ширбәт бирә безнең Җаек кызлары, дигәннәре шушы буладыр инде күрәсең, – дип куйды.

Шул арада Мәрьям Миңлебайның кочагыннан чыкты. Аның озын керфекләре астындагы соргылт күзләре сөйкемле генә елмаялар иде. Ул:

– Кара аны, Миңлебай, моннан соң болай итәсе булма, – диде.

– Син миңа үпкәләмә, Мәрьям, мин бит яратып...

Мәрьям, кыйгачланып торган нечкә генә кара кашларын уйнатып, алай булса ярый, дигән мәгънәдә елмаеп һәм башын иеп куйды. Аның кояшта янган кып-кызыл бит урталары, бөтерелеп-бөтерелеп аккан Җаек суының уелмалы урыннары кебек, уйдык кына чокырланып торалар иде.

**8**

Көз. Печән эшләре күптән беткән һәм онытылып бара инде. Ашлыгы күп булмаган кешеләрнең сугу эшләре дә тәмамланган. Байларның исә кыш көнендә һәм язгы сабаннан соңгы буш арада сугыла торган өлеше кибән һәм эскертләргә салып куелган. Авыл әйләнәсендә, авылдан унар-унбишәр чакрым ераклыкка кадәр, шундый бик күп кибән һәм эскертләр утыра. Петлюк – шәһәрдән килеп, Муллагалигәялланган яңа хезмәтче – әнә шул байлыкларга карап ымлый да:

– Йә, Акмырза, синең эшләр ничек соң әле, ашлыгың кышка калу куркынычы юкмы? – дип сорый.

Акмырза аның шаяртуын аңлый һәм бер дә иренмичә генә:

– Байларның шул булыр инде аларның – һаман кеше актыгына калып йөриләр. Ә менә минеке тып-тыныч. Быел үсәчәк ашлыкларым моннан әллә ничә ел элек үк чабылган да, сугылып та алынган, ашалып та беткән, – дип сөйләнә.

Муллагалинең Карбыз тавы битендәге утыз алты дисәтинә җире көзге сөрүгә калдырылган иде. Акмырза, Петлюк һәм Миңлебай, ике атнадан бирле әнә шул җирне сөреп, авылга бөтенләй кайтмыйча, салам куышта яшиләр. Аларның өчесенә алты пар үгез, өч сабан. Миңлебайның хезмәткә бара торган аты да шунда үзе белән, ләкин ул аны җикми дә, атланмый да. Алар, сабан саен икешәр пар үгез җигәләр дә, берсе артыннан берсе төшеп, бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр буразна буенча акрын гына әйләнеп йөри бирәләр. Аларның эше авыр һәм ялыктыргыч... Шулай булса да, Петлюк үзенең бер генә минут вакытын да бушка үткәрми. Ашаган-эчкән вакытларда, утырып тәмәке тарткан араларда гына булса да һәртөрле китаплар яки кулдан гына язылган кәгазьләр укый. Укыганнарын Миңлебай белән Акмырзага да сөйләп аңлата. Ул бик күпне белә, тормышның ул таныш булмаган бер генә тармагы да юк кебек. Ул байлар һәм ярлылар турында, байларга каршы көрәш белән җитәкчелек итүче яшертен партия булуы һәм революция турында сөйли. Ул боларны бик җиңел һәм аңлаешлы итеп, үзенең карашларына һәркемне дә ышандырырлык итеп аңлата. Аның сүзләрен тыңлап утырганнан соң, Миңлебайда аерым бер дәрт һәм кыюлык туа бара. Ул моңарчы үзе өчен бик буталчык кебек күренгән тормышка ачык һәм барысы да аңлаешлы итеп карый башлый.

Менә хәзер дә алар куыш алдындагы учак әйләнәсендә, кичке ашны пешергәннән соң калган утлы күмер өеме янында утыралар. Акмырза, сорауфәлән бирмичә тыңлап кына утыра. Миңлебай исә, теге яки бу мәсьәләләр буенча кызыксынып, әңгәмәне һаман куерта бара.

Озак кына шулай сөйләшеп утырганнан соң, Петлюк, куыш алдына эленеп куелган чолгауларын үрелеп алды да, аягына итеген кия башлады.

– Ярый, мин юнәлим инде, үгезләр берәр якка кереп китмәсен тагын, – диде ул. – Ә син, туганкай, Мәрьямең янына кайтырга тырыш. Өченчекөннән бирле кайтканың юк, тәмам сагынып беткәндер инде үзеңне.

Аннан соң, куыш кырыенда яткан юан зур чыбыркыны иелеп ала-ала:

– Ә безгә, карт кешеләргә, ярар шунда, үгезләр тирәсендә генә чуалсак та... Шулай, туганкаем, син Мәрьямеңне ничек та кулыңнан ычкындырмаска тырыш, – диде. – Кем әле, теге юнкерлар мәктәбенә укырга киткән? Гарифҗан бит әле? Күзеңне ачыбрак йөрмәсәң, яшь офицер киемнәрен киенеп кайтыр да Мәрьямеңне каптырып та куяр...

Вакыт төнгә авыша һәм караңгылана бара иде инде. Акмырза, зур гына яңалык ачкан шикелле итеп:

– Карагыз әле, кемдер килә! – дип күрсәтте.

Чыннан да, эскертләр ягыннан берәү кызу-кызу гына килә иде. Аның кем икәнен танығач та, Миңлебай:

– Васильев! Соң, дустым, бик соңга калдыгыз бит, – диде.

Озын гына буйлы, зур кылыч борынлы Васильев, фуражкасын рәтли-рәтли алар янына килеп җитте дә, өчесенә берьюлы җавап кайтарып:

– Бездә күңелсезлек килеп чыкты әле. Бүген хуҗа, Григорий Григорьевич, үзе килде. Улы Михаилны чакырып алды да, куыш янында бик озак сөйләшеп утырдылар, – диде. Петлюктан бераз җайсызланыбрак торганнан соң: – Иван Петрович, алар кемнедер эзлиләр, сезнең маңгаегызда ниндидер яра эзе булырга тиеш дип шикләнәләр, – дип өстәде. – Бая Михаил сезнең янда булды түгелме? Хәзер ул авылга кайтып китте. Безгә монда килмәскә кушты. Беләм мин сезнең ни өчен йөргәнегезне, ди.

Васильев, үзе белдергән яңалыклардан соң тегенең исе-акылы китәр дип уйлап, Петлюкның зур кара күзләренә йотлыгып карады. Ләкин Петлюк гадәттәгечә үк тыныч һәм салкын канлы иде. Ул, кызык кына итеп көлемсерәде дә, Васильевка якынрак килеп һәм аның җилкәсенә кулын салып:

– Хәбәр итүегез өчен рәхмәт, – диде. – Михаил сезгә янап китте, дисез? Бер дә курыкмагыз. Ул бу мәсьәләдә нәкъ балаларча эш итә икән әле... Ярый, сез хәзер үк иптәшләрегез янына кайтыгыз да тагын бер мәртәбә исләренә төшереп куегыз: ишеткән-белгәннәре турында авызларын да ачмасыннар, үзегезгә җайсыз булыр...

– Ә сез, Иван Петрович?

Петлюк, Васильевны җилкәсеннән сөя-сөя:

– Ах, бик яхшы дуслар булдыгыз әле сез! Мин сезне һич тә онытмам, – диде. – Ә минем турыда тыныч булыгыз. Хәзер инде алар мине тота алмаслар...

Васильев китте. Петлюк Миңлебай янына килде. Гаять тыныч һәм җитди тавыш белән:

– Ә син, туганкаем, Мәрьямең янына тизрәк кайт! Ләкин бүгенгә аны күрмәсәң дә ярар. Урядникның планнарын беләсе иде. Ул, мөгаен, Муллагалидә булыр. Үзеңне сак тот, синең бүген авылга кайтуыңны Акмырза белән миннән башка берәү дә белмәскә тиеш. Артык озаклап каласы булсаң, миңа сине

көтәргә туры килмәс. Ярый, туганкаем, сәламәт бул, – дип, Миңлебайның кулын нык кына кысты да, чыбыркысын болгый-болгый, үгезләр киткән уңайга таба атлады.

Миңлебай аңа нәрсә дип әйтергә дә белмәде. Ул караңгылык эченә кереп югалганчы карап торды-торды да, үзендә көчле бер эч пошуы сизеп, теләр-теләмәс кенә сулга борылды һәм авылга кайтып китте.

**9**

Көз аеның салкынча төне. Һава тын. Ай, качышлы уйнаган шикелле, әле бер болыт артына, әле икенчесе артына яшеренә. Вак ташлы комсу юл, айның шулай кылануын һич тә яратмагандай, ай күренү белән, әллә кайларга сузылып ялтырый да, ул яңадан болыт артына яшеренгәч, чыраен сытып, тиз генә күздән югала башлый. Ләкин бөтенләй үк түгел...

Миңлебай алга таба атлап барган саен, аның алдында кыска гына аксыл тасма һаман сузылуында дәвам итә. Юлның бер ягында карбыз-кавыннары алынган буш бакча, икенче ягында печәне чабып алынган ялан. Ара-тирә сөрелгән урыннар да очрый. Юлның ике ягы да, ай болытлар артына яшеренгән минутларда, куе караңгылык пәрдәсе белән каплап алына. Әмма теге аксыл тасма, Миңлебайның алдында сузылып барган комсу юл тасмасы, ул һич тә бетми һәм кара пәрдә белән дә каплап алынмый. Әйтерсең лә Миңлебайның алдында гаять зур йомгак, чыннан да аксыл тасма йомгагы булып, Миңлебай аның сүтелгән урынына баса-баса атлаган саен, йомгак тагын да күбрәк сүтелә һәм алга таба тәгәри дә тәгәри иде. Менә ай кинәт кенә болытлар артыннан чыгып куя да, әлеге йомгак күз ияргесез җитезлек белән алга йөгерә...

Миңлебай кинәт тукталып калды. Аңардан берничә адым гына ераклыкта ике бүре ята иде. Гаять зур бүреләр. Икесе юлның ике ягында, алгы аякларын юлга салып, башларын аяклары өстенә куеп һәм үзләре Миңлебайга таба карап яталар. Аларның икесе дә, ай яктысында ялтырап күренгән комсу юл шикелле үк, аксыл-соргылт төстә иделәр. Миңлебай, күктәге айлы болытларга карап килә торгач, бүреләр янына килеп җитүен сизми дә калган...

Моннан байтак еллар элек, Котырык Муллагалигә ялланып эшли башлавының нәкъ беренче елында, Миңлебай шушындый ук хәлгә очраган иде. Анда да көзге сөрү вакыты булып, шушындый караңгылы-яктылы төндә ул Мәрьямне күрергә кайтып бара иде. Ул вакытта әле, чын-чыннан егет булып, кызлар белән йөрүнең барлык тәмен һәм ләззәтен белеп йөрү түгел иде. Юк. Үзенең авылдагы бердәнбер акыллы һәм чибәр кыз белән йөрүен кешеләргә сиздереп масаю шикеллерәк тойгы белән йөри иде әле Миңлебай ул вакытта. Шунда ук: «Котырыкка ялчы булу белән генә минем кешелегем юкка чыкмас. Акмырза агай, гомере буе Котырыкка эшләп йөреп, хатынсыз һәм йорт-җирсез калган икән, мине һич тә андый хәлгә төшерә алмассыз. Мин яшәрмен һәм үземнекен итәрмен әле», – дигән кебегрәк бер фикердә булып, ул фикер Миңлебайны өзлексез тынгысызлап тора иде. Һәм бу фикер егет булып үскән саен киңрәк тамыр җәя һәм ачыклана барды. Завод эшчесе Петлюкның Яңа Чиркас авылына килеп чыгуы һәм аның белән булган әңгәмәләр мондый фикернең көчәя һәм билгеле бер эзгә салына баруына ярдәм итте...

Хәзер ул бүреләрдән дә курыкмый кебек. Ә ул чакта Миңлебай алардан шундый курыккан иде... Әйе, бүгенге кебек үк ул төнне дә Миңлебайга ике бүре очрады. Башта ул катып калды. Бераздан, анасының бүреләр турында кабат-кабат сөйләгәннәрен хәтерләп, үзенең курыкканын бүреләргә сиздермәс өчен, туп-туры

аларга таба китте. Аның уң кулы чалбар кесәсендә иде. Ул, бүреләргә якынлашу белән, кесәсендәге кечкенә пәкесен учына кысып тотты. Ләкин ни өчендер кулын кесәсеннән чыгара алмады. Шул хәлдә бүреләргә якынлашты. Бүреләр, юлдан аз гына читкәрәк тайпылып, яңадан юлга карап һәм койрыкларын читкә ташлап яттылар. Миңлебай бүреләрнең нәкъ уртасыннан үтеп китте. Мондый вакытта кешенең өне алына икән дип сөйләгәннәрен ишеткәне бар иде Миңлебайның. Аңарда да шундыйрак бер хәл туды, күрәсең. Аның тәне кызышты, уйлау һәм нәрсәне булса да аңлау куәсе бетте...

Бүген, үзенең каршысында яткан ике зур бүрене күргәч тә, Миңлебай әнә шул кечкенә вакытында булган хәлләрне исенә төшерде... Бүген ул үзенең курыкканын да, курыкмаганын да сизми калды. Әйтерсең лә ул нindидер тылсымлы дөньяга барып кергән иде. Шул тылсым эчендә сихерләнеп, ул үзенең бүреләр янына ничек килеп җитүен, аңар юл бирү теләге белән, бүреләрнең читкә тайпылуларын, үзенең Карбыз тавы биеклегеннән ничек итеп төшүен һәм авылдан ерак булмаган ындырларга якынлашуын сизеп тә, аңлап та өлгермәде. Башында, хәзергене онытырга тырышып, төрле-төрле уйлар кайный; аяклары үзләреннән-үзләре җиңел атлыйлар. Миңлебай, теге вакыттагы шикелле үк, бүреләрнең үзе артыннан ияреп килүләренә ышана, ләкин ындырларны узып киткәнгә кадәр артына әйләнеп карамаска тырыша иде. Салам һәм ашлык өемнәре белән тулы ындырларны узып бераз баргач кына – нәкъ шулвакыт ай да болытлар арасыннан үрелеп карады – Миңлебай артына әйләнеп күз салса – бүреләр, икесе юлның ике кырыеннан акрын гына атлап һәм койрыклары белән җир себереп, чыннан да аның артыннан киләләр иде...

Менә Миңлебай авыл кырыена килеп җитте. Шулчак ул егетләрнең гармун уйнап, җырлашып килүләрен ишетте һәм тукталып тыңлап торды. Артына әйләнеп караса, бүреләр дә чүгәләгәннәр һәм, балчыктан коеп куйган шикелле, кузгалмый гына утыралар иде. Миңлебай, бүреләргә таба шаян ымлап: «Ярый, озата килүегез өчен рәхмәт... Сез минем авылга кайтуым турында кешеләргә шаулап йөрмәссез инде», – дип, эченнән генә көлемсерәп куйды.

## 10

Акмырзаның колагына кемнеңдер сүгенүе, нәрсәдер эзләнеп, куыш әйләнәсеннән актарынып үтүе ишетелде. Ләкин ул озак кына уяна алмый ятты. Ул күзләрен ачарлык һәм кузгалып тора алырлык хәлдә түгел иде. Күз кабакларын тырышыбрак киерү белән, әллә нинди ачы агу кергән шикелле булып, күзенең эче әрни һәм авырта башлый. Татлы йокы барыбер үзенекен итә – күзләр яңадан рәхәт кенә йомыла.

Шулай да башта Акмырза уянды. Ул, яткан җиреннән генә күзләрен ачып җибәрүгә, куышның тишек-тошыкларыннан саркып торган аксыл кояш нурларын күрде. Акмырза, өстендәге каеры тунын аяклары белән этәреп җибәрде дә сарык тиресеннән тегелгән калын чалбарын кия башлады. Шул ук вакытта:

– Энекәш, тор! Тор әле, без йоклап калганбыз, – дип, Миңлебайны уята башлады. – Әллә кемнәр сүгенеп йөри анда...

Соңгы сүзләр Миңлебайның йокысын шундук ачты. Ул, тиз генә торып утырды да, авызын Акмырзаның колагына ук куеп:

– Без бернәрсә дә белмибез, кичтән үк ятып йокладык...

Котырык Муллагали зур гәүдәсе белән куышның авызын бөтенләй каплап басты:

– Сез, эттән туган нәрсәләр! Шушы көнгә хәтле нишләп ятасыз? – дип кычкырып җибәрде. – Үгезләрегез ындырдагы ашлыкны таптап бетергән. Бар, хәзер үк күземнән югалыгыз!

Акмырза ашыга-ашыга чабата бауларын бәйли иде. Ул, аптырап кына әйткән шикелле итеп:

– Менә, Иван Петрович һаман килмәгән, Муллагали абзый. Йоклап-нитеп калды микән әллә берәр җирдә? Без ул уятыр әле дип ята биргәнбез, – диде. Ә үзе тиз генә урыныннан кузгалып куыш эченнән чыкты һәм ындырга таба китте.

Акмырзаның әйткәннәре чын булырга да мөмкин иде. Андый хәлләр башка вакытларда да булгалап тора иде бит. Ләкин Муллагалинең күңеле нәрсәдәндер шикләнде. Акмырзаның тавышы артык тыныч һәм ышандырырлык иде. Ул, бер мәртәбә күз төшереп алу белән, Миңлебайның авыз кырыенда кечкенә, бик кечкенә генә елмаю, ниндидер мәгънәле һәм шатлыклы елмаю билгесе барын күреп калды. Янында торган урядникка карап, серле генә каш сикертте һәм ияге белән Миңлебайга таба ымлады да, үзе ындырга китте.

Куыштан чыгуга, Миңлебайның күзләре кояш нурларыннан чагылды.

– Бүген үгезләрне көтү кайсыгызның чираты иде? – дип сорады аңардан урядник.

Миңлебай, инде төшлеккә якынлашкан кояшка карап нык кына төчкереп җибәрде дә, Акмырзаныкы шикелле үк сарык тиресеннән тегелгән авыр ак чалбарын күтәреп куйды. Шуннан соң гына:

– Бүгенме? Бүген Акмырза агайның чираты, – дип җавап кайтарды.

Урядник Миңлебайның юри аңлап җиткермәгән булып кылануын сизеп алды. Ул, ачулы гына калын тавыш белән:

– Юк ла! Бүгенгең миңа нәрсәгә? Кичә, менә үткән төнне? – дип соравын кабатлады.

– Иван Петровичның чираты иде, менә бу үткән төнне, – диде егет.

– Ә ул хәзер кайда булыр?

– Кем белсен инде аны. Даладагы бүреләр белән ябалаклар гына белмәсә...

– Җитәр сиңа! Патша хезмәтендә торучы казак, имеш! Минем каршыда туры гына басып тор, сорауларыма әдәпле генә җавап кайтар. – Ул, җиз башлы юан камчысын һавада селтәп җибәрде дә: – Кая, куыш эчендәге әйберләрне чыгар әле монда! Жи-во! Барысын да чыгар! – диде.

Миңлебай карышмыйча гына куыш эченә кереп китте. Андагы үзенең чикмәнен, Акмырзаның каеры тунын, түшәк һәм мендәр урынына түшәлгән арыш саламын – һәммәсен дә берәм-берәм куыш авызыннан тышка ыргытып бетерде. Куыш эчендә ачы, чыдап булмаслык тузан күтәрелде. Миңлебай, күзләрен йомгалап, борынын учы белән каплый-каплый ачык һавага чыкты. Урядник бераз тузанның басылуын көтеп торды. Аннан соң, камчы сабы белән төрткәләп, куыш эченнән нәрсәләрдер эзләргә кереште...

Муллагали килеп, урядник белән нәрсәдер пышылдашып алды. Шуннан соң, читкәрәк китеп баскан Миңлебайга таба борылып:

– Сине станицага начиз уенына чакыралар. Иртәгә үк барырга. Хәзер авылга кайт, кирәк-яракларыңны әзерләп, җыенып куй, – диде. – Кич белән әллә кайларга китеп йөрмә, господин урядник синең белән сөйләшергә тели.

Миңлебай шунда ук үзән буенда курпы ашап йөргән атына таба ашыкты. Бу озын торыклы җирән кашканы атланып йөрү, аның белән уенга бару һәм һәртөрле сугыш һөнәрләренә өйрәнү өчен асрыйлар. Шул вакытларда аяктагы зур сабан катасын, боттагы калын һәм авыр тире чалбарны, өстәге

иске чикмәнне, баштагы тишкәләнеп-тузып беткән киез эшләпәне салып ташлау, алар урынына форма буенча тегелгән яңа һәм тәнгә җиңел киемнәр кию – болар барысы да Миңлебайда аерым дәрт һәм күңел ашкынуы тудыра иде. Мондый вакытта ул ничек тә Мәрьямне күрергә, җирән кашкасын матур гына уйнаткалап, Мәрьям торган өйнең каршысыннан, ягъни алар урамыннан үтеп китәргә тырыша. Бүген, менә хәзер генә авылга кайту аны бигрәк тә шатландыра. Ни өчен дисәң, Муллагали белән урядникның колак төбендә быжылдауларыннан азга гына булса да котылып тору иде бу. Шуның өстенә, Мәрьямне күреп сөйләшү мөмкинлеге иде. Аның белән аңлашырга кирәк иде. Нигә әле төнлә авыл егетләре Сабира белән Миңлебай турында җырлап йөри иде?

Миңлебай атын йомшак кына юырттырып олы юлга барып төшүгә, сул яктагы сукмактан Васильев килеп чыкты. Ул да үзенең хезмәт атын иярләп атланган иде. Олы юлның комсу тузанын тузгытып, аларның атлары янәшә юырта башлады. Миңлебай:

– Нихәл, дустым! Синең дә начизга юнәлешме? – дип сорады.

– Әйе. Үзегездә хәлләр ничек соң?

Ни өчендер, алар икесе дә кинәт кенә артларына әйләнеп карады. Анда, куыш әйләнәсендә, Акмырза сабанга үгезләр җигә, Муллагали белән урядник биек читәнле тарантас һәм кыңгыраулы атлар тирәсендә чуала иде. Миңлебай күңелле генә елмаеп куйды:

– Әмма утлы табага бастырдык та соң үзләрен!

– Димәк, барысы да шома гына үтеп китте? – дип сорады Васильев.

– Бу кадәр уңышлы чыгар дип һич тә уйламаган идем. Бигрәк кызык икән бу эш! Ләкин бездән әле каты гына сорау алачаклар. Нык торырга кирәк.

– Әлбәттә. Үз күзләре белән күрмәгәч, алар безгә бернәрсә дә эшли алмаячак... Безнең егетләрдән сүз чыга торган түгел. Акмырза гына нык булсын инде.

– Акмырзамы? Ул синең белән миннән дә хәйләкәр икән андый чакта...

Алар авылга якынлашты. Васильевка авылның руслар тора торган як яртысына борылып керергә кирәк иде. Ул, атының сул як тезгенен тартып:

– Ярый, хәзергә исән булып тор, – диде. – Иртәгә миңа тукталырсың, бергә китәрбез.

Миңлебай аңа җавап кайтарырга өлгермәде. Уң яктагы киң урамнан Мәрьям узып бара иде. Әнә, кызу-кызу гына атлап, ул Хәнифә ахирәтенең өенә якынлашып килә. Миңлебай аны чачаклы зәңгәр шәленнән, яшькелт күлмәгенең гармун итәген җилбер-җилбер китереп вак-вак кына атлап баруыннан һәм, гомумән, озын гына зифа буй-сыныннан танып алды. Миңлебай аны куып җитәргә һәм бер генә авыз булса да сүз кушып үтәргә теләде. Һәм ул, атын кинәт кенә уңга борып, Мәрьям артыннан китеп барды. Тезгеннәрен тарткалап, аякларын тибенеп атын куды. Җирән кашка кызу гына җилә башлады һәм, ат өстендә утырган кешесе тукталыбрак өч-дүрт мәртәбә сулыш алган арада Мәрьямне куып та җитте.

– Сиңа хәерле юл булсын, Мәрьям, хәлләрең ничек?

Кызу гына чабып килгән ат, кинәт туктаган уңайга борылып китеп, кызның каршысына чыкты да, үзенең биек озын гәүдәсе белән аның юлын кисте. Мәрьям дә тукталып калды. Шулвакыт, терсәге селкенеп китеп, аның шәл почмагы бик аз гына ачылды; Миңлебай кызның курку һәм ачудан агарынган йөзен, калтыранып торган юка гына яфрак иреннәрен күреп калды.

Мәрьям:

– Сездән хәл сорарга калган көнебез юк әле! Юлыгызда булыгыз! Нәрсәгезгә мине кешеләр алдында көпә-көндез мыскыл итәсез? – диде.

– Мәрьям! Син нәрсә сөйлисең? Бу нинди хәл?

– Бернинди хәл дә түгел. Зинһар өчен, үз юлыгызда гына булыгыз!

– Тукта әле, Мәрьям, син аңлап сөйләшәсеңме?

– Мин барысын да белеп сөйләшәм.

Мәрьям, гармун шикелле сырланып-сырланып торган озын һәм киң күлмәк итәге белән тузан тузгытып борылды да, киредән әле генә үзе килгән якка таба китте. Миңлебай аның зәңгәр белән каеп чигелгән өр-яңа сары читегенең үкчәсен генә күреп калды.

Бу нинди хәл? Бу Мәрьямнең Миңлебайны кимсетеп шулай кылануымы? Гөл чәчәге шикелле булып киенгән чибәр кызның малайлыкта йөреп үскән ярлы Миңлебайны, аның сарык тиресеннән тегелгән шыксыз калын чалбарын, тупас кына киндер күлмәген һәм тузып беткән киез эшләпәсен мыскыл итүе һәм хурлавымы? Әллә, узган төндә булган хәлләр, берәрсенең аны, бәлки, Котырык ишегалдында күрүе аркасында туган гади бер аңлашылмаучылык кынамы? Кыскасы, Миңлебай артык нәрсә дип әйтергә, Мәрьямнең бу кыланышын ничек итеп аңларга да белмичә аптырап калды. Әмма җирән кашка Миңлебайның исен-акылын җыюын һәм нинди дә булса берәр фикергә килүен көтеп тормады. Ул, егетнең тезгенне ычкындыра төшүеннән файдаланып, урам буенча чабып китте.

## 11

Атасы Хисамый ягыннан Миңлебайның бердәнбер якын туганы Фатыйма иде. Аның, Герьял станицасы егетенә кияүгә чыгып, авылдан китүенә җиде-сигез ел тула инде. Ләкин ул ире белән рәхәтләнеп, бәхетле кешеләр шикелле тигез тормыш итә алмады. Моннан дүрт ел элек аның ирен хезмәткә алдылар. Өч елы тула, озакламый кайтыр инде, дип көтеп торганда гына, Япония белән Россия арасында сугыш башланып китте. Ул сугышка Фатыйманың ирен дә озаттылар. Фатыйма өчен ачы кайгы һәм авыр хәсрәт көннәре килде: ике-өч ай да үтмәде, иренең үлүе турында хәбәр алды...

«Начиз» көннәрендә Миңлебай әнә шул Фатыйма апасында торды. Бүген ул соңгы бер ай эчендә беренче мәртәбә яхшылап ял итте. Ул, урманнан утын кисеп кайткандагы шикелле арып, аерата каты һәм тыныч йоклады. Ул Фатыйма апасының иртә белән иртүк торуын да, мичкә ягып кабартма пешерүен һәм күмәч салуын да, гөжләтеп самавыр куеп җибәрүен дә сизмәде. Самавырын кайнатып мич алдына куйгач, Фатыйма Миңлебайның тәмләп һәм рәхәтләнеп йоклавына сокланып карап торды. Һәм аны беркадәр иркәләгән йомшак тавыш белән генә:

– Тор инде, энем, Миңлебай! – диде.

Егет апасының сүзләрен беренче әйтүендә үк ишетте. Ләкин аның шунда ук торасы килмәде. Ул – апасы тарафыннан әйтелгән сүзләрнең, күңелгә шулай ягымлы һәм колакка шундый йомшак тавыш белән әйтелгән иркәләү сүзләренең, яңадан кабатлануын теләп, ул аны балаларча өмет итеп көтә иде. Һәм ул күзләрен ачмый гына киерелгәләп, сузылгалап куйды. Фатыйма апасы бу иркәләнүләрнең тәмен, ләззәтен белә; моның ул бик тыныч, үз хәленнән үзе канәгать чакларда гына була торган иркәләнү икәнен аңлый иде.

* * *

Моннан бер ай элек кенә әле Миңлебай гаять кайгылы һәм күңелсез иде. Ул вакытларда Миңлебай рәтле-башлы йокламый да, кирәгенчә ашамый да иде. Ул Мәрьям кайгысыннан, үзе белән Мәрьям арасында чыккан аңлашылмау аркасында шундый булды. Китәр алдыннан саубуллашырга дип үз өйләренә кайткач, аны анасы белән атасы да тиргәп, өйдән куып дигәндәй чыгарып җибәрделәр. Анасы Мәгузә, Миңлебайның йөрәгенә агулы ук булып кадалырлык итеп:

– Оятсыз ук икәнсең, балам! Мин сине бу кадәр өметсез булырсың дип бер дә уйламаган идем. Ул Котырык Сабирасы, кырык мирдән калган сөйрәлчек, синең ни җаныңа хаҗәт булды? Үз балам булсаң да, синнән бигрәк Мәрьям җанашымны кызганам. Шундый акыллы, шундый инсафлы кыз! Ничә еллардан бирле сине көтеп утыра бит. Бер абруйсыз кешенең баласы булса, йөз мәртәбә аты-чабы чыгып бетәр иде инде. Көн саен килеп торган яучылар аның бусагасын таптап туздыралар бит инде, – диде. Шуннан, күз яшьләрен яулык почмагы белән сөртә-сөртә дәвам итте: – Шулкадәр якын, шулкадәр үз булып китте бит ул безгә, җанашым! Бүгеннән үк килен, дип әйтергә дә риза идем үзенә... Кызым, Мәрьям кызым, дип кенә йөртермен кебек уйлап йөри идем. «Алла бирсә» дип әйтмәгәнмен, күрәсең дә, уйларым фәрештәләрнең «амин» дигән чакларына туры килмәгән икән.

Миңлебай анасына йөрәген ярып салырга һәм үзенең гөнаһы юклыгына антлар эчәргә әзер иде, ләкин ул эчке серләрен, яшертен түгәрәк эшләренә бәйле булган хәлләрне аңа сөйләп бирергә һич тә булдыра алмады.

Йокысыз төннән соң Миңлебай, аш өендәге ялчы хатыннан күмәч, сөт алып ашады да, башка вакыттагы кебек Муллагали белән саубуллашып-нитеп тормастан, тиз генә атын иярләде һәм атланып капкадан чыгып та китте. Җирән кашка, башка вакытларда өйрәнгән гадәтен саклап, күл буе урамы белән китеп барды. Ләкин бераздан Миңлебай аны сулга тартты. Бүген ул, гомерендә беренче мәртәбә, ата-анасыннан хәер-дога алып китәргә теләмәде. Бүген ул туры Мәрьям тора торган урамга юл тотты. Аның йөрәге Мәрьямне, шул акыллы һәм чибәр кызның бер генә мәртәбә елмаеп каравын күрәсе килеп ашкына иде. Башка вакытларда аны Мәрьям йә капка төпләрендә басып көткән килеш, йә пәрдәсе күтәрелгән тәрәзәдән карап озата торган иде. Бүген Мәрьям үзләренең капка төпләрендә дә тормый, аның тәрәзә пәрдәсе дә күтәрелмәгән. Миңлебай алар өе турыннан атын атлатып кына узды, ләкин ул Мәрьямнең шәүләсен генә булса да күрә алмады. Бу хәл аның хәсрәтен арттырды, кемдер аның йөрәген чеметеп-чеметеп алгандай булды. Аңа, бу кайгыны азрак онытып тору һәм җиңеләйтә төшү өчен, юлдагы тузан-туфраклардан өермәле буран тузгытырга, атының тоякларыннан очкыннар чәчрәтеп чабарга кирәк кебек тоелды. Менә ул хәзер, атын уңга борып, Лор-лор тыкрыгы дип аталган тар гына тыкрыкка керәчәк... Әмма Миңлебай атына камчы белән селтәнә алмый калды. Тыкрык уртасында басып торган Мәрьямне күреп, югары күтәрелгән камчысын кире төшерде. Көтүгә сыер куа барган Мәрьям, Миңлебайның шушыннан үтәсен белеп, бу аулакта аны көтеп тора иде. Ләкин ул үзенең көтеп торуын сиздерергә теләмәде. Миңлебайны күрү белән, ап-ак алъяпкычын җилфердәтеп, тыкрыкның бу башына таба килә башлады. Егет, атын кызу-кызу атлатып, кызга таба китте. Барып җиткәч, үзе дә сизмәстән «сез»гә күчеп:

– Исәнмесез, Мәрьям?! – диде.

Атын кинәт кенә борып, кыз белән янәшә бара башлады. Мәрьям аңа һичбер сүз әйтмәде. Ләкин ул артык дулкынланудан кызарган йөзен дә, яшь белән юешләнгән озын керфекләрен дә Миңлебайдан яшермәде. Аның дебет шәле җилкәсенә төшкән, сары кәшимир яулыгы чәч толымнары астыннан артка каерып бәйләнгән. Чәчүргеч башындагы көмеш тәңкәләре атлаган саен челтер-челтер тавыш биреп бара, аның кечкенә генә колакларында зур көмеш алкалар селкенгәли. Аның йөзе саргайган, күз төпләре эчкә баткан. Йокысыз үткән төн йогынтысы аның моңсу һәм хәлсез күз карашларында да чагыла. Миңлебай аңа кызганып карап куйды. Аннан соң:

– Мәрьям, сез миңа юкка гына үпкәлисез, – дип сүзгә кереште. – Минем күңелемдә тырнак очы кадәр дә кер юк...

Мәрьямнең сөйлисе сүзләре бик күп, ләкин аның елыйсы, башын Миңлебайның күкрәгенә салып, үксеп-үксеп елыйсы килә һәм хәзер ул бер генә авыз сүз дә әйтә алмый иде.

Миңлебай:

– Менә бит ул ничек килеп чыкты, мин кичә дә синең янга бара алмадым, – дип сүзен дәвам итте. – Мине кичтән үк урядник чакыртып алды. Ул мине төн буенча яныннан җибәрмәде... Аның Иван Петрович турында нәрсәдер беләсе килә...

Мәрьямнең йөзе яктырып киткәндәй булды. Шуннан соң ул сулык-сулык елый башлады. Шәлен башына күтәреп куйды һәм аның белән йөзен каплап:

– Мин сине бүген төн буенча көттем... Тагын шул Сабира белән чуалып калуыңдыр дип уйлаган идем. Алайса, син урядник янында гына булгансың икән? – диде.

– Нишләп алай дисең, Мәрьям? Урядник янында булу бик үк күңелле хәл түгел бит ул.

– Күңелле булмый бирсен. Шулай да урядник сине миннән аера алмас. Тик менә, Миңлебай, синең Сабира белән чуалуыңны да дөрес дип әйтәләр бит әле. Алай бай кызлары белән чуала башлагач...

Кешеләр йөрми торган тар тыкрык бетеп, егет белән кызны адым саен тәрәзә һәм гайбәт күзәтеп торган киң урамга килеп чыктылар да, аларның сүзләре шул урында киселеп калды... Миңлебай атын киредән тыкрык эченә таба борды, Мәрьям аны моңсу гына баш иеп озатты...

Станицага баргач, Миңлебай атна буенча күңелсезләнеп йөрде. Фатыйма апасы аның кайгысын уртаклашырга теләсә дә, Миңлебай аңа үзенең эч серләрен сөйләмәде. Ул һәрвакыт үз эченнән генә янды һәм шуңардан ниндидер тәм-ләззәт тапты. Ләкин бу хәл бер атнага кадәр генә шулай сузыла алды. Аннан соң Миңлебайда үз башында гына кайнаган уй һәм фикерләрне кемгә булса да сөйләү, ачыктан-ачык әйтеп бирү, ул кешедән ниндидер киңәш-фәлән алу теләге туды. Шуның өстенә, бу соңгы «начиз» уены булып, озакламый алар өч еллык хезмәткә алынырга тиеш. Бу турыда сүзләр көннән-көн куера башлады... Димәк, Мәрьямгә өйләнәм, хезмәткә кадәр туй үткәреп китәм, дип йөргәндә генә, аны үпкәләгән һәм рәнҗегән хәлендә калдырып китәргә туры килә.

* * *

Миңлебай үзенең эчендәгеләрне Фатыйма апасына ачып салды. Апасы, аны баштанаяк тыныч кына тыңлап утырганнан соң:

– Әй, энем, шушы көнгә кадәр әйтмичә, юкка гына үз-үзеңне уй белән бетереп йөрисең икән, – диде. – Мәрьям моны гына аңламый торган кызмы

инде. Синең серләрең минем дә, аның да серләре булыр. Безгә Мәрьямне генә ныгытып алырга кирәк. Ата-анасын ул үзе күндерер...

Яхшылап юынды һәм киенде-ясанды да, Фатыйма шул көнне үк Яңа Чиркас авылына китте. Миңлебайга озак көтәргә туры килмәде. Ике көн үтеп өченче көн дигәндә, апасы әйләнеп тә кайтты. Аны, Җәләй картның җирән чабышкысын җигеп, Җәләй белән Хисамый үзләре озата килгәннәр иде.

Картлар, ишектән керә-керешкә үк уен-көлкеле сүзләр әйтеп, Миңлебай белән күңелле генә исәнләштеләр. Чәй янында аның хәлен, ничек-ничек хезмәт итүен сорашып белделәр, яхшы хезмәт итүе өчен рәхмәт әйттеләр. Кояш күптән баеп, вакыт шактый соң булуга карамастан, картлар икәүләшеп станица атаманы янына киттеләр. Атаманның кәефле чагы туры килгән, күрәсең. Шул ук вакытта Хисамый картның күчтәнәче – ул алып килгән ике каз да, Миңлебайның бик яхшы хезмәт итүе дә үз тәэсирләрен ясаган булса кирәк. Атаман картларның үтенечен җиренә җиткергән. Хезмәткә китәр алдыннан туй үткәреп алу өчен картлар Миңлебайны эштән бушатуны сораганнар иде. Станица атаманы моның өчен бер ай вакыт биргән.

Бу хәл моннан егерме көн элек булды. Шуннан соң озакламый Миңлебай Мәрьямнән шатлыклы-куанычлы хат та алды...

Менә шул-шул хәлләрдән соң гына Миңлебайның чиксез шатлануы, үзе өчен дөньяның бер генә дә китек урыны калмаган кебек итеп, үзен-үзе тыныч тота, кичләрен каты йоклый башлавы Фатыймага бик билгеле иде. Шулай ук бу тынычлыкның артык озакка сузыла алмавын, егерме дүрт яшенә җиткән егетнең үз гомеренә беренче мәртәбә килгән һәм фәкать вакытлыча гына булган шатлык икәнен дә Фатыйма, ничектер йөрәге белән сизенеп аңлый. Шунлыктан да ул Миңлебайны һәрвакыт иркәләргә, шәфкатьле ана шикелле үк итеп аны юатырга, аның шат һәм тыныч күңеленә һичбер кара тап төшермәскә тырыша. Ул, кулыннан килгән кадәр, энесе янында үзен шат һәм күңелле тота; һәрвакыт Мәрьямне искә алып, аның йөзенә шунда ук яктылык бирә торган сүзләр сөйли. Ул, еш-еш кына үзенең Яңа Чиркас авылына кайтуын һәм Мәрьям белән сөйләшүләрен исенә төшереп:

– Куйсана, Ходай үзен яман күздән генә сакласын инде! – ди. – Бу кадәр дә уңган бала булыр икән! Үземне өрмәгән җиргә утыртмады, иясен яратсаң, этенә сөяк ташла, дигәндәй, күрсәтмәгән хөрмәте калмады. Авызымдагы сүзләремне, мин әйткәнче үк суырып алып, йотардай гына булып тора... Кая ул курку! Миңлебай белән бергә булсам, утына керергә дә, суына төшәргә дә риза, «уф» дип тә әйтмәм, сыртым сынса да, дошманнарыма сынатмам, дип тик тора.

Миңлебайның урыннан тормыйча иркәләнеп ятуын күргәч, Фатыйма әнә шуларны хәтерләп алды. Һәм ул, инде өченче мәртәбә кабатлап:

– Тор инде, энем, тор! Соңга калып куйсаң, үзеңә яхшы булмас, – диде. Аз гына уйланып торганнан соң, елмая төшеп: – Әй, хәтерең коргыры, исемнән дә чыккан икән. Менә, Мәрьямнән тагын хат килде, әле яңа гына китереп киттеләр, – дип өстәде.

Миңлебай өстенә ябынган юрганын тезләре белән күтәреп җибәрде дә тиз генә торып та утырды. Аннан соң, күңелле генә елмаеп:

– Нәрсә, түти? Мәрьямнән хат дисеңме? Әллә юри генә шаяртып әйтәсеңме? – дип сорады.

– Нишләп юри генә әйтим? Менә, хат бар.

Миңлебай аның кулындагы иске генә сары кәгазь төргәгенә йотлыгып карады, һәм аңа Фатыйма апасы юри акрын сөйли кебек аңлашылды.

– Авылдан Лор-Лор Ситдыйк килгән икән, шуның Сәрвәре артыннан биреп җибәргән... Йә, сөенечкә нәрсә бирәсең?

Фатыйма бу сүзләрне сөйләп бетергән вакытта Миңлебай ике балагына да буйлатып зәңгәр тасма тоткан яшькелт чалбарын, артык тупас булмаган казак итеген киеп тә өлгергән иде инде. Ул, мич алдындагы калай комганны алды да, сөенечкә яулык алып бирәчәге турында апасына вәгъдәләр бирә-бирә, эчке күлмәктән генә ишегалдына чыгып китте. Фатыйма:

– Ай, энем, өйдә ләгәндә генә юын! Тышта бүген салкын, кар яуган, – дип кычкырып калды.

Миңлебай, өйгә кергәч, өске күлмәген киде һәм биленә каеш буып куйды. Фатыйма аның кайчан да бер яулык алып бирүенә каршы түгел иде. Ләкин, әнә шул булачак яулыкка өстәмә рәвештә, аның хәзер үк биеп алуын сорады. Миңлебай моңа да каршы килмәде. Фуражкасын сул яккарак кырын салып киде дә, уң як чигәсенә тузгып төшкән куе коңгырт чәчен тиз-тиз генә сыйпаштырып, авыз эченнән үз-үзенә такмак әйтеп, кулларын селеккәли-селеккәли биергә кереште. Биеп туктавы белән үк апасы аңа хатны китереп тоттырды.

Хат шактый калын иде. Ул чит-читләреннән һәм урта бер җиреннән ак җеп белән теккәләп куелган. Кара яки сары җеп белән түгел, ә бәлки ак җеп белән тегелүе, бу инде, хатның бик зур шатлыклы хәбәрләр китерүен аңлата. Хатның бер ягына: «Ошбу хат тапшырылса иде Миңлебай Гомәревнең үз кулына», – дип язылган.

Дөньяда иң яраткан һәм өзелеп сөйгән кешесеннән килгән кадерле хатны мондый ашыгыч арада гына укуның бер дә тәме, күңелендәгечә ләззәте булмас кебек тоелды. Шунлыктан, хатны күкрәк кесәсенә салды да, атын карап керү өчен, Миңлебай яңадан ишегалдына чыгып китте.

Беренче кар яуган төннең иртәсе бик матур, һавасы саф, җиле йомшак һәм җылы иде. Табигатьнең бу матурлыгы Миңлебайның шатлыгын тагын да үстереп, йөрәгендәге ашкынулы дәрт хисләрен берничә мәртәбәләргә арттырып җибәргәндәй булды. Ул ниндидер бер җиңелчә көйгә сызгырынып лапаска кергән вакытта җирән кашка тиз генә башын күтәрде; аякларын тыпырчындырып, колакларын уйнаткалап куйды; иреннәрен калтыратып, йомшак кына аваз белән тавыш бирде: бу аның су эчәргә теләвен аңлатып куюы иде. Миңлебай аның маңгаеннан, аркасыннан, ботларыннан сыйпаштырды. Муеныннан ипләп кенә кочаклап алды да, үзалдына уйнаклап һәм селкенгәләп торган колакларын, әйе, аларның әле берсен, әле икенчесен үпте. Акрын гына пышылдап: «Рәхмәт сиңа, малкай!» – дип куйды. Җирән кашканы кичәге иң катлаулы һәм авыр сикереш вакытында беренчелекне алганы өчен кадерләү иде бу.

Миңлебай атын ишегалдына алып чыкты. Бер кулын чалбар кесәсенә тыккан, ә икенчесе белән озын каеш тезгеннең очыннан тоткан килеш, җирән кашка өчен күптәннән таныш бер көйгә сызгыргалап торды. Җирән кашка озак ялындырмады, күпереп торган йомшак кар өстенә ипләп кенә ятты да, рәхәтләнеп, аякларын селкә-селкә ыңгырашып ауный башлады... Аунап туйганнан соң торды. Аякларын җәя төшеп, бөтен гәүдәсе белән селкенеп куйды – өстендәге кар һәм балчык кисәкләре кагылып ташланды. Миңлебай, аны сугарыр өчен, күлгә алып төшеп китте.

Миңлебай эшләрен бетереп өйгә кергән вакытта сәкегә кызыл шакмаклы ашъяулык җәелгән, аның өстенә самавыр һәм кечерәк агач табакны тутырып кабартма утыртылган иде инде. Фатыйма, кабартманы Миңлебай утырасы урынга табарак этәреп:

– Йә, энем, утыр! Җылы көенчә генә ашап алыйк әле, – диде. – Әйдә, син үзең сындыр инде, ир-ат барында хатыннарга көлчә сындырып утыру килешми ул.

Миңлебай, кайнар кабартманы сындыра-сындыра:

– Түти, сиңа бик зур рәхмәт инде... Җылы күмәчең дә булгач, көлчәсен пешереп тормасаң да яраган булыр иде, – диде.

– Аша, энем, туйганчы аша. Бар вакытта сыйлап калыйм әле.

Кабартмаларны тагын да егетнең алдынарак этәреп, майлыракларын астан алып өскә куйды. Аннан соң:

– Хатыңны укыдыңмы соң әле? Авылда нинди яңалыклар бар дигән? – дип сорады.

Миңлебай Мәрьямнең хатын шулай озак укымавы өчен апасы алдында уңайсызланып куйды. Аның түгәрәк йөзенә алсу кызыллык йөгерде.

– Мин ул хатны иркенләбрәк укырмын дигән идем, түти.

Чәйдән соң Миңлебай хат укырга утырды. Хатның җепләрен тешләре белән өзә-өзә, аның байтак вакыты узды. Бу арада Фатыйма самавырын алып куйды, чынаякларын кайнар су белән чайкады; аларны кызыл шакмаклы тастымал белән сөртә-сөртә:

– Бигрәк тә инде, бер дә кеше ачып укырлык итмәгән, – диде.

Хат бер дә иренмичә һәм күп итеп язылган. Аның чит-читләре чәчәксыман кәкре-бөкре кызыл һәм ал сызыклар белән бизәлгән. Фатыйма, моны күреп:

– Һай, җан кисәгем, иннек буяуларына кадәр калдырмыйча буяп бетергән икән, – дип куйды.

Миңлебай хатны игътибар белән генә укый башлады...

...Сәлам хат, хуп күрсәң, укып бак, хуп күрмәсәң, утка як, – дип, гадәттә һәрбер хатта була торган баш куелган иде. Аннан соң: – Сезки гыйззәтле вә хөрмәтле күрүче җанкаема, безки сезләрне бер күрергә зар вә интизар булып, сезнең өчен көн-төн утлар йотып, бик сагынып вә бик саргаеп торган җанкаеңнан күптин-күп вә янә чуктин-чук сәламнәремне күктәге йолдызлар, җирдәге чәчкәләр санынча итеп, иртәнге искән салкынча җилләр белән син җанашым торган Айгырҗал станицасына таба очырып җибәрәм, – дип сәлам бүлеге язылган. Аннан соң: – Әй, җанашым, энҗе ташым, каләм кашым, син җанымның дәвасы, ике күзем карасы, йөрәгемнең пәрәсе, син былбыл кош баласы... кебек сүзләр белән егетне мактау бүлеге дәвам иткән. Боларның барысыннан соң бик күп итеп җырлар язылган. Хатның иң ахырында, онытып калдыра язганы өчен бик-бик гафу үтенеп, һәр ике якның да кызу-кызу туй хәзерлеге алып баруын, шушы көннәрдә генә атасы Җәләй белән Миңлебайның атасы Хисамыйның Оренбург шәһәренә барып, аннан туй кирәк-яраклары җитештереп кайтуларын әйтеп язган.

Миңлебайның бу хатны укыгач туган шатлыгын язып та, сөйләп тә бетерә алырлык түгел иде. Ул, күзләрендәге шатлык яшьләрен туктатып кала алмаганы хәлдә, Фатыйма апасыннан уңайсызланып, тиз генә ишегалдына чыгып китте.

## 12

Кояш, һаман саен яктырак балкып, акрын-акрын гына югары күтәрелә. Ләкин яңа яуган йомшак карлар аның иркәләвен һич тә күтәрә алмый. Кояш ягымлырак елмаеп, ул йомшаграк караган саен, аяк астындагы карлар да юкарганнан-юкара һәм соргылт комсу җирнең куенына һаман ныграк сеңә бара.

Станица йортларының төрле капкаларын ачып, аның киң урам яки тар гына тыкрыкларыннан атларын юырттыра-юырттыра, уеннар мәйданына казак

яшьләре җыела. Алар, үз урыннарын үзләре белеп, килә-килешкә үк сафка тезеләләр. Аларның һәммәсенең дә сул ягында ияр өзәнгеләренә тиеп-тиеп торган ялтыр кара кыннары, ул кыннар эчендә үткен корыч кылычлары бар. Ул кылычларның сары җиз саплары кояш нурларында җем-җем итеп елкылдап тора. Саф каршында, әле берсенә, әле икенчесенә бәйләнеп һәм өсте-өстенә төрле приказлар биреп, зур гәүдәле биек кара айгырга атланган сотник йөри. Мәйданның бер кырыеннан икенче кырыена кадәр, кара-каршы ике саф итеп нечкә сыек таллар утыртып чыгылган. Тамаша белән кызыксынучы карт-коры һәм бала-чагалар мәйдан тирәсендәге өй һәм таш коймалар яныннан карап тора.

Мәйдан станица атаманын көтә. Тынлыкны бозып, анда да монда чапкалап торучы сотник айгырының тояк тавышлары гына ишетелә; үзен бөтен мәйданга хуҗа итеп сизгән сотникның карлыккан тавышы әле бер, әле икенче урында яңгырап кала.

Атаман кызыл калай түбәле биек агач йортлар ягыннан килеп чыкты. Ул, мичкә кебек түгәрәкләнеп кабарган корсагын көч-хәл белән генә күтәреп, сөт шикелле ап-ак бия өстендә утырып килә. Атаманның уң һәм сул якларында берәр офицер, алар артында дүрт-биш казак булып, болар һәммәсе дә уйнаклап торган таза бияләргә атланган. Һәммәсенең дә бияләре, атаманныкы кебек үк, ап-ак.

Боларны күреп, сотник аптырап калды. Ни өчен атаман бүген генә биягә атланып чыккан? Башка вакытларда ул йә җирән айгырга, яки кара туры кашкага атланып чыга иде бит. Бүген әллә ул сотник өстеннән шаяртып алырга уйлаганмы? Ләкин сотник өчен башка һичбер чара да юк иде инде. Ул, ажгырып торган көчле айгырының тезгеннәрен нык кына тартып тотты да, бөтен саф буенча:

– Смир-рно! – дип боерды.

Сафка тезелгән атлар да, алар өстендәге казаклар да торган урыннарында катып калды. Сотник, айгырның корсагын шпорлары белән тиз-тиз кытыклап, үзен мәйдан уртасында көтеп торган атаманга таба чаптырып китте. Ул, атаманга берничә метр җитмичәрәк туктап, сотняның әзер булуы турында белдерергә тиеш иде. Ләкин ул кирәкле урында тукталып кала алмады. Аның айгыры, алгы һәм арткы аяклары белән дулап, бөтен мәйданны тутырып кешнәп җибәрде дә атаманның биясе өстенә ыргыла башлады. Таза гәүдәле, калын җилкәле сотникның айгырга көче җитми иде. Моңа атаманның ачуы кабарып китте. Ул, кулындагы җиз очлы юан каеш камчысы белән башта айгырның нәкъ маңгаена, аннан соң сотникның аркасына сугып җибәрде.

Сафта торучылар кинәт кенә җанланып, бер-берсенә карашып алдылар. Озын буйлы, чибәр йөзенә ниндидер өстәмә матурлык биреп торучан зур кылыч борынлы Васильев Миңлебайга таба башын һәм фуражка козырёгын кагып куйды. Миңлебай аның уйларын, ул моны сүз белән әйтмәсә дә, кояш кебек балкып торган йөзеннән укып белде.

Станицага җыелган яшь казаклар арасында Миңлебай ай буенча беренчелекне алып килде. Моңа бай балаларының ачулары чыга һәм аларның көнчелек тамырлары өзлексез рәвештә кузгалгалап тора иде. Ләкин берсе дә Миңлебай кулындагы алдынгылыкны ала алмады. Шулай да бай малае Михаил ара-тирә беренчелекне алгалап куя. Сотник исә һәрвакыт Михаилны яклый, ничек тә беренче урында итеп аны күрсәтергә тырыша. Бүген таллар кисү номеры үтәләчәк. Бу – актыккы сбордагы соңгы уен, һәм ул атаман күз алдында эшләнә. Шушы соңгы уенда өстен чыккан кеше барлык өч ел буенча да беренче булып килгән исемен алачак. Васильевның Миңлебайга башы белән

ымлап куюы һәм чын күңелдән елмаеп каравы: «Но, туганкай, булды! Хәзер инде атаман сотникның сүзләренә колак та салмаячак. Кара аны, беренчелекне бүген дә син алырга тиеш», – дигән мәгънәне аңлата иде.

Сотник яңадан казаклар янына килде. Ул ачулы һәм көлке бер кыяфәттә. Ләкин казаклар, ул инде үзе килгәч, аңардан ачыктан-ачык көлә алмыйлар, бары тик эчтән генә кеткелдиләр иде. Бу аларның шаян якты йөзләреннән, көлемсерәп ерылган авыз кырыйларыннан, бер-берсенә күз очлары белән генә карашып куюларыннан аңлашыла. Сотник моны үз күзләре белән күрә һәм бөтен йөрәге белән сизенеп тора. Ул, башка берәү дә түгел, монда сотник Петров үзе, бары тик ул үзе генә хуҗа икәнлекне тагын бер мәртәбә кисәтеп куярга теләгәндәй, бугазының төбеннән карлыгып чыккан калын тавыш белән кычкырып җибәрде:

– Сот-ня-я!.. Марш-ма-ар-рш!.. Стой!

Тал кисү уены башланып китте. Михаилга кадәр бу эшне берсе дә яхшы итеп үти алмады. Кайберләре бер-ике талны кисеп өлгерә алмый үтеп китә; икенчеләре артыннан тал утыртылган агач станнар аугалап кала; өченчеләре талны тиешле урыннан йә югарырак, йә түбәнрәк кисәләр. Менә чират Михаилга җитте. Ул, үзенең ак бәкәлле җирән атын уйнаткалап, башкалардан аерылып чыкты. Кылычын кыныннан тиз генә суырып алды да, аны тантаналы кыяфәттә югары күтәрде. Ак бәкәл өчен артык бернәрсә дә кирәк түгел иде инде: ул шунда ук чабып таллар арасына кереп китте. Михаил баштан ук атаманга ошап куйды булса кирәк. Башкаларга ул күзенең кырыен-кырыен гына төшергәләп ала иде. Михаилның берничә селтәнүе булды, атаман аны җентекләбрәк күзәтә башлады. Сотник та җанланып һәм канатланып киткәндәй булды. Әйе, әгәр дә ул ахырга кадәр шулай уңышлы итеп үтәп чыга алса, беренчелекне Михаил алачак; сотник аны теше-тырнагы белән яклаячак, атаман да моңа каршы килмәячәк. Ләкин аларның бу шатлыклары артык озакка бара алмады. Михаилның кулы, ничектер, калтыранып куйды; аның кылычы, йөзе белән түбән әйләнеп, бик аз гына үзенең юнәлешен үзгәртте дә, ак бәкәлнең сул колагын кисеп үтте. Моңа Михаилның шулкадәр ачуы килде ки, аның тик бер генә талны кисәсе калган иде, ул аны кисеп тә тормады. Кылычын туп-туры итеп югары күтәрде дә, атын тагын да ныграк чаптырып үтеп китте. Ак бәкәлнең киселеп төшкән ярты колагы тояк эзендәге пычрак кар суына батып калды.

Атаман бу хәлләрне башыннан ахырына кадәр карап торды. Ул, ачуыннан кемне дә булса кыйнап ташлар инде, дип көткән вакытта, бөтен гәүдәсе белән селкенеп һәм һич тә тыела алмыйча көлә башлады.

Сафтагы казаклар да шаулашып көлешәләр иде...

Чират Миңлебайга да җитте. Ул, сотник приказы буенча башкалардан аерылып чыгып, киселәчәк таллар тезмәсенә якынлашты. Кылычын кыныннан суырып алып югары күтәрде. Корсагын итек үкчәләре белән кытыклап алуга, җирән кашка йомылып алга чапты. Миңлебайның уң кулындагы авыр кылыч, җиңел генә уйнаклап, бер уңга, бер сулга селтәнә башлады. Җирән кашка үткен кылычның бер яктан икенче якка селтәнү ритмына шунда ук җайлашып алды. Ул, беленер-беленмәс кенә, башын әле бер якка, әле икенче якка авыштыргалап барды. Аның муены һәм башы алга сузылган, колаклары тигез генә сыланып артка ятканнар; корсагы нык кына эчкә тартылып, ул үзе бөтенләй нечкәреп калган. Миңлебай актык талны чабып өзгәнгә кадәр ул шулай барды.

Мәрьямнең хаты, Васильевның һаман дәртләндереп йөрүе һәм әле генә

Михаилның көлкегә калуы – болар һәммәсе дә Миңлебайның күңелен үстерде, аның үз-үзенә ышанычын ныгытты.

Менә Миңлебай иң соңгы талны кисеп үтте. Аны түземсезлек белән карап торган атаман, камчысын һавада кискен генә селтәп, нәрсәдер кычкырып җибәрде. Сотник саклык белән генә атаманга якынлашты. Атаман аңа:

– Гомәровны минем янга! – дип боерды.

Миңлебай шунда ук атаман янына килеп тә җитте. Атаманның кулында көмеш саплы яхшы кылыч иде. Ул, күзнең явын алырдай булып елкылдап торган кыйммәтле кылычны Миңлебайга сузып:

– Менә бу миннән бүләк булыр, – диде. – Киләчәктә бөек патша хәзрәтләренә турылыклы, аның дошманнарына каршы рәхимсез булуыңны телим.

Миңлебай атын атаманга якынрак китерде. Көмеш саплы кылычны бер кулы белән генә алды да, аны күкрәгенә кысты һәм башын иде. Ләкин ул бүләк кылычын үпмәде һәм бер генә авыз сүз дә әйтмәде. Атаманга Миңлебайның ант итеп вәгъдә бирмәве дә, авыз кырые белән генә көлемсерәп куюы да, үзен-үзе тәкәббер тыныч кыяфәттә тотуы да ошамады.

Бу хәлләр атаманны айнытып җибәргәндәй итте. Хәтта ул үзенең исерек баштан сотник өстеннән шаяртулар оештыруыннан үкенеп куйды. Бүләкне бит, һәрвакыттагыча, тантаналы рәвештә саф алдында бирергә иде. Менә шунда Миңлебай ант итеп вәгъдә бирмәсен һәм кылычны үпми калсын иде әле! Ул вакытта күрсәтер иде атаман аңа...

Атаманның миеннән әнә шундый кайнар уйлар йөгерде. Хәтта ул, кулларын Миңлебайга таба сузып, әле генә биргән бүләк кылычын кире тартып алудан көчкә-көчкә генә тыелып калды. Ләкин хәзер соң һәм эш беткән иде инде.

Атаман, камчысын ачу белән һавада селтәп, күк биянең алгы ботына каты итеп сукты да чаптырып кайтып китте. Янындагы офицер һәм казаклар да аңа иярде.

## 13

Миңлебай шул көнне үк кайтырга чыкты. Төрле-төрле уйларга бирелеп бара торгач, ул үзенең Чиркас елгасына килеп җитүен сизми дә калган. Ике кылычның да бер якка тагылган булуы беркадәр уңайсызлый, алар, бер-берсенә бәрелгәләп, борчып бара иде. Миңлебай бер кылычын уң якка тагарга уйлады. Вак кырчын ташлар өстеннән чылтырап аккан саф елга суын чыкканда һәм атын атлатып кына тауны менгән вакытта Миңлебай әнә шул эш белән шөгыльләнде.

Тауны менгәч, ул кызурак кайтырга теләде. Аякларын селкеткәләп, ияр өзәнгеләре белән җирән кашканы кытыкларга кереште; тезгенне дә тарткалап куйды. Ләкин ул артык озак юырттырып бара алмады. Миңлебайның алдыннан гына юлны аркылы кисеп чыгу теләге белән чабучы ерткыч аның игътибарын үзенә юнәлтте. Тезгенне тиз генә тартып кую аркасында җирән кашка тукталып калды.

Бу – зур гына гәүдәле бер карт бүре иде. Ул бик-бик тырышып чаба һәм арткы аякларын җиргә каты-каты этәреп сикерә. Ләкин аның алга баруы һич тә үрчеми. Әйтерсең лә ул арткы аяклары белән җирне каты этәреп алга сикерә дә, нәрсәдер аны койрыгыннан тартып арткарак, ул төшәргә теләгән ноктадан чигенебрәк төшәргә мәҗбүр итә. Аның калын муены аз гына бөгелеп, башы уң якка таба карап каткан, тәне юеш, авыз-ирен тирәләре ап-ак күбек. Миңлебай бу бүренең кемнәр тарафыннандыр күптәннән үк куылып килүен һәм инде аның тәмам арыган булуын аңлады. Ул: «Башы уң якка карап каткан, сул

ягыннан барасың икән, ул бернәрсә дә күрә алмый. Маңгаена кылыч сырты белән генә сугып алырга була», – дип уйлады. Сул кулында атның тезгенен уйнатып, уң беләгенә эленгән камчыны селеккәләде, хәтта атның алгы ботына берне сугып та алды.

Җирән кашка җан-фәрманга йомылып чабып китте. Миңлебайның уң кулы тураеп югары күтәрелде һәм аның ялангач кылычы һавада чайкалгалап бара башлады. Менә җирән кашка бүренең артыннан куып та җитте. Алар бергә, янәшә үк бара башлады. Шул ук минутның эчендә дип әйтерлек Миңлебайның уң кулында югары күтәрелгән кылыч кискен генә селтәп җибәрелде, һәм бүре әйләнеп-әйләнеп барып җиргә ауды. Ул – судан алып корыга ыргытылган зур балык шикелле – башын, койрыгын һәм аякларын нык тыпырчындырып, барлык гәүдәсе белән сузылып чирәмгә ятты. Миңлебай, аз гына узып киткән җирән кашканы киредән борып бүре янына китерде дә үзе шунда ук җиргә төште. Бүре үлеп бетмәгән иде әле. Миңлебай, кылыч сырты белән аның маңгаена, колак төпләренә һәм муен тамырына суккалап, бүрене тиз-тиз генә үтереп ташлады.

Шул арада бүре чабып килгән яктан биш эт күренде. Алар, үзләре куып килгән бүрене ниндидер чит кеше сугып алганга ачулары килгәнлекне аңлатырлык рәвештә ырылдашып, бер-бер артлы алгы аяклары белән җиргә нык кына таянып туктадылар. Миңлебай бармак янап һәм иркәләү сүзләре әйтеп аларны тыйды, бүрегә һөҗүм итәргә, аны өзгәләп ташларга ирек бирмәде. Этләр исә, тешләрен кысып һәм зарлы гына шыңшып, көчкә-көчкә генә түзеп кала алдылар. Алар арасындагы зур торыклы, бүре шикелле үк соры йонлы, очлаеп килгән озынча авызлы бер акыллысын Миңлебай яхшы таный иде. Бу – Мәрьямнәрнең ау эте, авыл халкы телендә бик макталып йөртелә торган эт, аның исеме – Бурзай. Димәк ки, аучылар арасында минем бабай буласы кеше Җәләй карт та бар, дип, Миңлебай мәгънәле генә фикер йөртеп алды. Ул Бурзайны үзенә чакыргалап та карады. Ләкин, көннең-көн буенча азапланып куган һәм үзе беренче булып килеп алачак бүрене сугып еккан өчен, Бурзайның хәтере бик нык калган икән. Ул, үзенең хуҗасы Мәрьям янына еш кына килеп йөри торган һәм шактый таныш, бөтенләй ияләшеп беткән кешесе булуга карамастан, Миңлебайга якын да килмәде. Хәтта койрыгын да селекми, күзләрен бүре үләксәсенә текәп, таштан коеп куйган шикелле тик тора иде.

Этләр күтәрелгән яр буеннан иярле атларга атланган кешеләр дә килеп чыкты. Миңлебай аларны елмаеп каршылады, алар да егет белән күңелле генә исәнләштеләр.

Аучылар арасында элек-электән үк сакланып килгән гадәт буенча, бүрегә аны сугып алучы, бу урында Миңлебай хуҗа иде. Ләкин моның тагын икенче ягы да бар: әгәр дә бу төркем эчендә иң олысы Миңлебай булса, бүрегә дә ул хуҗа, ягъни ерткычны ул тагып алып кайта; әгәр инде аңардан да олылар бар икән, ул вакытта Миңлебай үзе кемне олы һәм хөрмәт итеlә торган дип тапса, бүрене әнә шул кешегә тагуны тәкъдим итәргә тиеш. Аучылар хәзер Миңлебайның нинди карар кабул итүен кызыксынып көтә иде.

Монда ике кеше арасыннан кайсысын сайлау мәсьәләсе кыенрак хәл булып калды.

Бәетче Низаметдинның ап-ак сакалы бөтен күкрәген каплап алган, төсе-бите дә шактый картка охшый. Миңлебай уенча, ул Җәләйдән ике-өч яшькә олырак булырга тиеш. Шулар өстенә, ул әле бәетче дә иде. Аңа тиешле булган хөрмәтне күрсәтмичә калырга Миңлебайның күңеле һич тә тартмый. Аны бөтен авыл

халкы хөрмәт итә бит. Шулай булмаска мөмкин дә түгел. Яңа Чиркас авылында кем генә өйләнмәгән дә, Низаметдин карт кемне генә бәет әйтеп кәләш куенына илтеп япмаган икән? Авылда иң оста бәетчеләрдән Низаметдин һәм аның энесе Гыйльметдин санала. Алар үзләре дә бу эшне бик теләп башкара. Аларда һичбер ялындыру гадәте юк. Билгеле, дөнья булгач, аларның да хәтерләре калган вакытлары, ачулары килгән кешеләре була торгандыр. Андый чакларда да алар ялындырып яки кыстатып-мыстатып тормыйлар, алдан ук кисәтеп, кырт кына өзеп әйтеп куялар: «Бәет әйтү өчен дип безгә килеп йөрмәсен. Без аның туена барып йөри торган кешеләр түгел».

Бу хәбәр авыл халкына алдан ук ишетелә, шуның белән булачак туйның дәрәҗәсе шактый гына төшеп тә кала.

Шулай булгач, Низаметдин картка тиешле хөрмәтне күрсәтмичә калу бик тә уңайсыз иде. Ләкин Җәләй карт аңа караганда да күбрәк хөрмәткә лаек булып тора. Ул бит сөекле Мәрьямнең атасы, әнә-менә Миңлебайның бабасы булырга торган кеше. Миңлебай, бүре үләксәсен арткы аякларыннан тотып күтәрде дә:

– Җәләй абзый, бу нәрсәне сезнең ияргә тагыйк инде, – диде. Аннан соң, сүзләренә беркадәр уен-көлке төсен бирергә тырышып: – Низаметдин абзыйның да, Җәләй абзыйның да яшьләрен белмим, алай-болай ялгышлык булса, гафуррахим инде, – дип өстәде.

Миңлебайның бит урталары кызарып киткәндәй булды. Ләкин, аның шатлыгына һәм гаҗәпкә калуына каршы, Низаметдин картның йөзендә тамчы кадәр дә ачу һәм көнчелек билгесе сизелмәде. Хәтта ул үзе, егетне тынычландырырга тырышып:

– Ярый, энем, ярый! Бик яхшы, мин бик риза, – диде.

Алар юл буенча төрле уен-көлке сүзләр сөйләшеп кайттылар. Низаметдин карт, тыныч кына куе тавыш белән:

– Безне беләсең инде, энем, кышка керсәк, куян шулпасы эчмәгән көнебез булмый безнең, – диде, ияренең арткы кашагасыннан эләктереп, атының ике ягына аскан куяннарны селкеткәләп куйды: – Бурзайлар бик яхшы бит безнең, барысы да Җәләй чордаш бурзаеның балалары.

**14**

Сабира Миңлебайдан ничек тә үч алырга, аның теләк һәм өметләрен кисәргә уйлый, шуның өстенә, Мәрьямнең дә бәхетен күпсенә, алар арасына агулы кара елан булып керергә тели иде. Дөрес, Сабирада Миңлебайны сөю һәм аңа карата үзендә саф мәхәббәт тойгыларын саклау дигән нәрсәләрнең берсе дә була алмады. Мәгәр Сабираның хис һәм уйлары яшен тизлеге белән үзгәреп, өермә шикелле бөтерелеп һәм буталып тордылар. Вакыт-вакыт аның күңеле Миңлебайга да төшеп куя. Бу уңган егетне Сабира үзенә буйсындырырга, аны бары тик үзе теләгән сукмактан гына йөртергә уйлый. Атасының малы һәм байлыгы белән үзенә кияү сатып алучылар Яңа Чиркас авылында элек-электән була килгән. Ләкин нәрсәдер Сабираның күңелен Миңлебайдан бик нык кире этәрә. Бала вакыттан ук Миңлебай белән талашып үсүләре, ачы теллелек күрсәтеп, үзенең егетне «хәерче» дип, «өтек» дип, «килмешәк» дип хурлау һәм мыскыл итүләреме? Юк. Сабира аларның һәммәсен дә онытырга әзер. Бөтенләй үк булмаса да, Миңлебайны үз кулына төшереп алганчы, аны үз сукмагына салып, үзе теләгәнчә генә йөртә башлаганчы онытыр иде ул хәлләрне Сабира. Аннан соң үзе белер иде әле нәрсә эшләргә, Миңлебайны ничек итеп үз кубызына биетергә. Ләкин монда Сабирага башка бер хәл

уңайсызлый. Ул – Миңлебайда булган чиксез горурлык. Хәтта алар арасында берничә мәртәбә ачыктан-ачык әйтешүләр дә булгалап алды.

Беркөнне шулай, Миңлебай ерак юлга барасы атларга солы салып, ә Сабира көтүдән кайткан сыерларны лапаска ябып йөри иде. Берсе атлар ягыннан, икенчесе сыерлар ягыннан килеп, алар икесе дә лапас капкасы янында тукталып калдылар. Сабира, кулларын аркылыга җәйгән хәлдә Миңлебайның юлын кисеп:

– Мин сине чыгармыйм, – диде.

Ләкин Миңлебай һич тә Сабира белән шаярырга җыенмый иде. Ул, Сабирага якынлашыр-якынлашмас кына тукталып:

– Шаярмагыз әле, минем вакытым юк, – диде.

Сабира, аның сүзләрен бөтенләй ишетмәгән шикелле кыланып:

– Миңлебай! Мин сиңа бер сүз әйтергә җыенып йөри идем, – диде.

Миңлебай аны аңламаганга салышты һәм йөзендәге әүвәлге җитдилеген югалтмыйча гына: – Мин сезне тыңлыйм, әйтегез сүзегезне, – диде.

– Әйтегез дип... Егетләр үзләре башлап әйтә торган сүз инде ул... Миңлебай, син ни өчен миңа ачулы-кычулы йөрисең әле? Ә мин сине... сине...

Миңлебай аңа әйтеп бетерергә ирек бирмәде:

– Турысын әйткәнем өчен гафу итегез... Сез нәрсә, минем мәхәббәтемне сатулаштырырга уйлыйсызмы? Моның өчен бер Сабираның гына түгел, Котыриклар нәселенең бөтен байлыгы да җитмәс, – диде дә, көлемсерәп, лапастан чыга башлады.

Әмма Сабира урыныннан кузгалмады. Ул Миңлебайның мондый хурлауларына да түзәргә әзер, горур егетнең ирке алдында бай кызының көяз тәкәбберлеген вакытлыча гына буйсындырып калырга да риза иде. Ләкин Миңлебай аның белән артык чуалмады, аны үз юлыннан читкә этәреп җибәрде...

Бу хәл Сабираның ачуын чиктән тыш кабартты. Ул, үзенчә Миңлебайга үч итеп, кемне дә булса башка берәүне сөю, шуның белән үзен-үзе юату, ничек тә йөрәгенең ярсуын басарга тырышу фикеренә килде. Хатыны һәм баласы өстеннән йөреп, «мәхәббәтен» Бәхтиярга «бүләк» итте. Бәхтиярны тәрәзә аша үз янына кертеп, озын да, күңелсез дә, кайгылы да булган төннәрен аның белән үткәрде. Дөрес, кыз башы белән хатынлы ир белән чуалу кешеләр алдында аны хурландыра иде. Ләкин Сабираның башка һичбер чарасы юк... Ул Бәхтиярны көчләп сөяргә, мәҗбүри яратырга, үзен-үзе ирексезләп күңелен шуңа беркетергә тырышты.

Ләкин боларның берсе дә Миңлебайны кара елан ачуы белән тешләү, ничек тә аның үзәк-бәгыренә үтәрлек берәр явызлык эшләү теләгеннән юкка чыгара алмады.

Менә шунлыктан да, Миңлебай белән Мәрьямнең туе турында сүзләр куера башлагач ук, Сабира бу турыда агасына хәбәр итәргә ашыкты. Гарифҗан да озак көттермәде, сеңлесенең хатын алгач та кайтырга чыкты.

Иске өйдә Сабира ялгызы гына иде. Ул, зур стена көзгесенең каршысына басып, үзенә-үзе моңсу гына карап тора. Ни өчендер соңгы көннәрдә ул үзен олысыман итеп сизә башлады. Ашау-эчүнең дә һичбер тәмен тапмый. Көннән-көн аяк һәм кул буыннарының хәле китә кебек. Көзге аша ул үзенең эчкә баткан кайгылы күзләренә, яңак сөякләре калкып торган зур битенә, тузгыган киң кара кашларына карап торды.

Шулвакыт аның янына Гарифҗан килеп керде. Аның кашлары җыерылган,

чырае сытык, кыяфәте ачулы иде. Ул туп-туры сәке кырыена барып утырды. Ләкин бер генә авыз сүз дә әйтмәде. Исерек башын түбән иеп, бер кулы белән сәкегә, икенчесе белән тезенә таянганы хәлдә, башлап Сабираның нәрсә булса да әйтүен көтте.

Сабира ул кергәч үк көзге каршыннан читкә тайпылды. Аркасы белән ягылмаган салкын мичкә сөялеп, бераз гына агасына карап торды да:

– Абзый, турысын гына әйт әле, син нигә миңа ачуланып йөрисең? – диде.

Гарифҗан, һаман шулай сәкегә таянып утырганы хәлдә:

– Ачулану гына түгел, мин сине эт урынына кисәр идем әле. Теге хахул Петлюк качкан төнне шушында ниләр булганын да сөйләп бирә алмыйсың бит. Ә үзең мине чакыртып хат язасың. Хәзер минем күпме укуым калды, – диде.

Сабира ялынулы юаш тавыш белән дәвам итте:

– Абзый, минем шикләнгән нәрсәләрем бар да барын, тик мин аларны әйтергә генә куркам. Кыз башым белән урядник янына чакыртып йөрсәләр... Аннан соң, ни... Бәхтияр...

Гарифҗан аңа уендагын тулы ачарга ирек бирмәде. Ул:

– Юкларны сөйләп торма әле син, сеңлем! Син миңа ишеткән-күргәннәреңне әйт тә бир, калганын мин үзем башкарырмын, – диде.

– Мин, абзый, дүрт нәрсәдән шикләнәм, – диде Сабира. – Берсе шул. Мин Бәхтияр белән тәрәзә аша сөйләшкәндә, аның янында кемдер бар кебек сизелде. Мин аңардан, яныңда кеше бармы әллә, дип сорадым да, ул миңа, берәү дә юк, бер эт үтеп китте бугай, диде. Мөгаен, шунда Миңлебай булгандыр, дим мин. Теге кәлпәк турында үзең дә беләсең инде. Бәхтияр бервакытта да урамга кәлпәк киеп чыкмый бит ул. Миңлебайга өйалдына кереп тыңларга җайлы булсын дип, мөгаен, алар баш киемнәрен алмашканнар.

Гарифҗан кинәт әсәренеп китте. Ул, башын җитез генә хәрәкәт белән югары күтәреп:

– Син нәрсә дисең? Син ул сүзләрне кайдан алып сөйлисең? Ничек инде ул – өйалдына кереп тыңлау? – дип, өсте-өстенә сораулар бирде.

Сабира инде үз-үзенә ныклы ышаныч белән дәвам итте:

– Әйе, мөгаен, кем дә булса өйалдына кереп тыңлап торган. Мин ишегалдында вакытны кемдер шушы бүлмәнең утын сүндерде. Өйгә кереп, курка-курка гына ут яндырып карасам, котым очып, йөрәгем ярыла язды. Менә шушы сәкедәге киез өстенә кемнеңдер аяк эзләре төшеп калган иде. Тузанлы ката эзе. Мин бу эзләр турында этигә дә, әнигә дә әйтергә курыктым. Барыбер үземне генә тиргәрләр иде.

Мондый яңалыктан Гарифҗанның йөрәге җилкенеп куйды. Аның өчен барысы да аңлаешлы иде инде. Ул, ярсуыннан түзә алмыйча сикереп торды да ишекле-түрле йөрергә кереште. Ул түбәндәгечә сөйләнеп фикер йөртә иде:

– Тәрәзә артындагы шәүлә. Кәлпәк белән кәләпүш алыштырып киелгән. Киез өстендә тузанлы аяк киеме эзләре. Болай булгач, шик тә юк, Миңлебай этиләрнең сөйләшкәнен тыңлап торган, аннан соң хахулга барып әйткән, тегесе шул төнне үк качып киткән.

Гарифҗан ишек катында тукталып калды.

– Тәрәзәнең биге нинди хәлдә иде соң? – дип сорады.

– Гомер-гомергә бикле торган әчке келә ул төнне ачык иде.

Гарифҗан яңадан ишекле-түрле йөри башлады. Ул, Сабирага күтәрелеп карамыйча гына:

– Сиңа боларны күптән әйтергә кирәк иде. Ничава, хәзер дә артык соң

түгел әле! Миңлебайны кәләш куенына керәм дип йөргәндә генә, төрмәгә илтеп тыгарга бик мөмкин әле. Бәхтияры да ачуымны күп китерде, аның белән бергә китәр, – диде.

Ишек янындагы агач чөйдән камчысын алып, аны беләгенә киде; биленә кылычын тага башлады. Сабира аңардан:

– Абзый, син кая җыендың? – дип сорады.

– Айгырҗалга, станица атаманы янына барам.

– Абзый, кара әле...

– Йә, карап торам, нәрсә әйтәсең бар тагын?

Сабира акрын гына почмак якка таба атлады. Яулык кырые белән яшьле күзләрен каплый төшеп:

– Абзый, зинһар өчен дип әйтәм, Бәхтиярны гаепле итеп йөри күрмә инде, – диде.

– Ни өчен ул тагын? Бәхтияр кебек затсыз белән башыңны бәйләмәсәң, үзеңә тиң табылмас дип куркасыңмы әллә?

Сабира почмак сәкедәге түшәк һәм мендәрләр өстенә йөзе белән капланды да елый башлады. Гарифҗан, сеңлесенең янына ук барып:

– Нәрсә булды тагын сиңа? Нигә елыйсың? – дип сорады.

– Абзый җаным, миңа хәзер үземне-үзем суга ташлыйсы гына инде. Хәзер минем кеше күзенә күренерлегем дә калмады. Абзый, минем синнән башка эч серемне сөйләр кешем юк...

– Йә, нәрсә, нәрсә булды тагын? Әйт сүзеңне.

– Абзый! Минем... Минем йөгем бар...

– Кемнән? Шул Бәхтиярданмы әллә?

– Әйе, аңардан...

Гарифҗан сул кулы белән кылыч сабын, уңы белән камчысын кысып тотты. Аның Сабираны шушы урында йә кыйнап ташлыйсы, йә кылыч белән чапкалап бетерәсе килде. Ул тешләрен шыкырдатып кысты да тиз генә ишеккә таба борылып өлгерде.

Юл буенча ул үз-үзенә түбәндәге уйларны тукып барды:

– Менә хәзер мин станица атаманын ничек ышандырырга белермен. Хәзер ул минем юкка гына уку калдырып йөрмәгәнемне аңлар. Шулай, Миңлебай чалкасыннан әйләнеп төште дигән сүз инде хәзер.

**15**

Ярату һәм сөю тойгылары, кайнар ташкын, көчле дәрт булып, Мәрьямнең бөтен тәнен, миенең иң нечкә җепселләреннән алып аяк һәм кул бармакларының очларына кадәр өретеп алган иде. Аның йөрәге ярсып һәм ашкынып, кеше кулыннан ычкынырга омтылган тургай шикелле талпынып-талпынып тибә. Аның күңелендә оеп яткан талгын рәхәтлек, чын сөю һәм саф мәхәббәт җылысы аша туган бу хозурлык, ярсу йөрәгенә азмы-күпме тынычлык та, шул ук вакытта беркадәр борчылу да биреп тора.

Әйе, Мәрьям гадәттән тыш зур шатлыклар алдында тора. Ләкин, бер генә тәүлек вакыт калуга да карамастан, ул шатлыкның килеп җитүе өметле дә, шул ук вакыт һичбер өметсез дә кебек иде. Котырык Гарифҗанының нәрсәдер иснәнеп йөрүен Мәрьям ишеткәләп тора. Шул исенә төшкән саен, аның йөрәге үзалдына жулап куя. Әйтерсең, аның күкрәк куышы эченә ниндидер куркыныч җанвар кереп оялаган да йөрәген бер кырыйдан гына тырнап һәм кимергәләп тора иде. Шулай булмаска соң! Миңлебайга ул нәкъ унике яшеннән, теге зур

Сабан туе булып үткән көннән үк күңелен салып куйды бит. Аның бу мәхәббәте еллар узган саен көчәя һәм ныгый барды. Ул үзенең алдагы барлык өмет һәм юанычларын Миңлебай белән бергә бәйләнгән итеп күрә. Ул һәрвакыт: «Минем башка һичбер теләгем юк. Ни генә күрсәм дә, аның белән бергә күрәм. Утына да аның белән, суына да аның белән бергә төшәм», – дип уйлый.

Хәзер Мәрьямгә егерме ике яшь тула. Яңа Чиркас авылында егетләрне болай озак көтү гадәте юк иде әле. Уналты-унҗиде яшькә җиттеме, тормышы тигезрәк булган хәлле кешеләр үзләренең улларын өйләндерә, кызларын кияүгә бирә башлый. Унтугыз яшь тирәләре ул инде иң актыккы баскыч булып танылган.

Мәрьям, ун ел буена Миңлебайны көтеп, бик күп егетләрнең тәкъдимнәрен кире кага килде. Үз авылыннан яки чит станицалардан килгән күп яучыларның кайберләреннән ул ансат кына котыла иде. Ләкин арада шундый яхшы кешеләр килеп чыга ки, ата белән ана аларның яучыларына берничек тә каршы сүз әйтә алмый. Яучыны тегеләй-болай юаткалап чыгарып җибәрәләр дә, ул киткәч тә Мәрьямне үгетләргә керешәләр. Мәрьям исә үзенең Миңлебайны көтүен, сабый чагыннан ук колагы аңа тешләтелгән булуын ачыктан-ачык әйтеп, ата-анасына ялынып һәм ялварып еларга тотына. Ул, әгәр дә Миңлебайдан башка кешегә бирсәләр, барыбер дөньяда тормаячагын, үзенең гомерен үзе һәлак итәчәген яшермичә белдереп куя. Мәрьямнең бу сүзләренә ышанмаска мөмкин дә түгел иде. Яңа Чиркас авылында андый күңелсез хәлләр булгалап тора: яратмаган иреннән котылу өчен, бер яшь хатын үзен-үзе коега ыргытты, ә икенчесе асылынып үлде. Әнә шуңа күрә дә, Мәрьямнең кайнар күз яшьләре аша әйткән сүзләреннән соң ата белән ананы сагышлы кайгы һәм курку баса. Бердәнбер балаларының тормышын фаҗигале вакыйгалар белән чикләргә ата да, шулай ук ана да риза түгел, әлбәттә...

Булачак туйны алар шулай көтеп алдылар.

Бүген Җәләй карт мал-туарларын көндәгедән иртәрәк карап эшен бетерде. Ишегалдын һәм капка төпләрен тагын бер кабат җыештырып, карларын көрәп, себереп куйды. Ләкин күзгә күренмәгән башка вак-төяк эшләр дә килеп чыкты: чормадан ит чаба торган тагаракны төшерәсе, казларга ашарга чыгарып бирәсе, мунча ишегенең тупсасы купкан икән – аны кагасы, урам бакчаның читәнен төзәткәләп куясы булды. Җәләй, әнә шуларның һәммәсен эшләп бетергәч кенә, тәмам арып йокларга ятты. Дөресрәге, аш өе сәкесенең бер кырыена гына башын терәп, берәр сәгать черем итеп алмак булды.

Ләкин аның күзләренә йокы кермәде, ул берсеннән-берсе тынгысыз уйларга бирелеп ятты.

Аның хатыны Мөршидә, үзенең бертуган апасы Фәрхиҗамал карчык белән бергәләп, туй кирәк-яраклары әзерли. Алар көндездән үк инде табак-табак бавырсак һәм кош теле пешерделәр, дүртпочмаклы озынча җиз подноска баллы бавырсак катырып куйдылар. Ә хәзер, Мәрьям янына кич утырырга киләчәк кызлардан пилмән ясатып алу өчен, ашыга-ашыга ит төяргә керештеләр. Җәләй аларның пычак белән кыштыр-кыштыр ит турауларын, туралган итне тагаракка салып төюләрен, аны йоклый дип белеп, пышаң-пышаң гына сөйләшүләрен ишетеп ятты. Апалы-сеңелле карчыклар, булачак туйга кагылышлы теге яки бу мәсьәлә турында кайгыртып серләшәләр. Хәтта Җәләй карт уйлап яткан нәрсәләр турында ук фикер алыша башлыйлар.

Фәрхиҗамал карчык:

– Мулла никах укырга риза булды микән инде, кияүдән сорашмадыңмы? – дип кызыксынды.

Мөршидә:

– Никах укыган өчен бәрәнле сарык бирергә булгач, ризалашкан. Тегеләр аны котыртып кына торалар бит, таң атканчы тагын кырык төрле уйга төшеп бетмәсә ярый инде.

Җәләй карт та нәкъ шул турыда уйлый иде: «Габделхалыйк мәзин белән алданрак сөйләшеп куймый ялгыш иттем. Хәзер ул кайдадыр башкорт ягына китеп барган. Ә Хәләф мулла бер дә ышанычлы кебек итеп әйтмәде бит. Котырык – аның кияве. Шулай булгач, ул кемнең җырын җырларга тиеш? Иртәгә ул никах укымаса йә бара алмыйм-фәлән дип авыру-мазарга салышып калса – бөтен әзерләнгәннәрең юкка чыкты дигән сүз инде».

Мәрьям ялгызы гына ак өй ягында. Ул, өйне берничә мәртәбә җентекләп җыештырып чыкты. Киштәдәге кием-салымнарны, почмак яктагы зур яшел сандык өстенә өелгән ястык һәм мендәрләрне, тәрәзә төпләрендәге матур-матур чәчәкле гөлләрне, ишектән кергәч тә сул якка урнашкан һәм алды белән урам як тәрәзәгә карап торган шкафтагы савыт-сабаны – барысын һәм барысын да кабат-кабат кузгалткалап, үзенең күңеленә ошаганча килешле итеп урнаштырды. Кич утыра килгән кызларга ашату өчен әзерләп куелган карбыз һәм кавыннарны өстәл өстеннән алып өстәл астына куйды; чәчәкле зур ашъяулыкны өстәл кырыеннан салындырып төшереп, өстәл астындагы әйберләрне тәрәзәгә килгән егетләр күрмәслек хәлгә китерде. Аннан соң, ишек белән мич арасындагы зур җиз ләгән эченә җиз комганны утыртып, хуш исләре аңкып торган йомшак сабын белән кулларын һәм битен юды.

Мәрьямнең эшләре моның белән генә тәгәлләнмәгән иде әле. Ул, кершән һәм иннекләрен шкафтан алып өстәлгә куйды да, зур стена көзгесенә киң өстәл аркылы карап, үз шәүләсенә үзе сокланып кына елмаеп торды. Аның чем-кара чәчләренең калын һәм озын толымнары калку күкрәге аша алга төшкән. Мәрьям аларны иплән кенә сыйпап куйды. Аннан соң, ашыкмыйча гына чулпылы чәчүргеч белән үреп, чәч толымнарын яңадан артка ташлады; өй эчендәге тирән тынлыкны бозып, чулпы тәңкәләренең бер-берсенә бәрелеп чыңлаулары ишетелде. Мәрьям әле һаман да көзгедән күзен алмыйча карап тора. Ул үз матурлыгыннан үзе канәгать. Аның күзләре сөрмәле соргылт, күз алмалары төсле үк керфекләре озын һәм тип-тигез, нечкә генә кыйгач кашлары шомырт кара. Аңа каш карасы тартып торуның да, кашларын нечкәртү өчен вакыт үткәрүнең дә кирәге юк. Болай карап торуга аның битләренә кершән дә, юка гына алсу иреннәренә һичбер төрле иннек-фәлән дә кирәкми кебек иде. Шулай да ул бизәнүдән бөтенләй үк баш тартмады... Шуннан соң ул күлмәк якасын һәм муенындагы эре-эре сары гәрәбәләрен рәтләде, аягындагы чәмчәле читекнең җыерыла башлаган кунычын тартып куйды, беләзек һәм йөзекләрен киеп алды. Аның зәңгәр ахак кашлы көмеш йөзек киелмәгән бер генә бармагы да юк иде.

Шулар белән Мәрьямнең бизәнү-төзәнүләре бетте. Ул бәйли торган шәлен алып сәке түренә менде дә урам як бакчага караган ике тәрәзә уртасына барып утырды.

## 16

Кызлар шаулашып килеп керделәр. Алар, нәрсәдәндер кызык тапкан булып, үзләреннән-үзләре чырык-чырык көлешәләр, бер-берсенә уен-көлке сүзләр әйтәләр, ишектән кергәндә, берсен-берсе төрткәләп җибәргән булалар. Монда, Хәнифәдән башка, барысы дүрт кыз иде. Алар һәммәсе дә бәйрәмчә матур киенгәннәр, берсеннән-берсе уздырырга тырышып бизәнгәннәр.

Алар дөберләшеп килеп керүгә, башындагы уй һәм фикерләре таралып,

Мәрьямнең дә күңеле күтәрелеп китте. Ул бәйләп утырган шәлен тиз генә сәкегә куйды да урыныннан сикереп торды. Күлмәгенең озын итәген куллары белән күтәрә төшеп ишеккә таба бара-бара:

– Килерләр инде, нишләп болай соңладылар икән, дип кенә утыра идем әле, – диде. Кайсыларының шәлләрен алып почмак яктагы киштәгә элде, кайберләренә бишмәтләрен салышырга, киез итекләрен алып мич алдына куярга булышты. Шул эшләрне кызу-кызу башкарган арада:

– Әвекәйләр, ничек соң әле сез болай барыгыз да бергә киләсе иттегез? – дип сорады.

Кызлар арасында шаярып сөйләнүләр һәм бер дә керәге булмаган урыннарда да көлгән булып кыланулар дәвам итте. Арадан берсе:

– Менә Хәнифә ахирәтең бит, Бәхтиярын ияртkән дә безнең барыбызны да җыеп чыкты. Әйдәгез, дигәч, әйдәгез, ди, бизәнеп маташмагыз, анда сез кунак булып утыру өчен бармыйсыз, дигән була.

Икенчесе аңа өстәп:

– Шулай ди, әү! Әллә инде тагын бездән таш кистерергә җыена.

Арада күп сүзле һәм усалрак теллесе шадра Мәрзия иде. Ул:

– Бәхтияры тагын, сөмсез сыер шикелле! Капка төбенә килеп җиткәч тә безнең арттан калмыйча аптыратты. Әй алла, кызлар күрдеме, сагыз инде менә, ябышырга гына тора, – дип, Хәнифәгә төрттереп әйтеп куйды.

Хәнифә Мәрзиянең үзенә нәрсәдер кадабрак әйтмәкче иде, акыллы кыз Гөлсем тизрәк сүзне башка юнәлешкә борып җибәрергә ашыкты:

– Бу Бәхтияр абзый бигрәк кызык кеше инде. Сезне, ди, мин үз өстемә аманәт итеп алдым. Шулай булгач, барыгызны да санап, Җәләй абзыйга үз кулым белән тапшырып чыгам, ди.

Мәрзия дә, үзенең урынсызрак ычкындыруын аңлап, Гөлсемнең сүзләрен куәтләде:

– Сезнең өчен, дигән була, әти-әниләрегез алдында мин җавап бирәчәк. Сез, дигән була, Мәрьямгә ияреп, бер төн эчендә барыгыз да кияүгә китеп бармагыз тагын анда, дигән була.

Арадан берсе:

– Хәнифә тутагызны да аздырып куймагыз тагын, ди әле ул, – дип өстәде.

Алар һәммәсе дә көлешеп алдылар. Шуннан шау-гөр килеп сәке түренә тезелеп утырдылар да шәл бәйләргә керештеләр. Ишектән Мәрьямнең анасы Мөршидә килеп керде. Ул, кайсысының аркасыннан сөеп, кайсысына килгән өчен рәхмәт әйтеп, кызлар белән бер-берәм күрешеп чыкты да Хәнифәне аш өенә чакырып алып чыгып китте.

Берничә минуттан Хәнифә яңадан кызлар янына әйләнеп керде. Ул бер кулына зур гына коштабак тулы төелгән ит, икенче кулына иләк белән дүрткелләп киселгән камыр кисәкләре тоткан иде. Ул, куана-куана көлеп:

– Ягез әле, кызлар, кул эшләрегезне куеп торыгыз. Кул-кулдан гына тизләтеп пилмән бөгеп алыйк, – диде. Шунда ук кередән борылып чыгып китте дә куна тактасы һәм, ясалган пилмәннәрне тезеп бару өчен, зур-зур ике ашъяулык алып керде.

Кызлар, сәкегә куелган куна тактасы әйләнәсенә утырышып, эшкә керештеләр. Мәрьям, өйнең почмак һәм түр якларын бүлеп торган чаршауны төшерде дә:

– Егетләр күрмәсен әле үзегезне. Өмәләр котлы булсын, дигән булып, үчекләргә керешерләр тагын, – дип куйды.

– Әй-й, үчекләмәсәләр тагын! – диде Мәрзия. – Аларның инде, төне буенча тәрәзә янында катып-туңып тора торгач, телләрен җылытасы килә торгандыр.

– Әле дә рәхмәт инде ул мескеннәргә, – диде Гөлсем дә. – Төннәр буенча безне сагалап чыгалар бит. Урам әйләнеп кенә киләләр дә, тагын шул тәрәзә төбенә өеләләр.

Берничә минут өй эчендә тирән тынлык хөкем сөрде. Аннан соң, исенә төшерүдән үзе дә куанып, Мәрзия кинәт кенә кычкырып җибәрде:

– Анысы да монысы, кызлар! Без әле бик кирәкле нәрсәне онытып җибәргәнбез. Тозлы, җепле, камырлы, күмерле, балдаклы пилмәннәрне безгә кем ясап бирер? Туй көнендә кияүне сынамыйча булмый инде анысы.

Гөлсем бу урында да Мәрзия әйткәннәрне куәтләде:

– Чынлап та! Әгәр дә кияү әче телле булса – аңа тозлы пилмән, юкка-барга бәйләнеп эч пошыра торган булса – җепле, җебеки булса – камырлы, кара эчле булса – күмерле...

Мәрзия Гөлсемгә әйтеп бетерергә ирек бирмәде. Ул, елмаюлы кысык күзләре белән Мәрьямгә карап:

– Әгәр дә мәгәр кияү бик яхшы, бик күңелле һәм бәхетле кеше булса – аңа балдаклы пилмән чыгар. Балдак урынына үземнең ахак кашлы чын йөзегемне салам, – диде.

Хәнифә аларны каты гына тиргәп әйтте:

– Кызлар, кыбырсымый гына эшегездә булыгыз! Безнең кияүне бер дә сыныйсы-нитәсе юк, аны без биш былтырдан бирле сынап киләбез инде, чүп-чарларыгыз белән ашны пычратмыйча гына утырыгыз! Аулак өйләрдә егетләрне сынау өчен генә килешә ул андый чурт-чураманнар.

– Йөзек кенә салырга да ярамыймы, Хәнифә түти? – дип сорады Мәрзия.

Хәнифә, бу юлы инде тавышын шактый йомшарта төшеп:

– Артык йөзекләрегез булса, ник тә йөзне салмагансыз! Бер сүзем дә юк. Тик карагыз аны, йөзекләрегез кире кайтарып бирми торган кешегә чыкса, соңынтын үпкәләшеп йөрисе булмагыз, – диде.

Мәрзия:

– Салабы-ыз, салабыз! Йөзек тә салмагач, аның ни кызыгы була соң? – диде дә, сул кулының кечкенә бармагына киелгән яшел кашлы матур йөзекне салып, куна тактасы өстенә куйды. Гөлсем дә, аның артыннан Сәрвәр белән Мәрвәр дә берәр йөзекләрен салдылар.

Мәрьямне көчле шатлык дулкыннары яулап алды. Аның соргылт күзләре бәхетле елмая. Бу сөйкемле күзләрдән, булачак кияүне шулай хөрмәт иткәннәре өчен, иптәш кызларына рәхмәт очкыннары бөркелә. Мәрьям: «Кызлар, йөзекле пилмәннәрегезне билгеләбрәк куегыз, аларны кияү табагына салып кертерләр», – дип, хәтта тегеләрнең исләренә дә төшереп куя язды. Тик, нигәдер уңайсызланып, ул үзенең бу фикерен әйтүдән тыелып калды. Шул арада кызлар моңлы гына итеп җырларга кереште:

Казлар оча, казлар оча, казлар оча тезелеп,
Алма булсам төшәр идем алларыңа өзелеп.

Бу җырга кушылучыларның берсе дә үзе турында, үзенең сөйгәне турында уйламый. Бу җырны алар Мәрьям өчен, аның тирән күңеленнән алып җырлыйлар. Моны Мәрьям үзе дә аңлый, һәм ул эченнән генә җырга кушыла.

Кызлар тагын бер җыр башламакчылар иде, Мәрьям, уң кулы белән һавада хәрәкәт ясап:

– Чүегез әле, кызлар! Урамда гармун тавышы ишетелә түгелме соң? – диде.

Хәнифәдән башкалары барысы да, эшләрен ташлап, урам як тәрәзәләргә йөгерде. Хәнифә почмак якта килеш пилмән бөгүен дәвам итте. Ул, тынын аз гына кыса төшеп, сагыз чәйнәвеннән бөтенләй үк тукталып, урам якка таба колак салып утырды. Мәрьям исә, уң терсәге белән тәрәзә яңагына таянып, башка кызлар шикелле үк башын пәрдә кырыеннан аз гына тыга төшеп тыңлады. Урамда, өздереп-өздереп уйнаган дәртле гармун көенә кушылып, егетләр җырлый. Арадан берсе шул ук көйгә бик нык сызгыра. Кайсыларыдыр кулларын шапылдата...

Кинәт җыр тынып калды. Тик гармун гына өзгәләнеп-өзгәләнеп көйләвен дәвам итте. Кызлар сулышларын да алмыйча тыңлап тордылар. Ләкин аларга гармун тавышыннан башка бернәрсә дә ишетелмәде. Шулай булса да кызлар бу тукталуның төп серен яхшы аңлый. Гадәт буенча, Мәрьям тәрәзәсе турына якынлаша башлагач та, җырны Миңлебай башларга, ә башкалар аңа кушылырга гына тиеш. Һәм ул җырлар фәкать сөелүче кызга, бу урында, бары тик Мәрьямгә генә каратып җырланырга, аның йөрәгендәге дәрт, мәхәббәт тойгыларын тагын да ныграк кузгалта торган булып яңгырарга тиеш иде.

Озакламый, гармунның аеруча дәрт белән сайрарга керешкән тавышына кушылып, Миңлебайның ягымлы авазы, дулкынланып, бөтен авыл өстенә җәелеп китте:

– Ач тәрәзәләреңне,
Күтәр пәрдәләреңне,

– аңа кушылып, җырның икенче бүлеген барлык егетләр дә күтәреп алды:

– Күтәрсәң пәрдәләреңне,
Күрәм гәүдәләреңне.

Тагын Миңлебай башлап, баягысы шикелле үк ахырын барлык егетләр күтәреп алды:

Атымның дагасы алтын, сынмаса, алдырмамын.
Үлмәсәм, гүргә кермәсәм, ятларга калдырмамын.

Мәрьям, сул кулы белән Гөлсемнең муенын кочаклап, җырларның һәрбер авазын су урынына эчеп һәм йотып торгандай итеп тыңлады. Бүген Миңлебай үзенең кечкенәдән үк сөеп җырлаган җырларын кабатлый. Соңгы ун ел эчендә ул бу җырларны һәр көн саен диярлек җырлап килде, ә Мәрьям аларны ишеткән саен яратып һәм куанып тыңлады. Менә хәзер дә, күңеленнән Миңлебай шикелле үк ант итеп, Мәрьям эченнән генә кабатлап торды:

– Үлмәсәм, гүргә кермәсәм, ятларга калдырмамын.

Егетләр Мәрьямнәр өе турына килеп җиттеләр. Гармунчы һич тә ялыкмыйча өзлексез уйный иде. Егетләр аны уратып, бер-берсенең иңбашларына таянышып туктадылар. Миңлебай уртага, гармунчы янына ук кереп басты да, тагын җыр башлап җибәрде:

Бакчаңа сулар кермәсен, чәчкән гөлең чермәсен.
Нык тот, бәгърем, күңелеңне, дошман сүзе кермәсен.

Җырның ахыргы өлеше ике мәртәбә кабатланырга тиеш иде. Ләкин, ни өчендер,

ул артык кабатланмады. «Нык тот, бәгърем» дигән сүзләрне икенче мәртәбә әйтү белән, Миңлебайның да, башка егетләрнең дә тавышлары өзелеп калды. Өй эчен дә, шулай ук урамны да шомлы тынлык биләп алды. Ләкин ул тынлык бер минут чамасына гына сузылды. Озакламый урамда нindидер буталыш башланды, әллә ниткән шау-шу күтәрелде, кемнәрнеңдер сүгенүләре ишетелде.

Шуннан соңгыларын Мәрьям тыңламады. Ул, куркынып, башын тәрәзәдән алды да пәрдә кырыен тиз генә ябып куйды; нәрсәдер үтенгән, нидер сораган кебек итеп әле Хәнифә ахирәтенә, әле Мәрзиягә, әле Гөлсемгә карап торды. Аның йөзе кинәт кенә күгәреп киткәндәй булды, иреннәре һәм куллары, бизгәк тоткан кешенеке кебек булып, дерелди, калтырана иде. Ләкин аңа җавап бирү турында уйлап та караган кеше булмады. Чөнки өйдәгеләрнең барысы да, нәкъ Мәрьям шикелле үк, үзләре чиксез бер аптыраштa калган иде.

Байтак вакыт шулай узды.

Кинәт, көчле тартылудан эчке биге йолкынып чыгып, өй ишеге төбенә кадәр ачылып китте. Аннан Бәхтияр килеп керде, һәм ул ишекне тиз генә ябып куйды. Өйдәгеләр барысы да кинәт айныган кебек булдылар. Ләкин Бәхтияр аларга һичбер шатлык китермәде. Аның йөзе куркудан агарынган, тавышы каушаудан карлыккан иде. Ул:

– Миңлебайны алып киттеләр! – дигән сүзләрне көчкә-көчкә генә әйтеп бирә алды. Аңа шунда ук төрле яктан сораулар яудыра башладылар:

– Нәрсә дисең?.. Миңлебайны?.. Нәрсә өчен?.. Кемнәр?.. Кайда алып киттеләр?..

Бәхтияр:

– Туктагыз әле, кызлар, тынымны алырга ирек бирегез! Туктагыз әле, уф-ф! – диде. – Менә шулай... Станицадан пәлитсәйләр килгән. Шулар, теге урядник тәре белән бергәләп, Миңлебайны станицага алып киттеләр... Туктагыз әле, бүлдерми генә торыгыз әле, кызлар!.. Ни өчен дә ни өчен! Анысын әйтеп торалармыни алар.

Бу вакытта инде, маңгаен беләкләре өстенә куеп, йөзе белән сәкегә капланып яткан Мәрьям кызганыч рәвештә үксеп елый иде. Бәхтиярның йөзендәге әйтеп бетергесез үзгәреш, аңардагы чиксез каушау билгеләре Мәрьямгә гадәттән тыш нык тәэсир итте. Аңа, Бәхтияр барысын да белә, ләкин, Миңлебайның башына төшкән бәла бик зур һәм йөрәкне әрнеткеч булганлыктан – тик менә шуның өчен генә – әйтеп бетерми кебек тоела иде.

Хәнифә Мәрьямнең башын тотты; икенче кулы белән аны акрын гына күтәреп торгыза башлады. Ул, ипле генә йомшак тавыш белән:

– Яле, ахирәт, җылама инде ул кадәр! Үз-үзеңне бетермә, бернәрсә дә булмас әле, – дип, Мәрьямне юатырга тырышты. Ләкин Миңлебайга нәрсә булса да булырмы, әллә бернәрсә дә булмый калырмы – анысын Хәнифә үзе дә белми, хәтта ул болар турында уйларга да өлгермәгән иде әле.

Мәрьям, бер кулы белән Мәрзиягә тотынып, икенчесе белән Хәнифәнең иңбашына таянып, сүзсез генә тора башлады. Аның күзләреннән бөрчек-бөрчек яшь тамчылары тәгәри иде. Шул ук вакытта Миңлебайның соңгы җыры аның колак эчендә, миенең кайсыдыр бик тирән урынында кабатланып, йомшак кына тирбәлеп торды: «Нык тот, бәгърем, күңелеңне, дошман сүзе кермәсен». Ул яңадан сәкегә ауды.

**17**

Мәрьямнең үз гомерендә беренче мәртәбә шундый зур кимсетелүгә очравы иде бу. Ата-анасының бердәнбер кызы булганлыктан, анасы Мөршидә әйтмешли, Мәрьям аларның «кунаклары булып», «уч төпләрендә генә»

үсте. Аның анасы еш кына: «Мин кызымны өрмәгән җиргә дә утыртмыйча кадерләп үстерәм. Күз алмамдай итеп тәрбияләгән баламны Котырыкның мәми авызына биреп хур итәмме соң? Дөньяда андый акылга таманнар күп булыр!» – дип сөйләнә торган иде. Мәрьям үзе дә бик акыллы һәм үз намусын үзе саклый белә торган кыз булып, әйләнә-тирә авыл егетләре әйтмешли, Яңа Чиркасның тоткасы булып үсте. Матурлыгы белән ул беркайчан да масаймады. Матурлыгы һәм үзен-үзе яхшы тота белүе аркасында гына була алган өстенлекләрен һичбер вакытта да кешеләрне кимсетү һәм хурлау өчен файдаланмады. Шунлыктан да булырга кирәк, кайда гына бармасын, егетләр һәм кызлар аңа чиксез хөрмәт белән карадылар. Миңлебай белән Мәрьям арасында кайнар мәхәббәт бәйләнеше барлыгын яхшы белгәнлектән, авыл егетләренең күпчелеге бу мәхәббәткә тап төшермәскә тырышып, хәтта аларны төрле хәвеф-хәтәрдән киртәләп килделәр. Нәкъ менә шунлыктан да, Гарифҗан шикелле бай балаларының Миңлебайны тере килеш йотарга әзер торуларына карамастан, аңа берничек тә тешләре үтмичә килде. Бу яктан Миңлебай белән Мәрьям үзләрен тиңсез бәхетле итеп санайлар, «йөз сум акчаң булганчы, йөз дустың булсын» дигән мәкальнең кадерен белеп яшиләр иде...

Ә менә бу соңгысы! Бу соңгы хәл, чиктән тыш авыр һәм хурлыклы кимсетелү булып, әле яңа гына чәчәккә бөреләнгән яшь тормышның бөтенләй өзелеп ташлануы булып аңлашылды. Шунлыктан, иптәш кызларының юатулары да, ата-анасының еламсыраган тавыш белән ялынып газаплванулары да – болар берсе дә Мәрьямнең күзләреннән өзлексез аккан кайнар яшь чишмәсен туктатырлык көчкә ия була алмадылар.

Ул өзгәләнеп, маңгаен сәке тактасына бәргәли-бәргәли елады. Барысының да чыгып китүләрен, аның фәкать ялгыз үзен генә калдыруларын үтенде. Әнисе:

– Әй балам-балам, гөл бөртегем! Сине ялгызың гына калдырып буламы соң инде? Әти-әниеңне кызгансаң, дошманнарның куанычы артмасын дисәң, үзеңне-үзең кулга ал, тынычланырга тырыш, – диде.

Бераздан Мәрьям тынычлана төште, ләкин берәү белән дә сөйләшмәде. Нәрсә эшләргә, ничек итеп уй һәм фикер йөртергә икәнен үзе дә белә алмыйча тып-тын гына ята бирде.

Җәләй карт, салынып төшкән башын күтәреп тә карамыйча, сәке кырыенда тик кенә утырды. Ул бәлки шулай бер сүз дә әйтмичә уйланып тәүлек буе да утырган булыр иде. Ләкин Мөршидә карчык аңа бу хәлдә озак калырга ирек куймады. Ул, Җәләйнең терсәгеннән ипләп кенә тотты да:

– Әтисе, әйдә, без чыгыйк әле, – диде. Аннан соң, кызларга карап: – Мәрьям янында Хәнифә ахирәте генә калсын да, сез, балалар, өйләрегезгә кайтыгыз инде, – дип өстәде.

Кызлар сөйләшми-шаулашмый гына кайтырга җыена башлады. Мәрьям белән шыпырт-шыпырт кына саубуллашып, Җәләй карт артыннан чыгып та киттеләр.

Бәхтияр ишегалдында тора иде. Җәләй карт аңа:

– Энем, минем бер дә йөрер-нитәр хәлем юк, бу балаларны өйләренә озатып куй инде, – диде.

– Була ул, Җәләй абзый, – диде Бәхтияр. – Мин әле, дошманлык белән йорт-җиргә берәр хәл эшләп ташламасыннар, дип саклап тора идем.

Җәләй карт кызларның урам буенча баруларын күздән югалтканчы карап калды. Шуннан соң, урам бакчаның читәненә сөялеп, яңа яуган йомшак карларга, күктәге кисәк-кисәк ак болытларга, алар артыннан күренеп-күренеп

калган айга һәм йолдызларга карап торды. Урамда җил. Салкын. Әле кыш суыгына өйрәнеп җитмәгән битләрне, колак яфракларын өшетә. Җәләй карт башындагы түгәрәк кама читле мескен бүреген ике куллап нык кына басып куйды. Тәрәзәгә күзе төште. Бер пәрдә кырые азрак кына ачык калган икән. Җәләй карт шул тәрәзә янына килде. Куллары белән салкын бүрәнәгә таянды. Өй эченә күз ташлады.

Мәрьям торып утырган иде. Ул, куллары белән аякларын кочаклаган да, билен нык бөгеп, башын тезләре өстенә салган. Хәнифә аның чем-кара чәч толымнарын сыйпап утыра.

Өй эчен авыр тынлык басып алган. Җаннарны тетрәндерә торган тынлык, гаять дәһшәтле бер тынлык иде бу. Нинди генә куркынычлар вакытында да каушамый торган атаның йөрәге, эсселе-суыклы булып, калтыранып китте. Аның борын очын ниндидер ачы нәрсә әрнетеп үткәндәй булды. Аның иреннәре дерелди башлады. Аның бөтен гәүдәсе, кинәт кенә көзән җыергандай, тартылып һәм куырылып куйды. Аның хәлсез карт күзләреннән, вак-вак кына бозлар шикелле, салкын яшь тамчылары тәгәрәп төште. Кызгану да, азрак кына юана төшү дә, шулай ук әрнү һәм кимсенү дә бар иде аның бу хәлендә. Әйе, азрак кына юана төшү дә! Бу минутларда карт атаның сынык күңеле: «Болай булгач, артык куркыныч юк инде. Акыллым шул ул минем, кирәк урында үзен-үзе кулга ала да белә», – дип уйлый, шулай дип юана иде.

Шул көннән алып Җәләй бермә-бер картайган һәм исен-акылын югалткан шикеллерәк булып калды. Ни өчендер, ул мөмкин кадәр кызы белән очрашмаска тырышты. Ашаган-эчкән вакытларда бергә туры килсәләр дә, ул Мәрьямнең йөзенә күтәрелеп карамады, аңа бер генә авыз сүз дә кушмады, аның күз алдыннан тизрәк югалу өчен юллар гына эзләп тора торган булды. Аңа, нәрсә генә әйтсә дә, ул бик мәгънәсез сүз булыр, кызының йөрәгенә барып кагылыр да аңарда ялгышлык белән яңа авыртулар кузгалтып куяр кебек тоела иде. Ул үзенең күбрәк вакытын абзар-кура тирәсендә, мал-туарлар арасында үткәрә. Йә аш өендә, йә лапастагы печән өемендә ятып ял итә. Хатыны Мөршидә Җәләйнең шундый итеп йөрүен һич тә яратмый, аңа башын күтәребрәк йөрергә куша. Аны ешрак мәчеткә барырга өнди. Боларга каршы Җәләй танавын җыерып һәм кулларын селтәп кенә җавап кайтара. Кайбер вакытларда:

– Үзең белмәгәнне миңа өйрәтмә әле син, хатын! – дип тә кырт кистереп әйтеп куя.

Мөршидә үзе дә Җәләй кебек үк авыр кичерешләр белән яши, аның шикелле үк кайгы һәм хәсрәт утлары эчендә яна, кешеләр арасында кимсенә һәм чиксез дә хурлана, ләкин ул эчендә кайнаганнарның берсен дә тышка чыгарырга яратмый. Шунлыктан да ул барасы җиренә бара, йөрисе урыннарына йөри, күрәсе кешеләрен күрә һәм сөйлисе сүзләрен сөйли. Әмма үз йортында ул да юашланып кала. Аш өендә теге-бу эшләр белән чуалган чагында да, соңгы вакытларда Мәрьям ялгызы гына көн кичергән ак өйгә кергәндә яки ишегалдында йөргәндә дә – һәрбер урында Мөршидә акрын йөри, юан гәүдәле булуына карамастан, күләгә шикелле тын гына шуышып үтә. Әйтерсең лә һәрбер каты һәм урынсыз тавыш Мәрьямне рәнҗетәчәк, аның нәкъ йөрәгенә барып тиеп, аңа кирәге булмаган артык сыкранулар тудырачак иде.

Буш вакытларын Мөршидә намаз укып, догалар кылып, һәртөрле теләкләр теләп үткәрә. Ләкин ул нәрсә тели, кемнең исәнлеге өчен хәер-дога кыла? Әле кияү булып та өлгермәгән бер егетнең бәладән котылуы өченме? Яки кызының башка юллар белән бәхеткә ирешүен теләпме? Ул якларын Мөршидә үзе дә

аңламый, хәтта ул аларны аңларга да, белергә дә теләми. Ул бары тик дога кыла, сәгатьләр буенча намазлык өстендә утырып, Ходайның, Алласының азрак шәфкатьле булуын үтенә. Кызы бәхетсезлеккә төшкәннән соң, намаз укуын бөтенләй ташлаган ире Җәләйне тиргәштереп ала, аңа үзенең рәнҗүен белдерә:

– Әй-й, Аллам! Нинди генә гөнаһе шомлыкларым бар икән тагын? Кара инде син бу картлачны: кешеләргә ачу итеп, Аллага үпкәли бит. Шулай булгач, бу өйдә нинди бәхет торсын, бу өйгә нинди бәрәкәт кунсын?!

Миңлебайны ике атналап вакыт станица төрмәсендә яткырдылар. Аны яшерен оешма әгъзасы Остап Петлюк белән бәйләнеш тотуда, Петлюкны качырып җибәрүдә гаепләргә тырышып карадылар. Петлюкның кай тарафка китүен, кайсы юнәлешкә таба юл алуын белергә теләп сорадылар; көн саен, сәгать саен сорау алып, йоклатмыйча, ял иттермичә теңкәсенә тиеп беттеләр. Акмырзаны котыртып карадылар, тик Акмырза бер дә алар кушканча итеп сөйләмәде. Бәхтиярны чакыртып сорау алудан да эш чыкмады...

Ахыр килеп, бик озак азаплангач кына, Петлюк качып киткән төнне гармунчы Нәбиулланың Миңлебайны авылда күрүен әйттеләр. Мондый көтелмәгән хәлдән Миңлебай башта аптырап калды. Шулай да ул бик тиз арада исен җыйды, фикерен туплап өлгерде. Ул, Нәбиулланың күзләренә туп-туры карап: «Алдыйсың! Котырыклар сине сатып алган», – дип әйтергә булды.

Ләкин Миңлебай белән Нәбиулланы кара-каршы очраштырып сөйләтә алмый калдылар. Өчтерсәк Хәсән бу ялганны ачып салды. Ул төнне Өчтерсәк Хәсән белән Нәбиулла тегермәндә, Яңа Чиркастан унсигез чакрым ераклыктагы Алабайтал авылында булганнар икән...

Бу хәйлә дә барып чыкмагач, Гарифҗан һәм аны яклаучылар тәмам коралсызланып калды. Миңлебайны станица атаманы үз янына алдырып, бик озак «үгет-нәсихәт» укыды, «киңәшләр» бирде. Ата-бабасының йөзенә «кара якмаска һәм казаклык исемен пычратмаска» кушты да Миңлебайны кайтарып җибәрде.

Миңлебайга авылына җәяү кайтырга туры килде. Күптән үк кич булган. Авыл өйләрендә берәм-сәрәм генә лампа утлары яна. Миңлебай, үзләренә кайта торган тыкрыкка борылмыйча, турыдан-туры Мәрьямнәр өенә таба китте.

Мәрьямнәрнең ак өйләрендә ут балкып яна. «Әһә, бик әйбәт, кич утыралар икән», – дип уйлап алды Миңлебай. Менә ул аларның урам як бакча читәне янында тукталды. Өй эченнән тонык кына тавышлар ишетелә. Ләкин нәрсә турында сөйләшкәннәре бик аңлашылмый. Миңлебай тәрәзә янынарак килергә булды. Шулчак өйдә утыручы кызлардан берсе, Мәрьямнең икетуган сеңлесе Сәрвәр:

– Минем күңелем бүген әллә ничегрәк булып, үзалдына куанып тора!.. Мәрьям түти, әгәр дә Миңлебай абзый хәзер кайтса, сөенечкә нәрсә бирер идең? – диде.

Аңар каршы Мәрьямнең сагыш белән юашланган, ләкин күтәренке тавышы ишетелде:

– Әгәр дә юравың юш килеп, шушы ике-өч көн эчендә кайтса, сеңлем, сиңа мин үземнең әдрәс камзулымны бүләк итәм!

Сәрвәр куанып кулларын чапты. Ул, нәкъ балаларча беркатлылык белән:

– Кайта, Мәрьям түти, менә күр дә тор, кайта! Хәсән абзый миңа иртә белән үк әйтеп куйган иде инде, – диде.

– Әйдә, берүзең яраткан гына җырны башлап җибәр әле, Мәрьям, – диде Хәнифә ахирәте.

Мәрьям назландырмый гына җыр башлады, башкалар аңа кушылды:

Агым суларның агуы,
Дагалы атның баруы.
Кайсы илләрдә бар икән
Янган йөрәк даруы?

Миңлебайның кызларны озак моңландырып утыртасы килмәде. Ул, үзенең куе калын, тыңлаучыларга яхшы тәэсир итә торган тавышы белән җырлап җибәрде:

Ач тәрәзәң, күтәр пәрдәң,
Гөл күрмәгән гөл күрсен.
Орма башың, түкмә яшең,
Без күрәсен кем күрсен.

Кызлар Миңлебайның тавышын шунда ук танып алды. Мәрьям тәрәзәнең пәрдәсен зур итеп ачып җибәрде. Куе гөл яфраклары өстеннән тышка карады. Тәрәзә янында, чыннан да, Миңлебай тора иде. Ул, уң терсәген тәрәзә кырыена терәгән дә, үзе тәрәзәгә яны белән тора.

Менә Миңлебай җырлап бетерде. Һәм ул кинәттән генә борылды да туптуры Мәрьямгә карады. Ул киң итеп елмайды, бүреген кул аркасы белән күтәреп куйды. Мәрьям аның саргая төшкән ябык битләренә, шактый гына үскән сакал һәм мыекларына карап, бер сүз дә әйтә алмыйча байтак вакыт аптырап торды. Аның тәрәзә аша урамга, Миңлебайның кочагына ыргытыласы, ә Миңлебайның исә, тәрәзәне рамы-ние белән куптарып ташлап, Мәрьямне үзенең көчле күкрәгенә кысасы килә иде...

**18**

Көн иртә иде әле. Акрын гына буран кузгалып тора. Битләрне чеметтереп ала торган ачы салкын җил исә. Мәрьям белән Сәрвәр, шәлләрен битләренә үк төшергәннәр дә, ярым атлап, ярым йөгергәләп баралар. Озакламый алар, киң урамны үтеп, мәчеткә каршы булган тар тыкрыкка керделәр. Бу тыкрык бер ягыннан Тәбәнәк Хәмчкинең, икенче ягыннан Хафиз байның биек читәннәре, озын-озын лапаслары һәм таш сарайлары белән камалган. Киң урамга караганда тыкрык эче тын да, шактый гына җылы да кебек иде. Шунлыктан, тыкрык эченә кергәч тә шәлләрен бераз күтәрә төшеп, кызлар битләрен ачтылар. Хәзер алар акрын гына атлап һәм сөйләшеп бара башладылар. Мәрьям:

– Туй көнне Габделхалыйк мәзиннең оннары очмаса да ярап торыр иде инде, – дип, күңелле генә көлемсерәп куйды.

Моннан күп еллар элек Габделхалыйк мәзин, тегермәннән кайтып килешли буранда адашып, далада кала. Чананың астын өскә әйләндереп, шуның куышына кереп ятарга туры килә. Төне буе бүреләр улап чыга. Иртән торып чыкса, мәзиннең капчыкларын бүреләр ерткалап бетергән. Ике олау оны җилгә очкан. Шул вакыттан бирле Яңа Чиркас авылында буран көнне «Габделхалыйк мәзиннең оннары оча» дигән әйтем яши. Мәрьям дә әнә шул гадәт буенча әйтеп куйды.

– Сезнең никахны мәзин укыймы? – дип сорады Сәрвәр.

– Әйе. Хәлләф мулла укымыйм дип әйтеп җибәргән, – диде Мәрьям. – Әбезнең өчен кайсысы укыса да барыбер.

– Бу Габделхалыйк мәзин, – диде Сәрвәр, – мулла карышкан урында һәрвакыт ул җайлап җибәрә. Һаман саен муллага кире төшә дә йөри.

Мәрьям, каршы якта кеше күләгәсе күреп, сискәнеп куйды.

– Кара әле, Сәрвәр, ул нинди кеше икән? Бер дә урыныннан кузгалмый.

Кызлар аңа шикләнә-шикләнә генә якынлаштылар. Толып эченә яшеренгән кеше Гарифҗан булып чыкты. Ул, кызларның юлына аркылы төшеп:

– Туйларыгыз котлы булсын, Мәрьям! – диде.

Мәрьям:

– Рәхмәт, шулай булсын, – диде дә, Гарифҗанны тиз генә узып киткән Сәрвәр артыннан йөгермәкче булды. Гарифҗан, җилкәсендәге толыбын читкә ыргытты да Мәрьямнең юлын бүлде.

– Ул хәтле кая ашыгасың?! Хәерче Миңлебайларда кайнар әлбә пешереп куймаганнардыр бит, суынмас!

Бу сүзләрне Гарифҗан шулкадәр ачу белән әйтте ки, ул Мәрьямнең өстенә ыргылудан, аның бугазыннан алудан үзен көчкә-көчкә генә тотып кала алды кебек тоелды. Гарифҗанның иреннәре, куллары, бөтен гәүдәсе калтырана иде. Мәрьямнең аны мондый ук хәлдә күргәне юк иде әле. Ләкин ул үзенең куркуын Гарифҗанга сиздермәскә тырышты. Ул, үзен-үзе мөмкин кадәр тынычрак тотып:

– Урамда очраган кеше саен тукталып тора алмыйм, йомышым бар, – диде.

Бу сүзләр Гарифҗанны тагын да зәһәрләндереп җибәрде. Аның йөзе-кыяфәте бозылып, аксыл күзләреннән нәфрәт очкыннары чәчелде. Ләкин ул, эчке ачуын Мәрьямгә белдермәскә тырышып һәм ялагайланып кына:

– Мәрьям, мин синең белән соңгы мәртәбә сөйләшәм. Мин Оренбурга китәргә җыендым. Тыңла, хәзер үк чанага утыртам да алып китәм үзеңне. Рәхәтләнеп шәһәрдә торырсың... Бай хатыны булып, ялчыларга эш кенә кушып йөрисең килмиме әллә синең? – диде.

Мәрьям аңа:

– Юкны сөйләнеп оятсызланма әле, Гарифҗан! Үгезебез үлгән, уртагыбыз аерылган, дияр идем, синең белән минем уртак үгезебез дә булганы юк бит, – дип кырт кистереп кенә әйтте.

Әмма Гарифҗан чигенмәде. Ул, Мәрьямне читән буенарак тагын да кыса төшеп:

– Тукта, ул хәтле кәпрәймә әле! Миннән узып син барыбер рәхәт күрә алмассың. Кара аны, әле уйларга соң түгел!.. Әгәр дә миңа килсәң, урының түрдә, авызың балда-майда гына булыр.

Мәрьям:

– Мин синнән урын да, бал белән май да сорамыйм! – диде дә, Гарифҗанны этеп җибәреп, тиз генә юлга ташланды. Ләкин ул үзе дә сизмичә тирән көрт эченә барып керде, тезенә кадәр карга батты. Чәмчәле читек өстеннән кигән кунычлы калошына кар тулды.

Гарифҗан аның күпереп торган зур дебет шәленнән эләктереп алды. Ул, чиксез бер ачу белән, Мәрьямне яңадан артка таба этәреп җибәрде. Сәрвәр, бу тупаслыкка инде түзеп тора алмыйча, башта яхшылык беләнрәк алдырмакчы булды:

– Ай Алла-а, Гарифҗан абзый, бу нишләвең тагын синең? Без сиңа бәйләнмибез лә, тик кенә барган кешедә синең ни эшең бар иде соң әле?

Ул, Гарифҗанның калын итеп чорналган кызыл путасыннан һәм бишмәт итәгеннән тартып, Мәрьямне алга таба уздырып җибәрергә тырышып карады. Ләкин Гарифҗан Сәрвәрне күкрәгеннән этәреп җибәрде. Кыз аркасы белән көрткә егылды. Ул, куллары белән карга таянып тора-тора:

– Миңа суккан өчен, илаһи, кулың черсен, чучка авыз! Синең кебек җүләргә кыз бирәләрме соң?! – дип, Гарифҗанны мыскыл итәргә, аны хурларга кереште.

Гарифҗан Сәрвәргә борылып кына карады да:

– Син, сеңлем, ачуымны китереп торма әле! – диде.

Сәрвәр аңа каршы:

– Ачуың килсә!.. Кешедә синең ни эшең бар, Котырык җүләре! – дип җавап кайтарды.

Шулвакыт тыкрык башыннан бер чаналы ат килүе күренде. Моңардан Мәрьямнең куркуы тагын да артты. Аның, кинәт кенә йөрәгенә кан коелгандай булып, йөзе агарып ук китте. Ә Гарифҗан масаюлы эре кыяфәткә керде. Ул, чыннан да, үзенә ат һәм ярдәмгә кеше килүен көтә иде. Аның үз кешесе белән сөйләшеп куюы шулай. Бүген ул Мәрьямне ирексезләп булса да алып качарга җыенды. Аның кешесе әле яңа гына Хафиз байның читәне аша карады. Гарифҗан аңа ачуланып йодрыгын күрсәтте. Бу Гарифҗанның тегеңә тизрәк килеп җитәргә кушуы иде. Мәрьям дә, шулай ук карга егылган Сәрвәр дә моны күрми калдылар. Хафиз байның ишегалдында җигүле торган әзер атны китереп җиткерергә вакыт иде инде...

Ләкин шул ук вакыт Мәрьям Бәхтиярның кара юргасын танып алды. Ул, шатлыгыннан тиз генә кирегә борылды да, ат белән килүчегә каршы йөгерде. Бәхтияр атын туктатырга да өлгермәде, Мәрьям аның чанасына менеп тә утырды. Кулындагы шәле белән битен каплап, акрын гына елый башлады. Аның артыннан Сәрвәр дә килеп утырды. Бәхтияр:

– Нәрсә, ни булды бу сезгә? – дип сорады.

Мәрьям аңа тиз генә җавап кайтарып өлгерде:

– Атыңны тизрәк ку! Безне Ситдыйк абзыйларга илтеп ташла! – диде.

Гарифҗан яныннан узып киткән вакытта эшнең нәрсәдән торуын Бәхтияр үзе үк аңлап алды.

**19**

Хафиз байның Харисы бары тик бер генә минутка соңга калды, һәм шуның белән, үзе аны һич тә теләмәгән хәлдә, Мәрьямне тиңе булмаган бәхетсезлектән, гомерлек үкенечле булган күз яшеннән һәм бәла-казалардан коткарды.

Гарифҗан белән Харис, Котырыкларга кайтып, мунчада аракы эчәргә утырдылар. Гарифҗан, дустын тагын да ныграк әрләү өчен, бик үк «тупас әйтелми» торган сүгенү һәм хурлау сүзләре эзли иде. Ул, Харисның кабарып торган килешсез шадра битләренә, килбәтсез зур борынына карап алды да, инде әллә ничәнче мәртәбә:

– Иштең син дә ишәк чумарын! Син үгезгә ышанган мин җүләр, – диде.

Гарифҗан шактый ук исерә башлады. Ул, үзенә тагын бер кечкенә генә чынаяк өсте аракы салып эчте дә:

– Аңгыра түгел диген инде сине! Шундый уңай килеп чыккан иде бит. Кызлар тыкрык эченә кереп киткәч тә, артларыннан ат белән төшәргә иде бит сиңа.

Харис, үзенең тубал кадәр зур башын түбән иеп, байтак вакытлар дәшми утырды. Шуннан соң гына:

– Нишлисең. Үзебезнең сөйләшү шулай булды бит. Мин һаман синең әйткәнне көтеп тордым, – диде.

– Син бит әле мин әйткәч тә бик озак чыкмадың. Анда да әле син Бәхтиярга кадәр өлгерә идең.

– Син кушкач та, мин тизрәк ат янына йөгердем. Барсам, ни күзем белән күрим, атымны лапас ягына борып керткәннәр дә, алдына печән салып, аркалыгын чишеп куйганнар. Дилбегәсен читәнгә чияләндереп-чияләндереп бәйләп бетергәннәр.

– Әһә! Соң, бу кайсысының эше булыр дип уйлыйсың?

– Вәлидән башка берәүнең дә эше булмас. Лапас тирәсендә ул гына чуала иде.

– Соң, син аңардан сорамадыңмы, бу кем эше дип?

– Сорау гына түгел, мин аңа төбәп әйттем. Син, мин әйтәм, кушмаганга нигә куштанланып йөрисең? Бу атны, мин әйтәм, ни өчен монда китереп бәйләдең?

– Соң?

– Юк, дигән була. Кайсысы шулай иткәнен мин үзем дә күрми калдым, дигән була.

Гарифҗан, күп аракы эчүдән бүрткән кып-кызыл танавын җыерып, кашларын кинәт күз өстенә төшереп һәм тагын күтәреп куйды да:

– Аңардан башка берәү дә түгел, әлбәттә! Миңлебайның кордашы, икесе бергә хезмәткә баралар.

Харис:

– Мин әле, без лапас буенда сөйләшкән вакытта ул эчке яктан тыңлап та тормады микән дип шикләнәм, – диде.

Гарифҗан ачынып тешләрен шыкырдатты:

– Инде нәрсә эшләргә? Барысын да шул килеш кенә калдырабыз да, мин үз юлыма китә биримме?.. Бу тәмам җиңелү булыр иде.

– Нишлибез соң?

– Синең янга тагын таза гына җиде-сигез егет табарга кирәк. Кияү уеннарының астын-өскә китереп, барысын да кыйнап, канга батырып чыгарсыз.

– Кешеләре табылыр. Тик менә син үзең дә барсаң яхшырак булыр иде инде ул.

– Юк, миңа ярамый. Үзең беләсең, офицер кеше...

– Ярый алайса, без үзебез дә...

– Ә Бәхтиярны, кадерне белмәгән ул кара ишәкне, үтереп салырга тырышыгыз.

– Бәхтияр дигәннән, Сабира белән алар мәсьәләсе ничек булып калды инде?

– Ничек булып калганын күреп торасың бит. Башта ул Сабирага өйләнергә йөрде. Әти дә моңа күнгән иде инде. Миңлебай мәсьәләсе куера башлагач та, без һаман Бәхтиярны яклап килдек. Шуның аркасында Миңлебай өстеннән дә кирәгенчә тулы күрсәтә алмадык. Ә хәзер, беләсең бит, Бәхтияр Миңлебайның кияү егете булды да китте. Ул Сабираны чын-чынлап алдады дигән сүз.

Шулвакыт ишегалдында нindидер шау-шу күтәрелде. Кемдер, ачы тавыш белән өзгәләнә-өзгәләнә елап:

– Үлгән! Үзен-үзе харап иткән! – диде.

Бу тавыш мунча тәрәзәсеннән аермачык ишетелде. Ләкин Гарифҗан ләүкә кырыена утырган җиреннән кузгалмады. Ул, Хариска үзенең болганчык су төсле тонык күзләрен текәп:

– Карап кил әле, нәрсә бар икән анда? – диде.

Харис шунда ук чыгып китте, һәм ул берничә минуттан әйләнеп тә керде. Ул, булган хәл турында кинәт кенә әйтергә уңайсызланып:

– Сабира... Ак серкә эчкән, – диде.

Гарифҗан, сикереп торып, ишеккә таба берничә адым атлады. Ишек тоткасына ябышкан хәлдә тукталып калып:

– Син хәзер үк кирәкле кешеләрне җый. Җиң эчләренә тыгып, тимер башлы чукмарларын алсыннар. Сезнең белән мин үзем дә барам, – диде.

## 20

Кияү уенына егетләр һәм кызлар тиз җыелды. Бәхтияр, уенны тәмам оештырып җибәргәч, уенга кияү белән кызны алып килергә тиеш иде. Ул, зур гына артлы чана өстенә чуар чыбылдык корып, Хисамый йортына

китте. Миңлебай аның килүен тәрәзәдән карап көтеп утырган икән. Ул, тиз генә йөгереп чыгып, Бәхтиярга капка ачты. Миңлебай капканы киредән яба башлаган иде дә, Бәхтияр:

– Үзең әзерләнеп беткән булсаң, мин өйгә кереп тормыйм, – диде.

Миңлебай, Бәхтиярга бер мәртәбә күз төшерү белән, ниндидер күңелсезлек барлыгын аңлады. Аның чырае сытык, танавы җыерылган, киң сары кашлары нык кына төелгән иде. Ләкин Миңлебай аңардан нәрсә булганын сорашып-нитеп тормады. Әйдә, үзе рәтләсен, үзе кичерсен – шуның өчен дә ул кияү егете бит. Әгәр дә хәл кылынмаган берәр зур вакыйга булса, ул вакытта Бәхтияр үзе башлап Миңлебайга әйтер иде.

Миңлебай әнә шундыйрак фикердә булып алды. Ул бүреген баскалап һәм кызыл билбавын рәтләп торган арада, ишегалдын әйләнеп чыгып, Бәхтияр атны борып китерде. Миңлебай:

– Әйдә, киттек алайса! – диде дә, чанага менеп, чыбылдык эченә кереп тә утырды.

Мәгузә карчык Бәхтиярны чәйгә дип чакыра чыккан вакытта урам буенча карлар тузгытып, чыбылдыклы чана шактый ерак киткән иде инде.

Бәхтиярга кызларны чакыру өчен дә өйгә кереп йөрисе булмады. Тәрәзәдән карап утырган Сәрвәргә кулын гына болгады. Сәрвәр белән Мәрьям шунда ук чыгып та җиттеләр. Алар, Бәхтиярның әйтүен дә көтмичә, чыбылдык эченә, эндәшми генә утырган Миңлебай янына чумдылар. Бәхтиярның куллары дилбегәне аз гына күтәрә төшүгә, кара юрга ачык капкадан чабып чыгып та китте. Бәхтияр, атын урамның нәкъ уртасына борып төшерде дә, дилбегәсен каккалап, аны тагын да кызурак чаптыра башлады. Ачы салкын җил Бәхтиярның йөзен кисә, аңа күзен ачарга да ирек бирми. Ул, ара-тирә башын артка ташлап:

– Сез анда тотыныбрак утырыгыз, егылып калмагыз тагын, – дип шаяртып куя.

Миңлебай, үзен уртага алып утырган кызларның әле берсенә, әле икенчесенә карап, күңелле генә елмаеп куйды. Мәрьямнең алсу юка иреннәренә, озын керфекле соргылт күзләренә иркәләп карады. Ләкин ул бер генә авыз сүз дә әйтмәде. Шулай тып-тын гына бер-береңә терәлеп утыру күңелле дә, рәхәт тә кебек иде.

Алар барып җиткәндә, уен шактый гына кызган иде инде. Гармун тавышы һәм кызып-кызып әйтелгән такмак авазлары урамга ук ишетелеп тора иде. Бәхтияр атын капкадан кергәндә бик нык чаптырып керде дә, «тыр-р!» дип һәм дилбегәсен каты тартып, ишегалды уртасында аны туктатып та өлгерде...

Кияү белән кыз килеп керүгә, уен тагын да җанланып китте. Башта кияү егете Бәхтияр белән аның хатыны Хәнифәне биетеп алдылар. Аннан соң, гадәт буенча почмакка, хатын-кыз арасына кереп утырган Миңлебайның биюен сорый башладылар. Ул артык кыстатып йөдәтмәде. Идән уртасына чыгып, Мәрьям биргән чуклы кулъяулыгы белән маңгай тирен сөртә-сөртә, үзе өчен Бәхтиярның гармунчыга акча түләвен көтеп торды. Кияү акчасы гармунчының дәртен үстерерлек, карап торучыларның күңелләрен хуш итәрлек иде. Камалы бүрек эчендәге ике тиенлекләр өстенә, чыңлап, илле тиенлек көмеш төшеп ятты.

Миңлебайның нинди көйгә биергә яратканын гармунчы үзе дә белә иде. Ул өздереп-өздереп уйный башлады. Миңлебай ишек ягыннан бер әйләнеп килүгә, Мәрьям дә биергә төшкән иде инде. Ул, шәл кырыен нәкъ күзләре турыннан куышлап тотып алган да, терсәкләрен канатсыман итеп җәеп җибәргән. Миңлебай шунда ук аның каршысына барып басты. Уң кулының бармак очлары белән генә кызның сул җилкәсенә таянып, тыпырчынып һәм

гәүдәсен килешле селкеткәләп, биюен дәвам итте. Алар шулай – әле әйләнгәләп һәм бер-берсеннән аерылып, әле яңадан кушылып – бик озак биеделәр. Такмак әйтүне Акмырза башлый, тагын биш-алты егет аны күтәреп ала:

Бас, дустым, эзенә,
Күз тимәсен үзеңә,
Фәрештәләр канат җәйсен
Синең баскан эзеңә.

Уен гадәттә була торган уеннар шикелле үк дәвам итте. Үзләре яраткан егет белән бию өчен кызлар арасында тарткалашлар, ирләре белән биегән кызларны яшь киленнәрнең тиргәүләре булгалап алды. Шул ук вакытта, бер генә кыз-хатыннар, биергә төшмичә дә, кайбер егетләрне көлкегә калдырып бетерделәр. Миңлебайның бертуган энесе Гатауга хәзер унсигез яшь. Аның бер дә арымыйча биюенә бөтенесе хәйран калырлык булды. Ул, еш һәм оста бию өстенә, бер төшкәндә икешәр-өчәр кыз белән биеп, тәмам тирләп һәм арып беткәч кенә туктый иде.

Төш вакытлары якынлаша иде инде. Ишектән Хәнифәнең энесе Бикбулат килеп керде. Ул, тиз генә почмак якка үтте дә, ашыга-ашыга сөйләп, никах укылганлыкны әйтте. Миңлебай җизнәсе аңа сөенечкә агач саплы матур гына пәке тоттырды. Малай, шатлыгыннан кайда басканын да белмичә сикергәләп, уен бара торган өйдән чыгып та китте.

Никах укылу турындагы хәбәр уенның барышын тагын да җанландырып җибәрде. Такмак әйтүчеләр дә, бер-бер артлы төшеп биючеләр дә күбәеп китте. Моңарчы кычкырышып алган хатын-кызлар да, ничектер, кинәт кенә барлык ачу-кычуларын онытып җибәрде. Тагын, инде алтынчы мәртәбә, кияү белән кәләшнең биюен сорый башладылар...

Уенның шундый кызган гына вакытында гармунчы Нәбиулланы өйалдына чакырып чыгардылар.

Өйалдында җиде-сигез исерек егет белән бергә Гарифҗан басып тора иде. Күп эчү һәм йокысызлыктан аның күзләре кызарып беткән, яңак итләре суырылып эчкә баткан. Ул, Нәбиулланы күрү белән, күзләрен ямьсез кысып, тешләрен шыгырдатып куйды. Бераз шулай сүзсез генә карап торды. Аннан соң, сарык өстенә ыргылган ач бүре шикелле, кинәт кенә ташланып, аның чикмән якасыннан эләктереп алды. Йодрыгын гармунчының борын астына ук илтеп терәде. Үләргә җитешкән кешенең гырылдаулы тавышы белән:

– Хәзер үк күземнән югал! – диде. Артына тибеп, гармунчыны өйалды ишегеннән чыгарып җибәрде.

Бәхтияр нәрсәдәндер шикләнде, ләкин ул гармунчыга өйдән чыкмаска куша алмый калды. Ә инде үзе гармунчы артыннан чыга башлагач, аны киредән эчкә бәреп алып керделәр...

Өй эчендә сугыш башланып китте. «Чыр-чу» килгән хатын-кыз шау-шуы күтәрелде. Эшләр иң соңгы чиккә үк барып җитмәсә, Миңлебайга сугышырга һич тә ярамый иде. Ул, унлап хатын-кыз белән Мәрьямне почмак як сәкегә мендерде дә, үзе аларның алдына чыгып басты.

Сугышырга төбәп килгән исерекләрнең бишмәт җиңнәрендә агач чукмарлары бар икән. Ләкин Акмырза, берсенә чукмары белән файдаланырга да ирек бирмичә, аны якасыннан тотып алды, тиз генә идән уртасына егып салды һәм аяклары белән типкәли дә башлады. Ә Бәхтиярны өч исерек өч

яктан камап, чукмарлары белән кыйный да башлаганнар иде. Бәхтиярның хәле чын-чыннан мөшкелгә әйләнеп баруын күреп торучы Миңлебай, энесе Гатауга кычкырды һәм Бәхтиярга булышырга кирәклек турында ымлап күрсәтте. Гатау ишек тирәсендәрәк чуала иде. Ул, үзенең көчле гәүдәсе белән ныклы сикереш ясап, бер секундның эчендә түр якка килеп җитте. Сәке кырыендагы гармунны ничек эләктереп алуын үзе дә сизми калды. Һәм шул ук мизгелдә Бәхтияр тирәсендәге исерекләрне гармун белән бер-бер артлы дөмбәсли дә башлады. Гармун берсенең башына, икенчесенең авыз-борынына, өченчесенең колак төбенә һәм тагын әллә кайсы җирләренә эләкте. Бәхтияр тирәсендәгеләр бер-бер артлы читкә тайпылды. Аларның чукмарлары уендагы егетләр кулына төште, һәм аларны үз чукмарлары белән үзләрен кыйнарга керештеләр... Гарифҗанның кешеләре берәм-берәм ишектән чыгып кача башлады...

Гатау, урталай өзелгән гармунның ике кисәген ике кулында тотып, идән уртасында басып калды. Егетләр һәм кызлар, күңелле генә көлешеп, аңа карадылар. Аның талчыга төшкән сары йөзендә һәм куе зәңгәр күзләрендә ашкыну, дәртле ашкыну нурлары балкый иде. Кулындагы гармун кисәкләрен ул сәкегә ыргытты. Кемнәрдер көлешә-көлешә аларны тотып алды. Гатау исә, җиңелчә генә хәрәкәт ясап тыпырчынды да идән уртасыннан бер-ике әйләнеп:

– Егетләр, уенны туктатмыйбыз! Кая, кызлар, тарак белән көйләп җибәрегез әле, башлап үзем биим! – диде.

Хатын-кызлар ягында үзара пышаң-пышаң сөйләшүләр булып алды. Хәнифә кызларның әле берсе, әле икенчесе белән сөйләште. Аннан соң, арада оста уйнаучылардан Сәрвәр, Мәрвәр һәм шадра Мәрзия, башларыннан таракларын ала-ала, бер тирәгәрәк җыелдылар. Хәнифә Гөлсемне дә таракта уйнарга кыстый башлады. Ә Гөлсем, шәле белән нык кына капланып актарына-актарына, күкрәк кесәсеннән кубыз китереп чыгарды. Һәм чаршау кырыендагы тарак осталары янына барып басты. Аның кулындагы кубызны күргәч, уендагылар шатлыктан шау-гөр килеп, уен-көлке сүзләр әйтешә башлады. Гатау исә:

– Булды гына, гармунның кирәге дә юк хәзер безгә! – дип кычкырып җибәрде.

Гөлсем, иреннәрен матур гына бөрештереп һәм кубызны алгы тешләренә терәр-терәмәс кенә куеп, «Әпипә» көен уйнап җибәрде. Юка гына кәгазь куелган тарак тешләрен иреннәренә терәп, башка кызлар Гөлсемгә кушылды. Егетләр такмак әйтергә кереште.

Гатау шактый озак биеде. Аның белән башта Хәнифә, аннан Мәрьям җиңгәсе биеделәр. Ләкин ул һаман дәвам итте. Гөлсем, кубыз уйнаудан туктап, Гатау белән биергә төшү өчен җыена башлады. Ләкин, моны күреп, икенче яктан Сәрвәр төшеп тә китте. Ул шулкадәр ашыга иде ки, шәленең идәннән сөйрәлгән кырыена абынып, чак кына егылмыйча калды. Ләкин ул үзенең хатасын шунда ук төзәтте һәм, орчык шикелле бөтерелгәләп, матур гына итеп биеп китте. Кайберәүләр шактый ук кычкырып көлешеп алсалар да, такмак әйтүчеләр дәртләнеп-дәртләнеп дәвам иттеләр:

Әй икегез, икегез,
Икегезнең битегез,
Икегез дә пар килгәнсез,
Тигез гомер итегез.

Алар бик озак һәм кызып биеделәр. Гатау тиргә батты. Гөлсемнең Сәрвәргә

ачуы килде, ул кубызын киредән күкрәк кесәсенә салып куйды. Ә Сәрвәр, ул Гатауны аяктан егарга тели иде булса кирәк, һаман бөтерелепме бөтерелде. Таракта уйнаучылар да, шулай ук такмак әйтүчеләр дә тәмам арыдылар. Алар, көлешеп, берсенә иярә икенчесе акрын-акрын туктальп беттеләр. Ләкин Гатау белән Сәрвәр һаман биеде. Алар уйнаучыларның тукталуын да, кешеләрнең эчләрен уа-уа көлешүләрен дә сизмәде...

Шулвакыт, бөтен шау-шуны басып үтеп, кемнеңдер ачы тавышы ишетелде:

– Мулла килә, мулла-а!

Ябырылып тәрәзәдән карауччылар аның сүзләре дөрес икәнен раслады:

– Егетләр, мулла килә!

– Чукмар башлы яшел таягын болгый-болгый килә, егетләр!

Өй эчендәгеләрнең барысы да ишеккә атылды. Сәрвәр белән Гатау да, икесе бергә бөтерелеп, ишектән тизрәк чыгып калу өчен ашыгучы кешеләргә кушылып китте...

Шулай итеп, уен таралды.

## 21

Төн шактый гына салкын булып, җил искәләп һәм карларны себертеп тора иде. Пар ат җигелгән иң алдагы чанага, чана өстенә корылган чуар чыбылдык эченә кереп, Миңлебай белән Бәхтияр утырдылар. Гатау аларның кучерлары булды. Икенче һәм өченче чаналарга бәет әйтүгә яхшырак кушылырдай егетләрдән алтысы, дүртенче чанага бәетче Гыйльметдин һәм тагын ике егет, калганнарына да икешәр-өчәр кешедән урнаштылар.

Капканың тышкы ягында, урамда, бәет әйткәнне тыңлау өчен җыелган ирләр, хатын-кыз һәм бала-чагалар шаулый. Аларны ишетеп, бәетче Гыйльметдиннең йөрәге ярсый. Аның тизрәк бәетне башлап җибәрәсе килә. Менә кешеләр чаналарга урнашып беттеләр. Хисамыйның:

– Барысы да булды. Башласаң да ярый инде, Гыйльметдин энем! – дигән сүзләре ишетелде.

Урамда һәм ишегалдында халык тынып калды. Капканың ачылуын да көтмәстән, Гыйльметдин бәет[1] әйтә башлады.

Мөҗарибат якын ирде Диаим бән делләрем,
Рәхатендин җан гүзәл яшь Кызлари бән үтмәдем.

Мәгузәнең бәет әйткәнне тыңлап каласы килә иде. Ул, күзләреннән аккан кайнар яшь тамчыларын яулык почмагына сөртә-сөртә, байтакка кадәр капканы ачмый торды. Ул арада Гыйльметдин бәетнең яңа бүлеген әйтә башлады:

Бел яратмыш хак кәрима
Кызлар оҗмах нигъмәти,

– башкалар аны күтәреп алды:

– Мәюсән җиңгән егетләр
Таба җан тик ләззәти.

Мәгузәнең бирелеп тыңлавының чиге юк иде. Хисамыйга хатыны капканы

[1] Бәет – Халык шулай «бәет» дип атый иде. Казакъларның «Сәүлемай» көенә тартым, ләкин үзенә аерым бер моң белән әйтелә.

һичбер вакытта да ачмас кебек тоелды. Ул, тиз-тиз генә барып, Мәгузәне читкәрәк этәреп җибәрде һәм капканы үзе ача башлады. Бәет әйтүчеләрнең тамаклары һаман саен көйгә салына һәм дәртләре үскәннән-үсә барды:

Гөлбакчага чыгар таңда шәлен салып муенына,
Ихтыярсыз гашыйк булып гизләер сән куенына.
Иштиһа зәүкыни салыр кальбә нечкә билләри,
Хәйран итәр гаклымызный Зифа нәзкәй буйлари.

Бәет тыңларга килүчеләр берничә минутка тын калды. Алар, урам буенча өермәле кар тузгытып киткән чаналарның артларыннан карап, зур игътибар белән тыңлап тордылар. Тынлыкны беренче башлап Өчтерсәк Хәсәннең хатыны Сәлиха бозды:

– Нәрсәгә авыз ачып карап торабыз? Алар барыбер яңадан монда килмиләр инде!

Арадан берсе:

– Тик кенә тор әле, тыңлыйк! – дип, ачуланып әйтте.

– Сүзләре ишетелмәгәч, нәрсәсен тыңлыйсың инде аның?!

Кемнәрдер урыннарыннан кузгала башлады:

– Киттек Җәләй картларга!

– Әйдәгез, әй, малайлар! Мылтык атканны ишетми калабыз.

Төн йокыларын калдырып, бәет тыңларга килүчеләр кыз йортына таба киттеләр.

**22**

Җәләй картның өе тирәсенә бала-чага кичтән үк җыела башлаган иде инде. Кечкенә капка да, шулай ук зур капка да төбенә кадәр ачып куелган. Кеше шулкадәр күп, урам белән ишегалдын аерырга да мөмкин түгел. Олылар, төркем-төркем өелешеп, әңгәмә кора. Бала-чага ишегалдына үтеп керү өчен эткәләшә. Зур капканың бер ягында Өчтерсәк Хәсән, икенче ягында Габдулла – икесе дә мылтык тотып, кирәкле минут килеп җитү белән үк атарга әзерләнеп торалар. Өчтерсәк Хәсән янында аның бик күп сөйләшә торган хатыны Сәлиха тора. Ул, иренең колагына гына иелә-иелә, сүзләрен тизрәк әйтеп бетерергә теләгәндәй ашыгып, нәрсәләрдер сөйли. Менә кешеләр нәкъ дулкын шикелле чайкала башлый. Төрлесе төрле яктан:

– Киләләр, киләләр!

– Кияүләр килә! – дип хәбәр бирә.

Кешеләр кинәт кенә тынып кала. Алар чанада килүчеләр тарафыннан әйтелгән бәетне тыңларга керешә:

Җөмлә кайгым заел улды назина җар куенина,
Җаныңны фида әйләрсең ышбу кызның җулына.

Иң алдагы кияү чанасы Җәләй картның капкасы турына килеп тә җитте. Менә-менә атлар капка алдында өелеп торган кешеләрне бәргәләп һәм таптап ишегалдына кереп китәчәкләр дип уйларлык дәһшәтле күренеш туды. Хатын-кыз һәм бала-чагаларның кайберләре чыр-чу килеп читкә йөгерделәр. Әмма атларга турыдан-туры гына кереп китәргә ирек бирелмәде. Ике таза егет кияү чанасына җигелгән ике усал атның тезген һәм дилбегә башларыннан эләктереп алдылар. Егетләр, барлык көч һәм авыр гәүдәләре белән асылынып, атларның

башларын түбән ияргә, аларны ничек тә үзләренә буйсындырырга һәм киредән борып җибәрергә тырыштылар. Гатау белән Бәхтияр исә, дилбегәне каккалап һәм атларны чыбыркы белән куркытып, егетләрне җиңү һәм ишегалдына кереп китү өчен омтылдылар. Арттагы чаналар белән дә шундый ук хәл иде... Ләкин, нәкъ умарта кортлары һәм аларның аналары шикелле үк, барлык мәсьәләне кияү чанасының кайда булуы хәл кылганлыктан, әлеге ике таза егет янына тагын берничә ир һәм егет килеп булыша башлады...

Атларның, чыннан да, баш бирмичә кереп китүләре мөмкин иде. Өчтерсәк Хәсән белән Габдулла, үз урыннарында гына басып, мылтыкларын ату өчен әзер хәлдә тоттылар. Бу вакытта инде, халыкның аяк астына чәчү өчен әзерләнгән һәм зур агач табакка тутырылган бавырсакны алып, Хәнифә дә өйалды түбәсенә менеп басты. Ә бәетчеләр, боларның берсенә дә игътибар итмәгән кебек, бәет әйтүләрен һаман дәвам итте:

Мисле мәҗнүн кылды бәни
Бу гыйшыклык хәлләри,
Зәгъферан тик саргаепдур
Җан фәкыйрьнең йөзләри.

Атларны өч мәртәбә кире борып җибәрделәр. Егетләр үзләренең батырлыклары белән мактанышып, башка кешеләр шушы вакыттагы ыгы-зыгы кызыгыннан һәм бәет тыңлаудан кәефләнделәр.

Аһ, бәнем чын тәлимәм,
Догамыздыр ышбу яр,
Күрмәк өчен гөл йөзеңни
Газиз улдым би карар...

Кияү һәм бәет әйтүчеләр авылның һәрбер урамыннан икешәр һәм өчәр мәртәбә үттеләр. Авылда, туйның булуы турында белмәгән, кабат-кабат әйтелеп йөрелгән бәетне ишетмәгән кеше калмады. Атлар дүртенче мәртәбә килгән вакытта, Җәләй карт үзе чыгып, егетләргә бу уенны туктатырга кушты. Кешеләр барысы да, килүче атларга юл ачып, читән һәм койма буйларына сыендылар. Әйләнә-тирәне искиткеч тирән тынлык каплап алды.

Көчле дәрт белән әйтелгән бәет авазлары ерактан ук яңгырап ишетелеп килде:

Бакчадагы гөл чыбыкның
Башина был-был кунар,
Зифа егет гүзәл яргә
Кочаклашып буй сынар.

Беренче ат капкадан килеп керүгә, Өчтерсәк Хәсән белән Габдулла һавага таба мылтыктан атып җибәрделәр. Атлар, кинәт кенә сикергәләп читкә тайпылдылар да тагын алга ташландылар. Мылтыктан атучылар икенчесен корган арада ике-өч чана ишегалды уртасына кереп туктаган иде инде. Дүртенче ат капкадан кергән вакытта көчле ату тавышлары яңадан кабатланды.

Өйалды түбәсендә басып торучы Хәнифә дә эшкә керешкән иде инде. Ул, беренче ат капкадан кергәннән алып иң актык чана кереп туктаганга кадәр, ишегалдына һәм кешеләр өстенә бертуктаусыз учлап-учлап бавырсак сипте. Бәет тыңларга килүчеләр, ябырылып, берсен-берсе төрткәләшеп, җирдән бавырсак җыярга кереште...

Кияү озата килүче кодалар чаналарыннан озак төшмәде. Алар, кайсылары тезләнеп утырган, ә кайберләре чана өстендә аягүрә баскан килеш, берсен-берсе кочаклап яки берсенең иңөстенә икенчесе таянып, һаман бәет әйттеләр.

Бавырсакларның кар астына һәм чана араларына кереп югалганнарына кадәр эзләп алынды һәм көлешә-көлешә шунда ук ашалып бетелде. Шуннан соң гына кешеләр бәет әйтүче кодаларның чаналары тирәсенә җыелды. Кодалар уртада калды. Ишегалдында һәм урамда бәет тыңлау өчен кирәкле булган тынлык урнашты:

Суларыгыз эзгә үзгә, кулымда көмеш йөзек,
Күп илләрни гизеп йөреп тапмадым синдин төзек.
Гөлбакчада йөргән чакта, башмагыма кар тигән,
Рәхмәт төшсен әнкәсенә, сөйгәнеңә бар, дигән.
Иртә сөбхан җил исәдер, ярима сәлам, диген!
Мәхсудемез хасил улды, әлхәмделилла шөкер.

Шуның белән бәет әйтелеп бетте. Чана башына менеп баскан Бәхтиярның:

– Әссәламегаләйкем, кодалар! – дигән сүзләре яңгырап ишетелде.

Аңа каршы:

– Вәгаләйкемәссәлам! Әйдүк, хуш килдегез, кодалар!

– Әйдүк-әйдүк, төшегез чаналардан!

– Бик хуш килдегез! – дигән җаваплар кайтарылды.

Бу вакытта Миңлебай белән Бәхтияр өйалды ишеге янына барып басканнар иде инде. Бәхтияр ишеккә куллары белән тøрткәләп карады. Ләкин ишек ачылмады. Бәхтияр, үзе белән килүчеләргә мөрәҗәгать итеп:

– Монда әле, егетләр, килүен килдек тә, кайтып китәргә туры килер, ахры, – диде. Башкалар:

– Нәрсә, нәрсә бар тагын анда? – диештеләр.

– Ишекне ачмыйлар, кайтып китәргә туры килмәгәе, дим.

– Ачмасалар ни, тип тә ват! Анлык кына көч юкмы әллә синдә?

– Катып-туңып килгәч, ничек тә өйләренә кереп җылынырбыз инде, егетләр!

– Әйе, нәрсә булса да эшләргә кирәк.

– Бәхтияр үзе ишекнең телен белеп җиткерми торгандыр ул. Кая, үзем барыйммы әллә булышырга?

Шулвакыт ишекнең эчке ягыннан «Ишек бавы» җырын әйтүче кызлар тавышы ишетелде. Җырны Сәрвәр башлый, башка кызлар аңа кушылалар иде:

Ишек бавы бер алтын,
Безнең апай мең алтын,
Җылыныйм, дисәң, бер алтын
Бир, җизни, тыш бик салкын.

– Җизни килгән икәнен дә, тышның бик салкын булуын да беләләр, ә үзләре һаман кертмиләр, карагыз әле сез боларны, егетләр! Дөньяда шундый усал балдызлар да була икән тагын, – диде Бәхтияр. Ул ишекне тагын да катырак дөбердәтә башлады: – Ягез әле, кызлар, туңдырып бетердегез бит инде!

Ә кызлар берөзлексез үзләренекен җырлап торды:

Безнең апай гәүһәрдер,
Тәннәре чын мәрмәрдер,
Ләгыль, якут, гәүһәрдер,
Авызы балдыр, кәүсәрдер.

Зур дәүләт ич, җизни, бу.
Тагын моннан зур ни бар?
Торма малың кызганып,
Җан бирсәң дә урыны бар.

Бәхтияр ишекне тагын да катырак дөбердәтә башлады. Ул:

– Мәгез инде, кызлар, бүлешегез шунда үзара, – дип сөйләнә-сөйләнә, өйалды ишегенең өске ярыгыннан кызларга акча бирде.

Ләкин ишек һаман да ачылмады. Кызлар «ишек бавы» өчен акча сорауларын дәвам итте:

Бирсәң, күп бир син безгә,
Без разый түгел әзгә,
Яудыр алтын, көмештән,
Бакыр төрмә кәгазьгә.

Бәхтияр тагын ишек ярыгыннан акча сузды, һәм кызлар ишекне ача да башладылар. Әмма Бәхтиярның чамалап алып килгән акчасы бирелеп бетмәгән икән әле. Ул, кеше-кара күргәнче биреп калу теләге белән, калган берничә тиен акчасын тиз генә Сәрвәрнең кулына тоттырды һәм:

– Әй, кодача, алай ашыгып ачмыйлар аны! – дип, тегенең колагына гына пышылдап куйды.

Кунакларны бик зурлап һәм хөрмәт белән өйгә керттеләр.

**23**

Кунаклар сәкегә утырышты. Өчтерсәк Хәсән аш өенә кереп киткән иде, ул аннан кечкенә генә җиз ләгән белән гаять зур җиз комган тотып, иңбашына баш-башлары кызыл белән чигелгән киң һәм озын сөлге салып чыкты. Ләгәнне сәкенең уртасына куйды, аннан соң түр почмакта утыручы Миңлебайның алдынарак шудырды да:

– Кияүдән башлап җибәрик әле, – диде.

Ул шулай табындагыларның һәммәсенең дә кулларын юдырып, авызларын чайкатып чыкты...

Ашау әйберләреннән иң элек токмач килде. Токмачтан соң табак тутырып ит һәм уллама бишбармак яки алдама дип тә атала торган куллама, аннан соң кияү пилмәне һәм кияү бәлешләре китерелде.

Гадәт буенча үткәрелә торган туйларга туры китереп, Миңлебайдан башкалар һәммәсе дә өс һәм баш киемнәрен (түбәтәйләр генә үз урынында калды) салып утырдылар. Миңлебай исә, өй эчендә гаять эссе һәм бөркү булуга да карамастан, өстендәге соры чикмәнен һәм аның өстеннән киелгән кара җиләнен салмады. Җиләи өстеннән чорнап-чорнап куелган кызыл билбавын да чишмәде, башындагы камалы бүреген тагын да басыбрак куйды. Аның маңгаеннан һәм битләреннән бөрчек-бөрчек тир тамчылары агып торды. Чаршау артындагы кызлар, шаяртып, аның җилкәсенә инә белән чәнечтеләр. Ләкин Миңлебай бер сүз дә әйтмәде һәм чыраен да сытып күрсәтмәде. Кызларның сынауларына каршы ул түзәргә, бары тик түзәргә генә тиеш иде.

Бәхтияр, мәҗлесне күңелле итеп уздырыр өчен, үзенең барлык көчен салды. Чаршау артындагы кызлар да аның белән күбрәк шаярдылар, аңа һәрвакыт инә белән кадап, аны кычкыртып һәм сикертеп кенә тордылар. Бәхтияр, тәненә инә кадалган саен:

– Харап итәләр мине монда, егетләр! Бу Сәрвәр кодача бигрәк усал булып чыкты. Туйдырыйк әле шуларны бер, – дип сөйләнә-сөйләнә, аерым табак яки тәрилкәгә салып, кызлар ягына токмач, ит, пилмән чыгарып торды.

Калай табага катырылган баллы бавырсак иң актыктан китерелде. Аны чыгаручы Өчтерсәк Хәсән, подносны табын уртасына куйды да:

– Менә, кодалар, теләсәгез нәрсә эшләтегез! Пешерүе бездән булды, ашавы – сездән, – диде.

Бәхтияр аның масаюлы кыяфәтеннән көлеп җибәрде, һәм ул шунда ук кодасы белән «сатулаша» башлады:

– Ашавы сездән, дип соң, бу нәрсәне пычаксыз ашап булмый инде аны. Ашатасыгыз килсә, пычак китерегез!

– Бездә пычак юк шул инде, кода, гафу итәсез!

– Әле яңа гына бәлеш кискән пычак та ярый безгә. Үз кеше итеп кенә, син безгә шул пычакны чыгарып бир инде, Хәсән кода!

– Егет кешенең кесәсендә бер сум акча белән бер пәке йөрергә тиеш, диләр бит. Шуның шикелле...

Хәсән кодасы белән эш чыгарлык булмагач, Бәхтияр Миңлебайга карап сөйли башлады:

– Нишлибез соң инде? Монда, туганкай, синнән дә ныграк газапланып утырган кеше юк, берәр әмәлен табасыңмы әллә? Кактырып-суктырып та әйтеп куйдылар. Бер сум акчаны ишектән кергәндә биреп калдырдык... Синдә юкмы соң берәр пычак кебек нәрсә?

Миңлебай:

– Бер нәрсә бар иде бугай шунда, казан кыргычы сымак кына, – дип сөйләнә-сөйләнә, кесәсен актарырга кереште.

Аның кесәсеннән ялтырап торган ак калай саплы пәке чыкты. Бәхтияр, бу пәкене кулында әйләндерә-әйләндерә, озак кына мактап торды. Шул арада табындагыларның һәркайсысы өстеннән күз йөртеп чыкты да, пәкене бәетчегә сузып:

– Моны син башкарып чык инде, Гыйльметдин абзый! – диде.

Гыйльметдин табын аша үрелеп кенә пәкене алды. Күзләрен челт-челт йомгалап, ишек янындагы бала-чагага таба ияген һәм кып-кызыл түгәрәк сакалын кагып куйды. Пәкене малайларга күрсәтеп кенә алды да:

– Ай-һай, пәкесе лә пәкесе! Үзе көмеш саплы, үзе алтыннан ясалган икән. Моны кайнеләрнең кайсысы эләктерер икән? – дип сөйләнә-сөйләнә, баллы бавырсакны кискәләргә һәм кодалар алдына бүлгәләп куярга кереште. Сәлиха белән Хәнифә исә, түгәрәк чынаякларга каты гына чәй ясап, берәм-берәм кодалар ягына чыгарып тордылар.

Бүгенге көнгә карата Бәхтиярның тагын бер «зур» эше калды. Ул да булса, «үзе көмеш саплы, үзе алтыннан ясалган» пәкене «кемгә эндерек!» кычкыртырга кирәк иде. Бәхтияр ишек катындагы малайларга тиз-тиз генә аңлата башлады:

– Менә шулай. Мин: «Кемгә эндерек?» дип пәкене югары күтәрүгә, «Миңа эндерек!» дигән сүзләрне кайсыгыз элек кычкырса, пәке шуңа була... Кемгә эндерек?!

Ишек катында торучы балаларның һәммәсе дә берьюлы:

– Миңа эндерек! – дип кычкырдылар һәм пәкенең кемгә булса да бирелүен көтеп тора башладылар. Ләкин Бәхтияр пәкене тиз генә ычкындырырга теләми иде. Ул:

– Юк, булмады әле. Кайсыгыз алдан кычкырганны да белми калдым. Йә, кемгә-ә әндерек?

– Миңа-а әндерек! Миңа!..

Әмма уен малайлар өчен шактый ук күңелсез бетте. Малайлар янында, үзенең әле сөйләшә дә белмәгән баласы Хөсәенне күтәреп, Сәлиха тора иде. Туйның билгеле тәртипләре буенча, Мәрьямнең иң якын энесе шул Хөсәен булганлыктан, бавырсак пәкесе аңа тиеш иде. Бәхтияр да:

– Булмады, бу егетләр кычкыра да белми икән. Әнә Хөсәен, ичмасам, булдырды, – дип сөйләнә-сөйләнә, пәкене Хөсәенгә тоттырды...

Баллы бавырсактан бушаган подноска, хәлле-хәленчә дигәндәй, һәркайсысы үзенең өйдән үк әзерләп алып килгән акчасын салды. Бәхтияр, төрле уен-көлке сүзләр әйтеп, подносны Өчтерсәк Хәсәнгә алып бирде. Аның аш өеннән әйләнеп керүен көтеп торганнан соң:

– Ярый, егетләр, хуш иттек, – диде...

Кунаклар, яшьләргә исәнлек-саулык, бәхетле тормыш теләп, таралыша башлады...

* * *

Алар икәүдән-икәү генә калгач, бераз вакыт өй эчендә тирән тынлык хөкем сөрде. Гадәт буенча, беренче башлап Мәрьям чыбылдык эченнән чыгарга, Миңлебай белән ике куллап күрешергә һәм аңардан хәл-әхвәл сорашырга, ахыр килеп, Миңлебайның чуалтып-чуалтып бәйләнгән кызыл билбавын чишәргә һәм аның киемнәрен салдырып алып куярга тиеш иде. Ләкин, Сәлиха җиңгәсе кабат-кабат өйрәтеп кертүгә дә карамастан, ул гадәтләрнең барысын да шулай кушылганча гына эшләргә уңайсызланып, Мәрьям чыбылдык эченнән чыкмый торды. Барысын да шулай алдан кушканча гына итеп эшләү, ничектер, бик тә коры һәм гаять мәгънәсез кебек тоела иде аңа. Аның күңеле башкачарак бер хәл булуын көтә иде.

Миңлебай исә, шушы тынлыкның үзеннән аерым бер тәм табып һәм ләззәтләнеп, ишек янында баскан килеш кузгалмыйча гына торды. Ләкин ул берничә секундка, бары тик берничә секундка гына шулай түзә алды. Ул, бүреген салып сәкегә ыргытты да, маңгаендагы тир тамчыларын чикмән җиңе белән сөртә-сөртә, чыбылдыкка таба бара башлады. Менә ул барып җитте, менә ул чыбылдыкның бер кырыен ипләп кенә күтәрә башлады.

Нәкъ шул вакытта Мәрьям дә чыбылдык эченнән чыгып килә иде. Ул, шундый кинәт очрашудан сискәнеп куйды да, бер генә авыз сүз дә әйтмичә, Миңлебайның кочагына ташланды. Берсе өчен икенчесе утка керергә дә әзер торган ике яшь кешенең кайнар иреннәре бергә кушылды. Һәм алар, берсен-берсе кысып кочаклаган килеш онтылып, озак кына вакыт тын тордылар. Мәрьямнең күзләреннән шатлык яшьләре, кайнар һәм татлы яшь бөртекләре акты. Ул, Миңлебайның көчле күкрәгенә башын салып, балаларча гамьсез һәм эчкерсез иркәләнү белән аңа сыенды, акрын-акрын гына аның куенына сеңә барган кебек булды...

## 24

Җәләй карт кияве белән кызын кунак итүгә бер атна, аларның килеп-китеп йөрүләренә бер ай вакытны чамалап, шул турыда Хисамый кодасы белән дә сөйләшеп куйган иде. Ләкин аңа үзенең бу уйларын тормышка ашырырга мөмкинлек булмады.

Миңлебай белән Мәрьямне «кияү мунчасы»на уяткан вакытта таң да атып җитмәгән иде әле. Мунча Җәләйнең үз ишегалдында гына булганлыктан, кияү белән кызны илтер өчен ат җигүнең кирәге булмады. Шулай да, кияү җиңгәсе Сәлиха аларны мунча ишегенә кадәр озата барды. Ул, яшьләр уйный-көлә мунчага кереп киткән вакытта:

– Оза-ак итеп, рәхәтләнеп керегез! Эссесе дә бик һәйбәт, суы да җитәрлек, – дип, үз хезмәтен үзе мактап калды.

Миңлебайлар чыккач, Сәлиха тиз генә мунчага керде. Мунча яккан җиңги өчен дип, кияүнең тәрәзә төбенә куеп калдырган бер сум акчасын алды. Мунчаны яхшылап җыештырды. Шуннан соң мунчага Бәхтияр белән Хәнифә киттеләр.

Кода-кодачаларны кияү мунчасына кертү эше кояш чыкканга кадәр дәвам итте. Өчтерсәк Хәсән берөзлексез ат белән йөреп, тиешле кешеләрне ташып торды. Ләкин Хисамый белән Мәгузә кияү мунчасына килмәделәр. Моны ишеткәч, Сәлиха төкерекләрен чәчә-чәчә ирен тиргәргә кереште:

– Алар ни өчен шулай итәләр, дисең? Барысы да синең аңгыралыктан. Кем дә кем төп кода белән кодагыйны адәм актыгына калдыра? Әйттем бит мин сиңа, кияүләрдән соң ук кода белән кодагыйга әйтик, дидем.

Хәсән:

– Мин аларга яхшылык ягыннан уйладым бит. Артык кызу мунча карт белән карчыкка ярамас, дип.

Хатыны аңа тынын алырга да ирек бирмәде:

– Уйладым да уйладым! Мондый вакытта уйлап кына калмыйлар аны. Үзләреннән сорарга иде... Юк, мин моны өйдәгеләргә кереп әйтә алмыйм. Бар, ничек кенә итеп булса да алып кил үзләрен!

Хәсән аларга өч мәртәбә барды, ләкин Хисамый һаман үзенекен әйтте:

– Без бара алмыйбыз, кода! Бу бер дә үпкәләүдән түгел. Уйламаган зур кайгы килеп чыкты. Җәләй кода үзе безгә килсен дә, аның белән аңлашып аласы эшләребез бар.

Шулай итеп, бу мәсьәлә зурга күтәрелде. Сәлиха уйлаганча шома гына үтеп китмәде. Бу турыда Җәләй картка әйткәч:

– Хисамый кода алай мунча-мазар өчен генә үпкәләп йөрмәс. Нәрсә булса да башка берәр эш бардыр, – диде дә, тиз-тиз генә киенеп, ашыга-ашыга чыгып китте.

Ул киткәч, Мөршидә Сәлихадан сакланып кына сорап куйды:

– Әллә кияү белән Мәрьямнең арасы бозылганмы, килен? Араларында ул-бу хәл сизмәдеңме?

– Юк-юк, җиңги, ул турыда уеңа да китерә күрмә! Киявебез бик матур, бик күңелле генә йөри.

Мөршидә карчык, авыр гына көрсенеп:

– Шулай була күрсен инде, йә Рабби! – диде.

Озакламый, Хисамый кодасын ияртеп, Җәләй үзе дә әйләнеп кайтты. Сәлиха аларны тәрәзәдән күреп калды һәм тиз генә чыгып китте. Мөршидә яулыгы белән йөзен каплады, киштәдә элүле торган чаршауны төшереп, үзе почмак якта бүленеп калды. Тегеләр ишектән килеп кергәч тә, ишетелер-ишетелмәс кенә тавыш белән:

– Әйдүк, кода, исән-сау гына торасызмы? – диде.

Хисамый сәке кырыена барып утырды. Ул, сүзне бәлки Җәләй кодасы үзе башлар дип көтеп торганнан соң:

– Бик күңелсез хәлләр бар әле безнең, кодагый, – дип сөйләргә керешге. – Менә Миңлебай киявегезгә, берсекөнгә хезмәткә китәргә дип әйтеп язу килеп төште. Берәр айсыз да китмәс әле дип уйлап йөри идек, – диде.

Мөршидә тыела алмыйча үксеп елый иде инде. Ул, күз яшьләрен алъяпкыч итәге белән сөртә-сөртә:

– Ходаем! Бәхетсез балалар! Куй инде, бу кадәр боларга гына туры килеп торыр икән, – диде.

Җәләй карт башта аны юатып карады. Мөршидә алай да тыелмагач:

– Син, әнисе, үзеңнең хатынлыгыңа барма әле! Еламагаең, гомерең буена улап торсаң да, безнеңчә булмаячак бит, – дип тиргәп тә, үпкәләп тә әйтте. – Менә шушы ике көн эчендә нәрсә эшләргә? Туйның эшен ничек итеп бетереп алырга? Ана кеше булсаң, син менә шуны әйт!

Хисамый да Җәләй әйткәннәрне куәтләде:

– Кодагый, һәркайсыбызга да уңайсыз инде бу хәл. Ни эшләмәк кирәк бит, авыр булса да түзәргә туры килә.

Ул, сүзен бүлеп, бераз гына уйланып алды. Аннан соң, бер Җәләйгә, бер Мөршидә ягына карап, дәвам итте:

– Минем уемча, килен төшереп, туйның эшен бетереп алу яхшы булыр иде. Вакыт бик кысынкы инде кысынкысын. Бары белән әмәлләрбез әле шунда...

Мөршидә елавыннан тукталырга тырышты. Ул, ирексезләп аккан күз яшьләрен яулык почмагына сөртә-сөртә:

– Килен төшерүне калдырып торсак та инде... Ике йорт арасында йөрер иде әле шунда, Мәрьямне әйтәм, – диде.

– Алай итәргә ярамый! – дип, хатынына каршы төште Җәләй.

– Әйе, килен төшерми калсак, бик күңелсез була ул, – диде Хисамый да. – Дус-дошман арасында да яхшы түгел. Ул бит, киявегез, бүген барып иртәгә кайтыр өчен генә китми. Өч елга китә, нәкъ өч елга!

– Аптыраганнан әйтүем инде, кода, күңелеңә авыр ала күрмә тагын. Ничек итеп әйтсәң дә, вай инде моңа, – диде Мөршидә.

Җәләй, мәсьәлә тәмам хәл кылынган кебек кискен генә:

– Мондый хәл булгач, кеше гайбәте, фәләне-фәсмәтәне дип торып булмый инде, кода. Мөмкин булган хәтлесен генә әзерләнерсез дә, иртәгә бетереп тә алырбыз. Без дә күп кеше җибәрмәбез...

Бу вакытта, аларны картлардан бер генә стена аерып торуга карамастан, Миңлебай белән Мәрьям бернәрсәдән дә хәбәрле түгелләр иде әле. Миңлебай, кайнар тары коймагы белән чәй эчкәннән соң, чыбылдык эчендә рәхәт кенә хәл җыеп ята. Мәрьям чынаякларны почмак якка чыгарып йөри иде. Мәрьям, әле «әй» дип тә, «әтисе» дип тә әйтергә күнекмәгәнлектән, Миңлебайны берничек тә атамыйча гына сорау бирде:

– Сине бик тиз җибәреп куймаслар микән инде?

– Кимендә бер ай тотарлар әле. Бәлки, безнең бәхеттән, биш-алты айга да сузарлар. Кайбер елгыларны шулай соң да алалар бит.

Мәрьям, Миңлебайның биш-алты айга калуы тәмам хәл кылынган шикелле аңлап:

– Әмма шулай булса! Әмма сине тагын бер елга калдырып куйсалар! – диде.

Нәкъ шулвакыт, Миңлебайның берсекөнгә китәчәк икәнен әйтү өчен, алар янына Сәлиха керде...

**25**

Төш вакытлары якынлашты. Ишегалды һәм капка әйләнәсе туй карау өчен килгән кешеләр белән тулды. Кинәт кенә:

– Киләләр, киләләр!

– Килен килә! – дигән тавышлар әйләнә-тирәне шаулатып җибәрде. Малайларның берсе, шул арада йөгереп барып, капканы ачып та куйды. Гатау:

– Капканы ачарга кем кушты сезгә? Әле беренче килүдә генә кертәләрмени! – дип, бала-чаганы тирги-тирги капканы ябып куйды.

Иң алдагы килен чанасына Җәләйнең карт чабышкысы белән Лор-Лор Ситдыйкның көрән аты парлап җигелгән. Алар, җиңел генә җил капканы бәреп кереп китәрдәй булып, туп-туры Бәхтияр белән Гатауның өстенә килә башладылар. Бәхтияр тиз генә аларның тезгеннәреннән эләктереп алды, сул кулындагы мылтыкны Гатауга сузып, атларны киредән урамга борып төшерә башлады. Ат башында унике-унөч яшьләр тирәсендәге юаш кына бер малай иде. Ул өйдән үк өйрәтелеп җибәрелгән булса кирәк, Бәхтиярның кыланышларына аның бер дә исе китмәде. Киресенчә, атларны яңадан урамга борып төшерүдә ул үзе Бәхтиярга булыша башлады.

Миңлебай белән Мәрьям чыбылдык эчендә иде. Бәхтияр, үзенең шаян сүзләрен аларга да ишеттерергә тырышып:

– Барыгыз әле, бераз туңыбрак килегез! – дип кычкырып калды. Аннан соң янындагы малайларга борылып:

– Менә инде капканы ачып җибәрсәгез дә була, – диде.

«Таянчык бозавын» Барый, Миңлебайның кече энесе тотарга тиеш иде. Ләкин ул, Барый, кечкенә генә ябык ала бозауны лапастан алып чыга алмыйча аптырап бетте. Тагын аз гына азапланса, Барыйның кычкырып елап җибәрүе, ә бавырсак чүпләргә килгән малайларның аңардан көлүләре, аны мыскыл итүләре мөмкин иде. Моны барысыннан да алда Сәрвәр күреп өлгерде. Ул:

– Һай-й, үземнең кечкенә генә акыллы кодамны берсе дә күрми, – дип сөйләнә-сөйләнә, Барыйның күңелен күтәреп, бозауны чыгаруда аңа булыша башлады.

Күңеле белән һәрвакыт Сәрвәрне эзләп, күзләре белән аның һәрбер хәрәкәтен күзәтеп, адым саен аңа сокланып йөргән Гатау, уңайлы мәлдән файдаланырга һәм Сәрвәргә нәрсә булса да әйтергә, берәр сүз кушарга, күңелендәген аңа сиздереп, аңлатып калырга теләп, кызу-кызу гына Барый белән Сәрвәр янына барды.

Сәрвәр, Мәрьям апасы шикелле үк килешле генә таза тәнле, ак чырайлы, сызылып кына торган нечкә кара кашлы, куе соргылт күзле бер кыз булып, Мәрьямгә караганда шаянрак, һәрвакыт шат күңелле һәм уйнап-көлеп йөрергә яратучан. Аның аз гына кыланыбрак, шул ук вакытта үзен-үзе түбәнсетмичә бераз гына эрерәк тотып сөйләшүендә дә, көйдереп алырлык итеп карый торган үткен күз карашында да Мәрьям белән нык охшашлык бар. Бишмәтсез генә, күкрәген кабартарак төшеп, Миңлебай төрмәдән котылып кайткан көнне Мәрьям сөенечкә биргән укалы камзул өстеннән ак алъяпкыч бәйләп йөрү аңа бигрәк тә килешә. Мондый вакытларда Гатау аны тагын да ярата, аңа тагын да соклана төшә, аңардан күзләрен ала алмыйча, озаклап-озаклап карап тора. Моны Сәрвәр үзе дә яхшы сизенә. Һәм ул, юри Гатауның күзләрендә ут уйнатыр өчен, бишмәтсез генә һәм күлмәк җиңнәрен сызганып, тыгыз беләкләрен күрсәтеп йөри.

Ә менә хәзер, салкында, аның беләкләре кып-кызыл булып, тагын да

матурланып торалар. Гатау, лапастан бозау чыгарышуда булышкан булып, Сәрвәрнең уң беләгеннән кысып кына тотып алды. Сәрвәр Гатауның бу кыланышына һичбер каршылык күрсәтмәде. Ул беләген һаман элекке урынында, бозауның аркасында килеш калдырды. Аның соргылт күзләре матур һәм бәхетле елмаялар иде. Гатау, мондый вакытта сүзсез калырга ярамый, нәрсә булса да әйтергә кирәк дип уйлаганлыктан гына:

– Салкын тидерерсең, кодача! Өстеңә киеп йөрергә кирәк, – дигән булды.

Сәрвәр ягымлы гына елмаеп, беленер-беленмәс кенә башын чайкап һәм авыз кырыен тартып куйды. Бу аның: «Ю-юк, кода, мин салкынның нәрсә икәнен дә белмим», – дигән мәгънәне аңлатуы иде.

Шулвакыт малайларның:

– Киләләр, киләләр! – дип кычкырган тавышлары ишетелде.

Сәрвәр бозау яныннан китәргә теләде. Ләкин, беләгеннән кысып тоткан килеш, Гатау аны җибәрмәде. Сәрвәр бу юлы да аңа телдән җавап кайтармады. Башта елмаеп кына карап куйды. Аннан соң, лапас эчендәге тирес өеменә таба ымлап, күзен кысты һәм кашларын уйнатып алды. Бу: «Озакламый мин җыештырырга чыгам, ә син шунда килеп мине көтеп торырсың», – дигән сүзе иде аның. Гатау да моны шулай аңлады һәм кызның беләген шунда ук ычкындырды. Аның кып-кызыл беләгендә юл-юл ак таплар булып, Гатауның бармак эзләре төшеп калды. Сәрвәр, ишегалдындагы кешеләр күрмәсен өчен, беләгенең шул урынын сул кулы белән каплады да, кош тоткандай куана-куана йөгереп, аш өенә кереп китте.

Капкадан атлар керә башлады. Бәхтияр бер-бер артлы ике мәртәбә мылтыктан атты. Атлар, мылтык тавышыннан куркышып, берсен-берсе тыгызлап туктадылар. Өйалды түбәсендәге Хәнифә атлар һәм кешеләр өстенә бавырсак сипте...

Бу арада Гатау белән Барый да лапастан чыкты. Алар «таянчык бозавын» килен чанасы янына илтеп туктаттылар. Гатау, үзе генә тотмаганы өчен энесенең күңелсезләнүен күреп, бозауның муенчак бавын чана үрәчәсеннән эләктереп алды да Барыйга тоттырды. Ә үзе бераз читкәрәк китеп басты.

Бәхтияр, кар өстенә егыла-егыла бавырсак җыйган кешеләрне көч-хәл белән аралап үтте дә артлы чана өстенә корылган чыбылдыкның бер кырыен ачып җибәрде.

– Әйдүк, кунаклар, сау-сәламәт кенә килдегезме? – диде.

Миңлебай, дусларча елмаеп кына:

– Бик һәйбәт әле, үзегез сәламәтме? – диде һәм чанадан төшү өчен урыныннан кузгалды.

Улының китүе кайгысыннан Мәгузәнең йөзенә сары коелган, күз төпләре кара көеп калган, аның йөрерлек тә хәле юк иде. Аны өй ишегеннән килен чанасына кадәр Гатау җитәкләп китерде. Ана, авыру кешенең интегүле юаш тавышы белән сузып:

– Нихәл, килен, исән-сау гына килдеңме? – диде.

Мәрьям әле һаман да чанада утыра иде. Ул биеме килеп исәнләшкәч кенә урыныннан кузгалды. Аның белән ике куллап күрешә-күрешә:

– Аллага шөкер әле, үзегез исән-сау торасызмы? – диде.

Мәрьям, бер кулы белән Мәгузәнең иңбашына, икенчесе белән ала бозауга таянып, чанадан төште. Бишмәт кесәсеннән кечкенә генә бер төенчек алды. Бу төенчектәге көмеш тәңкәләр белән бизәлгән күкрәкчәне ул биеменә, ап-ак дебет перчатканы таянчык тоткан Барыйга бүләк итте.

Инде хәзер Мәрьямнең өйгә керәсе, үзе килен булып төшкән йортның бусагасын

беренче мәртәбә атлап үтәсе калды. Аның кулында – ал, сары, зәңгәр ефәкләр белән чукланган зур гына ак кульяулык. Монысы, бием һәм биатай бусагасыннан беренче атлап керү истәлеге итеп Миңлебайга биреләчәк бүләк. Мәрьям әнә шул кульяулыкны бишмәт җиңеннән чыгару белән, аңа өйгә керер өчен юл ачып, кешеләр тиз генә як-якка тайпылды. Миңлебай кульяулыкның бер почмагыннан тотып алдан, Мәрьям исә, икенче почмагыннан тотып аңа ияргәне хәлдә, алар өйгә кереп киттеләр. Кияү белән килен артыннан кодачалар, алар артыннан кодалар керде...

Мәҗлеснең башыннан алып ахырына кадәр – кодалар ягында да, шулай ук кодачалар ягында да – сүз Миңлебай турында, Мәрьям турында, аларның бик кызганыч рәвештә, туйлары да бетеп җитмәс борын аерылулары турында барды...

Мәрьямнең, ефәк күлмәк киеп, әллә нинди шәһәр хатын-кызлары шикелле эчке киемнәрен кешегә күрсәтеп йөрисе килми иде. Ул, Хәнифә ахирәте аша сүз җаен туры китереп кенә:

– Илдә-көндә булмаганны кыланып, кеше көлдереп булмас инде анысы, – дип ишеттерде.

Мәгузә карчык та:

– Нишләп яратсын ул аны? Акылсызмыни ул – ефәк күлмәк киеп, гәүдәсен сурайтып йөрергә?! – диде.

Моннан ун ел элек, ат чабышы вакытында, Җәләй карт Миңлебайга бүләк иткән күлмәклек ефәкне, авылда алучы булмагач, Оренбург шәһәренә илтеп саттылар. Аның урынына җете зәңгәр өстенә саргылт бизәкләр төшкән ситсы алып, изүенә әйләнмәле-әйләнмәле укалар тоткан, ука әйләнмәләре өстеннән тәңкәләр тезгән һәм җиде итәкле итеп тегелгән күлмәк, Мәгузә карчык әйтмешли, бик затлы һәм күңелгә ятышып торган бүләк, кияү бүләге әзерләделәр.

Мәрьям бүген әнә шул матур гына бүләк күлмәген киде, аның өстеннән «кетердәп торган» ап-ак алъяпкыч бәйләп алды. Кунак булып бер-ике чынаяк кына чәй эчте дә, күлмәк җиңнәрен аз гына сызгана төшеп, кызу-кызу эшкә кереште. Ул – үзен озата килгән агалары, җиңгәләре алдында эш белән сыналырга, үзе камырын басып һәм токмачын кисеп ашын өлгертергә, чәен куеп эчерергә тиеш иде.

Киленгә су юлы күрсәтәбез дип, Мәрьямне бүген суга җибәреп азапламадылар. Әмма өй эчендәге эшләрнең берсендә дә ул сынатмады. Нәрсәгә генә тотынса да, куллары килешеп, ал да гөл итеп эшләп куя иде.

Яшь киленне шаярту, бүләк бирмәгән яки аз биргән өчен дип, җәеп куйган токмачын үзе күрмәгәндә ертып китү кебекләр, гадәттә, Мәрьям шикелле уңган килennәргә карата да эшләнә. Әмма Мәрьямне алай шаяртып йөдәтүләр һич тә булмады. Мәгузә карчык:

– Киленнең болай да борчулы вакыты. Аның тирәсендә чуалып йөрисе булмагыз. Аңарда сезнең кайгы гына түгел, – дип, Гатауын да, Барыен да, башка туган-тумачаларының бала-чагасын да алдан ук кисәтеп куйган иде.

## 26

Ә менә хәзер төн. Тышта җил дә, буран да юк. Ләкин чатнама суык. Бу – тәрәзәләргә каткан боздан да, өй бүрәнәләренең шартлап-шартлап куюыннан да аңлашыла.

Әмма өйдә җылы, хәтта эссе. Төннең-төне буенча алар сөйләшеп, берсен-берсе иркәләп һәм юатышып чыктылар. Алар икесе бер түшәктә, икесе дә бер юрган астында. Миңлебай чалкан яткан, Мәрьям аның киң күкрәгенә башын салган да, аңа иркәләнеп, бөтен буе белән аңа сыенган. Аларның ялангач тәннәре бер-берсенә тиеп торудан рәхәт таба.

Алар таң алдыннан гына йокыга киттеләр...

Мәрьям ишекне каты гына дөбердәткән тавышка уянды. Миңлебай, бер кулы белән Мәрьямнең муены астыннан, икенчесе белән аның күкрәк өстеннән уратып алып кочаклаган килеш, тирләп кенә йоклый иде. Мәрьям күзләрен ачты. Ул үзенең кайда булуын, башыннан нинди хәлләр кичүен хәтерләргә тырышты.

Бу – Миңлебайларның зур өе иде. Кичә кич белән Мәрьямгә үз урыннарын шушы өйгә җәяргә куштылар. Башкалар аш өендә йокларга булып, тик Гатау гына үзенең дус-ишләреннән берәрсенә барып куну өчен дип урамга чыгып китте. Мәрьям боларны башын юрган астыннан чыгарып карау белән үк хәтерләп алды.

Яшь килен бүген бик иртә торырга, мунча ягып, бием белән биатайны хөрмәтләргә, алар мунчадан чыгышка ашын әзерләргә һәм чәен кайнатып торырга тиеш иде. Болар турында уйлагач, Мәрьямнең күңеле куркып куйды. Ләкин ул шунда ук Хәнифә ахирәтенең вәгъдәләрен хәтерләде. Кичтән үк ул:

– Мунча миченә үзем ут төртеп җибәрермен. Гатау мичкә белән су китерер. Син инде, ахирәткәем, тыныч кына йокла, болай да рәхәтләнеп тора алмадыгыз, – дигән иде.

Ишек кагу тавышын ишетеп урыныннан кузгалган вакытта Мәрьям шуларны исенә төшерде. Һәм ул:

– Нәрсә генә булды икән? Оятка гына калмасам ярар иде, – дип борчылды.

Ишек кагу тагын кабатланды. Мәрьям, Миңлебайны уятмаска тырышып, аның кулын үзенең күкрәге өстеннән акрын, бик акрын гына алып куйды. Юрган астыннан шуышып кына чыгып, өстенә күлмәген, ялангач аягына гына киез итеген киеп алды. Башына шәлен каплады да ашыга-ашыга ишеккә таба китте. Ишекнең эчке келәсен ачып, тиз генә өйалдына чыкты.

Ишек кагучы Хәнифә икән. Ул, Мәрьямне күрүгә аны кочаклап алып:

– Йә, ахирәтем, исән-сау гына йокладыгызмы? Әбәү, җаным, әле тәнеңдәге тирләрең дә кипмәгән икән, – диде.

Мәрьям, Хәнифәнең бишмәт суыгыннан чымрап киткән тәнен куырып:

– Хай, ахирәт, син дә иртәрәк уятмагансың! – диде.

Хәнифә аны тынычландырырга ашыкты:

– Юк-юк, ахирәт, бер дә хафаланма! Мунчаны үз вакытында булдырдым. Күптән үк керә дә башладык инде. Хәзер этиеңнәр кереп ята.

– Шуңарчы уятмагансың икән! Аш-су яклары ничек соң?

– Барысы да әзер. Тизрәк киенегез дә, этиеңнәр артыннан мунчага сез барырсыз...

Мәрьям, ишек тоткасына кулын салып:

– Рәхмәт инде, ахирәт, бу яхшылыкларыңны гомеремдә дә онытмам, – диде дә, ишекне акрын гына ачып, өйгә кереп китте.

Миңлебай һаман йоклый иде әле. Мәрьям аның киң маңгаен каплап торган коңгырт куе чәченә, сулыш алган саен калкып, сулыш чыгарган саен түбән тартылып кузгалгалап торган көчле күкрәгенә карап, берәр минут уйланып торды. Мәрьям аны уятырга, аны шундый тәмле йокысыннан аерырга кызгана иде.

Менә Мәрьям аның янына утырды. Ул, сизелер-сизелмәс кенә итеп, Миңлебайның тир белән юешләнгән маңгаен һәм каты гына чәч бөдрәләрен үпте. Аннан соң:

– Йә, торасыңмы инде? – дип иркәләп кенә әйтте.

Миңлебай акрын гына күзләрен ачты, һәм Мәрьям аны кулларыннан тартып торгыза башлады...

Алар мунчадан чыкканчы, Җәләй белән Мөршидәгә чәй эчерә тордылар. Хисамый, Җәләйнең чынаягына чәй ясап бирде дә:

– Заманалар бик үзгәреп китте хәзер, кода, авырлашып китте! Ярлы казачиларның хәлен патша белми микәнни? Күр инде, кичә туй, бүген хезмәткә, – диде.

Җәләй карт сакланып кына әйтеп куйды:

– Кеше сүзенә ышансаң, кода, әллә нәрсәләр бар хәзер дөньяда. Күрәсең, патшаның үз хәле дә мөшкел булса кирәк... Фатыйма кодачаның иреннән хат бар, диме?

– Әйе, хат та килгән, яныннан кеше дә кайткан. Ул Япон сугышыннан каты гына яраланып чыккан. Сәламәтләнү белән аны кайсыдыр бер ерак шәһәргә җибәргәннәр. Ә анда ике айдан артык эшчеләр чуалышы бара икән. Менә шунда, тегеләрне тәртипкә салу өчен, казачилар кирәк булган.

– Аның елы да тулды бугай инде? Кайту турында әйтмәгәнме соң?

– Юк. Хәзергә Оренбурга гына кайткан әле. Менә шул буталышлар булып торгач, кайту яклары да кыен күрәсең инде. Фатыйма ире янына киткән бит, шуңа күрә туйга да килә алмады.

Шулвакыт шыгырдап капка ачылды. Кем дә булса урыныннан кузгалып тәрәзәдән карарга да өлгермәде:

– Өйдәләрме-е? – дигән калын тавыш ишетелде.

Бу – авылның урядныгы Великороднов Степан Степанович иде. Хисамый, башына бүреген, аягына кыска кунычлы киез итеген киеп, бишмәтен җилкәсенә генә салды да, ишегалдына чыкты. Урядник аны күрү белән үк:

– Нусс! Хисамый Фатыйхович, Миңлебай чыгып киттеме әле? – дип сорады.

– Юк әле, господин урядник, җыенып бетә алмадык әле.

Урядник атының тезгеннәрен тарткалап куйды. Аның озын торыклы биек җирән аты тыпырчынып, бер алга таба ымтылып, бер исә артка чигенеп алды. Урядник:

– Бер минут та торгызасы булмагыз, Хисамый Фатыйхович! Башка авылныкылар үтеп китте инде. Безнекеләр дә хәзер чыгып бетәләр. Иртәгә иртә белән Оренбургта булырга кирәк аларга.

Урядник килеп киткәннән соң, аш-суның тәме һәм ләззәте югалды. Ашыгыч рәвештә Миңлебайны озату чараларын күрү, кайгырып елашулар башланды. Бәхтияр белән Гатау, атларны юлга әзерләп куярга дип чыгып киттеләр.

Мунчадан соң, Миңлебай белән Мәрьям дә килеп керделәр.

– Әйдә, улым, утыр! – диде Хисамый. – Килен дә ашап-эчеп алсын. Әле генә урядник килеп китте.

Җәләй, сөяк кимереп майланган кулларын тастымалга сөртә-сөртә:

– Син инде, кияү, уңны-сулны аера белә торган кеше. Үзеңә кирәген үзең аңлап, хезмәтеңне яхшы гына үткәреп кайтырга тырыш. Безгә дөнья малы кирәкми. Әнә, барысы да сезгә кала...

Бераз вакыт тын гына ашап утырдылар. Аннан соң Миңлебай:

– Әти, мин үзем генә китәрмен микән, берәрсе озата барырмы? – дип сорады.

– Килен белән Гатау Оренбурга кадәр озатып кайтырлар, – диде Хисамый. Тәрәзәдән үрелеп кенә карап алды да: – Әнә, Бәхтияр Җәләй коданың атын җигеп алып килде. Килен белән син чанага утырырсыз, Гатау синең атка атланыр...

Миңлебай белән Мәрьям юл киемнәрен киенеп алдылар. Мәгузәнең аларны озата чыгарлык хәле юк иде. Авыру ана улын үз янына чакырып китерде дә, аны муеныннан кочаклап алып:

– Исән-сау гына йөреп кайтырга язсын инде, балам! Шушы яшеңә кадәр дөнья рәхәтен күреп үсмәдең инде, – диде дә үксеп елап җибәрде.

## 27

Миңлебай Мәрьям янына чанага менеп, аның белән бер юрганга төренеп утырды. Гатау исә, күңеленнән бик риза булып, Миңлебай абзыйсының яхшы иярле атына атланып алды. Кулындагы җиз башлы зур камчыны селеккәләп, авылдан чыкканчы кешеләргә күрсәтеп һәм очынып барды.

Башка авыл егетләре Красногор күперен үткән һәм текә генә биек яр буендагы зур авылга якынлашып баралар иде инде. Миңлебай аларны куып җитәргә ашыкмады. Ул, егетләргә якынлаша башлагач та, дилбегәсен тартарак төште. Карт җирән чабышкы, шунда ук юыртуыннан туктап, акрын гына атлап бара башлады.

Төнге тынлык хәзер юкка чыккан. Каршы яктан салкын җил исеп, юл буенча карны себертеп тора. Мәрьям Миңлебайның аяклары тирәсендәге юрган кырыен кыстыргалап куйды, ә үзе аңа тагын да якынрак сыенды. Ул, чеметеп-чеметеп ала торган ачы җилдән капланып, битләрен Миңлебайның күкрәгенә куйды.

Атларга атланып алдан баручы егетләрнең һәммәсе дә исерек. Анда руслар өчен русча, татарлар өчен татарча көйгә гармун уйнап баручылар да бар. Миңлебай белән Мәрьямгә һәр ике гармунның да өзек-өзек авазлары гына ишетелеп, колак төпләрендә кышкы салкын шикелле үк шыксыз «гоңгылдау»лар яңгырап тора. Гармун тирәсендәгеләрнең кычкырып җырлаулары ишетелә.

Җырны яхшырак тыңлау өчен дип, Мәрьям акрын гына башын күтәрде. Шулвакыт Миңлебай аңа елмаеп кына карап куйды. Ләкин Мәрьямгә бу елмаю һич тә ошамады. Миңлебайның җитди кыяфәтенә мондый ясалма елмаю бөтенләй килешми иде. Бу елмаюдан аның битләре һәм күз тирәләре җыерчыклана, күз карашы юашлана һәм ул үзе кызганыч бер хәлгә керә. Мәрьям, яшь белән бозланып каткан озын керфекләрен төшереп, яңадан Миңлебайның күкрәгенә йөзен салды.

Атлылардан дүрт-биш кеше, ниндидер онытылган әйберләрен кинәт хәтергә төшергәндәй итеп, тиз генә артка борылдылар. Шулар арасыннан ук берсе, гармунчыга таба камчы изәп, нәрсәдер кычкырды. Аның әллә нинди начар сүзләр кушып сүгенүе ишетелде. Гармунчы һәм башка кайбер егетләр дә тукталып көтә башлады.

Җирән чабышкы аларга атлап кына барып җитте, һәм егетләр Миңлебай белән Мәрьям утырган чананы як-яктан камап алдылар.

Алар һәммәсе дә Алабайтал авылы егетләре булып чыкты. Барысы да форма буенча тегелгән хезмәт киеменнән. Өсләрендә мамыктын сырып эшләнгән күк гимнастёрка, ботларында шундый ук сырган чалбар, башларында зәңгәр тасмалы күк фуражкалар. Аякларында күн итекләр.

Алардан берсе:

– Ә-ә, Миңлебай! Син нәрсә, болай юрганнарга төренеп туйга барасыңмы әллә? – дип кычкырып җибәрде. Калганнары шаркылдап һәм Миңлебайны мыскыл итеп көлештеләр.

Арттан икенче бер калын тавыш:

– Бирегез әле миңа шунда үтәргә! Нәрсә ул анда суфыйланып бара? – диде.

Ул, атының тезгеннәрен тарткалап, алга үтә башлады. Аның зур гәүдәле кара аты, киң күкрәге белән башка атларны этәрә-этәрә чанага якынлашты.

Миңлебай аны тавышыннан ук таныган иде инде. Бу – Гәрәй исемле усал һәм үзсүзле егет иде. Ул, тупас кына зур кулы белән Миңлебайның чикмән якасыннан эләктереп алды да, аны күтәреп торгыза башлады. Аның икенче

кулында аракысы яртылаш эчелгән шешә иде. Ул, шешәне Миңлебайга сузып:

– Нәкъ синең өчен генә калдырылган иде бу, туган! Авызыннан гына эч тә җибәр! – диде.

Миңлебай аңа ачуланмый гына елмаеп карады да, Гәрәйнең баш бармагын бик нык каерып, аның кулын чикмән якасыннан ычкындырды һәм киредән чанага утырды.

Гәрәй, Миңлебайның бу эшенә сокланып караганы хәлдә:

– Но, уңган егет син, туган! Көч тә бар, акыл да бар синдә. Мин синең кебекләр белән сугышырга яратмыйм, – диде.

Башкалар тагын көлешеп алды. Тик бу юлы инде алар Миңлебайдан түгел, бәлки үзләренең авылдашы Гәрәйнең тапкыр сүзле булуын яратып көләләр иде.

Миңлебай да көлеп җибәрде. Ул, бу хәлдән күңеле күтәрелә төшеп:

– Син әллә чынлап та минем белән сугышырга дип килгән идеңме? – диде.

Гәрәй, һичбер уен-көлкесез генә итеп:

– Синең урында башка кеше булса, валлаһи, кыйнап ташлый идек, – диде.

– Нәрсә өчен?

– Әллә кемнәргә ачу килә. Аракы йөрәкне талый. Менә шуның өчен!

Гәрәй сүзеннән кинәт кенә тукталып калды. Ул, Миңлебай янында утырган Мәрьямгә таба ымлап:

– Син шул арада өйләнеп тә алдыңмы әллә? – дип сорады.

Миңлебай, башы белән генә ымлап һәм елмаеп, «әйе» дигән мәгънәне аңлатты.

Гәрәй, кулындагы шешәне һавада селтәп, авылдашларын кисәтеп куйды:

– Ипләп кенә, егетләр, сүгенәсе, начар сүз әйтәсе булмагыз анда!

Ул, аты чана кырыеннан атлап барган хәлдә, шешәсендәге аракыны тиз-тиз генә эчеп бетерде. Гармунчы җиңел генә бер җыр көенә уйный башлады. Егетләр җырлап җибәрде.

Гәрәй аракыдан бушаган шешәне ыргытып калдырды да, исерек башын ияр кашагасына салып, җырга кушылмыйча гына тыңлап барды. Ә тегеләр җырлап бетергәч, башын кинәт кенә күтәреп һәм бөтен гәүдәсе белән артка чайкалып:

– Эх-х! Тапкан маллар, сөйгән ярлар бар да ятларга кала, – дип, бөтен даланы яңгыратып кычкырып җибәрде.

Егетләр өченче мәртәбә шаркылдап көлеште. Әмма хәзер алар үзләренең дустын кызганып, аның белән бергә һәммәсе дә ачынып көләләр иде. Аларның исерек көлү авазлары кар белән капланган киң далада шыксыз һәм авыр тойгылар калдырып яңгырады.

Гәрәй һәм аның иптәшләре атларын чаптырып алга үттеләр. Миңлебай юлга чыкканнан бирле үзен изеп килгән күңелсез уйлар эченә чумды. Ул бүген – туган авылы, ата-анасы, туган-тумачасы һәм сөеп алган тормыш иптәше белән генә түгел – яшьлеге белән дә, егет булып йөрүләре һәм кайбер хәлләрдә өстәнрәк карап эш итүләре белән дә саубуллаша иде...

Ә буран көчәйгәннән-көчәя. Бер минут та үтмәде, барлык юлчылар да – атлары, чаналары, гармуннары һәм җыр-моңнары белән – әнә шул буран өермәләре эченә кереп күздән югалды.

*1937-1941, Олы Әтнә, Татарстан*

## Искәрмәләр урынына...

Бу әсәрнең язылу тарихы – үзе бер роман. Басылып та чыкмавына карамастан, вакытында зур бәхәсләр тудырган бу әсәрне дистәләгән еллардан соң да онытмыйча, аның авторы һәм роман турында **Мирсәй Әмир** менә нәрсәләр яза ***(«Казан утлары» – 1975, №5)***:

*«Сугыш алды елларында Казан педагогия институтын тәмамлап чыгып, Арча ягында укытып йөрүче Нәфикъ Яһудинны мин язучылар сафына ышанычлы адымнар белән килүче, әдәбиятыбызны яңа образлар белән баетырга тиешле өметле каләм иясе дип белә идем. Миңа аның төгәлләнеп бетмәгән бер романы белән танышырга туры килде. Роман Оренбург ягында яшәүче татар казаклары тормышын гәүдәләндерә иде. Бу әсәр мине әдәбиятыбызга яңалык алып килүе белән генә түгел, теле, стиле ягыннан да үзенчәлекле булуы белән бик нык кызыксындырган иде. Аны әдәби яктан тиешле дәрәҗәгә җиткерү өчен, авторга үз киңәшләремне әйттем. Ул аларны хуп күрде һәм әсәрен камилләштерү өстендә бик ныклап эшләргә керește. Ләкин тәмамларга өлгермәде, сугыш башланды...»*

### «Казаклар» романына рецензияләрдән

**Афзал Шамов. 1939 ел**

Яһудин иптәш! Романыгызны укып чыктым.

Бу көнгә кадәр әле бездә, әгәр ялгышмасам, татар казаклары тормышыннан алынган, бигрәк тә аларның көнкүрешләрен тулы итеп яктыртып биргән бер әсәр дә юк иде шикелле. Әсәрегездә бирелгән тормышның бик күп моментлары укучы өчен яңа һәм кызыклы булачак.

Әсәрегезнең матур гына эшләнгән бүлекләре бар. Туйга хәзерлек, туй итү һәм Хисамыйның көнкүреше шундыйлардан. Ул урыннарны, бик аз гына төзәтү белән, хәзер үк бастырырга мөмкин булыр иде. Ләкин, тулысынча алганда, романыгызны әле бу хәлендә басарга мөмкин түгел. Аның өстендә әле сезгә эшләргә кирәк.

1. Әсәрегездә җыйнаклык җитешеп бетми. Вакыйгаларның, күренешләрнең пропорцияләре тиешенчә сакланмаган. Кайбер урыннарда сез бик аз әһәмияте булган моментларга озын тукталып, әсәрегез өчен төп момент булган мәсьәләләргә өстән-өстән генә тукталып үтәсез.

2. Художество әсәрләрендә вакыйгаларны, типларны, характерларны барлык әдәби чаралар белән күрсәтү төп алым булып тора. Ә сез күп кенә урында бу чараны кулланмыйсыз, үзегез сөйләп бирү юлын аласыз.

Аннан. Әсәрегездәге типларның кул, күз, йөз, каш һ.б. хәрәкәтләре юк. Алар, тормышта булганча, кулларын селкемиләр, нәрсәгәдер кәефсезләнеп, кашларын җыермыйлар. Гомумән, аларның күңел кичерешләре тышка бәреп чыкмый.

3. Диалогларың аз. Хикәяләп бару гына бик ялыктыра, төрлелек кертергә кирәк иде. Кыска, көчле, характерлы диалоглар юк. Геройларың кирәк чагында янып, кызып китмиләр, бик каты нәфрәтләнә һәм чиксез сөя белмиләр.

4. Типларыгызның характерларына, аларның үзгәрүләренә җитәрлек игътибар итмисез. Һәм төп каһарманнарыгызның бөтен тормыш юлын ачып бирүне, аны күзәтеп баруны үзегезнең бурычыгыз итеп санамыйсыз.

5. Телегез шома һәм грамматик яктан дөрес. Ләкин әле ул әдәби яктан яхшыртуны сорый. Буяулар сыеграк. Мондый зур әсәрне образлы, матур, көчле тел белән язылган итеп күрәсе килә.

Әсәрегез турында әйтергә теләгән фикерләрем шулар. Казанга килеп чыксагыз, әсәрегезне ачып, тулырак та сөйләшергә мөмкин булыр иде.

Минемчә, сез бу әсәрне эшләп бетерергә тиешсез. Һәм мин – басарга яраклы, җыйнак бер әсәр ясый алачагыгызга бик нык ышанам.

* **

**Мәхмүт Максуд. 1940 ел**

«Казаклар» романының беренче кисәген укып чыккач, иң элек шуны әйтәсе килә. Бу әсәр, һичшиксез, авторның язучы булып үсә алу мөмкинлеге барлыгын күрсәтә. Автор (Афзал Шамов иптәшнең рецензиясендә бик дөрес әйтелгәнчә) татар әдәбиятына яңа тел, яңа материал алып килә. Әсәрдә татар казакларының тормыш-көнкүрешләре, аларның Сабан туйлары, кыз алу-бирүләре, ничек итеп патша хезмәтенә хәзерләнүләре турында бай материал бирелә. Әсәрнең художество ягыннан көчле язылган бүлекләре, аерым урыннары бар. Менә ундүрт яшьлек Миңлебай ат өстендә Гарифҗан белән ярыша. «Бу вакытта Миңлебайның күзләренә көрәш мәйданындагы шау-шу куптарган кешеләр томан эчендә селкенгән шәүләләр кебек кенә булып күренәләр» (18 бит). «Аның, үзе атланган ат белән бер бөтен булып, киң канат ярып очасы һәм очасы килде» (19 бит).

Шулай булса да, әле романның җитешсезлекләре бар:

1. Автор еш кына мәгънәне бер дә тулыландырмый торган сүзләр куллана, бер үк фикерне берничә җөмләдә кабатлый.

2. Авторның урынга экономия мәсьәләсенә игътибарсыз каравын күрсәтү өчен, җырларның артык күп кулланауын да әйтеп китәргә кирәк. Чама тойгысы булырга тиеш.

3. Әсәрдә, югарыда әйткәнемчә, этнографик моментлар, казакларның гореф-гадәтләре җанлы образларда бирелгән. Революцион хәрәкәт турында исә моны әйтеп булмый. Монда күбрәк – сөйләп, аңлатып ышандыру юлы тотылган. Шуңа күрә революция хәрәкәте җанлы картиналарда укучының күз алдына килеп басмый. Әгәр әсәрдә революция хәрәкәтләрен чагылдыру теләге күздә тотыла икән, бу моментларны өр-яңадан эшләргә кирәк.

Әсәрнең шундый кимчелекләре булуга карамастан, тагын бер кат әйтәм: бу әсәр авторда язучы булып үсү өчен көч барлыгын күрсәтә. Совет язучылары союзы һәм Татгосиздат Яһудин иптәшкә (аерым язучыны беркетепме, башка юллар беләнме) эш процессында ярдәм итәргә тиешләр.

***

**Мирсәй Әмир. 1941 ел**

Автор тарафыннан өч китапка чамаланган, инде ике китабы язылып беткән бу зур роман Җаек буендагы татар казаклары тормышын сурәтли.

Романның төп геройлары итеп бер семья кешеләре алына.

Ярлы казак Хисамый. Ул үзенең кешелек сыйфатлары белән Яңа Чиркас авылының иң алдынгы кешеләреннән санала. Ул, Сабан туенда көрәшеп, атаклы көрәшче Җәләйне ега. Җәләй дә Хисамый кебек үк һәм физик, һәм мораль яктан көчле кеше. Тик үзләренең күркәм сыйфатлары белән тирә-якны сокландырырлык бу кешеләргә бәхетле тормыш юк. Бай казак Котырык Муллагали аларга көн күрсәтергә теләми, һәр мәсьәләдә үзен өстен куймакчы була: малае Гарифҗанны Хисамый малае Миңлебай көрәштә екканга да ачулана.

Миңлебай (романның төп герое) Җәләй кызы Мәрьямне сөя. Мәрьямгә Котырык Гарифҗаны да кызыгып йөри. Әмма, аның төрлечә аяк чалуларына карамастан, Миңлебай белән Мәрьям арасындагы мәхәббәт җиңелми. Алар өйләнешәләр, туй була. Тик бәхетле көннәрне ишәйтергә ирек бирмиләр. Туйдан соң ук Миңлебай солдатка алына. Романның беренче китабы шуның белән тәмамлана.

Беренче китапта автор Сабан туе һәм туй моментларын тасвирлауда аерата осталык күрсәтә. Бу моментлар, романның сюжетына бәйләнгән вакыйгалар белән җанландырылып, укучыга җиңел итеп бирелү белән беррәттән, укучыны казак тормышының үзенчәлекләре, аларның гореф-гадәтләре белән нечкәләп таныштыра. Автор, гомумән, тормышны бик белеп һәм укучыны кызыксындырырлык итеп яза. Тормыш өчен характерлы булган кечкенә детальләрне зур вакыйгалар белән бәйләп алып баруда шактый осталык күрсәтә.

Романның беренче китабында төзәтергә тиешле байтак кына кимчелекләр бар (мин аларны текстта күрсәтә бардым). Ләкин алар әсәрне нигездән үзгәртүне сорый торган

кимчелекләр түгел, автор тарафыннан җиңел төзәтелә ала һәм күбесенчә редакцияләү процессында да бетерелүе мөмкин булган кимчелекләр.

Йомгак ясап, шуны әйтергә була: Татгосиздатның матур әдәбият секторы бу әсәр белән кызыксынырга, аны үзенең 1942 ел планына кертеп, басып чыгаруга ирешергә тиеш.

Автор тарафыннан бу әсәргә ифрат күп көч куелган. Бу көчнең нәтиҗәсе булып, татар матур әдәбиятын яңа әсәр белән баетырлык китап килеп чыккан.

***

**Мирсәй Әмиргә хат**

Мирсәй иптәш!

Минем соравым буенча, 14 июньдә прозаиклар секциясенең утырышы булды. Бу утырышта «Казаклар» әсәренә язылган алты рецензия тикшерелде. Әсәр белән таныш иптәшләрнең чыгышлары тыңланды. Үзенә күрә кечкенә генә бәрелеш, «кылыч ялтырату» сыман әйберләр дә булып алды. Ләкин утырышның гомуми тоны, иптәшләрнең бу мәсьәләгә нык әһәмият биреп караулары рәвешендә, минем күңелгә ошап калды.

Нәтиҗәдә, эш сезнең белән миңа авып калгандай булды. Сезне редактор итеп беркетергә һәм әсәрнең беренче кисәген 1941 елда басарга дигән карар чыгарылды. Сезнең, утырыш карарын кабул итеп, бу әсәрне дөньяга чыгару мәсьәләсендә ахырга кадәр миңа булышуыгызны, үзегезнең мастерлык ярдәмегезне күрсәтүегезне мин гаять зур шатлык белән каршы алыр идем.

**Дусларча сәлам белән, Нәфикъ ЯҺУДИН. 21 июнь 1941 ел. Казан.**

***

**Казаннан хат. 1986 ел**

Марс, Айрат һәм Нәфикъ абыйның башка балалары!

Казанның өлкән язучылары арасында шундый бер яхшы ният бар. Биредә сезнең әтиегезнең сугышка кадәр чыккан беренче хикәяләрен, Урал буе казаклары турындагы зур күләмле әсәрен беләләр, онытмыйлар. Күгәрченгә кайтып, әтиегез белән дусларча күрешеп сөйләшкән вакытларда ул үзенең шул әсәре кульязмасын миңа да күрсәткәне бар. Әтиегезнең ул әсәренә үз вакытында Мирсәй Әмир рецензия язган. Хәзер менә шул әсәрне яңадан карап, китап итеп чыгарырга кирәк дигән фикер кузгатылды. Сез моңа бер дә каршы булмассыз дип уйлыйм, әтиегезнең хезмәте дөнья күрү бик яхшы булыр ул. Фикерегезне язып җибәрсәгез икән.

**Мәҗит РАФИКОВ. 2.01.1986**

* * *

Мәҗит абыйга язган хатыма җавапны аның хатыны Миңлегөл апайдан алдым. Марс, безнең өчен бик зур югалту булды бит, Мәҗит вафат, диелгән иде анда.

Әтием Нәфикъ Яһудинның «Казаклар» исемле әсәре бүгенге көнгәчә басылып чыкмаган көе кала. Шушы әсәрне «Казан утлары»на тәкъдим итмәкчемен. Рецензияләрдә күрсәтелгән кимчелекләр өстендә эшләнелгән. Соңгы рецензия, Мирсәй Әмирнеке, моңа дәлил булса кирәк. Әтием планлаштырган өч кисәкнең 3 нче кисәге язылмаган, күрәсең, бернинди эзе табылмады. 2 нче кисәкнең күп өлешен туган йортыбызның чарлагында тычканнар кимереп бетергән иде (күчереп язылган нөсхәсе, әтиемнең үз кулы белән язылганы кайдадыр, билгесез). Монда – романның 1 нче кисәге. Шушы беренче кисәкне мөстәкыйль әсәр дип танып, Татарстан Язучылар берлеге 1941 елның 21 июнендә аны аерым китап итеп чыгару турында карар кабул итә. Сугыш башлану сәбәпле, карар үтәлми кала.

**Нәфикъ Яһудинның улы Марс ЯҺУДИН,**
*Россия Язучылар һәм Татарстан*
*Журналистлар берлекләре әгъзасы.*



Равил
Рахмани

# КҮКРӘК ТУЛЫ МОҢ КАЛГАН...

## Куа заман...

Арттан куа заман чыбыркысы,
Көннәр, айлар, еллар йөгерә:
Үгез чаба, барыс, куян чаба...
Узып барсын кеше элдерә!
Ашыктыра тормыш ихтыяҗы –
Хыял, максат, чынлык бәйләнә;
Өлгерә алмый җәяү барып адәм,
Ул ябышкан көпчәк-хәйләгә:
        Түгәрәк эчендә түгәрәк,
        Әйләнә өстендә әйләнә;
        Минутлар сәгатькә,
        Ай-еллар гасырга,
        Мизгелләр гомергә әйләнә...

Куа килә тарих тәгәрмәче!
Алга куйган иблис сыбызгысын:
Абын, тор, чап-йөгер
                йә тиз юл сап,
                                өлгер, –
Кеше диеп тормас – сытылырсың!
Туктый алмый вакыт тәгәрмәче, –
Аста калсак җирдә...
                        хушыгыз!
Ярсу типкән йөрәк пешкәгеннән
Атылып чыга янган «уф»ыбыз...
        Түгәрәк эчендә түгәрәк,
        Әйләнә тышында әйләнә...
        Җәйләрдән җәйләргә,
        Бәйрәмнән бәйрәмгә,
        Бәладән – бәлагә...
        Көйләнгән
                язмышлар шәйләнә!

---

Равил РАХМАНИ (1949) *– әдәбият галиме, шагыйрь; «Шигъри бишек», «Канатлы дөнья», «Мең чакрымга мең чакрым» исемле китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

Тыныч яшәү күптән артта калган,
Гомер елы тизрәк бәйләнә;
Буыннарны буын алыштыра...
Тизлек кулда – җаның җәлләмә!
Тәмам шашкан тиен тәгәрмәче!
Көләсе дә килә, елыйсы да... –
Хәят чыгры күптән буш әйләнә –
Кодрәт кипкән милләт коесында...
Түгәрәк эчендә түгәрәк,
Әйләнә өстендә әйләнә...
Күпме май калгандыр шәмнәрдә? –
Бар җиһан – шоу-кино
зырылдап әйләнә!

## Бәхетле булыйк!

Бу дөньяга гел бәхетле тусын,
Бәхетлеләр, әйдә, Җирдә бик күп булсын;
Бәхет белән бөтен җиһан тулсын...
Бәхетсезне килеп менә кем юатыр?!.

Тук кеше ул белми ач кайгысын,
Күңеле бөтен китеккә күз салырмы соң?..
Шаркылдаган сыктаганны таныр, димсең, –
Бәгырьләрдән тамган яшьне кем туктатыр?!.

Килсен Җиргә бәхетлеләр... килсен!..
Кадер-назны алар бездән күбрәк күрсен...
Тормышлары балда-майда йөзсен, –
Гамьсезлектән кешелекне кем уятыр?!.

Гафил булып,
мүкле таштай ятмаслармы...
Ата йортын сүтеп учак якмасларммы...
Бер-беренә ләгънәт уты атмасларммы...
Өр-яңадан таш гасырга кайтмасларммы...
Яшәү өмтен Җирдә кабат ни кузгатыр?!.

Бәхетленең гел татлымы татыганы,
Гамьсезлекнең зур очышмы атынганы?..
Кара төндә якты йолдыз атылганы
Һич тынгылык бирмәс җанга,
ул уйлатыр!

Юк, кирәкми әзер бәхет – торсын...
Тормыш җиргә ныклап басып йөрсен!
Бәхет өчен көрәшүче килсен!
Рәхәтлектә оетмаслык иман бирсен –
Киң җиһанда ул гына тик нур уйнатыр!..

## Аерылышу

Биздереп дөнья гаменнән,
Үзеңне тик уйлатасың;
Чыккысыз сагыш сазына
Керттең гомрем куласасын...
Үзең киттең, алып киттең
Ихтыярым ике кулдан;
Үткәннәрем хатирәсе
Йөртә хәзер мине юлда.

Иңнән сөйри көннәр, еллар...
Әвәләнәм төн буена;
Күчеп йөрим – атсыз җайдак,
Бер урыннан бер урынга.
Төпсез төннәр чоңгылыннан
Чыгасың да сүз катасың...
Төшләр азмы – аягүрә,
Уяу килеш сызлатасың?..

Инде барсы хәл ителгән:
Мең кичереп, мең янган;
Киләчәккә алыр нәрсә –
Күкрәк тулы моң калган...
Сине бәхетле итәргә
Ниләр биреп җиткермәдем...
Төннәремдә җил тәрәздән
Җан даулар дип ник белмәдем?

Адәм тәне чи иттән лә...
Тиз янып сызып беталмый;
Бәргәләнә җан – иреккә
Күбәләк булып күчалмый:
Кичтән төртеп аударасың,
Таңнан сөйрәп кузгатасың;
Янмый калган көнең... дипме –
Сүнмәс утта аунатасың?!.

## Остаз

*Әдәбият галиме, фикердәшем*
*Мәсгуд Гайнетдиновка*

Үсмер чактан ләмкә бәйләп, җиглеп милләт көймәсенә...
Бурлак язмышын сайлады тигез дөнья яктысында;
Тартып кертте коллык бавы яшәү-үлем арасына –
Кырык ел ул чәбәләнде, ятьмәдәге балык сыман.

Ерак торды рәсмилектән… кыйммәт иде саклык сүзе,
Чорма башы китабыннан табып җанга аклык тезде;
Кулъязмаларда казынды – орден-исем казанмады,
Булды бәхте  – табып сүтү төенләнгән хаклык җебен.

Шәхси өмет акланмады – калды ярсыз, гаиләсез,
Яшьлек дусларын югалтты, бәгъре өзлеп, ихтыярсыз:
Империя мәкеренә түзми эчеп кайсы янды,
Түрәләргә кушлып, күпләр дөньялыктан китте сансыз.

Алып ташлап хан заманнан өелгән бар пычракларны,
Меңнәрне ул күзле итте, аңлы итте чукракларны;
Ачышында милләт күзгә кырып салыр дәва тапты,
Делосында шелтә артты һәм кисәтү чираттагы.

Гадел зат, дип, килде сыенып, берән-сәрән теләктәшләр,
Канат астына җыйналды шәкерт – рухи йөрәктәшләр;
Теләделәр бу дөньяны синең күз белән күрергә –
Өч-дүрт айга үзен шагыйрь итеп тойган көрәштәшләр.

Хозурланып, җан савытын кемдер кат-кат тутрып китте,
Хаклык кизләвен татырга һәркемгә дә урын җитте…

Ялгыз калды… каләм тотып, тау-ташларда чокыныргга –
Кем дәрәҗә, кем шигырьдә сыңар шәм күк сүнеп бетте.

Исәннәрен гафу итте, җанны телде киткәннәре,
Максатлары бер иде бит, уртак иде шәкертләре;
Бәхилләде: нишлисең, дип…
милләт, өммәт, Хак каршында
Һәркемнең үз вазифасы,
илтер йөге,
бәхетләре…

Ул карт инде.
Куркып…
нәзрен үтәп чыкмый каласына,
Һәркөн иртүк килеп җитә
мәшһүр китап каласына;
Кереп китә кыштыр-кыштыр,
эшчән-тырыш керпе кебек,
Могҗизалы таш мәгарә – кулъязмалар арасына.

## Бәхетле кесә

Кышның очкынлы учагы –
Йолдызлы кичләр иде;
Дәрте күкрәктә дөрләгән
Ялкынлы хисләр иде.
Уттан-суыктан саклаган
Уртак бер кесә иде;
Дөньяда эреп бетәбез,
Кул шунда керсә инде...
Киң урамнарны тарсынып,
Тыкрыкка төшә идек...
Аңлашулар җан күпере –
Куш кулга күчә иде.
Башның күкләргә тиюен
Син безнең күрсә идең;
Сәбәбе шул: уртак оя –
Хикмәтле кесә иде!
Япан кырда сукмак салып,
Кар илен кичә идек;
Уйның бер очы – йолдызлар,
Бер ягы – кесә иде.
Кайчак каршыга рәхимсез
Әче җил исә иде;
Туган йорт, әни яккан мич,
Сабыйчак истә иде...
Җиһан урап кайткан хыял
Бергә үрелсә инде –
Шау йолдызлы өметләрдән
Шып тулган кесә иде!
Җир биргән дөнья гамьнәре
Еракта, эчтә иде;
Ярсу язмыш кануннарын
Аузлыклар исәр идек.
Төннәре бергә кушты да,
Аерды көндезләре –
Тормагач гел юл күрсәтеп
Йөрәктә йолдызлары.
Җилләрендә, суыгында
Аерылмас иңсә идек;
Куш җилкән булып язмышның
Күзенә керсә идек…
Пальтоларда  кесәләр күп,
Уртак – бер кесә иде...
...Могҗизалы шул яшьлеккә
Кайтып, их, йөрсәң иде!
Кочак җәеп, бата-чума,
Каршыңа килсәң иде;
Дөньясына алмаштырмас
Кесәңә тиңсәң иде!
Салкын кышларга бирешмәс
Бәхетле кемсә идек...
Гомергә җанны нурлаган
Сөюсез нишләр идек?!.
Серне ят күздән саклаган
Тиңдәшсез кесә иде!
...Кесә үзе юк –
җылысы
Тик искә төшә инде!



Рөстәм
Галиуллин

# ӘДРӘН

БӘЯН

Чү! Миңа ни булды?

Йөгерә-атлаган җиремнән шып туктап калдым. Аягыма авыр-авыр герләр такканнармыни – кыймылдата да алмыйм. Әйтерсең лә мине әкиятләрдәгечә, әфсенләп, тораташка әверелдергәннәр.

Нигә туктадым мин? Тирә-якка колак салам: ник бер тавыш булсын. Сәп-сәер тынлык. Безнең йорт янында хәтта багана уты да янмый. Тоташ караңгылык...

– Ччерррррррррр...

– Чикерткә-ә! – иң газиз кешемне очраткандай, сөенечемнән пышылдыйм: – Чикерткә дус...

Менә нәрсә туктаткан икән мине! Гәүдәмә көч кайтты, колагыма чикерткәнең канат кагышы моңлы көй булып ишетелә башлады, шунда безнең тугыз катлы тулай торакның түбәсенә сузылып яткан кабарынкы болыт мендәрләрен ертып якынлашкан алтын яктылыкка күзем төште. Таң ата! Аякларым ирексездән йорт янындагы агачлыкка – чикерткә моңланган сазлыклы күл янына әйдәкләде.

– Чччерррррр...

Әллә сөенеп, әллә хәвефләнеп, ул тагын да суза төште.

– Эх, чикерткә дус! – мин аркылы яткан черек бүрәнәгә чүмәштем. – Әйдә, сайра, җырла, туктама! Мин сиңа тимим дә, кумыйм да!

Гүя сүзләремне аңлагандай, чикерткә якында гына аваз салды.

Әллә кайчангы бер вакыйганы исемә төшереп, үзалдыма көлемсерәп куйдым. Кечкенә чагымда, мич артында төннәр буе черелдәгән чикерткәне, тотып, урамга чыгарып атканчы тынычланмый иде Камәр әбием.

– Ник тузынасың син, кортка! – дип сүгә иде аны Гайнан бабай. – Тик сайрасын шунда. Файдалы бөҗәк ич ул!

– Ниткән файдасы булсын аның! Бер колагыма син гырла, икенчесенә бу черләсен, ничек түзәргә кирәк бу галәмәткә?!

---

Рөстәм ГАЛИУЛЛИН (1987) – *язучы, филология фәннәре кандидаты; «Гипнозчы малай», «Юлларда җил ак иде...», «Одиночество» китаплары авторы. ТРның Муса Җәлил исемендәге премиясе лауреаты. Казанда яши.*

– Ник файдасы булмасын! Чебен-черкине киметә ул! Иччу матур җырлый! – Бабай, үзенә фикердәш эзләп, миңа эндәшә: – Әдрән улым, йоклыйсыңмы әле?

– Юк...

– Тыңладыңмы чикерткә сайраганын?

Миңа бабай сүзен куәтләргә кирәк. Юкса...

– Теләсәң нишлә, бер сүзем юк, әмма әбиең сүзен генә сөйләмә, – ди ул миңа.

Шуңа ул ишетергә теләгән җавапны бирдем:

– Тыңладым, бабай...

– Матур сайрый бит?

– Ие...

– Менә-менә! Моңлы бала шул, безнең якка тарткан. Мәгънәле...

– Һии, икәүләшеп бер сүздә тормасаларые... – Әби, тузына-тузына, ачулы шыгырдатып, караватка менеп ята. – Төне буе тыңлагыз, алайса, җырчыгызны!

– Бернәрсә дә аңламыйсың син, кортка. – Бабай әбине шелтәләп ала. Аннан инде чират миңа җитә.– Әдрән улым, йокламыйм, дисеңме?

– Юк, бабай...

– Әбиеңнән булмады, бар, мич артыннан чикерткәне тот та урамга чыгарып җибәр әле, бүгенгә кәнсирт тәмам...

– Менәтерәк... – Әби, тавышын күтәреп, сүз башларга өлгергәнче, бабайның калын тавышы анык басып китә:

– Әнә минем кипке белән тотып кара, улым, бер дә булмаса...

Тавышы колак төбендә генә кебек, әмма үзе һич кенә дә күренми. Себеркене тегеләйгә-болайга селеккәли торгач, чикерткә үз «сәхнәсе»н калдырырга мәҗбүр булды. Тоттыммы мин аны, әллә шуннан соң тынып калдымы ул – һич кенә дә хәтерләмим. Әмма Гайнан бабайның чикерткәне үзенчә шулай зурлавы истә калган.

Камәр әбием вафат инде. Гайнан бабай исә сиксән биштә дә егетләр кебек әле. Атна ахырында авылга кайткан саен, күзен хәйләкәр кыса да:

– Сиңа бу матур исемне кем кушкан әле? – ди.

– Син инде, бабай! – дим, җилкәсеннән кочып. – Тагын кемнең башына килсен инде мондый исем?

– Әйтмә дә генә! Әлфрид булып йөрисе идең син, тузгыдым, тузындым, әмма үземнекен иттем! Бер дигән җегеткә бер дигән исем кушабыз, дидем! Анаң лычык-лычык борын суганы тарта, атаң караңгы чыраен йөзенә ягып, тамак чылатып йөри. Әбиең, әтәчкә ияргән тавыктай кырт-кырт: «Кеше эшенә кысылма, үз балаң түгел, теләсә нишләсеннәр!» – ди. «Ничек инде үз балам түгел?! – дип, бик яхшылап әйтергә туры килде әбиеңә. – Үз малаеңны итәк астында йөртеп боламык ясадың, онык – миңа!» – дидем. Менә шулай бу вәйнәне җиңдем мин.

Бабай – алтын куллы механик. Колхозда кайсы техника ватылса да, ул җыйган, ул ясаган. Хәзер дә урамнан үтеп барган машиналарны туктаткалый:

– Энем, генератордагы подшипникларың тузган, алыштыр...

Гайнан бабай, элек тә, хәзер дә нинди генә эшкә тотынса да, авыз эченнән «Әдрән диңгез»не суза. Кайчагында дәртләнеп эшләгән җиреннән: «Ай, гүзәл диңгез!» – дип кычкырып җибәргәнен сизми дә кала.

– Менә, улым, үсәрсең, кеше булырсың, дөньялар күрерсең. Бабаңның васыяте шул: кайчан да булса бер Әдрән диңгезгә барып, шуның яр буенда кычкырып бер «Әдрән диңгез»не җырларсың. Менә шул вакытта бабаң теге дөньяларда сөенеп ятар!

– И бабай, икәү барабыз без синең белән, икәү җырлыйбыз! – мин әйтәм.

– Юк, улым, миңа үзебезнең Чияленең Якты күле дә бик җиткән, – ди ул, елмаеп. – Атаң да шуннан ары китә алмады, колхоз эшеннән бушап булмады шул, эх, тәрбияләрлек хут калмады шуны!

– Әти маладис ул, – дип каршы төшәм мин. – Районда иң яхшы комбайнчы, иң шәп тракторчы ул!

– Тракторны кем дә йөртә аны! – ди бабай, кул селтәп. – Олы йөрәк җитми, моңлы йөрәк! Кулың алтын булуы бер хәл, күңелнең дә алтын булуы кирәк! Менә синдә ул бар! Әйдә, җырлыйбыз, улым...

Әдрән диңгез, даулы диңгез,
Даулы ул диңгез.
Тирәләре таулы диңгез,
Бик таулы диңгез.
Хәлен җуйган син бөркеткә,
Ай, син бөркеткә
Шифа бирсен изге диңгез,
Изге ул диңгез. Әй!

Үз тавышымнан дертләп айнып киттем. Таң атканда, кем әйткәндәй, шәһәр уртасында җырлап утырам икән! Борын тәмам җебегән. Битемне сыпыргач, үзем дә аптырап калдым – елап утырам икән ләбаса! Әгәр кемдер мине читтән карап торса, хәйран калыр иде, билләһи. Ап-ак кәчтүмнән, кара күлмәккә ак күбәләк таккан ябь-яшь егет кара төн уртасында елап-җырлап утырсын әле! Авылда булса, өрәк йөри, әнә елый, дип шәрран ярырлар иде, мөгаен. Хәтерлим әле, балачакта без, өч сыйныфташ егет, өч дус – Сәет, Марсель һәм мин – әниләргә күрсәтми генә алган ак җәймәләргә төренеп, бер төнне, дөресрәге, төп-төгәл уникедә, зираттан атылып чыккан идек. Янәсе, кабердән өрәкләр кубарылган, очраган бер кешене, коты ботына төшәрлек итеп шыр җибәртәбез. Зират капкасыннан акырышып чыгуга ук, тавышыбыз кинәт сүнеп калды: ап-ак җәймәгә баштанаяк уралганлыктан – җәймәне тишәргә ярамый! – бер җан иясенә килеп төртелгәнемне сизми дә калдым. Зур куллар җәймәне бер тартуда суырып алды, шәрә король кебек үк булмаса да, Газиз малае Әдрән булып, карашымны өскә күтәрдем. Хәлим абый! Авылда теләсә кемгә очрасаң да, алдап-йолдап, һич югында, елап, ялынып, вәгъдәләр сибә-сибә котылырга, гафу үтенергә мөмкин әле. Әмма Хәлим абыйдан гына түгел! Юкса әти белән бергә тракторда, урак өстендә комбайнда эшли, урып-җыю башлануга, гел шулар янында кайнашам. Хәлим абый – күз яшенә, тәмле сүзләргә төген дә селкетә торган кеше түгел. «Үзенекен бирми, кешенекенә тими, – ди аның турында әти. Тагын өстәп тә куя: – Шушы кагыйдәне бозсаң, Хәлимнән якты чырай өмет итмә!»

Гәүдәгә әкиятләрдәге Алыплар сыман зур булса иде тагын: юк, киресенчә, Хәлим абый буйга кечкенә, башы да йомры, малайларныкы сыман. Өстәвенә пеләшләнеп тә килә, шуңа да зур колаклары филнеке кебек сәлам биреп тора. Әмма аның яргаланган, таш кебек каты кулы күрешкәндә үк җанны суырып алган сыман, нык кыса. Сыек зәңгәр күзе исә караңгыда да яктылыгын җуймый.

– Фию-фит!

Ул бер сүз дә әйтмәде, колактан эләктерде дә янәдән зират капкасына таба өстерәде. Тирә-якка карашымны йөгертәм, тик ярдәм итәрдәй бер генә дә өметле нәрсә күренми. Кая ул! «Өрәк»ләр күптән өйләренә таба сыпырткан, Хәлим абыйның кулына берәүнең дә эләгәсе килми. Мин генә менә...

– Хәлим абый...

Җавап юк.

– Башка алай эшләмәс идем...

Зират капкасыннан эчкә уздык. Зиратның урта бер җирендә алан сыман урын бар, шунда кадәр кердек. Колакны ычкындырмаган килеш, Хәлим абый бер кулы белән генә кычыткан җыеп алды.

– Әтигә әйтәм... – дип еламсырадым. Бу минем иң соңгы чара иде. Ләкин файдасы юклыгын үзем дә беләм. Тешемне кыстым, мускуллар киерелеп килде.

Хәлим абый дәшми.

Хәлим абый ашыкмый.

– Чыжжт!..

– Чыжжт!..

– Чыжжт!..

Авыртудан түгел, гарьләнүдән елап җибәрдем. Телгә килгән бөтен әшәке сүзне йөзенә бәреп әйтәсе, сөмсез битенә йодрык белән кундырасы, тукмыйсы килде үзен!

– Ыштаныңны күтәр, энекәш, киттек! – Хәлим абыйның үз итеп әйткән сүзләреннән гәүдәмне туктаусыз дерелдәткән сабырлыгым-түземлегем ычкынды да китте, акырып еларга керештем.

– Булды, булды, – диде Хәлим абый, җилкәмнән кочып. Үзе үк чалбарымны күтәрде. Җилкәдән кочкан килеш, чыгу юлына юнәлдек. Инде елавымнан гарьләнеп, борынны мышкылдата-мышкылдата, янәшәсеннән атладым. Хәлим абый ашыкмый гына капканың биген эләктерде. Мин һаман тынычлана алмый идем әле, югыйсә ачу белән бер таш алып тондыр да кач бит инде! Аякларым сумалага батканмыни – кымшатуы да кыен. Хәлим абый тәмәке кабызып җибәрде.

– Йә Әдрән, хуш иттек! Миңа ачуланма, син әйбәт малай, үз итәм мин сине, – диде ул һәм кулын сузды.

Минем елак күңел тагын да сытылды. Әмма сынатырга ярамый иде, кулны бирдем дә, кырт борылып, өйгә таба киттем. Күпмедер баргач, артка борылып карадым: Хәлим абый һаман да урынында басып тора иде.

Менә хәзер, ак кәчтүмнән, ак күбәләк таккан кара күлмәктән, шул вакыйганы искә төшерәм дә уйланам: Хәлим абыйга һич кенә дә ачуым калмаган икән. Мин ул хәлне беркемгә дә сөйләмәдем. Марсель ул вакытта да, еллар узгач та, кабат-кабат сорашты, әмма сер бирмәдем. Үзләренең шыр җибәреп, өйләренә сыптыруларын исләренә төшерәм дә, шым булалар. Ул төн исә авыр узган иде минем: тән кабарды, әүвәл кычытуга түзеп булмады, аннан инде авыртудан борсаланып чыктым.

Тән авыртуына түзү берни түгел ул, ә менә күңел тынычлыгы югалсамы?!

Мин – җырчы. Төгәлрәге, мәҗлес җырчысы. Ягъни мәсәлән, тамада Рузиләгә ияреп, җырлап йөрүче. Менә хәзер дә Казан янындагы район үзәгеннән туй уздырып кайтып килешебез. Теләмичә чыгып китәм, авыруга, ярым-йорты кешегә әйләнеп кайтып керәм. Бу эш миңа һич тә канәгатьлек бирми. Үземә нибары егерме биш яшь, үзем инде чытык чырайлы бер кемсәгә әйләнеп барам. Әмма мәҗлесләргә бармый хәлем юк, чөнки бөтен керемем шуннан. Мәктәптә музыка түгәрәге алып барудан кергән акчага гына гаиләне асрап булмый. Шуңа да Рузилә атна урталарында шалтыратып, җырларга чакырмаса, йөрәгем жу-у итә, күңелне ниндидер курку баса. Яшь ярымлык улым Искәндәр һәм аның белән өйдә утырган хатыным Миләүшәнең матди иминлеге өчен мин җаваплы.

– Ахырзаман алдыннан кемне уйласаң, шул каршыңа килеп чыгар, – дип кабатлый торган иде Камәр әби. Мин Миләүшә белән Искәндәр турында уйларга да өлгермәдем, тулай торакның беренче катында, без яшәгән бүлмәдә кинәт ут кабынды. Якынрак килеп, колак салсам, Искәндәрнең үксеп-үксеп елавы аермачык булып ишетелә иде. Күршеләр тагын диварга кагадыр инде, иртәгә Галя түти тагын арттан өреп калачак икән. Миләүшә кабат капланып елаячак, кайчан гына үз фатирыбыз булыр да, шушы җәһәннәмнән котылырбыз икән дип, язмышын каһәрләячәк. Шулай... өч елга якын без кайда гына яшәмәдек, ничәмә-ничә мәртәбәләр төрле фатирларга түләп тордык. Бала тугач, иң арзанлы санап, шушы тулай торакка калдык. Эһ... Искәндәр акырыпмы-акыра. Төне буе без аны чиратлашып күтәреп чыгабыз. Йокының иң тәмле вакытында чырыйлап кычкырып җибәрә дә кулга алганчы тамак төбе белән акыра. Аннан инде бик озак тынычлана алмый. Таныш-белешләр: «Күз тиюдәндер, әбиләргә алып барып карагыз, өшкертегез, – ди.

Барып карадык – файдасын күрмәдек.

«Берәр чире бардыр, табибларга күрсәтегез», – дип киңәш бирүчеләр дә булды. Йөреп чыктык. Без күренмәгән түләүле дә, түләүсез дә табиб калмады бугай Казанда. Кул селтәдек. Баланың әллә ниткән авыруларын да дәваладылар, эчендәге бөтен бозымнарын да чыгарып бетерделәр, янәсе, әмма яшь ярымлык Искәндәр генә һаман да ябык, инде йөгереп йөрергә тиеш булса да, хәлсез генә атлый, буе кечкенә, иң куркынычы – төн саен шулай тоташ үкерә. Миләүшә елап ялвара, сүгеп тә карый – һич тә көен таба алмый.

– Шәһәр һавасы килешми аңа, – ди Гайнан бабай. – Син үзең дә, Әдрән улым, Казанга китү белән, суырылып-ябыгып беттең. Калдыр берәр айга, көн дә яңа сауган сөт эчсә, кире кайтканда балаңны танымассың да.

Мин бабайның тәкъдимен Миләүшәгә әйтеп карыйм. Ул, черки кугандай, борын төбемдә кулын гына болгый:

– Ничек калдырасың аны авылда? Берәр җире авырта башласа, нишли ул? Булмаганны!..

Тулай торакка якынайган саен, Миләүшәнең ярым шыңшып җырлаганы ачыграк ишетелә: «И туган тел, и матур тел...»

Искәндәр башка җырны кабул итми. Тәмам тынычланмаса да, инде тавышы дөнья куптарырдай түгел.

Тәрәзә турысына чүгәләдем дә әллә нигә Искәндәргә кушылып елыйсым килә башлады. Кинәт нindидер бер ярсу көч урынымнан торгызды, җилләнеп ишектән уздым.

– Миләүшә!

Ул, сискәнеп, артына борылды да, нишлисең, исәр, дигәндәй, имән бармагын иренена аркылы куйды.

– Көчкә тынычландырдым, тагын башлый бит... – Аның тавышы шелтәле иде. – Яңа күзен йомды...

Мин, Миләүшәне кочкан килеш, Искәндәргә бактым: улым мес-мес йоклый иде, ара-тирә иреннәре тартышып куя, йомылып бетмәгән күзе исә менә-менә ачылып, тутырып карар сыман. Карашымны Миләүшәгә күчердем. Туктаусыз баланы кулында тирбәтеп торган хатыным күзгә күренеп кечерәйгән, бөкрәеп калган кебек, йокысызлыктанмы, авыр уйларданмы күз астында кара мендәрчекләр хасил булган, битендә хәтта җыерчыклар эз салган сыман. Әллә ничек, кыен иде миңа.

– Миләүшә, болай булмый...

Ул, баланы тирбәтүдән туктап, аптыраулы карашын миңа төбәде.

− Мин күптән әйтмәкче идем инде... − Миләүшәнең күзеннән нindидер хәвефле дулкыннар йөгерешеп узды. – Әйдә, үзебез дә интекмик, баланы да интектермик, авылга кайтып торыйк... Һич югы, бераз аякка басканчы...

− Әдрән!.. − Миләүшә капылт арты белән борылды. Иңсәсенең җиңелчә бер күтәрелеп, бер төшеп торуыннан аның тавышсыз гына елавын чамаларга була иде. Э-эһ! Кычкырсын, сүксен иде ул – анысы берни түгел, әмма шулай, тешен кысып, иренен тешләп кенә еламасын.

− Миләүшә, бәләм, өйләнгәндә вәгъдә бирдем, яхшы тормыш вәгъдә иттем, Казан уртасында фатирыбыз булыр, дидем. Әмма, үзең күреп торасың, кыен бит. Сиңа да, миңа да. Шушы унике квадрат метрлы бүлмәдә күпме интегергә мөмкин? Анысы да үзебезнеке түгел. Әйе, мин булдыксыз, ялганчы, бушкуык... Сиңа биргән вәгъдәләремнең берсен дә үти алмадым. Әйе, мин юаш, куркак − шушы тавышым белән сәхнәгә күтәрелергә теләдем. Әйе, заманнан артта калганмын – миңа мәктәптә шул мескен тиеннәргә музыка түгәрәге алып бару ошый. Әйе, мин тәкәббер – мәҗлесләрдә җырлау миңа ошамый, үзем өчен түбәнлек дип саныйм...

Миләүшә берни дә дәшми. Мин туктагач, өйдә, әй лә, бүлмәдә үле тынлык урнашты.

− Авылда клуб директоры эзлиләр. Миңа әйткәннәр иде...

Җавап юк. Ләм-мим. Акылы киткән кешедәй сөйләнүдән мәгънә юк, болай да йөрәгем урыныннан купты. Кечкенә караватта Миләүшә Искәндәр белән йоклаячак иде. Һәр төнне шулай, малай мине әнисе янынан куа, шуңа идәндәге матраста йоклыйм. Миләүшәнең абыйларыннан калган иске карават пружиналары шыгырдап куйды да, ниһаять, бүлмә тынып калды.

Күзгә йокы керми – йомсам, күздән әчеттереп яшь сытылып чыга. Миләүшә тәкъдимемне кабул итмәде. Бәләм инде, аның бик тә шәһәрдә яшисе, баланы яхшы мәктәптә укытасы, үз һөнәре буенча сәнгать мәктәбендә эшлисе килә.

Ул, бала тапканчы, музыка юнәлешле мәктәптә фортепиано дәресләре алып барды. Үзе үк көйләр дә чыгара, шуларны укучылары белән төрледән-төрле конкурсларда тәкъдим итеп, еш кына уңышларга да ирешә иде. Без аның белән институт лифтында таныштык.

Сентябрь ае иде ул. Дүшәмбе иртәсе. Мин, ул вакытта икенче курста укучы студент, авылдан туп-туры институтка килдем дә, шул тизлек белән, беренче лекциягә өлгерү өчен, ябылып маташкан лифт ишегенә аягымны тыктым – ул, теләр-теләмәс кенә, сукрана-сукрана кабат ачылды. Анда бер кыз гына басып тора иде.

− Гафу итегез, ашыгам, − дидем мин һәм аңа күтәрелеп карадым. Карадым да... бермәлгә өнсез калдым: кап-кара ике калын толымы җилкәсенә салынган, түгәрәк битендә мәхәббәт чокырлары балкып торган, калын алсу иренле, каратут йөзле, нәфис бер кыз иде ул.

«Чиб-бәр!» – Беренче уем шул булды.

Безнең бәхетсезлеккә, әллә бәхеткәме икән – лифт көтмәгәндә шып туктап калды. Кызыкай, болай да зур күзен тагын да түгәрәкләндереп, миңа бакты. Еламый гына инде.

− Беренче курсмы? – дип сорадым мин, тавышымны ышаныч тудырырдай көр чыгарып.

− Әйе, − диде ул, ишетелер-ишетелмәслек кенә.

− Бу лифтның гадәте шундый. Шулай кәҗәләнә ул. – Мин аны дер-дер селкетә башладым.

– Нишлисең син? – Кызыкайның йөзеннән кан качты.

Шулчак лифт кузгалып китте, алтынчы катта без бергә чыктык.

– Пока, әйбәт кенә укы! – дидем мин. Эчтән генә үземне сүгәм: «Кара инде, нинди буш сүзләр сөйлим бит!»

– Рәхмәт, тырышырмын! – Ул ап-ак тешләрен балкытып елмайды.

Лекция инде башланган иде, шулай да укытучы миңа бәйләнеп вакланмады, иң артка, егетләр янына кереп чүмәштем.

Шул көнне үк без чираттагы лекциягә кергән аудиториядән теге чибәр кызның төркеме чыгып килә иде.

– Егетләр! Ишетсен колагыгыз: бу кыз минеке! Мин әйттем, – дидем мин, ханнар җөпләвен кабатлап!

Кайсыдыр кул селтәде, кемдер көлде. «Дон Жуан» кушаматлы районддашым Радик кына:

– Исеме ничек соң? – дип сорап куйды.

– Белмим, – мин әйтәм.

– Әй, исемен дә белмәгәч, синеке булмый инде ул, бөтенебезнеке дә, – дип, гадәтенчә, кычкырып көлде ул. – Ә болай... кыз ничава күренә...

Шуннан китте... китте инде. Махсус күрсәтмә алган шымчыдай, иң әүвәл исемен белдем – Миләүшә икән. Аннан районын, авылын ачыкладым. Фортепиано, скрипкада уйнавын белештем.

Ул әнисенең сеңлесендә фатирда тора иде, мин – тулай торакта. Бик озак – ике ай бик күп тоелды – мин аның күңеленә ачкыч таба алмый изаландым. Радик бу мәсьәләдә академик: кызлар күңелен эретердәй сүзләрне вагонлап-вагонлап бушату аңа берни тормый, өстәвенә машинасы да бар – монысы инде үзе үк берничә киртәне җиңел генә узу дигән сүз.

– Булмас, ахры, синнән, давай, үзем кылын тартып карыйм, – диде ул беркөнне.

– Уйлап кына кара! – Мин аңа ачудан бармак янадым.

Дәшмәде тагын. Радик, әйткәнемчә, минем районддаш. Әтисе банк хуҗасы булса, әнисе – районның мәдәният «министры».

– Спонсорым да, продюсерым да бар, мин җырламый кем җырласын! – ди үзе.

Ул инде кечкенәдән әллә күпме җыр конкурсларында җиңеп, лауреат булып беткән. Сәхнә киемнәрем генә дә Казан–Мәскәү поезды вагоннарына сыеп бетмәс, ди. Шулай да безнең төркемдә ул иң талантсызы. Төрле кичәләрдә, очрашуларда беркайчан да үз тавышына җырламый – фонограммага авызын кыймылдатып тора. Райондагы иң зур чараларда Радик соңгы булып сәхнәгә чыга. Йолдыз, нишләтәсең...

...Миләүшәне мин барыбер үземә караттым. Дөресрәге, ул үзе юл күрсәтте. Беренче курсларның багышлау кичәсендә өлкәнрәк курслар да катнашты. Оештыру эшләренең эчендә кайнаган әлеге дә баягы тамада Рузилә – ул чагында бишенче курс студенты – минем дә җырлавымны теләде.

– Әдрән, үз диңгезеңне җырлыйсың, – диде ул, ике уйларга урын калдырмаслык итеп.

Бу «үз» җырымны инде берничә тапкыр башкарганым бар, репетицияләргә йөрмәдем.

Гайнан бабай белән кичләрен еш кына баян тартып, бакча башында утырырга яратабыз. Камәр әби әйтмешли, «кәнсиртебез» һәрчак «Әдрән диңгез» белән башлана. Аны бабай шулкадәр дәртләнеп, ихластан җырлый да... ахырдан бер рәхәтләнеп, бушанганчы елап ала. Сәхнәгә чыккач та, үземне әнә

шулай бакча башындагы каен төбендә җырлагандай хис иттем – кул чабулардан айнып китмәсәм, билләһи, үзем дә Гайнан бабамдай елап җибәрәсе идем.

Сәхнә артына керү белән, күзем Миләүшәгә төште – скрипкасын кулына кысып тоткан, ә үзенең бите буйлап яшь тамчылары тәгәри.

− Әдрән...

− Ни булды?

− Син, син – талант. Зинһар, тавышыңны боза күрмә. Мондый халыкчан бай тавышыңны, зинһар, әрәм итмә. Сине тыңлаганда, минем күңелдә яңа көй туды...

Бу, безнең сәлам бирешүләрне санамаганда, беренче тапкыр ачылып сөйләшү иде. Болай да дулкыннар йөгерешкән тәнем эсселе-суыклы булып китте.

− Рәхмәт! − дидем мин, ерылган авызымны җыя алмыйча.

Миләүшә кулымны кысып тоткан иде, шул килеш без аның белән җәяүләп кайтырга да кузгалдык, ахры.

Октябрь ахыры. Ямьсез, шыксыз кара көн, аяктан егардай әче җил, пыскак яңгыр. Ә миңа эссе, якты, күңелле иде. Ул да, мин дә тәмам чыланып беттек. Подъезд ишеге төбенә килеп җиткәч кенә, сөйләшер сүз калмады. Ул миңа тутырып карады, үзем дә сизмәстән, мин аны кочагыма тартып китердем һәм иренемә үрелдем.

Әйтерсең лә мине иң кызу әйләнә торган каруселькә утырттылар...

Йортлар, агачлар, машиналар – барысы да, барысы да зыр-зыр әйләнә, ә без Миләүшә белән, бер-беребезне кочкан килеш, акрын гына югарыга очабыз. Пыскак яңгыр инде коя ук башлады: чәч араларыннан, керфекләрдән, борын очларыннан тамчылар тама, иреннәрне аерып алырлык көч тә, ихтыяр да, теләк тә юк...

Әйтергә оят, шул яшемә җитеп, беренче тапкыр кызлар иренен тәмләп каравым иде. Ул да, минем кебек үк, үбешә белми, ахры, дип уйлавым истә.

Аннан инде без гел бергә булдык. Әмма Миләүшә минем өчен дигән көен һаман да иҗат итмәде, мин исә «уникаль тавышым» белән зур сәхнәләргә күтәрелә алмадым. Ул мәктәптә музыка дәресләре укытып, шунда чумса, мин исә мәҗлес җырчысына әйләндем. Әмма шул октябрь киче күңелемә мәңгелеккә кереп калды, иң авыр чакларда һәрвакыт шуны күз алдыма китерәм...

Битем буйлап агып төшкән тозлы тамчы иренемне кытыклаудан уянып киттем: Миләүшә яңагын яңагыма терәгән иде.

− Ни булды? – дидем мин, аңышмастан.

− Тсс... − диде ул, бармагын иренемә аркылы куеп. Аннан караватка таба ымлады: − Йоклый әле.

Мин кырыс чынбарлыкка кайттым. Кичәге төн искә төште, күтәренке кәефем шундук кырылды.

− Син кичә, дөресрәге, бүген иртән уйлап әйттеңме ул?

Мин сагая калдым. Төнлә аркасы белән борылган иде, бүген ничектер сөйләшә әле.

− Әдрән!

Минем кычкырышасым килми. Егет белән кыз булып йөргәндә дә, өйләнешкәч тә, бер-беребезгә авыр сүз әйтми идек, соңгы айларда хәтәр-хәтәр генә әйткәләшергә өйрәндек.

− Әдрән, ник җавап бирмисең?

− Әйе, дисәм, тагын елый башлыйсың бит...

− Әйдә, төптән уйлыйк әле. Чыннан да, болай яшәп булмый. Син бөтенләй тормыштан күңеле кайткан кешегә охшап калдың. Бернәрсәгә күңелең үсми...

– Әйтмәсәм дә беләсең бит инде, Миләүшә!

– Ләкин без бит шәһәрдә калырга теләдек, үзебезгә сүз бирдек! Бергә концертлар куярбыз, дидек. Зур сәхнәгә чыгарга бөтен мөмкинлегең дә бар бит!

– Арыдым мин, Миләүшә. Әйдә, бүген ул турыда сөйләшмик, ә?

– Юк, хәзер сөйләшәбез. Болай дәвам итә алмый. Нәрсә телисең син?

– Минме?

Аптырап калдым. Нәрсә телим соң мин? Мин... мин тынычлык телим, сыгылып торган өстәлләр янында утырган тук чырайлы, кызарышкан абзыйлардан, шунда ук күз кысып, визиткаларын кесәмә шудырган мут апайлардан, эчеп кайткан саен, хатыны Галя түтине акыра-бакыра, тукмый-тукмый бүлмәдән куып чыгарган күрше Коля дәдәйдән, шушы бүлмәдәге кысанлыктан, мәңге бетмәс шау-шудан – бөтенесеннән дә туйдым. Миңа тынычлык, ирек, ихласлык кирәк!

– Кайтып торыйк авылга! Һич югы, беразга. Аякка басканчы, Искәндәр ныгыганчы. Аннан яңа көч белән килербез!

Миләүшә, еламсырап, мине кочып алды.

– Кайтасым килми, Әдрән! Күңелсез, яшьләрсез, өметсез авылда нишләрбез?!

– Бөтенләйгә түгел бит, Миләүшә! Син көйләр язарсың, мин яңадан җырлый башлармын!

– Әдрән, бу бит – җиңелү! Чигенү, беренче авырлыкларга ук бирешү...

Миләүшәнең елавына саташып уянган Искәндәрнең үкерүе кушылды. Мин үземне гаепле тойдым. Бу кадәр авырлыкны күтәрә алмас идем, урамга чыгып киттем.

Күңелдә бернинди дә рәтле уй юк. Бушлык. Әрле-бирле йөреп туйгач, кире тулай торакка кердем. Ишекне ачуга, бермәлгә югалып калдым: бүлмә уртасында ике зур капчык, бала киемнәрен ташый торган зур сумка һәм тагын берничә төргәк тора иде.

– Карават та, суыткыч та калсын, алар инде тәмам эштән чыккан. Телевизорны гына алыйк, – диде Миләүшә, сагышлы елмаеп.

– Миләүшә...

– Киттек, Әдрән, әгәр сиңа шулай яхшы икән, әйдә, кайтып карыйк...

Ниндидер бер хис ташкыны күкрәктән үк кузгалып, бугаздан буып алды. Тамак төбенә төер тыгылды. Еларга ярамый иде.

Бар булган байлык белән «ундүртле»гә төялдек. Бу сәфәргә Искәндәр генә шат иде:

– Бабба! Әббә! – диде ул, кулын чәбәкләп. – Вуа-вуа! – машинага утырган, янәсе...

Алда – өч сәгатьлек юл. Казан артта калды...

* * *

Әти безнең кайтып төшүне бөтенләй өнәмәде. Үзебезгә әйтмәсә дә, әнинең җанын ашап:

– Аны авылга кайтасы булгач, райондагы механиклар әзерли торган техникумда гына укырга иде инде. Казанда биш ел ыштан төбе туздырып ятасы юк иде... – дип сөйләнүен без дә ишеттек.

– Бөтенләйгә түгел, ди бит атасы, ник караңгы чырай белән йөрисең, ә? Искәндәр ныгыганчы гына, диләр ич. Үз балаң бит. Бердәнбер малаең...

– Кулыннан эш килгән егетләр бөтенесе дә авылдан китеп бетте. Әнә

классташларыңнан кем бар? Берсе дә юк! Белмим, белмим... Җүнле җегетләр, һич югы, район үзәгенә юл саба...

Без кайткач, әнинең дә күңеленә шик-шөбһә төште. Үзе, бер яктан, шат та, икенче яктан, билгесезлек җанын ашый иде. Өстәвенә күрше-күләннең һәммәсенә дә «бар да әйбәт!» кыяфәте чыгарып, безнең кайтып төшүне дөрес гамәл иттереп аңлатып-сөйләп чыгасы бар.

Әле дә ярый Гайнан бабам бар! Менә ул, ичмасам, чын күңеленнән сөенде!

– И-и, дөньялар ямьләнеп китте, сез кайткач. Һай, Әдрән, әле дә кайтып дөрес эшләдегез. Өй генә түгел, авылга да ямь керде бит! Болар белән, – ул эти белән әнигә төртеп күрсәтте, – тормышның бер кызыгы юк. Ни моңнары юк үзләренең, ни күңелләре шып-шыр... Тормышмы инде ул, йә? Һай, син кайттың да яшисе килә башлады бит! Искәндәр – үземә! Боларга тапшырсаң, җансыз калдыралар!

Казан каласында күкрәк турысын яндырып торган учак авылга кайткач та басылмады бит әле! Киресенчә, бер эшкә дә күңел ятмый – тынгысызлык көчәйде генә. Үч иткәндәй, без күченеп кайткан атнаны классташым Сәет гаиләсе белән район үзәгенә китеп барды.

– Башкача түзеп булмый, Әдрән. Гомер әрәмгә үтә, көн-төн трактордан төшмим, өйгә берни дә кайтмый. Барып чыкмады бу инвестордан, үзе дә кыякларга җыена бугай. Районда тракторчы эзлиләр иде, шалтыраттым да, шундук чакырдылар да. Аннан өйдә энекәш кала барыбер. Бушка эшләп, йорт салып булмый, – диде ул миңа.

Минем кайтуым, аның китүе зур вакыйга иде. Сәет, авыл башындагы каенлыкны урап кайтыйк, диде. Элек ул каенлыкта безнең штаб урнашкан иде. Өч классташ егет – өч дус – шул каенлыктагы ерым төбендә ботаклар, яфраклар белән каплап ясалган штабыбыздан кайтмыйча уйнаган көннәр бар иде!

Минем машинаны кабыздык.

– Ышанасыңмы-юкмы, Әдрән, трактор белән җир сукалаганда йә басуга агу сиптергәндә, шул каенлык янында булсам, сикереп төшәм дә тәгәрәп елыйм. Бигрәк күңелсез бит, малай! Сез икегез дә чыгып киттегез. Ялга кайтканда да хәл белешмисез. Берүзем ятим кебек тик йөрим. Беркемгә кирәгем юк. Ул кичләре тагын... Бер яктан хатын талкый, гомер абзар арты күреп кенә уза, дип...

«Ундүртле»не кибет янында туктаттык.

– Тукта, Әдрән, кереп чыгыйм инде. Гомер эчендә бер вакыйга бит... – диде сабакташ дустым.

– Мин эчмим, Сәет...

– Беләм, беләм!

Сәет кибеттән кош тоткандай чыкты:

– Иялэшеп киттем, Әдрән, сизми дә калдым. Арып-талып кайткач, җиңелрәк булмасмы, дип йоткалый башлаган идем. Кая ул безнең тишек авызга?! Гадәткә керде...

Сәет үзенең китүенә шатлана идеме, минем кайтугамы – белмәссең. Өчебез арасында иң аз сөйләшүче иде ул.

– Марсель китте дә югалды. Сиңа да хәбәре юкмы?

– Язгалаган идем ватсаптан, әллә ни аралашкан юк. Ара-тирә кызык-мызык видеоларын куйгалый шунда...

– Авылны тиз онытты егет. Үзе һаман шул Курил утрауларындамы?

– Әйе, өлкән лейтенант булган. Капитан итүләре бар икән. Пенсиягә чыгар вакытым җитә инде, дип язган иде, көлеп. Аннан соң хәбәре булмады. Быел кайтмый, ахры.

## ТАТАР МОҢЫ

Татар моңсыз яши аламыни –
Татар күңеленә моң кирәк,
Тальяныңны гына сузып җибәр,
Дәррәү кушылыр аңа мең тирәк!

Мең тирәккә кунган мең сандугач
Шундук алыр аны күтәреп,
Томырылыр ул моң зәңгәр күккә –
Зәңгәрлеге артыр күкләрнең.

Кайда гына тыңламадым икән
Моң саркыган татар көен мин –
Сайрар кошлар, тал-тирәкләр белә
Һәр бормасын «Әллүки»емнең.

«Ишкәкче карт» җырын көйли-көйли,
Ярга кага Идел дулкыны,
«Карурман»ны көйләп сыкрый урман –
Тарихлардан калган сулкуы.

Әдрән диңгез ярларында йөрдем,
Алар инде кайдан откандыр –
Нәкъ татарча шаулый дулкыннары,
Әйтерсең лә мине көткәннәр!

Влтавада су коенганым бар
Аккошлары белән янәшә,
Аккошлары аның, күзгә карап,
Саф татарча миңа эндәшә.

Татар моңсыз яши аламыни –
Моң таба ул һәрбер аваздан,
Бәлки, шул моң саклагандыр аны
Мең дә ничә вәхши-явыздан.

Бәлки, халкым тарих чоңгылларын
Моңы белән имин үткәндер,
Шул моң аңа сынмас канат булган,
Шул моң аны Татар иткәндер!

Кайда йөрсәм – тоям татар моңын,
Ул моңлы да, уйлы, шаян да…
Кара елларда да тынмаган ул,
Тынмас инде килер заманда!

**Гарифҗан МӨХӘММӘТШИН**

– Кара син аны, ташбаш! Егерме биш яшьтә диген! Башкисәр иде шул үскәндә үк.

Без каенлыкка килеп җиттек. Элек сәпитләр белән ярыша-ярыша җилдерә идек, Марсель һәрвакыт беренче була, Сәет ахырга кала иде.

– Авыл ботә, малай, – диде Сәет һәм кара пакеттан шешә тартып чыгарды. Кыяр, ипине ул өеннән алган иде.

– Менә син уйлап кара, Әдрән... – Сәет шешәдән кырлы стаканына аракы койды... – Хәзер июль ахыры, әле авылда кеше бар. Казан халкы баласын кайтара, кемдер ялга кайта. Вәт. Әле түзәргә була. Урак өсте бетә, бәрәңгеләр аласың, и бетте шуның белән – авылда адәм тавышы ишетергә зар-интизар буласың, билләһи! Ничек җан әрнемәсен моңа!.. Ярый, Әдрән, әйдә, күрешү хөрмәтенә...

– Синең стаканың бирәү генә мәллә?

Сәет, гаҗәпсенеп, миңа текәлде:

– Син бит эчмисең?

– Әйдә, синең авылдан китү хөрмәтенә берне салып кара әле...

– Әдрән... – Сәет тотлыгып калды. – Әллә башламыйсың гынамы? Без инде, кем әйтмешли, диңгез эчкән кешеләр. Синең характерны да белмәссең. Җүнсез нәмәстә инде бу.

– Йөрәк яна бит, Сәет дус...

Күздән яшь атылып чыкты, Сәет кулыма кыяр тоттырды.

– Ачы шул бу, – диде ул, хәлемә кереп. – Урыс ничек эчәдер моны...

Балачак дуслар очрашса, нәрсә турында сөйләшә? Шул, элеккегеләрне искә төшердек.

– Син хәтерлисеңме?

– Мин ул чакта!..

– Ә мин!..

Вакыйгалар күп иде. Сәет кара пакетыннан тагын бер шешәне тартып чыгарганда, миңа бик рәхәт иде инде.

– Китмә, Сәет. Әйдә, авылны гөрләтәбез!

– Өмет юк, Әдрән. Китәм инде... – Ул җебегән борынын тартып куйды. – Колхоз бетте, мәктәп бетте...

Кинәт ул айныгандай булды:

– Тукта, ә син кая эшләрсең соң? Син бит – җырчы!

– Клуб директоры...

– Әлләй... Ул ябылмадымыни әле?

– Юк...

– Әдрән дус, син маладис, кайтып дөрес эшләдең. Син кайткач, әллә ничек, душага рәхәт булып китте. Менә монда, – ул күкрәгенә какты, – нәрсәдер кабынды.

Сәет мине кочаклап ук алды.

– Абзый, әй, йоклама! – Изрәп киткәнмен икән, Сәет терсәге белән касыгыма төртте.

– Всё нормально! – дидем мин, кузгалып. – Кайтырга кирәк...

– Абзый, җырла әле берне...

Мин кыстатып тормадым.

Хуш, авылым, сау бул,
Сәламнәр көт,
Таң җилләре искәндә...

Сәет элек тә нечкә күңелле малай иде, ә бүген тәгәри-тәгәри елады. – Бәхетсезләр без! – дип үкседе ул. – Ятимнәр, – дип ыңгырашты.

Көч-хәл белән машинаның арткы ишегеннән кертеп салдым үзен. «Ундүртле» үкереп кузгалды.

...Иртән су эчәсем килеп уянып киттем. Тамак кипкән, башны күтәрә торган түгел. Аш бүлмәсе ягыннан ярым пышылдап сөйләшкәннәре ишетелә:

– Казанда да шулай идеме? – Әнинең тавышына борчулы төсмерләр ягылган.

– Юк, гомеремдә беренче тапкыр күрәм... – Монысы хатын. – Бер тапкыр да эчкәне юк иде бит.

– Яшермә, килен! – Әти дә шунда икән. – Салып йөри башлаган инде бу, алайса. Бәйдән ычкынган. Яклама, дөресен сөйлә. Казанда шуңа рәте-башы булмаган...

– Күрше-күлән күрдеме икән?

– Күрмичә! – Әтинең тавышы кырыс иде. – Көтү куарга чыкканнары күрде инде! Машинасының ишеге ачык, үзе шунда ишек төбендә, җирдә ята иде...

– И Ходаем! – Әнинең сулкылдавы ишетелде.

Миләүшә эндәшми әле, болар җырына кушылып китмәде. Өмет бар, димәк, – эчемә җылы йөгерде. Шулчак бабайның тавышы өй диварларын яңгыратты:

– И-и пумала башлар, эшегез беттеме? Мужик ул эчми тормый. Йөрәге сызлыйдыр, ул сезнең кебек таш бәгырь түгел! Син монда нәрсә кыз-хатын арасында утырасың? – Ул әтигә ташланды. – Үзеңне лыгыр булып кайткан өчен күпме яңакладым? Оныттыңмы, ә?

– Әйсәнә! Син генә бездың малайны! Сүз әйттермәгән булып... – Әти, өстәлне кузгатып, урыныннан торды. – Мин эшкә киттем...

Шуның белән базар таралды, әти чәй эчәргә генә кайткан булгандыр – әле урак өсте җитмәгән. Мин, авырлык белән генә торып, аш бүлмәсенә чыктым. Беренче тапкыр күргәндәй, бөтенесе дә миңа текәлде.

– Беренче һәм соңгы тапкыр, – дидем мин. Әни кайнаган суны өч литрлы банкага салып куя иде – шуны голт-голт эчеп бетердем.

Ишегалдына чыктым – Искәндәр, аякларын чалыштырып атлап, тавык куып йөри иде.

– Әт-ти, тот! – диде ул, сөенеченнән балкып.

Аның уенына мин дә кушылып киттем – чуар тавык ахыр чиктә читән почмагына кысылды да, куырылып, язмышына буйсынды. Искәндәр чырык-чырык көлеп, аның канатыннан сыйпады.

– Улым, булды, җибәрик инде, әнә әтәч нишләргә белми анда.

– Тот! – Бу юлы Искәндәрнең үзе артыннан кудым.

Безнең уенның ахыры һәрчак Искәндәрнең елавы белән тәмамлана иде, бу юлы да ул сөртенеп егылды да җиргә тәгәрәп китте.

– Аб-бу!

Әмма елау озакка сузылмады, бозау «му»лап җибәрүгә, ул лапаска кереп китте.

– Бүген төнлә еламады... – Миләүшәнең тавышын ишетеп, сискәнеп киттем.

– Ә-ә...

– Әни яңа сауган сөт биргән иде, тагын сорап эчте...

– Әйбәт булган... – Кайчан хатын үгет-нәсихәтен башлар да, җанымда уйнар икән дип көттем. Әмма колагыма бөтенләй көтелмәгән сүзләр ишетелде: – Сүкмим дә, үпкәләмим дә. Син инде тормышның төбенә, тәмам түбәнлеккә

төшеп җиттең, хәзер инде күтәрелә башла. Иртәгәдән – эшкә, онытма. Малайны кара...

Ул кырт борылып кереп китте. Әгәр тотып сүксә, кычкырса, болай ук авыр булмас иде, бу сүзләре исә аңымны томалады.

Түбәнлек...

Тукта, нинди түбәнлек турында сүз бара соң? Нигә болар бөтенесе дә мине тәмам беткән кешегә чыгара әле? Нәрсә, туган нигезеңә яшәргә кайту түбән тәгәрәүме? Мин бит әти белән әнинең бердәнбер улы, апам күптән кияүдә, район үзәгендә үз гаиләсе белән яши. Киресенчә, минем бу гамәлем хупланырга гына тиеш түгелме соң?

Мине кечкенә чагымда «үҗәт» дип йөртәләр иде. Мәгънәсен аңлаганчы, ул сүзне мин үчекләү дип кабул иттем. Бабай иплəп кенә төшендерде:

− Мине дә шулай йөртәләр иде, улым, – диде. – Ул бик тә шәп сыйфат. Менә син нинди дә булса эшкә тотынсаң, аны тәмам ахырына җиткергәнче туктамыйсың. Укытучыларың да, тырыша, төбенә төшәргә тели, дия иде. Бик һәйбәт бу. Җырларның да иң матурларын гына җиренә җиткереп җырлыйсың. Комбайнда әтиеңне куалап эшләттең дә, беренчелекне алдыгыз. Менә бу үҗәтлек дип атала инде.

Ни гаҗәп, ул сыйфатымны мин Казанда җуйганмын, ахры. Менә хәзер, Миләүшәнең сүзләреннән соң, аларның аш бүлмәсендә сөйләшүләрен ишеткәч, кан тамырларының кызышып алуын тойдым – кабаттан миндә нindидер эшкә тотыну, аны җиренә җиткерү һәм шуннан ләззәт алу тойгысы уянды.

− Син боларның сүзләрен күңелеңә авыр алма. − Бабайның сөякчел кулы җилкәмә кагылды.

− Юк, бабай. Менә үҗәтлекнең ни икәнен аңлатуыңны искә төшереп утырам әле.

− Шулаймыни? Һе-һе. Әйбәт.

Ул арада лапас ишегеннән күршеләрнең ак мәчесе атылып чыкты, аның артыннан Искәндәр күренде.

− Мияу, мияу! – Малай аның артыннан урамга чыгып китте. Мин дә күтәрелә башлаган идем, бабай кулымнан тотып туктатты:

− Әдрән, көне буе шуның артыннан йөрмәгез әле, эшегез юк кеше кебек. Йөрсен рәхәтләнеп! Аңа сакчылар кирәкми.

− Адашмасын тагын...

− Адашса ни?! Аның Әдрән малае икәне маңгаена язылган, кайтарырлар! Безнең Чияледә бала урламыйлар...

Бабайның сүзләре кызык тоелды, икәүләшеп көлдек.

− Кара әле, Әдрән, авылга яңа клуб кирәк инде, монысы бигрәк иске...

− Шулаен шулай да, бабай. Газинур абый гына күңелгә шом салды: киләсе елдан ябарга исәпләре бар икән. Ничек тә саклап калырга инде...

− Силсәвит Газинурмы?

− Әйе!

− Ябасы булгач, ник кешене ышандырып эшкә кайтаралар? Син аны гөрләтеп эшләтеп җибәр, улым. Аннан яңасын салу артыннан йөрергә кирәк! Әнә бит район гәҗитендә язалар, төрле авылларда клубын, медпунктын, башкасын – бөтенесен бер түбә астына тыгып, яңа төрле биналар салалар. Безгә ярамыймыни?

− Шулай...

− Силсәвит үзебезнең авылда булмагач, игътибар юк инде, улым. Авылдан кешесе дә чыкмады шунда, каһәр...

– Менә бу иске клубны нишләтеп булыр икән, дип уйлыйм әле, бабай. Кешеләр клубтан бизгән, яшьләр бармак белән генә санарлык...

– Һи-и, заманында! – Бабай имән бармагын өскә күтәрде. – Райунда иң шәп җырчылар бездә иде! Мин гармунны тартып җибәрүгә, башкалар шундук тын кала иде!

– Туктале, бабай! – Берни уйламаска өйрәнгән башымда нәрсәдер гөлтләп кабынды. – Җырлый торган әбиләр калдымы икән әле?

– Ник калмасын? – Бабай бармагын бөкләп санарга кереште. – Маһруй шәп җырлый иде – булды бер, Төлке Саниясе райунда да җырлаштыргалады – булды ике, тагын килеп, Зимагур Әнәснең Мәрьяме, Күке Зөлфиясе бар, аннары – кибетче Гөлчирә... Ничә булды?

– Биш!

– Җырладык инде, Әдрән улым, Сабан туе да, Яңа еллар да бездән башка узмый иде. Хәзер генә ул бер бәйрәм дә юк, Сабан туена да күрше авылга барышлы, Яңа ел бәйрәме дә әллә нәрсә шунда...

Бабай минем башымда нинди уй-фикерләр кайнаганын белми әле! Мин инде клуб директоры булып фикерли башлаган идем! Яшьләр юк икән, алар битараф икән, димәк, картлардан башлыйбыз!

– Бабай! – Мин аның заманны зурдан кубып сүгәргә җыенганын беләм, әмма тыңларга һич вакыт юк. – Син миңа ярдәм итәргә тиеш!

– Ярдәм? – Бабай аптырап калды, аннан кеткелдәргә тотынды. – Сиксән биш яшьлек карттан нинди ярдәм була инде, улым?

– Ансамбль ясыйбыз! Чияле авылы ансамблен!

– Анысы нәмәстә тагын?

– Менә син тагын гармунчыга әйләнәсең, әбиләрең җырлый. Районны аякка бастырабыз, аннан Казанны алабыз!

– Аннан инде теге дөньяга да ерак түгелдер...

Мин чигенергә җыенмыйм. Бабайны кочаклап ук алдым:

– Бабай, син мине яратасың бит?

– Сорап торасың тагын...

– Мин синең иң яраткан улың бит?

– Ие!

– Димәк, син миңа ярдәм итәсең?

– Итәм!

– Яратам да инде бабаемны! Иң яраткан кешемдер ул минем, билләһи!

– Безнең чырайдан кешеләр куркып качмасмы?

– Качмас, бабай! Әбиләрне ничек көйләрбез икән?

– Менә анысы вапрус инде, Әдрән улым. Һи-и, яшь чагым булсамы?! Хәзер инде авызыңны ачсаң – теше юк, инструминтсыз осталар хәленә калдык... – Бабайның күзе ялтырый – минем сүзләр аны җилкетеп җибәрде кебек. – Корткаларны кузгату авыр инде ул, ә бер кузгатса-аң, туктата алмассың әле!

– Искәндәр кайда ул? – Безнең сүзне Миләүшә бүлде.

– Урамда йөри, – дидем мин.

Бераздан ул әйләнеп керде, куркуы йөзенә чыккан иде:

– Әдрән, тыкрыкка кадәр бардым, беркайда да юк...

Мин, атылып, урамга чыктым. Миләүшә дә миңа иярде.

– Кара, дидем бит. Яшь ярымлык баланы машина бәрсә... Әтәч күзен чукыса...

Бездән өч өй аркылы яшәүче Маһруй әбинең капкасы ачык, аннан сөйләшкән

тавышлар ишетелә иде – башымны тыгып карасам, Искәндәр белән икәүләшеп ишегалдындагы сары төс ягыла төшкән чирәмлеккә чүмәшкәннәр.

− Маһруй әби, нихәлләрдә сез? – Мин ике куллап күрештем. Миләүшә исә, еллар буе күрмәгәндәй, Искәндәрне кочаклап алды.

− Менә, җүнсез ак тавыгым, тагын чеби чыгарды. Киребеткән тавык булды шул, җәй ахырында кыртлый да, чебиләре барыбер кеше булмый инде аның. Ничә куып төшердем үзен...

− Искәндәр, әйдә, өйгә кайтабыз, − диде Миләүшә.

− Җоок! – Искәндәр бер кулы белән Маһруй әбигә ябышты.

− Бик дуслаштык әле Искәндәр улым белән. – Маһруй әби канәгать кеткелдәде. – Нәкъ син инде, валлаһи! Суйган да каплаган! Менә чебиләрне күрде дә хәйран калды. Син дә шулай корт-мазарга үлеп тора идең бит.

− Миләүшә, бар, кайт, мин улым белән калам.

− Тагын югалтма! − Ул, кырт борылып, чыгып китте.

− Һе, − диде Маһруй әби, әмма бер сүз дә эндәшмәде.

Камәр әби белән Маһруй әби җәйләрдә һәр кичтә капка төбенә чыгып утыра иде. Алар янында мин дә буталам. Маһруй әби, кесәсеннән суыра торган кәнфит чыгарып, гел җырлата иде үземне.

− Җырламады әле малаең, – дип, Искәндәрнең башыннан сөеп алды ул. – Гайнан бабаң да җырлый, әтиең аннан да остарак, дим үзенә. Аңлаган сыман карап тора. Җырлар әле, моңлыдан моңлы туа.

Маһруй әби сүзләре күңелемә сары май булып ятты, нәни учына сап-сары чебине кысып тоткан улымның юка саргылт чәченнән сыйпадым.

− Син үзең дә шәп җырлыйсың бит, Маһруй әби!

− И-и, кит инде, булмаганны! Яшь чакта кем җырламый инде!

− Бабай әйтә, Маһруй әбиең, калышса да, шул Әлфия Авзаловадан гына калышадыр, ди!

− Гайнан бабаң ни сөйләмәс! – Маһруй әби, үзе дә сизмәстән, яулык чите белән авызын каплады. – Аның теле белән! Камәр әбиең әйтә торгание, сүгеп тә булмый бит аны, дип. Камәрбану, Камәрсылу, дип, әллә ниләр әйтеп бетерә дә сихерли, дия иде. − Маһруй әби инде минем аркамнан сыпырып алды.

Берьялгызы яши ул. Гомер буе авыру − кечкенәдән аяксыз сеңлесе Миңлегөлне карады. Аны ялгыз калдырмас өчен, кияүгә дә чыкмаган. Миңлегөл әбинең вафатына өч ел була бугай, хәзер инде Маһруй әби гел берүзе калды. Бер дә тик тормый тагы: каз-тавыгын да асрый, бакчасында да мәш килә. Әти, аңа әйтеп тә тормыйча, тракторы белән бакчасын сукалый, бәрәңге алу чорында Гайнан бабай, күрәген таяк итеп, иң беренче Маһруй әбигә кузгала. Аңа мин иярәм.

− Бераз авылда торырга кайткансыз икән, әниең әйтте. Әйбәт булган, Әдрән. Авыл һавасы балага килешә ул... − Маһруй әби уйларымны бүгенгегә кайтарды.

− Шулайрак иде шул, Маһруй әби. Нәрсә булып бетәр?

− Бик әйбәт бетәр! − Маһруй әби, ни гаҗәп, гел шундый күтәренке күңелле булды. Юкса аның бу тормышта нинди шатлык күргәне бар да, нәрсәгә куанганы бар? – Гайнан бабаң белән очрашкан саен, синең җырлавыңны сагынабыз. Икенче Илһам син булырсың, Алла боерса! Бездә шул кешене вакытында күрә белмиләр! Үзең дә тыйнак инде...

− Ярар ла, Маһруй әби! Менә без бүген бабай белән синең җырлаганны сагынып утырдык әле!

− Кит, булмаганны!

– Гайнан бабай әйтә, Маһруй җырлый башласа, гармунымны тотып, янына басып җырлыйм, ди!

– И-и, син дә тач бабаң булып беткәнсең икән! – Ул кабат аркамнан сөеп алды. – Бабаң шулай гомере буе миннән көлде...

– Юк, чынлап, Маһруй әби! Мин клубта эшли башлыйм иртәгәдән. Менә көзге эшләр беткәч, бер җыелышып җырларбыз әле...

– Һай, Әдрән, җитмеш биштә кеше көлдереп йөриммени хәзер! Кит, булмаганны! Җүнле кеше бу яшьтә йә намазлык өстендә утыра, йә үлә. Тавышы да чыкмый инде аның хәзер, җырлары да онытылган...

– Көзгә кадәр кабат исеңә төшәр әле, Маһруй әби, – дип, мин дә карчыкның җилкәсеннән кагып куйдым.

Искәндәр, чебине тоткан килеш, капкага юнәлде:

– Улым, тукта, ул әле кечкенә, әнисеннән башка яши алмый!

Искәндәр башын чайкады.

– Тагын керербез, улым, яме?

– Җоок!

Хәзер ул елый башларга тиеш иде – иреннәрен бөрештерде, кашлары җыерылып килде.

Рәхмәт төшкере, Маһруй әби үзе ярдәмгә килде:

– Әнисенә алып кайтып күрсәтсен инде, аннары китерерсең!

– Рәхмәт! – дидем мин.

«Кош тоткандай» дигән сүзнең сөенүгә ни катнашы бар икән, дип уйлый идем элек, менә хәзер аңладым: сап-сары чебине учлап тоткан, авызы колагына җиткән Искәндәр улым дөньяның иң бәхетле кешесе иде бу мизгелдә!

Без өйгә шулай кайтып кердек. Гайнан бабай чәй эчеп утыра иде – тизрәк аның янына елыштым. Минем урында хәрби кеше булса, безнең өйне ике лагерьга бүленгән, дип әйтер иде. Бер якта – Гайнан бабай белән мин, икенче якта – әти, әни һәм Миләүшә.

Әмма мондый вак-төяк уйлар уйлап вакланырга башка вакытым булмады – иске дә, яңа да тормыш мине бөтереп алды.

* * *

Газинур абый туганнан бирле «силсәвит» бугай инде ул. Ипле дә кеше инде үзе! Карап торышка тиз арада әвәләнгән Кар бабайга охшаган – ике зур, бер кечкенә түгәрәктән тора: кыска юан ботларына түм-түгәрәк корсак, аннан түм-түгәрәк пеләш башны утыртып куйганнар. Әмма алтын-көмеш тешләрен елтыратып, күзен сызыкка гына калдырып елмаеп җибәрсәме?! Аннан да чибәр кеше табалмассың дөньяда.

– Әйбәт кеше ул шулай мулдан була... – Газинур абый шактый ук очлаеп торган корсагын яратып уа.

Ул – гаҗәеп кеше! Гел ак күлмәктән йөрер, «Шевроле Нива»сында горур гына узып китәр, кемдер кул изәсә, шундук туктар, аның гозерен, хәтта зарын да ахыргача игътибар белән тыңлар. Сүз сөрешенә карап, кашын җыерып алыр, тел шартлатыр, «Ну да?!» дигән атаклы сүзен йөзләгән интонациягә төрләндерер. Аның белән әңгәмә корган беркем дә канәгатьсез калмый. Иң мөһиме, Газинур абый аларның мәсьәләсен хәл дә итә әле!

– Сезон кергәнче, клубны сипләштереп чыгарсың, дигән идем, энекәш, булмады. Монда пакусны киң алдырырга туры килә, ну да! Район миллион төрле эш куша, кайсыннан башларга да белгән юк. Ну да! – Ул түм-түгәрәк йөзенә

килешеп торган түгәрәк кысалы күзлеген ипләп кенә сөртте, борын очына элде. Өстәлендә кәгазьләр аз түгел иде, берәм-берәм һәммәсен дә карап, миңа «фронт» сызыгын билгеләде: – Беренчедән, культура бүлеге урак өстендә агитбригада сымак нәстәкәй оештырып, кәнсирт-мазар белән игенчеләрнең күңелен күтәрергә тиеш. Культура башлыгы Венера Шәмсиевна әйтә, бездән бер номер, ди. Анда, ди, сезгә Әдрән кайтты, ди. – Ул, күзлеген тагын да аска тартып, зәп-зәңгәр күзен миңа төбәде. – Ул сине белә икән, ну да?! Малае белән бергә укыгансыңмы шунда?

– Әйе, Радик – минем группадаш... – Дөрес, бу хакта әйтәсем килмәгән иде.

– Ярар, бик әйбәт бит инде, ну да? Тәк, шул: моны хәл ит. Карамалыда җырлый белүче юк, үзең җырларсың инде. Венера Шәмсиевна турыдан үзеңә шалтырата башлар, үземә кагылмаган мәсьәләне башка кушмасын...

– Ярар, – дидем мин, ризалашып.

– Берәр атнадан уракка да төшәрләр инде. Кичке сменага ындыр табагына киләсе була. Силсәвитләрнең, клубларның бәхете инде ул. Клубыңа материалларны барыбер инвестордан сорыйсы, ремонтка быел акча каралмаган. Аңладың инде, ну да?

– Ну да! – дигәнемне сизми дә калдым.

Газинур абый теләсә нәрсәне гафу итә, әмма бу сүзләрен башка кешедән ишетүне күтәрә алмый иде. Ул, күзлеген салып, миңа карады.

– Ну да... – диде ул, башын чайкап.

– Газинур абый, гафу ит, телемнән ычкынды.

– Телдән ычкыну хәерлегә илтми. Тәк, дәлше барабыз. Кәнсиртне әйттем, ындыр табагын әйттем. Ә-ә! Ну да! Районда укытучыларның август киңәшмәсе була. Ай урталарында инде. Безнең Карамалыга да кирәселәр икән бер ише. Яңа койма тотарга, диделәр. Районның үзендә тишек-тошыкны ямарга кеше җитми, димәк, булышмыйлар дигән сүз. Карамалы мәктәбендә ирләр өчәүме-дүртәүме, аларның да берсенең ир диярлеге юк. Инвесторның кешеләре качып бетте. Бу атнада шунда кайнашырсың, ну да!

– Газинур абый...

– Анысы да монысы, иң мөһимен әйтергә онытканмын бит: бүген районга галимнәр килеп төшкән, ди. Венера Шәмсиевна иртәгә аларны безгә җибәрә. Безнең Карамалы авылы җирлегенә, диюем. Уттай эш өстендә йөрмәсәләр, кылны кырыкка ярырдай чакта! Миңа аларны каршы алып ашатасы, сиңа инде шулар белән йөрисе була.

– Нишләргә тиеш соң мин?

– Анысын үзем дә белмим. Кирәк булса – җырларсың, тыңласалар – сөйләрсең, үзләре әйтер, диде Венера Шәмсиевна. Башта Карамалыга килерләр, аннан үзеңнең Чиялеңә алып китәрсең, ну да.

– Клуб мөшкелрәк хәлдә бит әле, коймаларын рәтләп чыгасы иде, тирә-якны алабута баскан, чабармын дигән идем. Сәхнә идәннәре купкан, урындыкларны кагыштырасы бар...

– Ә, әйе! Клуб эшен әйтеп тормыйм, анысы тәртиптә булсын.

– Газинур абый, анда миңа атнасына әллә ничә чара да уздырырга кирәк бит әле...

Ул миңа гаҗәпләнеп карады:

– Уздыр соң...

– Бу эшләр белән мин клубка барып җитә аламмы соң?

– Нәрсәгә сиңа клуб? – Ул балкып елмайды. – Дәкүминтләрең тәртиптә булсын. Аны бит өйдә дә эшләп була, ну да!

– Алай ничек булыр икән?

– Шулай иң дөресе була! Бу клуб болай да ябылырга тиеш, синең өчен бер елга калдырдык. Әйбәт кенә эшләп ал да киләсе елга Карамалыга күчәрсең. Чияленекен барыбер ябабыз. Сезнең йөз йортка тулыр-тулмас авылда клуб тотып булмый. Венера Шәмсиевна шулайрак әйтте. Бераз чыныгу алсын, диде. Шуңа күрә дәкүминт ягыннан тел-теш тидерерлек булмасын...

Газинур абый мине озата чыкты:

– Барысы да әйбәт булыр, энем!

– Кайсыннан башларга соң әле, зиһен чуалды, – мин әйтәм.

– Синең клубта техничка кем әле?

– Разия апа.

– Башка кешең юк та бит инде. Тәк, менә шуңа эш кушудан башла. Кунаклар килер алдыннан, клубны бераз адәм рәвешенә кертсен. Җырлый-сөйли белә торган берничә карчык-корчык та әзер торсын, дигән иде Венера Шәмсиевна, шуларны йөреп чык. Елтыр-йолтыр күлмәкләрен киеп торсыннар иртәгә. Шуларны көйлә дә мәктәпкә койма тотарга бар, ну да...

Мин машинамны Чиялегә кудым.

– И-и Әдрән җаным, бигрәк өч тиенгә калдырдылар бит акчаны, бераз арттырсыннар, әйт әле үзләренә! – Разия апа мөмкинлек чыгудан файдаланып калырга тырышты.

Нәрсә диим? Буш вәгъдә бирә алмыйм, иңсәләремне генә сикерттем.

– Беләм, беләм, барыбер артмый инде ул, болай гына әйтүем. Япмасыннар гына инде, берүк...

– Менә анысы өчен тырышасы бар!

Разия апа, итәкләрен кыстырып, эшкә кереште, мин урам буйлап атладым.

– Китсәнә, Әдрән, Казан галимнәре алдында оялмыйча тагын! Булмаганны, юк-юк! – Сания әби кулын гына селтәде.

– Әйткәннәрие, Газиз малае авылга, клубка кайткан, дип, рас икән! – Мәрьям әби дә егылып төшмәде әле үтенечкә. – Без яшь чакта күлмәкләрнең матурларын киясен кидек, саласын салдык, улым. Хәзер алтыннан ясалганны кисәң дә юк инде. Авызыңда тешең, күзеңдә очкын булмагач... Юк, юк...

– Үләм, Алла сакласын! Алар алдында оятка каласым юк, минем бит гыйлем җиде класс кына. Алар кычкырып көлсенмени? Гайнан бабаң да яшь чагында кәмитче иде, син дә шул икән!

Зөлфия әбидән дә өметле сүз ишетә алмадым.

Маһруй әбинең капкасыннан узаргамы-узмаскамы дип икеләнеп торганда, бәхетемә, үзе күреп алып сүз башлады:

– Әдрән улым, мине эзлисеңме?

– Шулайрак, Маһруй әби. Хәлләр мөшкел әле, син генә коткарсаң инде...

Ул яныма ук килеп басты.

– Нәрсәкәй генә булды, Әдрән улым?

– Газинур абый, Карамалыдагы силсәвит инде, эш кушты. Иртәгә Казаннан галимнәр киләсе, ди. Чиялегә керәселәр икән. Җырлый-сөйләшә белә торганрак әбиләрең матур күлмәкләрен киеп торсыннар әле, ди. Берсе дә егылып төшмәде...

– Кемнәргә кердең соң?

– Мәрьям әбигә, Зөлфия әбигә, Сания әбигә...

– И-и, гомер буе җебегән булдылар инде! Соң, миңа керсеннәр!

– Чынлапмы, Маһруй әби?

− Яңа бал, мәтрүшкәле чәй белән сыйлармын үзләрен.

Мин Мәһруй әбине кочаклап алдым.

− Рәхмәт, яме, Мәһрүттәй! Иртәгә сиңа алып киләм! Матур күлмәгеңне дә кияргә онытма!

Мин машинама таба йөгердем, Карамалы мәктәбенә койма тотарга булышасым бар бит әле.

* * *

− Кая соң болар, сәгать тугыз тула бит инде?! Ни яңа эшкә тотынып булмый, ни башланганына нокта куялмыйм бу җәфалар аркасында, ну да! – Газинур абый, каш өстенә кулын куеп, район үзәгеннән Карамалыга килә торган юлдан күзен алмый.

− Утыз чакрымны бер сәгать киләләр бугай инде... − Мин дә учакка утын өстәдем.

− Заразылар! Унау ди бит әле алар, әбите безнең өстән, ну да! Әдрән, ишетсен колагың, ахыргача шулар белән йөрисең, бүген эшне бетерергә кирәк. Иртәгегә калмасыннар! Монда ничу бака туе ясап ятарга!

− Киләләр! – Карамалыга ак микроавтобус борылды. – Шулар булырга тиеш!

Газинур абый алпан-тилпән авыл советы бинасына кереп китте:

− Сәрия, кая син? Чык, әйдә, ну да!

Ишектән ак калфаклы, милли күлмәктән, камзулдан, читектән, чәкчәк күтәреп чыккан авыл советы секретаре Сәрия апаны күргәч, артыма авып китә яздым.

− Тигез җирдә абына торган гадәтең бар, аяк астыңа карап атла! Теге адәми затлар килгәч, авызыңны ерып тор!

Ашыкмас, пошмас Газинур абыйны җен алыштырдымыни – хәрәкәтләре җитез, фәрманнары хәрбиләрчә төгәл яңгырый.

Автобус килеп туктар-туктамас борын, ул, ике кулын киң җәеп, әллә ни гомер күрмәгән иң якын туганнарын каршы алгандай, кунакларга таба атлады. Җәйге кояш нурлары аның тук чыраен, пеләш башын аеруча яратып яктырта иде. Юк, алай түгел, Газинур абый үзе кояш иде бу мизгелдә, әнә күктән кояш төшкән дә Газинур абыйның баш урынында түм-түгәрәк булып утыра.

− Исәннәрмесез-саулармысез, милләтебезнең асыл затлары, хөрмәтле уллары-кызлары! Безнең Карамалы авылы җирлегенә килүегез өчен сезгә авыл халкы һәм шәхсән үз исемемнән олы рәхмәтемне җиткерәм, сезнең алда түбәнчелек белән баш иям.

Муены булмаса да, ул иелгәндәй итте.

− Без хөрмәтле кунакларыбызны һәрвакыт чәкчәк белән каршы алабыз. Халкыбызның милли тәгаменнән авыз итегез, мөхтәрәм кунакларыбыз!

Сәрия апа сынатмады, малай, авызын ерган килеш, ашъяулык өстенә куелган чәкчәкне галимнәргә тәкъдим итте.

Мин исә урынымда каккан казыктай басып тора бирдем. Чәч аралары юпь-юеш иде. Вәт, Газинур абый, аның сүзләреннән каз тәннәре чыкты, билләһи! Бу бит, ул бит коеп куйган артист! Әгәр спектакль куярга уйласам, әзер талантым бар!

Газинур абый, кулымнан тартып, үз янына бастыргач кына, уйларымнан айныдым.

− Менә бу инде безнең Карамалы авылы җирлегендә генә түгел, хәтта районыбызда гына да түгел, бөтен татар дөньясында йолдыз булачак

талантыбыз – Әдрән Гыйльфанов! Илһам Шакиров эшен кем дәвам итәргә мөмкин, дип сорасалар, минем җавабым әзер: ул, – һичшиксез, Әдрән Гыйльфанов!

Аркадан гөрләвектәй тир ага, күлмәгем лычма су, маңгайны әйтмим дә инде – керфекләргә тама башлады.

− ...Без, аның якташлары, Әдрәннең уңышларына сөенеп, аның белән горурланып яшибез. Ул туган җиренә тугрылыклы булып, Казанда укуын тәмамлагач, анда ике ел дәвамында музыка дәресләре алып барды да менә безгә кайтты, югары белемле белгеч. Хәзер инде безнең Карамалы авылы җирлегенә кергән бик тә ямьле табигатьле, матур күңелле кешеләргә бай Чияле авылында клуб директоры...

− Ммм... − диеште Казан галимнәре. Бетерде Газинур абый. Кунакларга күземне дә күтәреп карарлыгымны калдырмады.

− Бүген сез Карамалы авылы җирлегендә эшләячәксез, диделәр. Программа өчен Әдрән Газизович җаваплы. (Бу Газинур абыймы соң?) – Хәзер Чиялегә кузгалып, төшке ашка Карамалыга килерсез дә кичкә кадәр шушында эшләрсез.

− Рәхмәт, рәхмәт, − диеште кунаклар.

− Хәзер инде мин дә берничә сүз әйтеп үтим... − Ак чәчле, бөкрерәк, калын кысалы күзлек кигән, алтмыш яшьләр тирәсендәге бер абзый аз гына алгарак чыкты. − Беренчедән, болай зурлап каршы алуыгыз өчен рәхмәт! Бу авылларда бер генә көн булу бик кызганыч... – Газинур абый дертләп куйды шикелле, әмма йөзенә чыгармады. – Бу авыллар, мәгълүм булганча, Идел буе Болгар дәүләте вакытыннан ук билгеле. Моны сиксәненче елларда биредә уздырылган археологик экспедицияләр нәтиҗәсе дә, җитмешенче елларда бу якларда уздырылган беренче экспедицияләр дә ачыклаган һәм укылган борынгы кабер ташлары да дәлилли...

− Гомәр абый, тирәнгә кермә, эшкә керешик... − дип бүлдерде аны ярты башы чәчтән арынган, күзлекле, кыска буйлы, утыз яшьләрдәге егет.

− Әйе, безнең вакыт тар... − Кызыл чәчле, какча гәүдәле кыз аны җөпләп куйды.

− Яшьләр шул өстән генә барырга ярата, тирәнгә керми, − дип сукранды Гомәр абый дигәннәре. – Таныштыра да, максатны да аңлата алмадым...

− Борчылмагыз, борчылмагыз, − дип, аның җилкәсеннән үз итеп какты Газинур абый. – Төшке ашта рәхәтләнеп танышырбыз. Хәзер без болай итик, хөрмәтле кунаклар... − Газинур абый үзенең ипле тавышы белән барысын да тыңларга мәҗбүр итте. Аннан янә әфсененә кereште:

− Заман – яшьләрнеке, аларны тыңламыйча булмый. Чыннан да, сез хәзер Чиялегә кузгаласыз. Сезне Әдрән Газизович алып бара. Ул шунда барысын да хәл итәр. Шулай бит? – Газинур абый зәп-зәңгәр күзен миңа төбәде.

− Шулай, − дидем мин. Тагын нәрсә әйтә алам соң?

− Дөресе шул булыр, − дип җөпләде теге күзлекле егет.

− Ә хәзер, мөхтәрәм галимнәребез, автобуска утырып, Чиялегә китәсез. Ул нибары өч чакрым ераклыкта гына урнашкан. − Тимерне кызуында сугарга тырышкандай, ул, егетен, кызын да, әбисен, бабасын да кулларыннан тотып, артларыннан этеп дигәндәй, автобуска кертеште. Үзенең адымнары җиңеләеп, тавышы көрәеп китте: − Рәхим итегез, әйдәгез, − дип сөйләнде ул, ягымлылыгын бер мизгелгә дә җуймыйча. Аннары миңа: − Планканы төшермә, − дип пышылдады, хәйләкәр елмаеп. – Иң мөһиме, бүген эшне бетер, иртәгәгә кала күрмәсеннәр! Ну да!

Мин автобуска кергәч, ул ишекне ябып та куйды. Авызын колагына кадәр ерган килеш, автобус Чияле юлына чыкканчы, кул болгап торды.

Юлда барганда ук танышып чыктык. Гомәр абзый дигәннәре миңа Чияле тарихын сөйли генә башлаган иде, кырык яшьләрдәге яулыклы бер апа аны бүлдерде:

− Гомәр абый, әйдә, кешечә аңлатыйк әле иң әүвәл, − диде ул. – Менә без, автобус йөртүче Рифат абый белән бергә ун кеше, шулай җәй саен төрле якларга экспедициягә чыгабыз. Һәр елны бер районда булабыз. Шуның нәтиҗәсендә китаплар чыгарабыз. Без монда төрле белгечләр, менә экспедиция җитәкчебез Гомәр Садриев, ул – фәннәр докторы, фольклорчы галим, халык авыз иҗатын җыя.

− Гомәр Яруллович, профессор... − Ул, сул кулын күкрәгенә куеп, башын бераз гына иде дә уң кулын күрешергә сузды.

− Менә монысы... − Ул алгы якта ике генә бөртек чәче калып, шуны маңгаена кадәр үстергән күзлекле кыска егеткә ымлады: − Ирек Идрисов, шулай ук фольклорчы, Гомәр аганың эшен дәвам итүче.

Аның сүзләренә җавап иткәндәй, егет, калын кысаның уртасына төртеп, күзлеген өскәрәк күтәреп куйды.

− Без икебез дә фольклорчы булсак та, халык авыз иҗатын төрле аспекттан чыгып өйрәнәбез, − диде ул.

− Менә мин – телче! Динә Мөстәкыймовна, филология фәннәре кандидаты. Тел үзенчәлекләрен, диалектларны өйрәнәм...

− Бик көчле белгеч, между прочим, аның хезмәтләре Мәскәүдә, Новосибирскида да югары бәяләнә. − Гомәр ага миңа таба янтаеп, җилкәсен терәде.

− Артта утырган кызыбыз, − ул кызыл чәчле, ябык кызга таба борылды, − Алинә Мирзовна, сәнгать белгече. Бер ел элек диссертациясен Мәскәүдә уңышлы яклап, институтыбызда эшли башлады. Заманча фикерли, үзенчәлекле уйлый. Фәнни мәкаләләре Петербург журналларында, чит илләрдә даими басыла...

− Еш кына үзебез дә аңламыйбыз аны, шул дәрәҗәдәге югарылыкта хезмәтләре, һе-һе-һе... − Гомәр абзый учы белән авызын каплап кеткелдәде.

− Ә менә бу рәттә безнең кулъязма җыючылар, иске татар һәм гарәп язуы белгечләре утыра. Зәйни Садыйкович, − ул илле яшьләрдәге, балкып елмайган абзыйга күрсәтте, − доктор, бу өлкәдә төп белгеч. Янында – Айваз, аның шәкерте, аспирант.

− Дөнья шәкертләр кулына кала. − Зәйни абзый елмаюын бер дә сүрелдерми, ахры. – Но! – Ул имән бармагын өндәү билгеседәй өскә күтәрде. − Шәкерт остазын узып китәргә тиеш!

Ул әле тагын да сөйлисе иде, Динә Мөстәкыймовна аның сүзен кырт кисте:

− Алар артында кабер ташларын өйрәнүче, мөхтәрәм Госман Вәлиевич бара. Үзе гүзәл Башкортстанда туган.

Ул җавап итеп елмайды. Госман абзыйның әллә алтын, әллә бакыр тешләре күзне камаштырды. Ә менә бу эсседә баш очына кышын кия торган башлык элеп куюы, калын киенүе гаҗәбрәк иде анысы.

Минем күзәтүемне сизде булса кирәк, Динә Мөстәкыймовна: − Ул шул зираттан чыкмый инде. Үләнгә батып казынамы, эзләнәме шунда. Ничек черки ашап бетермидер үзен, курыкмавын әйт тагын... – дип өстәп куюны кирәк тапты.

− Миңа тими алар, − диде Госман Вәлиевич.

− Ә менә бусы инде... − Динә Мөстәкыймовна янында йокымсырап барган илле яшьләрдәге апаның кулыннан алды. – Безнең музыка белгечебез, гүзәлләрдән гүзәл Гүзәл Салиховна!

− Мөнәҗәт әйтүчеләр бармы авылда? Музыка коралларында уйнаучылар? – Гүзәл дигән апабыз шактый ук кырыс, ахры. Тавышы да чыңлап тора.

− Тукта, башта танышып бетерик инде, аннан эшкә керешербез, − диде Динә Мөстәкыймовна. – Ирина Илдусовна белән таныштырмадым бит әле. Ул безнең оста куллы кешеләрне барлый, матур өйләрне, тәрәзә кашагаларының үзенчәлекләрен өйрәнә, фотога төшерә. Соңыннан аны китабыбызга осталарның фотолары белән бергә эчтәлекле мәгълүматка төреп бирә...

Ирина Илдусовна кулын изәде:

− Исянмысез!

Чиялегә кердек. Автобус клуб каршына килеп туктады.

− Хөрмәтле галимнәребез! − Газинур абый искә төшеп, көләсем килеп китте. – Клубта кечкенә генә музей почмагы бар. Эшне шуннан башлыйк.

− Юк-юк, − дип бүлдерде мине Динә Мөстәкыймовна. Кемгә музей кирәк − шул карасын. Безгә җор телле әбиләр, хикмәтле бабайлар кирәк...

− Миңа – мөнәҗәт әйтүче...

− Миңа − мулла бабай, кульязмаларны, белсә, ул белер...

− Зиратка кем алып керә мине?

− Ирина Илдусовнаны урам буйлап машинада йөртергә кирәк...

− Чигүчеләргә кем алып бара?..

Бөтенесе миннән җавап көтә, бу кадәр игътибардан телсез калдым.

− Әйдә, күпне белгән, күпне күргән бер әбигә алып бар, ул үзе безне бүлеп бирә. − Динә Мөстәкыймовна мине авыр хәлдән коткарды.

− Киттек, − дидем мин, сөенеп.

Маһруй әби ап-ак яулыгын башына япкан, борынгы яшел күлмәген киеп, борчылып, безне көтеп тора иде. Ишегалдындагы сары чебине күрүгә, сәнгатьче Алинә Мирзовна белән Ирина Илдусовна, берсе – телефонына, икенчесе фотоаппаратына ябышып, черт тә черт фотога төшерергә тотынды, үзләре чебиләрне мактап-сөеп туя алмады.

Маһруй әбине яратам да инде, имтиханга бик яхшы әзерләнеп килгән студент кыз ише, галимнәр каршында нык торды, бөтен сорауларына да җавап бирде.

− Мулла абзый өендә иде, әле генә күрдем. Безнең Вәгыйз мулла бик укымышлы, этисе дә шундый иде, иске китаплары бар да бар инде... − Ул сүзен әйтеп бетерергә дә өлгермәде, Зәйни Садыйкович белән шәкерте шунда юнәлде, аларга кабер ташларын укучы Госман агай да иярде.

− Туктагыз әле, самавыр куйган идем элеккечә. Мәтрүшкә салып, чәй кайнаттым. Яңа вәринҗә белән эчәрсез...

− Вәринҗә! Әһә! Мин әби янында калам, − диде Динә Мөстәкыймовна. Теге ярты башы пеләш, күзлекле егет тә ушлы икән ләбаса:

− Мин дә бирედә калам. Фольклор ягыннан күп материал барлыгы сизелә.

− Без, элеккеге буын, кыр шартларында эшләргә күнеккән, − дип, Гомәр Яруллович, таягын каккалап-суккалап, урамга чыгып китте.

Калганнарын Маһруй әби үзе бүлеп бирде: сәнгатьчене – Сания әбигә, музыка белгечен, билгеле инде, Гайнан бабайга озатты. Ирина Илдусовнаны урам буйлап машинада мин йөртергә тиеш булдым.

Бер мәлгә күңелне шом басты: галимнәр өчен җаваплы итеп мине билгеләгән Газинур абый ялгышмадымы икән? Боларны таратып бетердем бит мин!

– Вот! – Ирина Илдусовна Сабир бабай йортына төртеп күрсәтте. Машинамны туктаттым.

– Ай-яй-яй! – Галимә апам тел шартлатты.

Гап-гади кечкенә агач йорт. Алгы якка өч тәрәзәсе карап тора. Сарыга буялган. Төсен ошаттымы? Сабир бабай – оста куллы кеше, чорма тәрәзәсе бизәкле – шул гаҗәпләндердеме галимәне?

– Кем яши? – Ирина Илдусовнаның әнисе марҗа икән, шуңа аның татарча җөмләсе ике-өч сүздән генә тора.

– Сабир бабай.

– Узе геня?

– Әйе, хатыны үлде, балалары Казанда тора.

– Исянмы ул?

– Исән, – дидем мин. – Чакырыйммы?

– Чакырыгыз.

Ул, фотоаппаратын тартып чыгарып, черт тә черт төрле яклап фотога төшерә башлады.

Сабир бабайның ишетү ягы чамалы, шуңа кулын колагына куеп сөйләшә.

– Сатмыйм мин йортны, монда үләм, – диде ул, сүзнең өй турында барганына төшенгәч. – Казанга ике дә аяк басмыйм, кайткан саен алып китмәкчеләр...

– Бабай, исянмысез! – Ирина Илдусовна аны кочаклап ук алды.

– Кем кызы син? – Сабир бабай аны танымакчы булып, хәтерен кузгатты.

– Илдус кызы!

– Кем кызы ди? – Ишетеп бетермәгән Сабир бабай миннән «тәрҗемә» көтә иде.

Мин, ниһаять, максатыбызны аңлата алдым. Сабир бабай бу кадәр игътибарга сөенеп, тагын сорау бирмәсеннәр дигәндәй, ашыгып сөйләп китте:

– Менә, балалар, бу йортны җитмеш бишенче елда салдым, ие. Әти дә балта эшенә оста ие, миңа да өйрәтте. Шулай тәвәккәлләдем дә тотындым, ие. Сиксән бишенче яшь белән барам мин, карт инде, әллә кайчан үләргә вакыт, һе-һе-һе...

Ирина Илдусовна, блокнотын ачып, нәрсәдер язды.

– Карчыгым бик әйбәт ие, биш ел инде киткәненә, уйламаган көнем юк. – Сабир бабайның эре генә күз яше бите буйлап тәгәрәде.

– Бабай кем? Профессия?

– Ветврач идеңме әле син, Сабир бабай?!

– Ие. Аллага шөкер, әйбәт эшләдек, булсын дип эшләдек. Ул вакытта кешеләр икенче ие...

Ирина Илдусовна үзенә кирәкле мәгълүматны алды, ахры, күрше йортларны күзли башлады:

– Бу йортта эшем бетте.

– Рәхмәт, Сабир бабай, вакыт санаулы, – дидем мин.

Машинага утыргач, Ирина Илдусовна йортка яңадан кул изәде:

– Курясезме, кояш рясемен?

Мин текәлеп-текәлеп карадым, әмма кояшны күрмәдем.

– Сары булганга әйтәсезме?

– Юк. Балконны курясез?

– Күрәм.

– Анда восточная арка бар...

– Әһе.

– Уртада – тярязя. Анын өстендя полукружие. Уф, татарча ничек?

– Ярымтүгәрәк.

– Вот. Бу – кояш чыгып киля.

Ирина Илдусовна һәр йортның үзенчәлеген ачып бирде. Һәр йортта татарга, мөселманга хас символларны күрсәтте, әллә нинди тарихларга кереп китте. Бермәлне мин үзем дә моңарчы гап-гадәти дип йөргән авыл өйләренә әкият сарайлары сыман карый башладым. Тәрәзә йөзлекләре өстенә кош рәсеме төшерү борынгыдан килә икән. Кош ул татарлар аңына борынгыдан кояш һәм яктылык символы буларак сеңгән, ди. Безнең авылда күгәрчен рәсемнәре генә бар дип йөри идем, Ирина Илдусовна аккошын да, үрдәген дә, сандугачын да, карлыгачын да күрсәтте. Әле боларның һәммәсенең дә мәгънәсе бар икән. Пар аккош ир белән хатынга тигез мәхәббәт, тугрылык, дус-тату тормыш тели, имеш.

Чияленең һәр йортында диярлек туктап, фотога төшереп, хуҗалары белән сөйләшә-сөйләшә, төшке аш вакыты да җитте Миндә ике төрле хис көрәшә иде. Бер яктан, Чияле өйләренең гади генә булмавы, һәр йортның гаҗәеп мәгънәгә ия икәнлеген белүдән горурлык кичерсәм, болар хакында беренче ишетүем шактый ук хурландыра иде.

Галимнәрне җыеп, автобуска утыртырга да Карамалыга илтергә кирәк иде. Өйгә кайттым – бабай да, музыка белгече дә юк.

– Гармунын кыстырып чыгып китте теге галимә дигән хатыныгыз белән. Хәерлегә булсын... – диде әни

Маһруй әбигә кердем, капкасы ачык – өй ишегендә йозак эленеп тора.

Аптырагач, клуб янына киттем. Ак микроавтобус урынында – күңелгә җылы йөгерде.

– Әдрән, син кайда йөрисең, монда кәмит күрсәтәләр. – Разия апа кулымнан тотып дигәндәй өстерәде.

Керсәм... Безнең клубның сәхнәсендә алма төшәрлек тә урын юк. Бабай гармунын тотып, күкрәген киереп баскан. Матур күлмәген кигән Маһруй әби, чәчәкле күлмәгеннән Сания әби, алъяпкычтан Гөлчирә әби, тула оеклардан Мәрьям әби, Зөлфия әби тезелешеп тора.

– Баш-ла-дык! – Гүзәл Салиховнаның дирижёр сыман кулларын болгап җибәрүе булды, Гайнан бабай гармунын тартып та җибәрде.

Йөгереп кердем өйләргә,
Бүрегем элдем чөйләргә.
Яшь чагында уйна да көл,
Калсын сагынып сөйләргә...

Әбиләр алдыннан вәкарь белән генә атлап, кыз сайлагандай җырлый-җырлый үтте бабай. Рәвеше!

Аллия-Гөллия,
Гөллия тирәккәем;
Яшә гөлләр арасында, –
Шул сиңа теләккәем...

Әбиләр дә сер бирмәде, җырны күтәреп алды.

Җыр тәмамлангач, галимнәр аягүрә басып кул чапты.

– Афәрин!

– Менә, ичмасам, чын талантларны ишеттек!

– Әзер фольклор ансамбле бу!

Мин тораташ булып басып тора бирдем. Гүзәл Салиховна яныма йөгереп килде. Якадан гына тотып алмады инде:

− Сез, һичшиксез, фольклор ансамбле оештырырга һәм Казанда чыгыш ясарга тиешсез! Мин үзем кайбер конкурсларда жюри буларак катнашам, сезгә тәкъдимнәремне җиткерермен. Әмма бу талантларны башкала халкы да күрергә тиеш!

− Әбизәтелне киләбез! – диде Гайнан бабай һәм, шуны дәлилләгәндәй, гармунын шыгырдатып куйды.

− И-и, каян килеп чыктыгыз әле? − Маһруй әби һәммәсе белән дә ике куллап саубуллашып өлгерде. – Онытылып беткән уеннарны искә төшердегез, әллә кайчангы җырларны җырлаттыгыз. Яшьлекләр искә төште, перәме!

Сәгать уникедә Карамалыга кире кайтырга тиеш идек, инде сәгать ике тулып килә.

− Гаҗәеп авыл, гаҗәеп кешеләр! – Динә Мөстәкыймовна шулай дигәч, эчемә җылы йөгерде.

− Мин бик канагат! – Ирина Илдусовна да аны җөпләде.

− Халык рухи яктан бик бай... − Гомәр Яруллович салмак кына сүз башлады. – Уеннарны хәтерлиләр. Якты күлгә бәйле кызыклы риваятьләр язып алдым. Әлбәттә, хәзер фольклор үрнәкләрен табу елдан-ел кыенлаша, бу очракта, аңлагансыздыр инде, сүз фольклоризмнар турында бара, ягъни...

− Монда һәр йортта Коръән китапларын саклыйлар. − Зәйни Садыйкович елмаюын сөйләшкәндә дә җуймый икән. – Күбесе Петербург басмасы, Казанныкылар да очрый. «Мөхәммәдия» күп табылды. Безгә мәгълүм булмаган кульязма да алдык әле мулла абзыйдан.

− Шулаймыни? Менә бит! – Динә Мөстәкыймовна алтын тапкандай шатланды.

− Зиратта XVII-XVIII гасырга караган дүрт таш таптым. Чистартып укыдым. Авылның борынгы булуына дәлилләр инде бу... − Госман Вәлиевич әле дә башлыгын салмаган иде.

− Эх, ул ташларның кайдалыгын билгеләп калмадым, – дидем мин, уфтанып.

− Мулла бабай белә, − контактларыгызны бирсәгез, текстын җибәрермен сезгә. Казанга кайтып, компьютердан тагын бер зурайтып укыйм да...

− Зиратта яз яки көз эшлиләр инде ул, үлән аз вакытта, − диде Госман Вәлиевич. – Зиратлары бик тәртиптә булган авылларны күреп сөенә торган идем. Бүген мин шундый авылда булдым, дип әйтә алмыйм...

Җир тишегенә керердәй булып уңайсызландым. «Егетләрне җыеп, көз башында ук өмә ясарга кирәк!» дип, күңелемә беркетеп куйдым. Быел яз көне биш-алты кеше генә кайнашкан идек шул.

Газинур абый иртән кайда басып калган булса, безне нәкъ шунда каршы алды. Авызы да нәкъ шулай ук ерылган, куллары җәелгән:

− Көтә-көтә көтек булып беттек, − диде ул, балкуын аз гына да сүрелдермичә.

− Без гаҗәеп авылда булдык, иптәш нәчәлник! – диде Динә Мөстәкыймовна. – Соңгы ун елда өзлексез экспедициядә йөреп, мондый да матур кешеләр яшәгән авылны очратканым юк иде.

− Ну да? – Газинур абый, шыттырмыйсызмы дигәндәй, миңа борылды. – Ник соңга калдыгыз, графиктан чыгасыз бит, − дип, пышылдарга да өлгерде.

Чәй өстәле янында да сүз эш турында барды. Бәлеш пешереп килгән Сәрия апага исә бөтенләй тынгылык булмады. Кызыл чәчле сәнгать белгече Алинә Мирзовнаның сорауларыннан ул тотлыга ук башлады.

– Бәлешнең размерын беләсезме? – дигәч, Сәрия апа бөтенләй коелып төште.

Сәнгать белгече, кесәсеннән җыела торган линейка тартып чыгарып, аның диаметрын үлчи башлагач, Газинур абыйның да кысынкы күзләре түм-түгәрәк булды.

– Ни, кем, мадам, туташ, нинди табада пешерәсең, шуңа бәйле инде ул, ну да! Зур табада пешерсәң – размеры зур була, кечкенә табада пешерсәң – кечкенә була, – Газинур абыйның аңлатмасы бик гади дә, бик аңлаешлы да иде югыйсә, әмма сәнгать белгече аны кабул итмәде:

– Фән төгәллекне ярата! – дип кырт кисте. Хөкемдәй яңгыраган сүзләрдән хәтта Газинур абый да шым булды.

Көннең икенче яртысы Карамалыда узарга тиеш. Бу авылга инде Карамалы клубы директоры Фәридә апа җаваплы.

– Син хәзер нишлисең? – дип сорады Газинур абый.

– Койма тотарга барам.

– Тукта, койма качмас, болардан әйбәт кенә котылырга иде бит. Фәридә апаң куркып калды әле, бергәләп йөртеп чыгыгыз инде, син тәҗрибәле хәзер, ну да!

– Рәхәтләнеп, Газинур абый!

– Ә? – Ул миңа сәерсенеп карады.

Карамалы авылында мин бөтенесенә дә ияреп йөреп чыктым. Динә Мөстәкыймовна ике сүзне кушып сөйли белмәгән кешеләрне ача икән – бер-ике сәгать утыргач, әбиләр-бабайлар туктаусыз сөйли башлый, Динә Мөстәкыймовна алар сөйләгән арада диктофонын әле сүндереп, әле кабызып тыңлый, кайчак «әһә» дип куя да блокнотына нидер яза башлый. Үзенә сиздерми генә күз салган идем, әлбәттә, берни дә аңламадым: «Тел очы [н] авазы ирен-ирен [б] авазлары алдында өлешчә охшашлана: сиксәмбиш – сиксән биш, ум малай – ун малай һ.б.», – диелгән иде анда. Ул арада галимә сумкасыннан кечкенә генә чәй каплары тартып чыгара да шуларны әбиләрнең кулына тоттыра. Тегеләр исә тагын да дәртләнеп сөйләргә тотына...

Гомәр Яруллович күбрәк үзе сөйли. Нәрсәдер сөйләп күрсәтә дә, шуны-шуны беләсеңме, дип сорый. Беләм, дисәләр дә язып куя, белмим, дисәләр дә.

Пөшәңгәрнең болынында йөрдем, аяк чылатып,
Нәләт суккан пөшәңгәрләр поши суйган, җылатып...

– Ишеткәнегез бармы моны? Юк? Һәй, моны да белмәгәч, хәзер сөйлим әле...

Шулай да, озак кына утыргач, аның әңгәмәдәшләре дә ачылып, әллә ниләр сөйләп куя. Гомәр Яруллович исә аларны мактап туя алмый:

– Һай, маладис! Әллә ниләр беләсез сез, халык зур ул, көчле ул!

Сәнгать белгече сөлге-тастымал, мендәр ише чүпрәк-чапрак рәсемнәре белән мәш килде, аларны фотога төшерде. Ул арада өй хуҗаларын да сискәндереп алды:

– Информант, фамилия-исемегез ничек әле?

– Ни ди ул? – дип дертләп китте «информантлар». Баксаң, шул мәгълүмат җиткерүчеләр икән инде ул. Фән төгәллекне ярата шул, һәрнәрсәнең үз исеме, үз урыны.

Зәйни Садыйкович иң әүвәл, хуҗаларны мактый-мактый, өч чынаяк чәй эчә. Шуннан үзе турында сөйли, тарихка кереп китә, акрынлап китапларга күчә:

– Эх, шуларны киләчәк буыннарга калдырасы иде, – дип уфтана. – Күпме китапларыбыз теге елларда тартып алынды, яндырылды, күмелде. Без шуларны

бергәләшеп кире кайтармасак, тарихыбыз да, телебез дә, гореф-гадәтләребез дә, милләтебез дә җуелачак, юкка чыгачак! – дип, катгый фикергә килә.

− Кара, әтидә шундый китап бар иде шикелле, чормада ята бугай ул, − дип, бер-берсенә караша, киңәшләшә өй хуҗалары.

Шундый мөхтәрәм галимне, Казаннан килгән профессорны болай чыгарып җибәреп булмый бит инде – чорма ишекләре ачыла, тузанга баткан, дымланып беткән иске китаплар, кәгазь битләре алып төшелә...

− Менә бездә үткәннәргә нинди мөнәсәбәт, − дип сызлана Зәйни Садыйкович. Әмма җитди сөйләшсә дә, күләчлеге җуелмый аның.

Аның өч күзлеге бар икән. Шуларның өчесен дә киеп карагач, берсен сайлап ала. Шәкерте Айваз, блокнотын алып, аңа текәлә, ул исә эшкә керешә:

– Монысы − Коръән, Петербург басмасы. Пөхтәләп саклагыз, монысы – Чәләби, тәк, алга таба − «Бакырган» китабының өлеше...

Хуҗалар, шаккатып, аның һәр сүзен тыңлап, сеңдереп барырга тырыша. Зәйни Садыйковичның хөкеме катгый:

− Бабайлар бездән акыллырак булган! Без алар калдырган китапларны нинди хәлгә төшердек!

Көтү кайтты, сыерлар савылды. Газинур абый кесә телефоныннан ун гына шалтыратмады инде. Ниһаять, рәсми булмаган җитәкче Динә Мөстәкыймовнадан фәрман яңгырады:

− Кузгалабыз!

− Эх, күргән кебек тә булмадык! – дип көрсенде Газинур абый. Еларга җыенган малай кыяфәтендә иде ул. – Сезнең кебек, милләтебезнең йөзек кашларына безнең ишекләр һәрвакыт ачык, теләгән вакытыгызда килегез, мөхтәрәм галимнәр, кадерле кунаклар!

Автобус кузгалды.

− Уф Алла! – диде Фәридә апа.

− Әйтеп бетермә, олы юлга чыксыннар башта, кире борылмасыннар, ну да!

− Рәхмәт, Газинур абый!

− Ә? – Ул сәерсенеп миңа борылды. – Нәрсә?

− Галимнәрне безнең якларга алып кайтканыгыз өчен. Алар минем күзне ачты, хәзер нәрсә эшлисемне, ничек эшлисемне беләм! Гаҗәеп кешеләр, фанатиклар!

− Ну да?! − дип гаҗәпләнде Газинур абый. Ул миңа беренче күргәндәй текәлеп карады. – Нишләп аны баштук шулай әйтмәдең? Венера Шәмсиевнасы, яптырниса, әрәмтамаклар, диде бит. Чынлап шәп кешеләр идемени? Әһ, әйбәтләп күрсәтә дә алмадык бугай авылларны! Их, әйләндереп каплыйсы җен хатыны!

Мин кайтып кергәндә, Гайнан бабай капка төбендә утыра иде. Өй каршындагы комлыкта күрше Хәлим абзыйның Казаннан кайткан оныгы белән Искәндәр уйный.

− Әт-ти! – дип йөгереп килде улым. Мин аны күтәреп чөйдем. Казанда чакта өскә күтәрсәң, дерелдәп, калтыранып елый башлый иде. Хәзер исә чырык-чырык көлә. Урам малае булган да куйган! Көне буе йөреп хәлсезләнгәнменме, ул шактый авырайган сыман тоелды.

− Артык нык яратып карама малаеңа, күз тидерерсең. − Миләүшә капка баганасына сөялеп тора икән.

− Менә, Әдрән улым, бөтенесенә дә әйбәтләп әйттем, син кайттың да авылга ямь керде, дидем. Әнә бөтенесе аякка басты бүген! Маладис, рәхмәт!

– Әт-ти, сөт тәмне!

– Маладис, улым, дәү буласың, көчле буласың...

Өйгә кердем. Әни помидор тозлый иде, Миләүшә ашарга бүлде. Әти исә зал ягында район гәҗитен укып утыра, миңа бер генә күз ташлап алды.

– Бөтен авыл әге-җөге килде бүген, – диде әни.

– Әйбәт бит инде, – дидем мин. Сүзне озайтмадым – кәефне бозасым килми иде.

– Алар шул гәҗиткә төшерүчеләрме инде? – Гомере буе балалар бакчасында аш пешерүче булып эшләгән әни тормышның ул өлкәсеннән бик ерак тора.

– Анда да төшерерләр, китапка да язарлар!

– И Аллам! Яманлап кына язмасыннар инде. Безнең бакчаны төшермәделәрме икән? Ябалар дигән сүзләр йөри, инде әллә ничә килеп тикшерделәр, соңгы ел эшләр, дип әйтәләр.

– Болар яптырмаслар, – дидем, әңгәмәне дәвам итәсем килмичә.

Без Миләүшә белән урамга чыктык. Искәндәр белән күршедәге малай мәче куып йөри.

– Сине көнозын күргән юк, – диде Миләүшә. – Бигрәк эшкә чумдың.

– Бу әле башы гына. Бүген Венера Шәмсиевна шалтыратты, иртәгә районга барам. Урак өстендә бөтен хуҗалыкларда да булырга, дигән глава. Мине ай буе бөтенләй күрмәссең әле.

– Авылга кайткач, мине бөтенләй оныттың...

Миләүшә иренен турсайтты. Кочагыма алдым үзен. Ул арада, алпан-тилпән атлап, Искәндәр килде. Үзе күзен уа.

– Ә-ә итәбезме, улым? – дип сорадым мин.

– Җоок!

Әнисе аны күтәргән иде, башын салды да йоклап та китте.

– Авылга кайтуның бер яхшы ягы бар: сәгатьләр буе күтәреп йөреп йоклатасы юк, урамнан тәмам бетеп керә.

Искәндәрне караватка салып чыккач, Миләүшә белән җитәкләшеп урам әйләндек.

– Соңгы тапкыр болай җитәкләшеп йөргәнне хәтерләмим дә инде, – диде Миләүшә.

– Менә бит, бүген йөрибез...

– Кара! – диде кинәт Миләүшә.

– Ни булды?

– Йолдыз атылды!

– Теләк телә!

Ул тын гына барды.

– Теләдем.

– Чынга ашсын иде.

– Әйтимме ни теләгәнемне?

– Әйтмә.

– Әйтим инде. Тизрәк үзебезнең торыр җиребез булып, Казанга китүне, сиңа яхшы эшләр туры килүен, зур сәхнәгә чыгуыңны теләдем.

Мин җавап бирмәдем.

– Син бу эшеңә чумып, яңа җырлар өйрәнүне, конкурсларда катнашып, зур сәхнәгә чыгу максатыңны онытма!

– Онытмыйм.

Без өйгә таң атканда гына кайтып кердек.

* * *

Венера Шәмсиевна бүлмәсендә ялгызы гына түгел иде. Район мәдәният йорты директоры Рәшит абыйны таныйм, калган икесен белмим.

– Тәк, Рәшит Ризакович, димәк, сездән – алып баручы Сәкинә, баянчы Фәрит, аппаратурага бер кеше. Сез, – ул өлкән яшьтәге апага борылды, – тулы составта чыгыш ясыйсыз. Ничә кеше әле сезнең «Яшь йөрәкләр»дә?

– Алты әби дә ике бабай.

– Яхшы. Сигез плюс өч, булды унбер кеше.

Аннары ул, урта яшьләрдәге, кыска итәктән, нык кына бизәнгән чибәр генә ханымга карап:

– Сез инде, гадәттәгечә, подводить итәсез! – диде.

– Нишлим соң, Венера Шәмсиевна! – дип акланырга керешә тегесе, озын керфекләрен челт-челт китереп. – Ике парны көч-хәл белән ризалаттым. Балаларны йөртергә ярамый бит, сезон булса...

– Сезон булса, сезнең кирәгегез дә юк. Биючеләр буа буарлык районда. Башка костюм сорамагыз миннән! Глава мондый башбаштаклыкны кичерми!

– Дүрт кеше белән биш-алты бию куябыз, борчылмагыз, Венера Шәмсиевна!

– Мин борчылмыйм, сез борчылыгыз!

Венера Шәмсиевна миңа текәлде.

– Таныш булыгыз, яңа коллегагыз – Чияле клубы директоры Әдрән Гыйльфанов. Ул – җырчы, район конкурсларында катнашып урыннар ала иде.

– Беләбез, беләбез, – диеште барысы да. Миңа уңайсыз булып китте. Район конкурсларында урыннар алу турында искә төшермәсә дә була иде Венера Шәмсиевнага. Анда мин гел икенче була идем, беренчедә исә... аның улы Радик.

– Сиңа районның культура тормышына да кереп китү булыр, обкатка да узарсың.

Без һәр хуҗалыкта булып, игенчеләрнең күңелен күрергә, Венера Шәмсиевна әйткәнчә, рухи яктан баетырга тиешбез икән. Көндезге аш вакытында – ындыр табагында, кичке җидедә – басуда, комбайнчылар ялга туктаган вакытта, концерт бирәбез. Кырык-кырык биш минут эчендә җыры да яңгырарга, биюе дә күрсәтелергә, мәгънәле дә, көлкеле дә хикәятләр дә сөйләнергә тиеш икән.

– Бу – глава контролендә! Смотрите! – Венера Шәмсиевна һәр бармагында йөзек ялтыраган йодрыгы белән өстәлгә китереп сукты. – Форс-мажорларны кичермим! Рәшит Ризакович, сезнең җаваплылыкта, аңладыгызмы?

– Аңладым, Венера Шәмсиевна, аңладым...

Көннәр коры килгәнгә, уракка ике-өч көннән чыгалар да икән. Шуңа да без Венера Шәмсиевна бүлмәсеннән туры район Мәдәният йортына килдек.

– Әдрән көн саен утыз чакрым юл йөри алмас, бүген үк Фәрит белән репетиция ясап алыгыз! – Рәхмәт яусын Рәшит абыйга, кешелекле адәм ул.

Фәрит абый исә мине кочаклап ук алды:

– Ичмасам, син булу күңелне күтәрде. Әтрәк-әләм җырчыга уйнаудан да зуррак җәза бармы икән баянчыга?

Фәрит абыйның миңа уйнаганы бар иде, тональностьны шундук дөрес алды. Миңа өч җыр сайларга кирәк иде.

– Көлке сүз сөйләгәннән соң – шаян җыр, мәгънәле сүз сөйләгәннән соң, моңсу җыр булсын. Концерт башында ук игенчеләргә багышланган җырдан алып китәрбез, – диде Рәшит абый.

– Игенчеләр турында җыр бар инде. Моңсу җыр дигәненә, әйдә, «Җидегән чишмә»не?

– Ярар, – дидем мин, ризалашып.

– Шаян җырга менә моны тәкъдим итәм.

Ул дәртләнеп уйный башлады. Үзе үк сүзләрен дә әйтеп барды:

Капка төпләренә чыгып,
Капка төбендә торасың,
Капка төбендә торасың,
Нечкә билең борасың, Хатирәм,
Нечкә билең борасың, Хатирәм.
Нечкә билләреңне борып,
Нечкә билләреңне борып,
Кемне кызыктырасың, Хатирәм?
Кемне кызыктырасың, Хатирәм?

– Бу җырны ишеткәнең бармы?

– Әллә тагын... – мин әйтәм.

– Флёра Сөләйманова җырлый аны. Мин сиңа сүзләрен өйрәтәм, әйдә, бәрик әле шуны.

Анысына да ризалаштым. Рәшит абыйга безнең репертуар ошады:

– Була бу, егетләр! Бер кызып китсәләр, тагын җыр сорарга мөмкиннәр, анысын да уйлагыз, – дип киңәшен бирде ул.

– Әдрән белән без теләсә кайсы диңгезне кичәбез, – дип шаяртты Фәрит абый.

...Ике көннән районда урак өсте башланды. Беренче тапкыр комбайнчылар янына килеп төшкәч, үземне бик уңайсыз хис иттем. Җиде-сигез җәй эти янында комбайн ярдәмчесе булып эшләдем мин. Штурвал тотып кырда эшләгәндә, үзеңне дөнья кендеге итеп, кирәкле кеше дип хис итәсең. Ул елларда әле колхоз иде, рәисе дә, агрономы да, инженеры да – барчасы да синең җайдан тора. Әти, «Нива»да эшләгәндә дә, «Дон»га күчкәч тә, алдынгылар рәтендә йөрде. Берничә тапкыр район гәҗитендә икебезнең фотоны да бастырып чыгарганнар иде. Ә хәзер? Хәзер урак өстен белүче бармы ул?

– Кирәкле кишер яфраклары! Йөрисез икән, эш калдырып... – Әти, безнең агитбригада турында ишетүгә, кашын җыерды.

– Глава кушкан бит, – дип тынычландырырга тырышты аны әни.

Гайнан бабай исә, гадәтенчә, бу яңалыкны бик сөенеп кабул итте:

– Акыллы икән бу глава! Игенчегә хөрмәтне арттырырга кирәк! Без яшь чакта, шундый агитбригадалар килгәч, дәртләнебрәк эшли башлый идек!

Менә шулай комбайнчылар чәй эчәргә туктагач килеп төштек без басуга. «Яңа заман» хуҗалыгының хуҗасымы-идарәчесеме – хәзер аларны белеп тә бетереп булмый – район башлыгының котлауларын җиткергәч, безнең номерларга чират җитте. Фәрит абый баянын сайратып җибәрде, икәүләшеп түгәрәкләнеп чәй эчкән комбайнчылар каршына килеп бастык.

Игенченең уңганлыгы,
Игенченең хезмәт яме,
Игенченең тырышлыгы
Кырларыннан күренә...

Ни хикмәт, кояшта каралган йөзләрендә баштарак сынап карау сизелсә, алар бик тиз җылынды, җырның ахырын без күмәкләшеп җырлап бетердек.

Беренче көнне үк мин ниятләнгән өч җыр урынына алты җыр башкардым.

– Рәхмәт, егетләр-кызлар, – диеште алар. – Тагын шулай килегез әле бер. Күңелне күтәрдегез, чынлап, малай, рәхмәт...

Үзебезнең дә күңелебез булды. Әмма иң зур сынау минем өчен бер атнадан булды. Бу көнне без «Карамалы» хуҗалыгы басуында чыгыш ясарга тиеш идек.

Әти бу турыда ишеткән, минем белән пыр-пыр гына сөйләште:

– Һәр минут исәпле. Болай да башаклар кибә. Безгә килеп тормагыз, – диде ул.

Мин эндәшмәдем, безнең агитбригаданың даны китте бугай инде, район гәҗитендә дә язып чыктылар. Дөресен әйткәндә, үзебезнең басуда, кайчандыр көннәр-төннәр бергәләшеп ашлык суктырган абыйлар каршында җырлау уңайсыз да. Штурвал тотып җырлап эшләүгә ни җитә?

Бу көнне безне тагын да зур сынау көткән икән: район башлыгы Әхәт Вәдүтович та басуга килеп чыкты. Ул сүзен кыска тотты:

– Табигать-анабыз шартларын тудырып тора. Бу көннәрнең бер генә мизгелен дә бушка уздырмыйк. Агитбригаданың басуларга чыгуы – бу сезгә булган хөрмәт билгесе!

Ул сүзен тәмамлады да комбайнчылар арасына чүгәләде. Мин җырлап килеп чыгуга, әти торып басты да комбайнына таба китте.

Безнең сценарий инде тәмам камилләшеп беткән, нәкъ башка басулардагыча, минем соңгы җырны инде без бөтенебез бергә башкардык. Җыр тәмамлануга, Хәлим абый – зиратта мине кычыткан белән пешекләгән шул Хәлим абый инде – торып басты:

– Әхәт Вәдүтович, рәхмәт сезгә! Егетләр-кызлар, мең рәхмәт! Безгә мондый хөрмәтнең күптән тәтегәне юк иде! Бер үтенечем бар, Әдрән тагын җырласын әле! Мондый җырчы Казанда юк, булса да, безнең Чияледә генә!

– Җырла, Әдрән!

– «Хуш, авылым»ны! – дип кычкырды Хәлим абый.

Җыр дигәндә без ялындырмыйбыз. Ул арада Хәлим абый Әхәт Вәдүтович янына алга күчте дә, җилкәсенә үк терәлеп утырып, нидер сөйли дә башлады. Мин җырлый башлаганда, Хәлим абыйның улы Хәйдәр әти комбайны янына чапты. Җырлап бетергәндә, әти дә башкалар янына килеп чүгәләгән иде.

– Бу агитбригаданы бөтен яклап мактап сөйлиләр иде миңа. Үз күзем белән күргәч, тәмам ышандым. Менә Хәлим абзый миңа Әдрәннең шушы авыл егете булып, кечкенәдән комбайнда эшләвен әйтте. Хәзер клуб директоры икән. Менә бит, авыллар бетә дигәндә, шундый егетләрнең кайтуы күңелгә ышаныч өсти. Алай гына да түгел, җырчының да ниндие бит! Мине күпертә, димәгез, әмма дә ләкин яшьләр арасында мондый да моңлы тавышлыны ишеткәнем юк! Аннан килеп, әтисе Газиз абый да биредә икән. Шундый малай үстергән өчен рәхмәт сезгә! Бу егетнең урыны зур сәхнәдә, ерак китәчәк әле ул!

Әхәт Вәдүтович комбайнчылар белән кул бирешеп чыкты, безгә рәхмәтен җиткерде. Иң ахырдан миңа кулын сузды:

– Молодец! Югалма! Син үсәргә тиеш!

Әти ул көнне дә, аннан соң да ләм-мим бер сүз әйтмәде. Мактамады да, хурламады да.

Венера Шәмсиевна гына үзен сәер тотты:

– Урак өсте тәмамлану хөрмәтенә районда зур концерт куябыз. Сезнең агитбригада вәкилләре анда чыгыш ясаячак. Син дә җырларсың инде, Әдрән, главага ярый белгәнсең икән. Шуңа күрә тагын бер кичәдә чыгыш ясарга туры

киләчәк... – Аннан пышылдауга күчте. – Октябрь аенда Әхәт Вәдүтовичка илле яшь тула. Казаннан зур кунаклар кайтачак. Шунда...

Венера Шәмсиевна баштарак миңа ягымлы шикелле иде, ни әйтсәң дә, биш ел буе улы Радик белән бер төркемдә укыдык. Урак өсте тәмамланганнан бирле, гел тинтерәтә әле үземне. Атлаган саен районга чакырта, вак-төяк эшләр кушып йөдәтә, кәгазь эшен әйткән дә юк. Болай да сезон башланды, кем әйткәндәй, райондагы миллионлаган чарада катнашырга кирәк. Өстәвенә Газинур абый да җайлы кеше тапты – йә тегендә чаптыра, йә монда йөгертә. Нинди оешма бар, кем иренми – шул эш куша башлады миңа.

Әмма минем эшкә дәрт кузгалган иде инде. Ниһаять, Гайнан бабай җитәкчелегендәге «Чияле» ансамбле беренче репетициясен уздырды. Тиздән районда смотр-концертлар башланып китәчәк, һичшиксез, алар анда катнашачак иде! Эх, күлмәкләр дә тектерсәң иде ул! Шул үтенеч белән кергәч, Венера Шәмсиевна беренче тапкыр миңа тавышын күтәрде:

– Вот тебе на, яшьләр! Эшләп күрсәт иң элек!.. – Ул әле, бәлки, тагын да дәвам иткәндер – чыгып киттем. Хатын-кыз чәрелдәвен тыңлаудан да күңелсез, аннан да ямьсез нәрсә юк дөньяда. Аралар суынганнан-суына әле никтер, әмма ни өчен икәнен генә аңышмый идем.

– Гамил Вазыйхович белән сөйләшеп карармын, – дип вәгъдә бирде Газинур абый. Анысы – район башлыгының социаль мәсьәләләр буенча урынбасары. Әмма мин Газинур абыйның беркемгә дә юк дип әйтмәвен беләм, димәк, хәл ителгән очракта да бик озакка сузылырга мөмкин. – Инвесторларга әйтеп тә торма, арыслан авызыннан ит алу белән бер ул!

Чыгу юлы күренми иде әле, ничек тә бу мәсьәләне алдагы ике ай эчендә хәл итәргә кирәк.

Искәндәрне күргән саен, горурлыгым арта – ул инде хәзер чын егеткә әйләнеп бара. Элеккечә өстәл янында чемченеп утырулар бетте, алдына куйганны ялт иттерә. Елаклыгыннан җилләр исте, ниһаять, әнисе итәгеннән туеп, миңа тартыла башлады. Алдыйм икән: аның көне Гайнан бабасы белән үтә, ул аннан бер адым да калмый.

Ә беркөнне кичен Миләүшә колагыма пышылдады:

– Күңелемдә көй туды, нишлим икән? – диде.

Соң иде инде, бөтенесе дә йоклый иде, мин сикереп тордым да аны күтәреп әйләндердем:

– Нишлисең, юләр?! Ишетсәләр!

– Иртәгә үк кәгазьгә төшер! – дидем мин.

Икенче көнне ул минем белән клубка барды һәм иске пианинода яңа көен иҗат итте. Аның очкынланган күзендә шатлык балкый иде.

– Сүзләрен дә языйк. Бу җыр – сиңа бүләгем, – диде Миләүшә.

Әлегә сүзләре булмаса да, бу җырны мин көйләп йөри башладым инде. Кайчагында хыялга бирелеп китәм дә шушы җырны зур сәхнәдән башкаруымны күргән-ишеткәндәй булам. Әмма әлегә... Чияле авылындагы клуб урындыкларын төзәтәм, кыйшайган сәхнә такталарын кагам. Аннан да бигрәк көз бәйрәменә чара уздырырга, райондагысына катнашырга һәм «Чияле» ансамбле белән конкурска әзерләнәм.

Көзге эшләр тәмамланды. Авыл тынып калды. Тәрәзәгә шап-шоп бәргән яңгыр да агачлардан соңгы яфракларны койган усал җил – әле дә шулар бар бу кадәр күңелсезлектән коткарырга.

Әнә шундый көннәрнең берсендә районның иң алдынгы авыл хуҗалыгы

хезмәтчәннәрен Мәдәният йортына җыйдылар. Әти, ашлык суктыруда «Карамалы»да иң алдынгысы булып, районда да бишенче урында иде. Әхәт Вәдүтович сәхнәдән аларга акчалата бүләк, грамота тапшырасын белгәч, бик озак тартышты ул:

− Сәхнәдә йөрүчеләр җитәрлек безнең гаиләдә. Миңа бүләкне басуда бирсәләр дә җиткән!

Әни ялынып-ялварып үтенде, бабай, гадәтенчә, аны сүкте, Миләүшә дә җайлап әйткәч, кая барсын – күнде. Аннан инде аңа кием сайлау башланды, әти кәчтүм-чалбарны кан дошманы күрә, баштарак аларны киюгә баш-аягы белән каршы булды. Аның инде агара башлаган бердәнбер кара кәчтүм-чалбары бар. Әни шуны табып чыгарды, Миләүшә яхшылап үтүкләде, мин, районга барып, ап-ак күлмәк алып кайттым. Бөтен яклап кысуларга түзә алмыйча, әти, кул селтәп, урамга да чыгып качкалады. Әмма иртәгә районга барасы дигән кичне аны барыбер сындырдылар.

− Кияү егете булдың да куйдың! Алып калмасыннар анда, районда ялгыз хатыннар күп, ди. − Әни аның борынына чиертеп алды.

Хәтта әтине мактауга саран Гайнан бабай да түзмәде:

− Анаң – авылның беренче чибәре, атаң да коеп куйгандай матур, нишләп син генә шундый булдың, кайда хата китте, дип йөри идем, болай ничава күренәсең тагын, − диде.

Сәхнә арты гөж килә. Район Мәдәният йорты директоры Рәшит абый – сценарийлар остасы. Ишеккә беркетелгән кәгазьгә бүген башкарылачак номерлар язып эленгән. Ашлык ташучы шофёрларны, ындыр табагы хезмәткәрләрен, терлекчеләрне, агрономнарны, комбайнчыларны – һәммәсен-һәммәсен район җитәкчеләренең төрлесе аерым-аерым зурлый, котлаулар исә концерт номерлары белән үрелеп бара. Иң ахырдан район башлыгы һәр номинация җиңүчеләренә бүләк, ягъни Гран-при тапшыра. Чара, әлбәттә инде, Венера Шәмсиевнаның улы Радик чыгышы белән тәмамланачак.

− Новый хит яздык! Слыхал?

− Юк шул...

− Вот бүген тыңларсың.

Радик һаман да үзе инде, һәр кызга күз кыса, затлы ап-ак кәчтүмнән, күкрәген кылыч белән ярып җибәргәннәрмени − кып-кызыл күлмәктән. Эшлекле кыяфәт чыгарып, эре генә атлап йөри. Каушауданмы, әледән-әле тәмәке тартып керә.

− Быел минем турне по районам, − диде ул, хәл-әхвәл белешкәч. – Аннан столицада аккорд поставлю!

− Котлыйм! − дидем ихластан. – Безнең группадан да бер йолдыз чыгарга тиеш ич инде!

Бу сүзләрдән ул бөтенләй үсенеп китте. Болай да җилкәсен уңга-сулга хәтәр генә авыштырып тиз хәрәкәтләнгән Радик, барысын да сөзеп дигәндәй, тагын тәмәке тартырга чыгып китте. Минем чыгыш ясау вакыты якынлаша иде. Бу юлы күңелле, дәртле җыр башкарасым килгән иде. Әмма Рәшит абый үзенчә хәл иткән булып чыкты:

− «Хуш, авылым»ны җырлыйсың, − диде ул.

− Рәшит абый, ул җыр бу чарага бөтенләй туры килми бит!..

− Быел Гамил Вазыйхович яңа номинация уйлап тапты – районнан читтә яшәп, ягъни җәйге чорда авыл хуҗалыгы эшләрендә Казаннан яки башка шәһәрләрдән кайтып ярдәм итешкәннәр дә хөрмәтләнәчәк.

Әле ничә генә ай эшләп-яшәп, мин шуны аңладым: райондагы барлык мәдәни чараларны башлап йөрүче кеше – район башлыгының социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Гамил Вазыйхович иде. Хәтерлим: элегрәк ул үзе дә бик матур җырлады, хәзер инде пенсия яшендә бугай. Берничә тапкыр мактап, җилкәдән какканы да булды аның.

− Гамил Вазыйхович эшли, Венера Шәмсиевна бүләк ала, медаль тага. − Баянчы Фәрит абыйның яраткан сүзе бу.

Менә шулай Рәшит абый мине сындырды. Димәк, мин шул моңсу җырым белән авылдан китеп, читтә яшәгән, әмма күңелләре белән монда булган, хуҗалыкларга ярдәм итәргә алынган кешеләргә ихтирам күрсәтәм икән. Казаннан һәм башка шәһәрләрдән кайтып, җәйге чорда көтү көткән малай-егетләр дә, ындыр табагында тырышып эшләгәннәре дә, комбайн ярдәмчеләренең иң уңганнары да бүләкләнәчәк икән.

− Аннары... – Рәшит абый, икәү генә калгач, әйтергәме-әйтмәскәме дип уйланып торды-торды да түзмәде: – Глава шул җырыңа үлә дә китә инде. Аның да үтенече бу.

Имәндә икән чикләвек! Мин моңа сөенергә дә, көенергә дә белмәдем.

− Радикны быел кертмәскә дип күпме тырышты Гамил Вазыйхович, әмма Венера Шәмсиевна барыбер үзенекен итте!

Әлеге номинациядә бүләк алучыларның бөтенесе дә диярлек өлкән классларда укучы Казан балалары икән. Аларга бүләкне районның якташлык җәмгыяте президенты – Казандагы кайсыдыр төзелеш оешмасының җитәкчесе тапшырды.

Йа Аллам, мәрхәмәтеңнән ташлама! Фәрит абый белән без сәхнәгә чыктык.

Җырлаганда, мин беркайчан да тамашачыларны күрмим. Сәхнәгә аяк басканчы мең терелеп, мең үлсәм, ни хикмәт, шулчакта мин тынычланып калам. Бу юлы да шулай булды. Җырның сүзләрен белмим, көен тоймыйм сыман, әмма үз-үземә хуҗа түгел идем инде.

Бик көчле кул чабулардан әйтерсең лә каяндыр читтән фани дөньяга кайтып төштем. Башымны идем дә сәхнә артына кереп киттем. Кул чабулар тынмый иде. Алай гына да түгел, көчәйгәннән-көчәя барды. Чараны Рәшит абый белән аның хезмәткәре Сәкинә апа алып бара иде, алар бер мәлгә югалып калды кебек. Шулчак мин Рәшит абыйның сүзләрен ишетеп, имәнеп киттем:

− Әдрән! Тагын бер кат сәхнәгә чык әле, тамашачылар сорый!

− Бар, бар! − Фәрит абый мине этеп дигәндәй чыгарып җибәрде.

Үз гомеремдә беренче тапкыр шундый хәлгә тарыдым, ни чарадан бичара, сәхнәнең урта бер җирендә туктап калып, башымны идем.

− Әдрән Гыйльфанов! – диде тагын бер кат Рәшит абый, үзенең көр тавышына ниндидер ясалма купшылык өстәп.

− Тагын җырласын!

− Сорыйбыз!

− Халык җырын!

Залдагы тавышларны мин аермачык ишеттем. Бу хәлдән Рәшит абый да югалып калды. Тотлыккан кешедәй, иреннәрен кыймылдаткан да төсле үзе, әмма сүзе чыкмый иде. Шулчак әлеге вазгыятьтә югалып калмаган бердәнбер кеше табылды. Коткаручым Фәрит абый иде. Сәхнәгә ул баянын тартып чыкты. Мин аңа кушылып җырлап җибәргәнемне сизми дә калдым:

Олы юлның тузанын
Үзем күрдем тузганын...

Әлеге җырдан соң да мине сәхнәгә тагын бер тапкыр чакырдылар, әмма бу юлы инде җырламадым, кат-кат башымны иеп, тизрәк кереп китәргә ашыктым. Баш әйләнә, аяк астын тоймыйм – ниндидер хәлсезлек биләп алды.

− Район тарихында мондый уңышка ирешкән җырчының булганы юк! Ихластан котлыйм, Әдрән! − Фәрит абый, гадәтенчә, үз шатлыгыдай куанды. Ул шундый инде. – Сиңа уйнавым белән горурланам, − дип тә өстәде.

Тагын кемнәрдер кулны кысты, кайсыларыдыр кочаклады. Алдагы номерны игълан итеп кергәч, Рәшит абый белән Сәкинә апа да бала-чагадай кулларын чәбәкләде:

− Быел Казанны яулыйбыз, болай булгач! – диде Рәшит абый. – Глава белән якташлык җәмгыяте президенты җанымны ашый иде, Казанга алып барырлык җырчыгыз юк, дип. Хәзер ничек сөйләшәсен беләм мин алар белән!

Әтигә кем бүләк тапшырганын мин күрми калдым, һава суларга чыгып киттем. Чара тәмамланганчы, урамда әтине көтеп, бергә кайтып китү иде исәбем. Бераздан телефоным аваз бирде. Сәкинә апа икән:

− Син кайда? Хәзер үк кереп җит! – диде ул.

Күңелгә шом керде, тизрәк клубның арткы ишегеннән эчкә уздым.

− Сиңа тагын сәхнәгә чыгасы бар икән бит! – диде Рәшит абый.

− Рәшит абый, зинһар, чыгарма инде. Көчкә йөрим, хәлем китте, − дидем мин, хатын-кызлардай зарланып.

− Сиңа җырларга кирәк тә түгел. − Рәшит абый серле елмайды. – Шушында гына тор!

Ул яңадан сәхнәгә күтәрелде. Яңгыравык тавышы белән Әхәт Вәдүтовичка сүз бирде.

«Яратам мин Әхәт Вәдүтовични! Ул – чын мәгънәсендә сәхнә кешесе, − дип еш кабатлый Рәшит абый. – Сценарийдан чыкмый, кыска сөйли...»

Бу юлы да район башлыгы сүзен кыска тотты. Аннан бүләкләүләргә күчте. Сәхнә артындагылар исә тынычланып калган, барысы да инде үз номерларын башкарды. Бары мин генә нәрсә буласын көтеп шомланам да, Радик кына, кулларын угалап, әрле-бирле йөри.

− Тагын фонограммага җырлый инде, яптырный малай! – Фәрит абый аны сөйми иде. – Миңа тагын уйнаган кыяфәт чыгарып, баян тотып торасы. Аннан да авыр әйбер юк дөньяда!

Кемдер миңа төртте. Аңламый да калдым – мин сәхнәгә чыгарга тиеш икән. Утлар яктылыгыннан күз камашты, сәхнәгә менеп килгән әти белән карашыбыз очрашты.

− Быел без яңа номинация булдырдык. Ул «Дәвам» дип атала. Бусы туган җиргә тугрылыклы гаиләләргә тапшырыла. Беренче бүләккә Чияле авылыннан Гыйльфановлар лаек дип табылды. Газиз абый – ничәмә-ничә еллар район күләмендә, алай гына да түгел, республикабызда зур уңышларга ирешкән комбайнчы. Улы Әдрән турында сөйләп тормасам да була, бүген үз күзегез белән күрдегез. Ләкин аның да һәр җәйне комбайнда эшләп, әтисенең уң кулы булуын әйтми кала алмыйм. Бүгенге көндә ул – Чияле клубы директоры, үз эшенең остасы...

Әхәт Вәдүтович әтигә пыяла кысага беркетелгән диплом белән конверт тоттырды.

Район үзәгеннән Чиялегә утыз чакрым. Без юл буе бер авыз сүз сөйләшмәдек. Әти үз ягындагы тәрәзәдән күзен алмады.

Әни белән Миләүшә, үзләре әйткәнчә, кешелеккә дигән күлмәкләрен киеп, бәйрәм табыны белән каршы алды. Без моны ук көтмәгән идек.

− Молодцы! – диде әни. Әтине кочаклагандай итте, мине үбеп үк алды. − Район радиосыннан турыдан-туры бирделәр. Барысын да ишеттек!

− Бабай кая соң?

− Лапаста, − диде әни. – Син җырлаганда елый башлаган иде, шуннан бирле тыела алмый әле...

− Искәндәр үзен артыннан калмыйча юатып йөри. − Миләүшә әллә бизәнгәнме шунда, әллә сагынганмынмы – аеруча чибәр күренә бүген.

Мин лапаска чыктым.

− Әт-ти! Бабай и-ии итә! – Искәндәр, кулымнан тотып, печәнлеккә менә торган баскыч янына алып килде.

− Рәхмәт, улым, − диде бабай, үзенең сөякчел кулын сузып. – Рәхмәт! Бу көннәрне әбиең генә күрә алмады...

Үземнең дә күз яше тибеп чыкты.

− Әт-ти, и-ии итмә! – Искәндәр дә тулышкан иде бугай.

Әллә ни сөйләшми генә бергәләп чәй эчтек.

− Зур акчалар салган глава! – диде әни. – Миләүшәгә бирдем, нәрсәгә тотсагыз да өстәрсез!

− Рәхмәт инде, әни! – диде Миләүшә. – Алай дөрес түгел инде...

− Дөрес, дөрес! – диде әни. – Без башкача ярдәм итә алмыйбыз. Бай баласы булса, Әдрәнне күтәреп кенә йөртерләр иде, әле дә кеше арасында йөри, балакаем... − Әни дә сытылды.

Әллә нәрсә булды әле бу. Октябрьнең елак көне кебек – һәммәбез дә балавыз сыгарга тора.

Башкалар йоклап беткәч, без Миләүшә белән лапаска чыктык.

− Анда илле мең сум акча! – диде Миләүшә. Шатланып әйттеме ул моны, шикләнеп әйттеме – белмәссең.

− Казанда бер квадрат метрга җитә түгелме соң? – дип шаярттым мин.

− Әдрән!

− Әү?

− Мин тыңладым... Тавышың ачылганнан-ачыла. Дөресен әйтәм, бу дәрәҗәгә җиткереп җырлаганың юк иде синең беркайчан да!

Мин дәшмәдем.

− Әле чынаяк юганда, әти белән әнинең пышылдашып сөйләшкәнен ишеттем. «Әдрән җырлаганда, каз тәннәре чыкты», − ди әти. Аның янында кушылып җырлаучылар да, елап утыручылар да булган. «Бу малайдан рәт чыга, ахры, әти дөрес әйтә бугай», − ди әнигә.

− Әни нәрсә ди?

− Ул елый да елый...

Яңа атна башыннан мин янә район үзәге белән авыл арасын таптый башладым – шимбә көнне тагын бер сынау көтә: Әхәт Вәдүтовичның илле яшьлегенә бик зур кунаклар килә. Шул мәҗлестә җырлыйсым бар. Аны исә Карамалы урманындагы аланлыкта уздырасылар икән. Анда «Аучы утары» дигән бик затлы ресторан бар...

Рәшит абый узган чарадан соң канатланып йөри – Әхәт Вәдүтовичтан да, Гамил Вазыйховичтан да мактау сүзләре ишеткән.

− Ну Венера Шәмсиевнадан гына эләкте түлке!

− Ник, Рәшит абый, яхшы уздырдык бит?

− Син күрмәдеңмени? Малае сәхнәдә күренүгә, халыкның бер өлеше ташлап чыга башлады бит. Анысы да монысы әле, глава үз туган көнендә аны

җырлатмаска кушкан Гамил Вазыйховичка. Хәзер апаебыз кан басымы белән өендә авырып ята...

«Аучы утары»нда булганым юк иде, шәһәрнең затлы рестор采ннарына биргесез икән ул: ишегалдында ясалма күле дә, төрле төсләргә кереп бии торган фонтаны да бар. Алансыман җирдә төрле ясалма җәнлекләрнең сыннары һәркайсы үз куышы янында басып тора. Октябрьнең соңгы яңгырларыдыр инде бу. Ара-тирә суык җил исеп куя, димәк, бик тиздән салкыннар башланачак.

Кунаклар күп, ирләр барысы да күлмәк-галстуктан, хатын-кызлар соңгы модалы күлмәкләрдән. Мине – авыл малаен – Миләүшә кием-салым аерырга өйрәткән иде инде.

Ике җыр башкарырмын дип уйлаган идек, тагын берне сорап җырлаттылар. Инде мәҗлес ахырына бара, минем эш бетте. Авылга күп булса биш чакрым ара бардыр, Рәшит абый, Фәрит абый, Сәкинә апа белән саубуллашып, урамга чыктым. Минем арттан ук мәҗлес кунакларының берсе – көмеш чәчен артка тараган, киң җилкәсенә ятышып кына торган түгәрәк корсаклы, ирләрчә җитди, матур кыяфәтле, илле яшьләрдәге абзый атлады:

− Танышыйк: мин Азат абыең булам, − дип, кулын сузды ул.

− Әдрән.

− Беләм. − Азат абый дигәнем кулын селтәде. – Шәп җырлыйсың, җанга үтеп керде.

− Рәхмәт.

− Син Чияленеке икән?

− Әйе.

− Мин дә Чияледә туганмын. Мин тугач, Казанга чыгып киткәнбез. Илле ел элек үк инде! Шәрифулла Хәсәновны ишеткәнең бармы?

Мин әйтерсең лә йөз йортлы авылыбызның һәр тәрәзәсеннән карап үттем – юк, исемә төшерә алмадым.

− Безнең йорт юк инде хәзер. Анда Гыйлаҗи исемле кеше тора. Аны беләсеңме?

− Әйе. Аны беләм.

− Әтине без Чияледә җирләдек, васыяте шундый иде. Соңгы минутларында авыл дип шашты картлач. Алтмышы тулуга ук китеп барды, бахыр. Ул чакта үземә дә утыз гына иде. Аякка басмаган идем әле. Хәзер булса, авылда йорт салып, шунда гына рәхәтләнеп яшәтер идем аны.

Агайның күзе дымланган иде. Кинәт ул үзен кулга алды, җитдиләнеп китте:

− Әхәт, главагызны әйтәм, минем дус. Бергә укыдык. Әйбәт малай. Сине мактады, клуб директоры икәнсең, тырышып эшли, ди.

Хәерлегә булсын, соңгы арада мактау сүзләрен күп ишетә башладым әле мин.

− Ярар, − диде Азат абый. – Мин, энекәш, бераз аякка баса алдым. Төзелеш фирмам бар, кибетләрем, башкасы дигәндәй. Авылга бераз ярдәм итәсем килә, нәсел шушы авылдан бит, кендек каны тамган, диләрме әле?

Мин баш кактым.

− Мәктәп юк икән инде авылда. Да-а... Мәктәп булмагач, бетәр инде ул...

− Бетермәскә иде бит, − дип бүлдердем мин аны. Кинәт күңелдә хис өермәсе купты. Бирәм дигән колына – чыгарып куяр юлына, дигән кебек булды бит әле бу?! Инде кайчаннан бирле җанны борчып, кытыклап йөргән уйларымны әйтеп салыргамы соң әллә?

− Азат абый, әгәр ихластан булышырга теләгең бар икән, эх, бик күп мәсьәләләр бар шул. Зурдан башлыйммы, кечкенәләрдәнме?

– Иң кечкенәдән башла, – дип көлде ул.

Мәҗлес шау-шуы башка каба, без акрын гына читкәрәк атладык.

– Иң кечкенәсе шул: бер айдан район конкурсында катнашу өчен, биш әбиемә һәм бер бабама сәхнә күлмәкләре кирәк...

Ул кәчтүменең эчке кесәсенә кереп китте.

Йа Аллам, әллә акчаны чыгарып та бирә инде?

– Мә, бу – минем визитка. Анда кесә телефоны номеры да, адрес та язылган. Иртәгә офиска килерсең, күпме кирәк – шуның кадәр акча алып китәрсең.

Без кул бирештек.

– Йә, зур мәсьәләңне әйт инде, анысына көчем җитәрлекме икән?

Мин икеләнеп калдым. Беткән баш беткән!

– Азат абый, үзегез дә беләсез: авыл бетүгә бара. Әнә кәчтүмнәр өчен акчаны да әбиләр өчен сорадым. Яшьләр китә, яңа йортлар салынмый. Инвесторның үз хәле хәл, инде банкротка да чыкмакчы бугай. – Мин Азат абыйга күз салам, игътибар белән тыңлый үзе. – Безнең авыл үзебезгә генә кирәк, болай дәвам итсә, берничә елдан Чияле калмаячак, берничә йортны Карамалыга күчерәчәкләр дә – вәссәлам. Авыл яшәсен өчен, эш кирәк. Бездә ул юк. Мәктәп бетте, инде менә клубны, балалар бакчасын ябу турында сүз бара, чөнки алар иске биналарда урнашкан, чыгым күп тотыла. Яшьләр булмагач, аларның да кирәге юк. Димәк, киләсе елга Чияледә тагын унга якын кеше эшсез калачак дигән сүз...

– Мин нишли алам? – Сүзем ураурак булды, ахры, Азат абый мине бүлдереп сорады.

– Хәзер республикада яңа программалар бар. Безгә әнә шуларның бөтенесен бер түбә астына җыйган яңа бина кирәк. Йөз урынлык клуб, шунда ук балалар бакчасы да, китапханә дә булсын. Медпунктка бер бүлмә бирергә кирәк, атнасына өч-дүрт тапкыр районнанмы, Карамалыданмы бер фельдшер килеп, халыкны кабул итсә, начар булмас иде. Авылда ялгыз әби-бабайлар шактый. Кем йөртә аларны? Музей да ясап куярбыз. Менә шундый күп функцияле үзәк төзибез икән, димәк, директорга, китапханәчегә, фельдшерга, идән юучыга, җылытучы-ягучыга эш була, димәк, берничә гаиләгә акча килеп тора, алар читкә китүне уйламый дигән сүз. Балалар бакчасындагы тәрбиячеләр, аш пешерүчеләрнең дә эш урыны саклана.

– Аңладым, егет! Бу мәсьәлә буенча Әхәт белән сөйләшермен.

– Аннары...

Ул миңа елмаеп карады:

– Мин уйлаганча, гади генә малай булып чыкмадың әле син...

Мин тыелып калдым. Чыннан да, аңа бу проблемалар нәрсәгә инде?

– Юк, юк, барысын да сөйләп бетер.

– Авылда тагын берничә эш урыны булдырасы иде бит! Эш булса, шәхсән үзем берничә егетне авылга кайтарыр идем! Кайтасы килгәннәр дә бар! Менә җәй көне классташым Сәет район үзәгенә күчеп киткән иде. Инвестор акчаны аз түли, башка эш юк, төп йортта энекәше кала. Мин инде үзебезнең силсәвит Газинур абый белән сөйләшкән идем, әгәр Сәетне авылга кайтарсам, яшь гаиләләр өчен каралган программа буенча йорт салырга булышачак аңа. Менә шул егетләргә эш урыны булдырып булмасмы? Әйтик, кирпеч җитештерә, агач эшкәртә торган берәр предприятие ачып җибәрсәгез? Карамалы урманы кул сузымында гына бит. Төзелеш фирмагыз, кибетләрегез өчен нәрсә дә булса эшләрләр иде. Бездә кайсы ир-атны алсаң да – оста куллы. Казан галимнәре дә, агач эшләренә оста икән авылыгыз, дип китте...

Азат абый кычкырып көлде:

− Әй энекәш, энекәш! – Ул кулын иңемә куйды. – Нәрсә диим? Төзелеш фирмам бик зур минем, әмма чималны чит илдән кайтартам. Чияледән алып килүгә караганда, Кытайдан кайтарту бермә-бер арзангарак төшә!

Ул шундук җитдиләнеп калды:

− Әйдә соң, берәр нәрсә уйлап карыйк. Үземә зыянга булса да...

Ул тагын кычкырып көлде:

− Мин синнән «чишмә ясарга кирәк, клуб түбәсенә калай булмасмы» ише сүзләр генә ишетермен дигән идем...

− Эх, минем сүзләрем шулкадәр күп шул әле!

− Аның барысын да үтәп булмас инде, дускай. Минем сихерле таягым юк шул...

− Авылда унбиш еллап Сабан туе булганы юк, әгәр киләсе елда оештырсак, бераз ярдәм итәрсезме?

− Монысы – ерунда, хәл ителгән, дип сана.

− Тагын...

Азат абый башын тотты.

− Мулла бабай картайды, алыштырырга кеше юк. Бер яшь мулла кайтартасы иде дә! Авылга ямь керер, яшь гаилә артыр иде. Шуңа берәр йорт салып чакырасы иде бит! Бүрәнәләре черегән мәчетне ничек тә бергәләшеп торгызыр, зиратның аварга торган коймаларын бергәләп корыр идек әле аннары!..

Шулчак яныбызда Әхәт Вәдүтович үзе пәйда булды. Берничә кунагы китәргә җыена икән, шуларны озата чыккан.

− Авылдашлар очраштымы? – дип, икебезнең дә җилкәбезгә кулын куйды ул. – Егет менә дигән, Азат дус. Поддержать итәргә тырыш.

Шулай диде дә глава китеп барды. Аңа Азат абый да иярде.

− Очрашканчыга кадәр! – дип, кул бирде ул.

Бермәл кузгала алмый тордым, октябрьнең әче җиле йөземә китереп сылагач кына айнып киттем. Үземдә җиңеллек тоеп, авылга юл тоттым.

* * *

Азат абый сүзендә торды – икенче көнне үк аннан акча алып, әллә кайчан белешеп-сөйләшеп куйган тегүчегә киттем. Иртәгә конкурс дигән көнне ул аларны өлгертте дә. Казаннан туп-туры клубка, репетициягә кайтып кердем.

Әбиләрем шулкадәрле зиннәтле күлмәкләрне күреп аһ итте.

− Әнекәчкәем лә генә! − Маһруй әби шундук көзге каршына китте.

− Үләм, затлылыгы! Үлчәп теккәннәрмени! – Сания әби дә аның артыннан иярде.

Гөлчирәттәй, Мәрьямбану, Зөлфия әбиләр дә үзләренә күлмәк сайлап алды: Миләүшә ниндирәк зурлыктагы күлмәкләр кирәклеген миңа сызып биргән иде, шуңа һәммәсенә дә таман иде алар.

Гайнан бабай исә бүген тотып өйләндерерлек иде: яшел камзул, күн читек, затлы кәләпүш, ап-ак күлмәк, кара чалбар!

− Безгә беренче урынны җырлап тормасак та бирерлек икән!

Бабайның юраганы юш килде: «Чияле» ансамбле тезелешеп сәхнәгә чыгуга, залдан ниндидер дулкын узды.

Янымда утырган Газинур абый, касыгыма терсәге белән төртте дә, үзе дә сизмәстән, бөтенесенә дә ишетелерлек итеп кычкырып ук җибәрде:

− Анаңны! Каян таптың боларны? Ну да-а!..

Гайнан бабай яшьләргә биргесез, башын горур чөеп, әбиләре арасыннан гармунын тартып узды:

Йөгереп кердем өйләргә,
Бүрегем элдем чөйләргә.
Яшь чагында уйна да көл,
Калсын сагынып сөйләргә.

Яшь кызларның борынына чиертерлек әбиләр җырны күтәреп алды:

Аллия-гөллия,
Гөллия тирәккәем;
Яшә гөлләр арасында, –
Шул сиңа теләккәем.

Иң көчле алкышлар – аларга, иң зур баллар да аларга иде. Котлаучылар күп булды, шулай да иң истә калырлыгы Гамил Вазыйховичның сәхнәдән әйткән сүзләре иде:

– Эшне өстән кушканга эшләүчеләр бар, күңел кушканга эшләүчеләр бар. Бүген без сәхнәдән шуның нәтиҗәсен күрдек. Әдрән, һәрвакытта да шулай күңел кушканча эшләсәң иде, син райондагы культура торышын әллә ничә баскычка югары күтәрдең, – диде ул.

Инде минем белән исәнләшми дә башлаган Венера Шәмсиевна икенче көнне күктән җиргә төшерде:

– Гыйльфанов! Хватит! Әхәт Вәдүтовичның артын ялап, урын сорап йөрүдән тукта! Синең әбиләреңне барыбер республикага чыгармыйм! Костюмнарың буенча прокурорга әйтәм, нәрсә творится анда синең? Онытма: киләсе елның июненнән клубың ябыла, эш эзли башла. Районда сиңа урын юк...

Мин авызымны ачып сүз дә әйтә алмадым, әмма бу сөйләшү күңелгә юшкын булып утырды. Әнә шундый өермәле хисләр белән Яңа елны каршы алдым.

Клуб ябылачак дигән хәбәр авыл буйлап таралган, соңгы тапкыр дип килүләреме – Яңа ел кичендә клубка кеше сыймады. Яшьләр басып карады, әти-әниләре алдына сыймаган бала-чага идәнгә чүмәште.

Сценарийны Миләүшә белән бергәләп төзедек. Үзенә күрә концерт-спектакль булды ул. Анда тамаша карарга килүчеләр дә катнашып китә: алар үзләренең хыял-теләкләрен, кар бөртеге итеп ясалган кәгазьгә язып, Кыш бабайның урланган капчыгына сала. Ахырдан Кыш бабай таягы белән кагылып алгач, янәсе, ул теләкләрнең һәммәсе дә чынга аша.

«Чияле» ансамбленең инде даны район буйлап таралды. Гайнан бабай үзе генә дә район гәҗитенә, радиосына, телевидениесенә дә кат-кат интервьюлар бирде. Сиксән алты яшь белән барганын онытып, кабат яшьлегенә кайтып йөрүе. Яңа ел кичендә дә алар сәхнә бизәге булды, авылдашлары аягүрә басып кул чапты үзләренә.

Иң соңгы җырны исә – Миләүшә көенә язылганын – мин башкардым. Сүзләрен Рәшит абый язды.

– Шулкадәр рухны күтәрә торган, күтәренке көй бу. Әйдә, «Бәхеткә юл» дип атыйк, – диде ул.

Кичә тәмамланды, әмма халык урыныннан кузгалмады.

– Рәхмәт!

– Мондый чараны күргән булмады!

− Клубны яптырмаска кирәк!
− Яптырмыйбыз!
− Хат язабыз!
− Бөтен авыл белән кул куябыз!

Әле дә ярый пәрдәне япкан идек, юкса күз яшьләремне тыя алырлык хәлдә түгел идем.

− Әдрән, син клубны яптырмаска тиеш! − Миләүшә кулымнан кысты.

Мине иң гаҗәпләндергәне шул булды: Кыш бабай капчыгындагы теләкләрнең күбесе бертөрле – «Клубыбыз киләсе елда да эшләсен», диелгән иде анда...

* * *

Яңа елның беренче көннәре үк минем өчен гаугалы башланып китте: Венера Шәмсиевна көн дә шалтыратып акыра да бакыра. Ул арада авылдашлар, чыннан да, хат язып, кул куеп, Әхәт Вәдүтовичка илтеп җиткерделәр. Газинур абый да миңа сагаеп карый башлады:

− Әдрән, нигә кирәк иде бу сиңа? Син – үсәсе егет бит. Глава яратмаячак моны. Карамалыга директор булып киләсең, бу мәсьәлә хәл ителгән бит инде безнең, ну да. Хәзер Шәмсиевна ашаячак сине! – диде ул.

Минем иңсәләр кабат салынып төште. Өстәвенә әни дә көн саен, еламсырап, бер сүзне кабатлый:

− Улым, Әдрән, сине глава ярата, диләр. Зинһар, яптырма инде бакчабызны. Никадәр кеше эшсез кала бит! Тырышып кара инде, улым, авыл халкы үтенеп сорады бит! – ди.

Мин, Миләүшәне елатып дигәндәй, Казанда чиратта торган Искәндәрне Чияле бакчасына күчерттем. Сәет дус та, ике баласын алып, авылга кайтып төште. Бу аның бик зур батырлыгы иде.

Түзә алмады алар район үзәгендә. Бер бүлмәле фатирда түләп торып карадылар, сулышым кысылды, көн дә авыл ягына карап елыйм, диде Сәет. Район үзәгенә барып кайтуның файдасы шулай да булды: инде кайчаннан бирле ул миңа яшь гаиләләргә йорт салуда булыша торган программа турында сөйли. Бар кыюлыгымны җыеп, Гамил Вазыйховичка җиткергән идем бу үтенечне – дәшми әле. Азат абыйдан да хәбәр юк.

− Әхәт белән син әйткәннең икенче көнендә үк сөйләштем, вәгъдә бирде. Мин дә үз ягымнан эш алып барам: Казан түрәләрен кымтырыклыйм, яңа бинаның проектын эшләттем, − дип, күңелгә өмет салган иде дә, яктылык күренми әлегә. Кысыр өмет булып калыр, ахры.

Җитмәсә, Венера Шәмсиевна белән мөнәсәбәтләргә соңгы нокта куйган күңелсез вакыйга булды. Беркөнне ул шалтыратты да исәнмесез-саумысызсыз гына:

− Радикның республика буенча концертлары бара. Киләсе атнага Чиялегә килә. Зал тулы булсын! Сиңа соңгы сынау бу! Если провалишь... – дип янады,

Афишаны, билетларны районнан үзем барып алдым.

− Заразы малай, тәмам туйдырды! − Фәрит абый нишләп йөрүемне белгәч сүгенде. – Республика буенча, имеш! Ике-өч кеше килгән башка район авылларында. Хәзер Шәмсиевна районның бөтен авылына шуны такты, тьфү!

Афишаны тотып, Чияленең һәр йортын йөреп чыктым.

− Ә-ә, бу теге телевизордан гел күренә торган малаймы? Җырлый белми бит ул!

– Кит моннан! Моңа акчам җәл!

– Аның шыңшыганын ишеткәч, радионы сүндереп куям!

Билет сату бик кыен бара.

– Өстән кушканнардыр инде, һәй...

– Синең хакка гына, Әдрән улым...

– Син сораганга гына...

Алланың рәхмәте, йөз билетны тәки саттым бит!

Март киче. Җил басу ягыннан әллә нинди хуш исләрне куып китерә. Аяк астындагы кар юкара төшеп, аңа инде зәңгәрлек йөгергән. Күңелнең каядыр ашкынган чагы бу.

Концертка безнең гаиләдән барыбыз да килде. Радик, гадәтенчә, фонограммага җырлый, аппаратурага кеше яллап тормаганнар – үзем утырдым.

Юк инде! Компьютерга никадәр генә исләре китсә дә, ул да тавышны барыбер ясап бетерә алмый. Кул чабулар җырдан җырга сыекланып, дүртенче җырдан соң бөтенләй ишетелми башлады.

– Авызыңны гына селкетеп торасың!

– Баянга җырла!

– Коммерсант!

Мин баскан урынымда тораташ булып катып калдым. Тагын да яманрагын Радик эшләде:

– Пошли вы...

Залда шау-шу купты, концертны дәвам итеп булмый иде инде.

Телефон ничек түзгәндер – анысын белмим, әмма минем колак түзде. – Провокатор! Заговорщик!

Венера Шәмсиевнаның бу сүзләре калганнары арасында мактау сүзләре кебек аерылып тора иде. Миңа бердәнбер юл калды – эштән гариза язып китү.

Минем эштә гамь калмады. Тагын җиңелү. Тагын билгесезлек. Гомер буе шулай булырмы икән? Нигәдер миңа шатлык өелеп килә дә, аны бер-берсе артыннан тагылган борчу-кайгылар алмаштыра. Тигез генә, бер көйгә аккан тормышны күргәнем юк та бугай.

Өйдәгеләр хәлемне аңлый, ничек тә күземә чалынмаска тырыша. Гайнан бабай күңеленә якын алдымы, әллә әҗәле якынлаштымы – ул кинәт хәлсезләнеп калды, тәненә сары төс игылды, күзгә күренеп ябыкты. Үзе исә хәлемне гел сорашып тора:

– Улым, бирешмә, чигенмә! Главага кер, ул сине ярата!

Мин Әхәт Вәдүтовичка кермәдем, Гамил Вазыйхович янына киттем. Сөйләп бирергә дә туры килмәде, рәхмәт төшкере:

– Ишеттем, беләм. Бернигә дә карамыйча, эшеңне дәвам ит. Тиздән күңелле яңалыклар булуы бар, – диде ул, күңелгә әллә нинди буталчык уйлар кертеп.

Күңелле яңалык озак көттермәде: безнең күп функцияле үзәк республика планына кертелгән булып чыкты! Ул көнне безнең өйдә чын мәгънәсендә бәйрәм иде, телефон рәхмәт сүзләреннән тынмады, әни исә янымда күбәләктәй бөтерелеп йөрде:

– И-и улым, рәхмәт сиңа! Бөтен авыл рәхмәт укый бит, – диде ул, күз яшьләрен күлмәк итәге белән сөртеп. Хәтта әти булып әти дә җилкәгә сак кына кагылып узды...

– Эт икәнсең, малай, ну да! Нәрсә әйтим, маладис! Тәки Карамалыга китертеп булмас микәнни сине, ә? – диде Газинур абый. – Венера Шәмсиевнаны шартлатасың икән...

Азат абый белән хәзер телефоннан көн дә сөйләшеп торабыз. Бинаны аның төзелеш фирмасы төзиячәк иде.

– Каңгырап йөргән авыл егетләрен барлый башладыңмы? Мин үземнең яктан тырышам... Синең клубыңны төзеп бетергәч, зур пилорама ачам. Алтыҗиде егет эшле булыр...

Бу хәбәргә иң сөенгән кеше Сәет иде. Ләкин аның йорт мәсьәләсе генә һаман да хәл ителми иде әле. Гамил Вазыйховичтан кабат сорарга уңайсыз.

Әмма тормыш бер ал ягын күрсәтә башласа, өеп бирә бит ул!

– Син дә йортны Чияледә саласыңмы? – дип сорады беркөн Газинур абый, клуб төзелешен тикшерергә килгән җиреннән.

– Аңламадым, Газинур абый. Нинди йорт?

– Ну да! Глава сиңа йорт салып бирергә кушкан бит. Белмим, димә тагын!

– Ә-ә! Аңладым! Миңа түгел, Сәеткә ул, Газинур абый! Әллә барып чыктымы?

– Ул аерым исемлектә! Анысын кыстырма син! Үзеңне әйт! Дүрт йорт турында сүз бара монда, Азат Хәсәнов дигәннәре ике йорт салмакчы. Мәчет тә төзи икән тагын. Сезгә җир урыны әзерләргә кирәк буламы, буш торган нигезләргә саласызмы... Ну да!

Кинәт башым әйләнеп китте... Җавап бирергә көч таба алмадым.

– Уйларсың да әйтерсең. – Минем югалып калуны ул үзенчә юрады. – Йорт салу уен эш түгел! Ярдәм итәрбез, борчылма! Миңа да начар түгел бит, үзара салым акчасы арта, йортлар ишәйгәч, ну да!

Чияледә тынгысыз көннәр башланды. Җәй буе, авылның тынычлыгын алып, төзелеш эшләре гөрләде. Иң элек Сәетнең ике катлы йорты төзелеп бетте. Азат абый аннан пилорама хуҗасы ясамакчы, шуңа да кая басканын белмичә йөри. Шуннан соң мулла йортын күтәрделәр. Район мөхтәсибе ике кечкенә балалы яшь мулла табып бирде, менә-менә ул күченеп килергә тиеш. Миләүшә прорабка әйләнде – Азат абый егетләре безнең ике катлы йортны түбә астына кертте.. Искәндәр үзенә кояшлы якка карый торган бүлмәне сайлады. Хәзергә исә көн дә балалар бакчасы яныннан урап кайта:

– Мин яңа садикка балам! – дип, канатланып йөри.

Көз көне яңа бинаны зурлап ачтык. Авыл халкының аякта йөри алганы, таякка таянганы, әнисенә асылынганы – һәммәсе дә килде. Быел Сабан туен оештырырга кул җитмәгән иде, читтәге авылдашларны җыярга форсат туды. Хәтта Курилдан Марсель дә ял алып кайтты. Сәет белән икебезнең йортны күреп:

– Скоро – отставкага! Таяклар кагып китәм, күршегездә миңа да урын калдырыгыз! – диде.

Чияле шулай кайнады-кайнады да тагын сүнеп калды. Минем күңелне дә ниндидер рәхәт бушлык биләп алды. Әмма тормышка бик тиз кайтардылар. Яңа бинаны тәртипкә салу өчен, ай-һай, бик күп йөгерергә туры киләчәк әле.

Беркөнне Әхәт Вәдүтовичның кабул итү бүлмәсеннән шалтыратып, тиз генә килергә куштылар. Бүлмәсенә керсәм, Гамил Вазыйхович белән икәү утыралар.

– Ну, Әдрән, үзеңә дә тынгылык юк, безгә дә тыныч яшәргә бирмисең, – дип җылы каршыладылар мине.

– Кемдер гомере буе эшләгәнне майтарып ташладың әле син кыска гына вакыт эчендә. Күрмиләр дип уйлама, мактап үсендермәскә генә тырыштык, һәр гамәлең, һәр адымың билгеле безгә. – Әхәт Вәдүтович сүзләреннән тәнем эсселе-суыклы булып китте. Венера Шәмсиевна тагын шикаять язган бугай,

дип уйладым эчемнән генә. – Дөнья тәгәрмәчен әнә шундый булдыклы кешеләр әйләндерә. Тик андый егетләр көннән-көн азая бара, шунысы кызганыч. Менә без әле Гамил Вазыйхович белән сөйләшеп-киңәшеп утырдык. Ул алтмыш өченче яше белән бара икән, мин дә алтмыш ягына чыктым. Эшне дәвам итәрлек егетләр бармы безнең? Тегеләй исәпләдек, болай санадык, аннан карадык, моннан уйладык. Ахыр чиктә барыбер синең исемгә килеп төртелдек. Бүгенге заманда бетеп барган Чиялегә яңа сулыш өрүең шаккатырды безне. Нинди кысмыр Азат абыеңны авылга эшләтүең генә дә ни тора! Хәзер менә пилорама корып йөри! Пакусны киң алуың әйбәт, Әдрән. Әмма сине Чияледә генә калдыра алмыйбыз инде без. Энергияңне район масштабында файдалана башларга вакыт. (Тешем тешкә тиеп шакылдар дәрәҗәгә җиттем. Бар гәүдәмә калтырану таралды) – Менә без уйлаштык-киңәшләштек тә районның культура бүлеген сиңа тапшырырга булдык...

Ул туп-туры күземә текәлде. Бу туры карашны күтәрү авыр иде, шулай да түздем.

– Гамил Вазыйховичның планы зурдан: ике-өч ел тәҗрибә туплагач, үз урынымны Әдрәнгә тынычлап калдырып, пенсиягә китәр идем, ди. – Әхәт Вәдүтович көлеп җибәрде. – Ә мин исә аннан да ераккарак киттем: ул сине алыштыргач, өч-дүрт ел эшләр дә, мин инде аңа район дилбегәсен үк тапшырырмын, дидем.

Алар рәхәтләнеп шаркылдаша, миндә исә көлү кайгысы түгел.

– Киләчәккә юлны шулай алдан сызарга кирәк, Әдрән. Район үзәгенә күчеп килү синең иҗатыңа да зыянга булмас. Бездә иҗади кешеләр күп, бергәләшеп яңа җырлар язарсыз. Көн саен үзебезнең радио синең җырларны тапшыра, рәхәтләнеп тыңлыйбыз. Бер яңа җырыңа клип сценариесы әзер булган. Анысын Казанга җибәрәбез. «Бәхеткә юл»ны әйтүем. Шулай бит, Гамил Вазыйхович? Дөрес сөйлимме?

Мин, аптырап, җилкәмне сикерттем.

– Монысы сер иде, Әхәт Вәдүтович. Рәшит Ризакович сюрприз итеп әзерли иде. Әдрән моны белми...

– Ник аны кисәтмәдең? Ярар, беткән баш беткән. Барыбер бергә эшлисез. Аннары... Тәк, фатир мәсьәләсен Гамил Вазыйхович белән сөйләшеп бетерерсең. Без инде эшкә билгеләнүең турында боерык әзерләдек, шулай да өйдәгеләр, хатының белән кайтып киңәшкән бул. Аларның шуннан да күңеле була. – Әхәт Вәдүтович кәефле елмайды.

– Яңа клуб нишли? – Беләм, бу соравым бик ахмакларча яңгырады.

– Директорны үзең билгелисең инде хәзер! – Гамил Вазыйхович та сүзгә кушылды.

Чиялегә ничек кайтып кергәнне хәтерләмим. Яңа бина янында Газинур абыйны күреп кенә туктадым.

– Кая йөрисең син? Документлар белән киләм, дидең бит! Телефоныңны да алмыйсың. Эзләп чыктым үзеңне, ну да!

– Әй Газинур абый, документларны яңа директор белән хәл итәрсең инде...

– Ә-ә? – Ул, куркып, миңа карады. – Ничек инде? Җен карчыгы тәки эштән алдырган икән!

– Алай гына булса!.. Районга чакыралар. Эшкә...

Ул зәп-зәңгәр күзен миңа төбәде. Аннары барысын да аңлагандай, кулын селтәде:

– Мин аның шулай буласын белдем инде. Асылташ җирдә ятамыни ул? Һәй,

мин, карт җүләр, үз урыныма кеше табылды дип, сөенеп йөри идем тагын. Ну да-аа...

Мин кайтып кергәндә, барысы да өйдә иде. Хәбәрне ишетүгә, әни, лып итеп, артына утырды:

– Ничек инде? Ә без, Чияле нишли?

Әти дә район гәҗите укуыннан бүленде:

– Бу кадәр эш күрсәткән кешене алып китәчәкләре билгеле иде...

Шулай да яңалыкны иң авыр кабул итүче тәмам хастага калган Гайнан бабай булды:

– И-и, инде үлсәм дә була икән, барыбер авылның яме китәчәк синсез! Әйдә, соңгы тапкыр буладыр, җырлыйк инде «Әдрән диңгез»не бергәләп.

Әдрән диңгез, зәңгәр диңгез,
Ай, зәңгәр диңгез.
Култыклары йөз дә сигез,
Ай, йөз дә сигез.
Үзенең батыр улларына,
Улларына
Көрәш дәртен биргән диңгез,
Биргән ул диңгез...

Кочаклашып җырладык, аннан икәүләшеп еладык.

– Васыятьне онытма, – диде бабай. – Диңгезне барып күр, дулкыннарында тибрәлеп, рәхәтләнеп бер җырла!

Мин барыбер дә тормышның асылын аңламыйм бугай. Бу хәбәрдән Миләүшә үрле-кырлы сикерергә тиеш иде кебек.

– Китәсем килми, – диде ул.

– Мин вәгъдәмдә торам, күрәсең бит, Казанга якынаябыз... Тормышның төбеннән күтәреләм...

– Ярар, искә төшермәле! Син вәгъдәңне үтәдең инде. Йортыбыз булды, яңадан җырлый башладың, иң мөһиме: Искәндәр савыкты...

– Район үзәгендә фатир бирәләр...

– Китәсем килми, – дип кабатлады Миләүшә. – Ияләндем, ахры. Карамалы мәктәбендә музыка түгәрәге алып барырга да сүз бирдем... Бала туганчы...

Җир катырак әйләнә иде. Мин урамга чыгып йөгердем. Күпме йөгергәнмендер, белмим – кинәт шып туктап калдым. Аягыма авыр-авыр герләр такканнармыни – кыймылдата да алмыйм. Әйтерсең лә мине әкиятләрдәгечә, әфсенләп тораташка әйләндергәннәр.

Артыма борылып карадым – Чияле утлары күренмәде. Шулай да күктә балкыган һилал ай юлны ак итеп яктырта иде...

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



Фәйрүзә
Мөслимова

# ДӨНЬЯ ШУНДЫЙ ТИЗ ҮЗГӘРӘ

## Хәлифәбез юкса...

Бирмәгән безгә бөркет күзләрен,
Ас елгырлыгын бирмәгән безгә.
Үлән астыннан елан шуыша –
Игътибар җитми, күренми күзгә.

Без җир өстендә хәлифә юкса,
Аллаһ Тәгалә яраткан шулай.
Әмма мәңгегә гөнаһлы иткән
Атабыз адәм кызыккан богдай.

Аяк астыннан елан шуыша –
Аңышмый кала күңел күзебез.
Башка «богдай»га үрелдерәсен,
Тагын алдыйсын сизми йөрибез.

Җир өсте безгә Җәннәттән гүзәл,
Сөрелгән чаклар онтылган инде.
Капкасын Җәннәт ачармы кабат?
Һава анабыз җимеш бирерме?

Фани дөньяда күпме җимешне
Инде татыдык, тәмләмәдекме?
Теләп алдандык, гөнаһлар җыйдык –
Өйдек иңнәргә тау кадәр йөкне.

Исәнгә тәүбә, ярлыкану бар,
Язмасын яшәү гөнаһлар санап.
Ул безгә бары җиңеллек тели –
Калеб күзләрен ачтырсын Аллаһ.

---

Фәйрүзә МӨСЛИМОВА – *шагыйрә, прозаик; «Ярату яралары», «Апрель кары», «Алтын йозак» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. С.Сөләйманова, А.Алиш исемендәге әдәби премияләр лауреаты. Казанда яши.*

## Патша белми

Безнең хәлне патша белми... –
Мәңгелек ялгышыбыз.
Яшәү өчен җан талашып,
Ташка баш ормышыбыз.

Кырмыскадан, бал кортыннан
Тырышын тырыш халык,
Җилкәләре чиләнсә дә,
Йөри авызлык кабып.

Көне-төне эшләсә дә,
Ыштаны юк ат сыман,
Мәрхәмәт көтеп хуҗадан,
Араннан башын сузган.

Патша берни белми, дибез,
Ерак шул бездән патша.
Икмәк җитми, дип зарлансак,
Әйтер ул: «Пылау аша!»

Хәлебезне Алла белә,
Аермый сабырлыктан.
Ә елгырлар баулар ишә
Бездәй гафил халыктан.

Мескенлектән араларга
Кирәк патша указы.
Безнең хәлне белми шул ул...
Ни дип юаныйк тагы?

## Тел тидермәгез!

*Бар күңелләрдән җылы,*
*Йомшак синең каберең ташы...*
Г.Тукай

Уйга – ирек, сүзгә – ирек,
Фикерләргә юк киртә.
Энәсеннән җебенәчә
Кемнәр ул тарих сүтә?

Әнә, Тукай әнисе дә
Кергән инде телләргә:
– Ник баласын ташлаган ул,
Чыгып киткән кияүгә?

Без шулай эшләр идекме?
Без, янәсе, әүлия!
Беләбезме, ул чакларда
Ни кичергән Мәмдүдә?

Язмышына каршы бару
Килмәгәндер хәленнән.
Хөкем итмәгез ананы
Торып бүгенге көннән.

Ахыр чиктә, Аллаһының
Кем үзгәртер тәкъдирен?
Тукайны ятим итүнең
Бары Ул белгән серен.

Ятим калмаса анадан,
Яшәр идек Тукайсыз –
Әдәбият гөмбәзендә
Балкыган кояш, айсыз.

Милләткә бүләк булсынга,
Шулай кылган язмышын.
Тукайны сызып ташларга
Хокукыбыз бармы соң?

Чын күңелдән кызганам да,
Яклыйм да Мәмдүдәне.
Бөек Тукай энисенә
Тел тидермәгез, яме!

## Сагынам, дисең...

*Мөдәррис Әгъләмовка (исән чагында )*

Киттем исә, сагынам, дисең,
Әллә чынлап, әллә көлеп,
Мин югында сезгә, дисең,
Әллә ниләр булган кебек.

«Әллә ниләр булган сыман,
Әйләнәм дә тагын киләм.
Барысы да әйбәт икән,
Хәлләрегез менә дигән».

Хәлләребез менә дигән,
Сиңа нидер булган кебек.
Эчләребез поша безнең,
Күренмәсәң үзең килеп.

Күренмәсәң, күренсәң дә,
Әллә ниләр булып тора.
Сезнең гомер, безнең гомер
Шуның белән тулып тора.

Гомер дә бит узып бара
Чынлап кына, уйнап-көлеп.
Яшәвебез үзе әле –
Әллә ниләр булган кебек.

## Шагыйрьләр урамы

Сезнең-безнең коридорлар
Бушады инде хәзер.
Киткән шагыйрьләр тавышын
Яңарта бары хәтер.

Бар иде бу коридорның
Шигырь урамы чагы:
Зөлфәт, Наис, Мөдәррисләр,
Илдар абый, Әхмәтҗаннар,
Нияз Акмаллар тагы.

Рәдиф абый кушылыр иде
Шул гәптәшләр янына.
Бәхәс кызар, шигырь туар,
Кучәрләр шаяруга...

Дөнья хәлләре сөйләнер,
Гөрләр иде коридор...
Ул шагыйрьләр урамыннан
Хәзер соң кемнәр узар?

Киткән саен сагынам, диеп
Булмас шул кайтучылар.
Үткәннәр кире кайтмасын
Белгәннәр түзәр, чыдар.

Коридоры элеккечә,
Тик бүтән анда урам:
Дөнья шундый тиз үзгәрә!
Шаккатып карап торам.

## Намаз карчыгы

Көн дә торып, таң атканчы намаз укый,
Ярлыкавын сорый көн дә Раббысыннан.
Гүр иясе әби-баба, ата-анасын,
Туганнарын һич калдырмый догасыннан.

Балалары, оныклары телдән төшми,
Бәрәкәтле гомер тели аларына.
Күңелләрен иман нуры яктыртсын, ди,
Хәерлеләр очрасын, ди, юлларында.

Кыштыр-мыштыр өй эшләрен эшләп куя,
Ул арада Коръән ала кулларына.
Балаларым килеп чыгар, бәлки, диеп,
Әче камыр бутап куя коймагына.

Телефоннан чакырыйммы әллә, дигән
Фикер килә кинәт кенә күңеленә.
«Килә алмыйбыз», – дигән җавап ишетмәскә,
Ул уеннан кайтып куя җиңел генә.

Һәм утыра телевизор каршысына,
Телевизор барысын да оныттыра.
Сериалларның геройлары кайчагында
Балаларын яраткандай ярattыра,
Бер адашып, бер турылап язмышларын,
Уйга сала, борчылдыра, елаттыра...

## Киңәш бирмә, ярыймы?

Алай эшләсәң, начар, дип,
Болай эшләсәң, яхшы, –
Алтмышка җиткән чагымда
Акыл өйрәтә барсы.

Ничек хәерле буласын
Беләм хәзер үзем дә.
Киңәш бирергә иде ул
Акылсыз яшьлегемдә.

Әмма яшьлек максималист,
Нәрсә аңа киңәшең?
Каян белсен бер хатага
Меңе белән түләсен?

Ә бүгенге яшьләр – кыю!
Күз сал футболкасына:
«Өйрәтмәгез яшәргә!» – дип
Язылган аркасына.

– Әй, егет, туктал беразга,
Җавап бир соравыма:
Синекедәй футболканы
Каян сатып алырга?

Егет көлде, сезгә, диде,
Соң кияргә андыйны.
Булсын, булсын! Син әйт кенә,
Тик өйрәтмә, ярыймы?
Киңәш бирмә, ярыймы?



Гөлнур
Васыйлова

# НӘСЕРЛӘР

## Таң

Сызылып кына алсу таң ата. Тып-тын.

Өзеп-өзеп кенә сандугач тавышы ишетелеп ала. Таң беленә бит, сандугач үзенең гаиләсен әнә шулай итеп уята бугай, бу вакытта башка кошлар изрәп йоклыйлардыр.

Ә мин эңгер-меңгердә имән агачы төбендә таң атканын күзәтеп утырам: әкрен генә караңгылык яктылык белән очраша. Караңгылыкка төбәләм – шомлы... Карт имән артында нindидер бер сәер нәрсә бар кебек... Куркыныч! Ул сәер нәрсә, менә-менә хәзер артымнан килеп, мине тотып алыр сыман булып китә, шундук күз карашымны яктылык сузылган якка күчерәм.

Таң яктысы! Күзләр иркәләнә, җаным нindидер рәхәтлек, ышаныч тоя. Күңелгә нурлар тула һәм авызым ерыла. Теге шомлы уй да каядыр юкка чыга. Яктылык эзләп, тагы да әллә кайларга төбәләм: анда иртәнге йомшак җилнең исеп алуыннан, зәңгәр кыңгырау чәчәкләре бер-беренә хәерле иртә теләгәндәй, тирбәнеп куялар, гүя алар башларын гына кагып, сүзсез исәнләшәләр. Әлеге йомшак җилнең уйнашып йөрүче шаян малайлары, әйтерсең лә агач башына менеп утырганнар да, яфракларга берәм-берәм кагылгалап, үзләре белгән серле шаян бер көй уйныйлар. Ә ул көйне ишетеп алган сизгер сандугач, бар җиһанны яңгыратып, дөньяда яшәүнең рәхәтлеген башкаларга ишеттерәсе, табигатьнең гаҗәеп матурлыгын тирә-якка күрсәтәсе килеп, яңа көн туганны белдереп, үзенең аһәңен суза.

Таң ата минем туган ягымда! Ә башка якларда – Парижда, Кытайда таңнар ничек ата икән? Бездәгедәй матур, серле, ал таңнар тагы кайда бар икән?!

Таң! Ә бу сүз – хәрефләр тезмәсе үзе дә көй сорап тора кебек. Хәрефләренә кагыласың, чыңлап җибәрер дә, ачылып китеп, эченнән аллы-гөлле нурлар сирпелер кебек.

---

*Гөлнур Васыйлова – күпсанлы шигырьләр һәм хикәяләр, «Күңелем җимешләре», «Балаларга», «Сөю кошым», «Җаннар моңы» кебек китаплар авторы; Шәйхи Маннур исемендәге әдәби премия лауреаты. Мамадыш районында яши.*

Таң! Табигатьнең бик тә зур могҗизасы ул – караңгылык китеп, яктылык иңгән вакыт! Кош-кортлар уянып, чәчәкләр керфекләрен ачып, чык белән юынган чак, кешелек яшәешне дәвам иткән чак. Әнә шундый гүзәл, серле булганга күрәдер дә инде, таң белән уянган кешеләргә бәхет килә, диләр.

Таң – әйтерсең, бәхетнең үзе!

## Каенкаем – дускаем

Шифаханә. Тәрәзәләре төньякка, каен урманына карап торган бүлмәләрнең берсе – җиденчесендә авырып ятам. Гомер булмаганны, инде ай буе тәнем температурасы 37 дән төшми...

Хәлем җиңел түгел... Ятагымнан каеннарга карап уйланам. Инде ничә көннәр буе уңайсыз итеп, каерылып ятам икән. Шәфкать туташы кереп, туры һәм уңайлы итеп ятыгыз әле, дип кисәтеп чыгып китте. Минем каерылып, көйсез итеп ятуыма каеннар сәбәпче икәнен соңыннан гына төшендем. Каеннарның күземә ниндие туры караганын түгел, ә күңелемә ошаганын эзләп тапканмын да каерылып аңа карап ятам икән.

Күңелемә якын каен – нәкъ үземә охшаган: артык озын да түгел, кыска да түгел – уртача буйлы. Буй-сыны да өзелеп төшкән зифа димәс идем, бераз тулырак. Ә бар икән арада бик зифалары да. Ябалдашлары да күп – ягъни, минем кебек түгәрәк. Ә яфраклары! Яфраклары вак та түгел – уртача, шундый күп – нәкъ минем куе, калын, бөдрә чәчем төсле.

Төс-кыяфәте генә түгел, хәтта холкы белән дә үземә охшаган каеным. Кичә булган көзге яңгырда, җил искән саен, ничек итеп бәргәләнгәнен, өзгәләнгәнен күрсәгез сез аның, түзә алмадым, аның хәлен аңлап елап ук җибәрдем. Әйтерсең, каеным ни беләндер көрәшә, ябалдашлары белән нәрсәнедер читкә этәрә, икенче яктан якынайган, янәшә торган каен ботакларына иpләп кенә, зинһар, якын килмәгез, сезгә дә авыр булыр, – дигән кебек итеп кисәтә төсле. Ә инде каяндыр өстән янаган афәтне ул үзенең баш очы белән селтәп-селтәп читкә чөя дә аннан, түбәндә ничек икән хәлләр дигән күк, аска карап-карап ала. Ул хәвеф-хәтәрләрдән башкаларны шулай итеп саклый сыман.

Ә бүген ул шундый тыныч, югарыдан барысын да барлап, күреп, яшәүнең матурлыгына сокланып, тормыш-көнкүрешне үзенчә матур итеп, үз агымына алып барасы килү теләге белән яна.

Күрәсезме? Берән-сәрән генә чайкалып алган ботаклары, әйтерсең, үтеп киткән берәүгә сәлам биреп кала, ә көдрә яфраклары, җилбер-җилбер килеп, җил малае белән әнчекләшеп ала да, әни ачуланыр, дигән кебек тынып кала. Акка тимгел төшкән жилет кигән тулы гәүдәсе, әкрен генә бала йоклаткан сыман, үз җаена көйләп тибрәлә. Ул әнә шулай итеп үзенең дә, тирә-яктагыларның да тынычлыгын саклый шикелле.

Каеным – дускаема эчемдәге моң-зарымны елап сөйлим, имеш, хәлем юк, ә ул дәшми-тынмый гына бераз тыңлап торгач, кинәт кенә дулап-ярсып, бөтен яфракларын дерелдәтеп, ябалдашларын уңга-сулга болгап, кәүсә – гәүдәсе белән миңа таба килә башлаган күк: «Әнә, күрше бүлектә кисәләр, тегәләр, яман чир белән көрәшәләр, җан саклап калырга тырышалар, ә син зарланасың! Тары бөртегедәй зарыңны тыңлап та торасым килми! Түз, сабыр бул!» – дип тураеп басты да тынып та калды.

Дускаемның шулай дәшүе яңагымдагы яшьләрне шундук киптерде, ничә көннәр буе хәлсезләнеп ятагымнан тора алмаган кеше – үзем торып тәрәз төбенә килеп басканмын икән...

## Наратлык


Көне буе кар ява. Кар бөртекләре әле йомшак кына җиргә куналар, әле бер-берсен кугандай ярышка кушылалар, кинәт кенә көчле җил чыккач, бөтен тирә-якны бер итеп, чабыша башлыйлар, үзләрен кая куярга да белмиләр кебек. Шул арада алар тын гына җиргә сибеләләр, әйтерсең лә җиргә томырылып томан тарала. Һәр бөртекнең үз урыны бар кебек, шундый саф булып, тигез итеп җиргә йомшак кына җайлап урнашалар да нур сибеп карап торалар кебек.

Күккә ашкан зифа, озын буйлы нарат кызларының яшел шәленә кунган кар бөртекләре иркәләнеп җемелдәшәләр. Ә томан арасында күмелеп калган башка гүзәл нарат кызлары урман юлы буендагы кызлар янына кабаланып йөгерәләр төсле. Шундук кар бөртекләре дә үзләренең саф рәтләрен югалтып чәбәләнә башлыйлар. Нигә шулай ашкыналар икән алар?..

Ә-ә! Ак томан арасына җил малае кергән икән, шуңа рәтләре буталган бит. Җил малае нарат гүзәлләре белән әбәкле уйный... Гүзәлләрнең шулай йөгерешүеннән, әнчекләп уйнауларыннан кәефләре күтәрелеп, алар тагын да зифарак булып үсәләр, күккә күтәреләләр. Ә нарат кызларының үскән саен көдрә чәчләре ак болытларга тиеп-тиеп китә. Әйтерсең, ак болытлар шул сабыйларның чытлыкланып чыркылдашуыннан вак-вак кар бөртекләре ясап, җиргә сибә.

Каяндыр, йөзенә усаллык чыгарып, инде күптәннән күз уңыннан югалган шаян улын эзләп, Җил абзый бу якка – нарат кызлары янына таба килә. Ә шаян малай, әтисе никадәр усал булып күренсә дә, аның яратуын сизеп, һаман кача, гүзәл нарат кызлары тирәсендә кайнаша. Гүзәлләрнең чәчләренә кунган ак кар бөртекләре тынычлыкларын җуеп, дулап килгән Җил абзый кочагына эләгә дә, аннан тыпырчынып, як-якка сикерешә. Алга таба нидер буласын сизенепме, нарат кызлары, үзләрен бизәп торган ак сәйлән кар бөртекләрен югалткандай, башларын ия-ия, бизәнгечләрен эзли. Әйтерсең, мәхшәр башланган, бөтен наратлык менә-менә урыныннан кубарылыр төсле.

Әнә-әнә! Әтисе шаян улының колагыннан эләктереп, үз урманына алып китте. Ак болыт, гүзәлләрдән көлгәндәй, һаман чыркылдавын белә. Ак болытларның чырык-чырык көлү тавышлары, ак кар бөртекләренә әйләнеп, тагын әкрен генә җиргә сибелә. Ә гүзәлләр, күңелләрен тынычландырырга теләп, әкрен генә ак томаннар арасына кереп югала. Тагын... Тагын... Тагын...



Фәнәвис
Дәүләтбаев

# САГЫНДЫРГАНЫ – ЯШЬЛЕК ЕЛЛАРЫ

РОБАГЫЙЛАР

***

Тормышымда акыл кергән чак кына.
Каударланмыйм, атлап барам сак кына.
Авыр булды «уфалла»ның арбасы –
Мин тартканны тарта алыр ат кына.

***

Адашмавым – кирәк читкә чыкмавым.
Үргә таба үзем салган сукмагым.
Чынлап әйтәм, тормышымнан канәгать,
Авыр, диеп, юк йөземне чытканым.

***

Гаҗәп түгел монда бәхет табуым –
Туган җирдә өзелмәслек тамырым.
Шушы җирне яратып, газизем, дип,
Күңелемнән күптән инде тануым.

***

Күңелемнән багамын да ил-көнгә,
Сорап куям: яшибезме иркендә?
Яклаучысыз калган урам этедәй
Түгелме без кирәкмәгән беркемгә?

***

Юлы ерак – барасы да барасы.
Ниләр генә күрми адәм баласы.
Ә чынында, туугa, һәр мизгелдән
Якыная яшәү-үлем арасы.

Фәнәвис ДӘҮЛӘТБАЕВ (1951) – *шагыйрь; «Суз җырыңны, былбылым!», «Карурман чишмәсе», «Таныш халәт» һ.б. китаплар авторы. Актанышта яши.*

***

Сабый түгел, күрәсез бит, мин үстем.
Инде хәзер ваклыклардан мин өстен.
Тормышымда күп нәрсәгә ирештем,
Әйтә алмас дөнья миңа: и мескен!

***

Инде күптән сизелсә дә арганым,
Артка түгел, алга таба барганым.
Алла кушып, алда исән-сау булсам,
Көйләп булыр әле, димен, калганын.

***

Агымыдай талгын аккан елганың
Сизелми дә үтеп киткән елларым.
Әйтмәсәнә, шул елларга ияреп
Үтеп киткән ямьле чагы дөньяның.

***

Валчык кына – зурдан түгел капканым.
Алтын түгел, бакыр гына тапканым.
Эшләвемнең нәтиҗәсе тир түгеп –
Хәләл барсы, шуңадыр да шат җаным.

***

Йөк күтәреп мендем гомер үренә.
Кызыкмадым урынның иң түренә.
Инде хәзер үргә менеп күз салгач,
Тормышымда бар да ипле күренә.

***

Илем, дисәм, мине ишетерме?
Улы итеп мине хис итәрме?
Онытылып торган үз баласын
Таныр өчен анда көч җитәрме?

***

Күкләре язган кеше язмышын.
Үзгәртеп булмас гомер агышын.
Күргәннәре дә җитеп ашса да,
Ниләр көтәргә икән тагын соң?

***

Уйларга чумып карап тормалы –
Турыга түгел, юлым бормалы.
Исемә төшеп, үзәккә үтеп
Сагындырганы – яшьлек еллары.

***

Алга барам, димен, салмак кына.
Адымнарны эчтән санап кына.

Кабатлана бер үк ялгышларым –
Алып булмый әмма сабак кына.

***

Аңлап эш ит шуны, и син бәндә:
Бар өстенлек – алдан өлгергәнгә.
Берни дә юк артка чигенгәнгә,
Йоклап калма вакыт йөгергәндә!

***

Яшәгән чак уйга талып кына.
Уйламыйдыр мәхлук сарык кына.
Ялгышлардан гыйбрәт алып кына,
Яшәп була алга барып кына.

***

Замананың эңгер-меңгер мәле.
Сытык йөзле әллә мин генәме?
Бер ай-һайсыз, кайгы-сагыш күрми
Яшәгәне бар соң кемнең әле?

***

Уйладыммы, борчуларым арта –
Шәп чакларым калып бара артта.
Нык кыскарды сиңа язганы, дип,
Вакытмы ул – чабуымнан тарта?

***

Бу дөньяның агы, карасы бар.
Безгә монда гыйбрәт аласылар.
Намус-кыйбласыннан тайпылмаган
Кеше булып җирдә каласы бар.

***

Акыллыдан ясый аңгыра.
Тормыш кайчак хәйран калдыра...
Тормыш сынауларын үтә алган,
Көче булган алга алдыра.

***

Кемдер – өстә, кемдер – төпкелендә.
Ныклап баксаң, монда юк кем генә.
Күтәрделәр, диеп, син масайма –
Ялган дан ул, дустым, төтен генә.

***

Бакчаның да иснәлмәгән гөлләре бар.
Гомернең дә менеп җитмәс үрләре бар.
Гомер буе эчтән генә саклап йөрткән
Күңелнең дә гел ачылмас серләре бар.

***

Күңелемнән белсәм дә мин ни әйтергә,
Тик мөнбәрдән сүз бирмәсләр мин ятимгә.
Әйтер идем: тел-динеңне сакла, диеп,
Әкеренләп бетеп барган милләтемә.

***

Уйламый да ничек авыр тапканыңны.
Бер әрсезе тартып ала капканыңны.
Тик онытма – аңардан да хәтәрерәк
Хәрамчылар урап алган як-ягыңны.

***

Савап кылып яшәп калыйм дигәннәргә
Сабыр гына юл күрсәткән пәйгамбәр дә.
Хөкем кырыс – чит өлешкә кергәннәргә,
Комсызларга, акча, байлык сөйгәннәргә.

***

Үзләренә җәза алар сорап тора –
Бәндәләрең хәрам җыя, гөнаһ кыла.
Тыелалмый азынганны-тузынганны,
Тәңрем, җыеп җәһәннәмгә олактыр ла!

***

Тыныч йокла, әлли-бәлли бәү, диясе.
Китеп барды дөньяның бер әүлиясе.
Туганнан соң, гомер дигән тукталышта
Озак тормый җирдә һичбер җан иясе.

***

Тыймасаң, эштән кудыра тел дигәне.
Буранлап карны туздыра җил дигәне.
Бәйрәмнәре бетеп торган араларда
Матәм көннәре уздыра ил дигәне.

***

Юлым – туры. Ак күңелдә – ак уйларым.
Ил – упкында, ник күрмисез, казыйларым?!
Кирәк икән, итәгенә ут төртегез
Ил талаган апаларның, абыйларның!

***

Кем ул әйтә: хаклык эзләп маташма да.
Юк ул хаклык – өндә килеш саташма ла.
Бар ул хаклык – Хак Тәгалә, аның дине
Юл күрсәтә саташканга, адашканга.

# XX ГАСЫРНЫҢ ИҢ ЗУР ТАРИХИ ВАКЫЙГАСЫ... ИРТӘГӘ БЕЗНЕ НИ КӨТӘ?

«ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛ»


*Бу айда – Бөек Октябрь революциясенең 100 еллыгы. Шул уңайдан «Казан утлары» журналы редакциясендә бер төркем тарихчы галимнәребез «түгәрәк өстәл»гә җыелды. Фикер алышуда **Индус ТАҺИРОВ, Рафаэль ХӘКИМОВ, Илдус ЗАҺИДУЛЛИН, Ленар ГОБӘЙДУЛЛИН** катнашты. «Казан утлары» журналының баш мөхәррире **Илфак ИБРАҺИМОВ** алып барды.*

**Илфак Ибраһимов:**



*– «Бөек Октябрь революциясе – XX гасырның иң әһәмиятле тарихи вакыйгасы. Ул кешелек үсеше тарихында олы борылышка сәбәпче булды». Мондый бәяләмәне, әлбәттә, СССР дәүләте тарихы, фәнни коммунизм дәреслекләреннән укып «белгән» идек. Төп яңалык булып, дөньяда колониаль системаның җимерелүе, социалистик дөнья илләре барлыкка килүләр дәлилләнде. Бөек түнтәрелештән соң 100 ел эчендә төрледән-төрле түнтәрелешләр булды... Социалистик дөнья системасы тәмам таркалды. Хәтта революциянең бишеге Рәсәй – СССР үзе дә унбишкә бүленде. Без – шул дәүләттә туып, шуның кануннары белән яшәп үскән буын. Әлеге бөек, бәлки гыйбрәтле вакыйгаларның шаһиты булдык. Әтиләребез, бабаларыбыз шәһитләре булдылар... Чыннан да, кешелекнең үсеше алгарышында төп вакыйга идеме Октябрь... Әллә, киресенчә, үсеш-алгарышны акрынайттымы ул?*

**Индус Таһиров:**



– Октябрь революциясе турында шулкадәр бер-берсенә каршы күп нәрсәләр язылган ки, кайвакыт аларның кайсы дөрес, кайсысы дөрес түгел икәнлеген билгеләү дә кыенлаша. Өстәвенә аңа капма-каршы бәя бирелә килә. Берәүләр аны хуплый, икенчеләр исә хурлый.

Ләкин, ничек кенә булмасын, Октябрь – дөньяның астын-өскә китергән вакыйга. Аңа күз йомып карау мөмкин түгел. Әлеге вакыйгаларның шаһиты булган Америка журналисты Джон Рид аны дөньяны тетрәткән ун көн, дип бәяләгән иде.

Чыннан да, Россиядәге Октябрь вакыйгаларыннан соң күп илләрдә төрле рәвештәге сыйнфый күтәрелешләр, революцияләр барлыкка килә. Аларны большевиклар, шул исәптән Ленин үзе, дөньякүләм пролетар революциясенә юл ачкан вакыйга рәвешендә бәяли.

Ләкин бу ялгыш фараз булып чыкты. Бернинди дөньякүләм революция дә булмаган. Алай гына да түгел, Октябрь нәтиҗәсендә барлыкка килгән Көнчыгыш Европа илләреннән торган социалистик система юкка чыкты. Коммунизм идеясе үзенең тормышка ашырылмастай хыял икәнлеген күрсәтте.

Бу революция Россия өчен котылгысыз идеме, әллә аның альтернатив вариантлары бар идеме? Моңа җавап табу өчен, 1905-1907 ел революциясенә тиешле һәм объектив бәя бирү зарур. Тукаебыз юкка гына: «Уяндык без бишенче елның бер таңында», дип язмаган. Шул революция елларында ил, аның халкы уяна, чын-чынлап яңача яшәү юлына баса. Көчәйгәннән-көчәя барган революцион хәрәкәт аркасында Николай II


17 октябрь Манифестын игълан итәргә мәҗбүр була. Ул моны теләми, ләкин тарихи мәҗбүрияткә буйсынмый кала алмый.

Ләкин шушы документның авторы О.Ю.Витте әйтүенчә, аның өчен ул революция әйтерсең лә бөтенләй булмаган. Әйтерсең, шушы революция нәтиҗәсендә Дума да, сәяси партияләр дә, иҗтимагый оешмалар да барлыкка килмәгән, гомумән, ил демократия юлына басмаган.

Ул бу үзгәрешләрне демократик Россиянең революцион таңы рәвешендә кабул итә алмый. Һәм тарих таләбенә буйсыну урынына революциядә катнашучыларга карата репрессияләр җәелдереп җибәрә, илне дар агачлары белән бизи. Күпләрне аттыра, астыра, сөрә. Илне канга батыра. Һәм шуның белән үзенә үлем карары да чыгара. Ул карарда тик аны башкаруның датасы гына күрсәтелмәгән була. Анысын инде 1917 ел билгели. Һәм карар бер елдан соң тормышка ашырыла.

Әйе, тарихта соңга калырга ярамый. Ул соңга калучыларны каты җәзага тарта. Николай II соңга кала һәм шуның аша илне яңа революциягә китереп җиткерә. Әгәр ул, беренче революциядән соң, тиешле нәтиҗәләр ясап, сәяси партияләр белән аңлашып, ил белән идарә итүне Думага тапшырган булса, Россия, Англия кебек, конституцион монархиягә әверелгән булыр иде. Тик менә үткәнне кире кайтарып булмый. Буласы булып, властька большевиклар килә.

**Рафаэль Хәкимов:**



– Октябрь революциясе – дөнья тарихында XX гасырның иң зур вакыйгасы. Хәзер аны рус революциясе, диләр. Кайберәүләр Троцкийны күтәрә. Тик барыбер революциянең төп символы ул – Ленин. Хәзер ул аерым күләгәдә калды. Күбрәк Сталинны күтәрәләр. Анысы аңлашыла. Сталин үзе дә Явыз Иванны, Пётр I не күтәргән. Инде үзе шулар исемлегенә кушылды. Демократия бетеп барганда, шундый шәхесләрнең калкып чыгуы табигый. Бу сафларга Столыпинны да кертергә була. Революцияне искә төшерү ул – Ленинны кайтару. Дөньяны үзгәртүдә кайберәүләр аны хәтта Чыңгызхан белән чагыштыра. Чыннан да, аның бөтен дөньяга тәэсир итүен инкарь итеп булмый. Андый шәхесләрне әле табарга кирәк.

Бездә перестройка башлануга, Ленинны оныттылар. Марксны алып аттылар. Әле ярый һәйкәлләре сакланды. Ә Европада Неоленинизм дигән фән бар. Аны өйрәнәләр. Марксизм югалмады. Алар, тарихта булган, хезмәтләр язып калдырган шәхесләр буларак, әле дә өйрәнелә һәм өйрәнергә кирәк тә. Францияне әйтәсе дә юк. Иң акыллы фәлсәфәчеләре, тарихчылары барысы да – йә коммунистлар партиясеннән чыккан, йә бүген дә Ленинны, Марксны хөрмәт итеп яшәүче кешеләр. Кимчелекләрен барысы да белә, шул ук вакытта тәэсирләре белән дә килешми мөмкин түгел.

Социалистик дөнья җимерелде, дип әйтәләр. Әмма нинди социализм турында сүз бара соң? Ул бит инде Сталин китергән социализм. Ленин үз юлын ничек дәвам иткән булыр иде, без белмибез. НЭП килеп чыга, Ленин Швейцариядә, Швециядә озак яши. Швеция үзен социалистик илгә саный. «Бездә чын социализм», диләр. Австрия гербында тәпиләренә урак белән чүкеч астырылган кош сурәтләнгән. Анда социализмны хөрмәт итәләр. Ә без таптап киттек. Бездә чын социализм да булмады. Сталин тоталитаризмы килде. Без социализм җимерелде, дисәк тә, социалистлар бар, алар хәрәкәте төрле илдә бик көчле һәм аларның тәэсире бик көчле булды. Рус революциясенә карап, капитализм да бик каты үзгәрде, күп нәрсәне үзенә алды. Мәсәлән, социаль яклау ул – шуның бер мисалы, социализмның тәэсире. Капитализм үзе дә үзгәрештә.

Сәбәпләргә килгәндә, монархиянең заманы бетте. Николайны бүген изге дип күтәрмәкче булалар. Ә ул, «сербларны яклыйм», диептерме, Беренче Бөтендөнья сугышына кереп чумган кеше. Анда патша түгел, генераллар сугышырга тиеш. Ул сугышта йөри, үз илендә сәяси буталчык бара. Распутин өендә хакимлек итеп утыра.

Рәсәй буйлап хлыстовщина дине котыра. Кеше хәзер аның коточкыч дин икәнен белми дә. Әгәр илдә Конституцион монархия төзелгән булса, бәлки, революция дә кирәк булмас иде. Шул ук вакытта революция ул – түнтәрелеш кенә түгел, ул – террор да, гражданнар сугышы да. Бу күренешләр – шулай ук гражданнар сугышының бер өлеше. Питирим Сорокин үзе революциягә катнаша, «Русская революция» дигән калын гына китап та яза. Ул соңыннан – кире кайтыш – реакция башлана, дип яза. Сталин ул – шушы реакция инде. Һәр революциядә чигенү була. Дантон: «Бөтен революциянең мәгънәсе ул – милек бүлешү, шуның белән революция бетә», – дип әйтә бит. Бүлеп бетергәч, реакция башлана. Перестройка үзе дә, революция сыман, ул шушы революциянең коточкыч дәвамы. Бу заманда милләтләрнең иң акыллы, зыялы катлавын кырып бетерәләр.

Революция ник кирәк, дигәндә (Француз, Германия, Рәсәй революцияләре булды), зур тарих, дөнья тарихы күзлегеннән караганда, һәр дәүләт урта гасырдан китәргә тиеш иде. Капитализм килеп чыга икән, урта гасырдан арыну шуннан башлана.

Рәсәй революциясез үзгәрә алмас иде. Британиядәге кебек йомшак кына акыллы үзгәрешләр кертсәләр, бәлки, ниндидер уңышка ирешә алган булырлар иде дә. Эшләр алай бармады. Революция ул – урта гасырдан тизләтеп китү юлы. Әмма бездә бу процессны Сталин кире бора. Шул сәбәпле, без бүген дә урта гасырдан ерак китә алмадык, ул кире кайтты. Бөтен схоластикасы белән иң күренә торган дин янә алгы планга чыкты, икътисадта деиндустриализация бара. Күп тармаклар юкка чыкты. Аның каравы, хәрби тармак үсә.

**Илдус Заһидуллин:**



– Европада тарихның яңа чорын Беренче Бөтендөнья сугышыннан, ягъни 1914 елдан башлыйлар. Әлбәттә, бу хронология Русиядә булган Октябрь революциясенең дәрәҗәсен киметми. Революциянең җиңүенә, бер яктан, хакимиятнең көчсезлеге, икенче яктан, халыкның гадел һәм тигез тормыш турындагы хыялы сәбәпче иде. Әлеге хыялны тормышка ашырырга тырышканда, СССРның үрнәге, халыкның көчле дәүләт төзү үрнәге, капиталистик илләргә зур йогынты ясады, капиталистларны эшчеләр белән килешүләргә этәрде, бу күренеш кешелек дөньясында зур үзгәрешләргә китерде; бүген алдынгы Европа илләрендә гади кешеләрне социаль яктан яклауның югары дәрәҗәдә булуында социалистик идеологиянең йогынтысы барлыгын танымый мөмкин түгел. Кызганычка каршы, СССРдагы тирән кризис әлеге идеяне чүплеккә чыгарды. Сәбәбе – коммунистлар хакимиятенең үзгәрешләрне кабул итә алмавы, аларны җитәкләргә көче калмау, хакимияттәге торгынлык. Кытай исә социалистик идеаллардан да ваз кичмәде, реформалар да үткәрде һәм бүген иң тиз үсеп баручы илләр сафында.

Икенче Бөтендөнья сугышыннан соң ике поляр дөнья формалашты, СССР таркалгач исә, АКШ бердәнбер лидер булып калды. Бәлки шуңа күрәдер, без үзебезне ничектер кимсетелгән итеп тоябыз. Нишлисең, көчленеке – замана.

**Ленар Гобәйдуллин:**



– Теләсә кайсы тарихи процессның ике яки берничә яклы бәяләнүе табигый күренеш. Шул исәптән, Октябрь революциясен дә озак еллар прогрессив күренеш буларак күкләргә чөеп мактадылар, әмма хәзер исә заманында һәр шәһәр, район, авылда әлеге «бөек көн» уңаеннан оештырылган демонстрацияләрне дә тарихта гына калды дияргә була. Алай гына да түгел, кайчандыр бу датаны белмәү зур гаеп саналса, хәзер белүчеләрнең саны да елдан-ел азая.

1917 елда илнең Советларга күчүе уңаеннан, Казан

шәһәрендә басылган иң күп тиражлы газета «Кояш»: «3 ноябрьдә, көндез сәгать 2дә Театр мәйданында, Дворянски собрание алдында Революция штабы тантаналы рәвештә властьны Эшче, солдат вә крестьяннар советына бирде. Иң әүвәл Ершов сөйләп, хәзер властьның бөтен халык кулында булганын, моннан соң чын хөрриятнең мәйданга чыгачагын бәян кылды. Башкалар да шул рухта сөйләделәр. Соңыннан музыка илә солдатлар таралды», – дип кыска гына хәбәр бастыра. Үзем яшәгән Арчада Совет власте 1917 елның 8 ноябрендә Шәһәр Думасының бинасында игълан ителә, шунда ук хәрби-революцион комитет та урнаша. Әмма бу дата белән генә тарихи процессны икегә бүлеп кую бик үк дөрес түгелдер, чөнки Россия һәм шул истәптән татар халкы тарихында да хәлиткеч вакыйгалар соңрак, 1918-1920 елларда була.

Дөрестән дә, революция бөтендөнья илләренә йогынты ясады, Россия капиталистик үсеш юлыннан йөз чөереп, социализм юлына аяк басты. Эре колхоз-совхозлар төзелде, сәнәгать оешмалары калкып чыкты, дөнья күләмендәге фәнни ачышлар Октябрь революциясеннән соң аеруча саллы булды. Шуның өстенә социаль революция һәм пролетариат властеның «тәхеткә» менүе татар хезмәт ияләренә, гади эшче һәм крестьянга үзләрен танытырга юл ачты. Революциягә кадәр университетта берән-сәрән генә морза баласы укыса, түнтәрелештән соң эшче-крестьян яшьләре дә әлеге уку йортына күпләп агыла башлый, дөньяви белемле татар егет һәм кызларының саны арта. Гомумән, революция татарларга, мөхтәрәм язучыбыз Галимҗан Ибраһимов язганча, «түбәннән, тормышның төбеннән» күтәрелергә мөмкинлек бирә... Мисал өчен, аерым төбәкләрне күз алдында тотсак, 1920 елның 14 февралендә Арчада өяз крестьяннарының съезды ачыла, анда 300ләп делегат катнаша, шул ук елның 10 маенда Арча өяз коммунистларының беренче конференциясе оеша. Болар барысы да гади авыл кешесенә үзләрен күрсәтергә, ниндидер фикер әйтергә мөмкинлек биргән... Әлеге «бөек» вакыйганың революциягә кадәр үк булган уңай күренешләргә тагын да киңрәк юл ачуын танырга кирәк. Ул да булса татар авылларында оешкан кооперацияләр. Белүегезчә, совет чорында кулланучылар кооперациясе үсеш алды, ә татар кооператив хәрәкәтенең төбе-тамыры патша Россиясендә ята.

Соңгы елларда өлкән буын кешеләреннән: «Без коммунизм төзергә хыялландык, ә коммунизмда яшәгәнбез икән инде...» – дигән фикерне еш ишетергә туры килә, алар үзләренең совет хакимияте чорында яшәгән вакытын сагына. Чөнки күпләрнең бабалары революциягә кадәр ат һәм сыерлар тотса, совет чорында һәр гаиләдә берәр сыер, дистәләгән сарык асралса, хәзерге вакытта күпләрнең кәҗә карарлык та мөмкинлеге юк... Газета-журнал тирәсендә хезмәт куючылар исә мул итеп каләм хакы алган вакытларын матур әкият итеп сөйли.

Революциядән соң татар халкы завод-фабрикаларга эшкә күбрәк агыла, шуның нәтиҗәсе буларак, Казан һәм башка шәһәрләрдә яшәүче милләттәшләребезнең саны арта. Урта гасырларда татар шәһәре булган, 1552 елда яулап алынып, революциягә кадәр бер дистә чамасы гына татар яшәгән Арча Совет чорында чын мәгънәсендә татар эшчеләр посёлогына әверелә. Мәгълүм ки, бүген анда яшәүче халыкның 92% татар халкы тәшкил итә.

Революция елларында Россиянең һәр җирендә канкойгыч вакыйгалар булып уза. Үзем яшәгән төбәктә 1918 елның 25 октярь – 15 ноябрь көннәрендәге «Арча фәтнәсе», ягъни Арча ягы крестьяннары кузгалышы әнә шундыйлардан. Шәһәр кешесен ашатабыз, дип авыл агаеннан мәҗбүриләп икмәкне тартып ала башлагач, крестьяннар, бөтенләй азык-төлексез, мал-туарсыз калабыз, дип шикләнә. Шулай итеп, Олы Мәңгәр волосте крестьяннары халыктан азык-төлек җыеп йөрүче отрядны коралсызландыра, икмәк туплау пунктларын талый. Казан, Лаеш, Мамадыш өязләрендә татар крестьяннары оештырган сәнәкчеләр восстаниесендә Күпербаш, Наласа, Казанбаш, Мәтәскә, Өчиле, Иске Йорт, Әзәк авыллары крестьяннары катнаша. Казаннан җәза отрядлары чакыртыла, баш күтәргәннәргә җәза салымнары кертелә. Сәнәкчеләр урманнарга кача,

Кызыл Армиягә барудан баш тартканнар белән берләшә, аклар ягына күчә. Шуның өстенә, 1918 елда арчалылар, Азин җитәкләгән Көнчыгыш фронтның Арча төркеме гаскәре составында да сугышып, Казан шәһәрен һәм губернаны акгвардиячеләрдән азат итү сугышларында катнашырга мәҗбүр була. Вакыйгалар кызганнан-кыза: 1919 елның язында Арча, Әтнә, Мәңгәр, Яңа Кишет, Балтач волостьлары һәм Арча шәһәре сугыш хәлендә, дип игълан ителә.

Алда уңай дип саналган күренеш зур фаҗига һәм югалтулар – «сират күпере» аша гамәлгә куела, дип язсак та дөрес булыр. 1929 елда колхозлаштыру чамасыз кызу темплар белән бара. Бу хәлле крестьяннарның йорт-җирләрен, милекләрен конфискацияләү, Себергә сөрү юлы белән эшләнә. Мәчетләр мәктәп-клубларга әверелдерелә. Бер Чүриле волостенда гына да 22 мәчет ябыла. Мәмсә волостенда 200 кеше кулак дигән ярлык белән Себергә куыла. 1930 елда колхозлар оештыруга каршы хәрәкәт көчәя. Күпчелек урыннарда аны дин әһелләре җитәкли. Кәче, Наласа, Югары Әзәк авылларында рәсми хакимияткә каршылык бигрәк тә көчле була. 1930 елда Сикертәндә колхоз таратыла, баш күтәргән халык амбардагы чәчүлек орлыкны бүлгәләп бетерә. 1931 елда кулаклар Масрада авыл советы рәисен утка ыргыта. Ашабаш авылында колхоз фермаларына, каралты-кураларга ут төртәләр. 1930 елда колхоз рәисе Ахунның (Гариф Ахуновның әтисе) кулаклар тарафыннан үтерелү вакыйгасын укучыларыбыз яхшы белә. Мондый мисалларны бик күпләп китерергә булыр иде. Шулай ук завод-фабрикалардагы коточкыч авыр хезмәтнең дә авылдан күченеп пролетариатка әверелгән элекке крестьян тарафыннан башкарылуын онытырга ярамый.

Колхозларга тукталыйк. 1990 елларда Россиядә, соңрак бездә «Уртак малны эт җыймас», дип элекке колхоз-совхозлар таркатылды, аларны эре агрохолдинглар басып алды, соңрак крестьян-фермер хуҗалыклары мактала башлады. Әмма хәзер күрәбез: кайда элеккеге колхоз системасы яши, шунда авыллар хәллерәк, аларга юкка чыгу, мәктәпләргә дә ябылу куркынычы янамый.

Түнтәрелеш зур корбаннар сорый, илнең дә үсешен берничә елга артка сөйри. Бары тик үткәннән гыйбрәт һәм сабак ала белергә кирәк. Күпчелек фаҗигаи хәлләр, сабак ала белмәү сәбәпле, яңадан кабатлана...

**Илфак Ибраһимов:**

*– Октябрь революциясе казанышларын Рәсәй империясенең 1913 елгы күрсәткечләре белән чагыштырып күрсәтү модада иде. Хәзер исә, СССР таркалгач чирек гасырдан соң, без казанышларыбызны 1990 ел белән чагыштырабыз. Баксаң, әле ул нәтиҗәләргә ирешә алганыбыз да юк икән. Әлбәттә, хәрби оборона комплексы үсешен исәпкә алмаганда. «Без кемнәр һәм кая таба барабыз?» дигән сорау туа бит?*

**Рафаэль Хәкимов:**

– Безнең алда бүген дә шул ук максат – урта гасырдан китү тора. 1913 елда урыста да, татарда да капитализм яхшы гына кузгалып киткән була. Бу бик кызык, татарда капитализм Европача түгел, ә авыл җирлегеннән башлана. Гадәттә бит, капитализм булсын өчен, университетлар, банклар, эшчеләр классы һәм шәһәр булырга тиеш. Арчада зур заводлар, фабрикалар салынып башланган бездә әлеге процесс. Бу, минемчә, яңа караш, без әле аны аңлап, бәяләп бетермәдек. Ул, Рәсәй империясе кысуына, кануннарның безнең өчен уңай булмавына карамастан, татарлар арасында бик тиз тарала. Үсеш, әлбәттә, була, әмма бит үсеш өчен сәяси структуралар да үзгәрергә тиеш. Ул үзгәреш юк икән, капитализм килми.

Революция булмаса, мәгълүм уңышларга ирешер идекме-юкмы дигән сорау туа. Мәсәлән, революциягә хәтле татар байлары бик көчәя. Әле, җитмәсә, аларның бер төркеме иң бай катлам – ак байлар исәбендә йөри. Ул катлам татар милләте өчен кызганмыйча акча түгә. Бу елларда университет кору мөмкинлеге булмый, ак байларыбыз мәчет-мәдрәсәләр, газета-журналлар, типографияләр булдыру, аларны сафта тотуга коточкыч күп байлыкларын сарыф итә. Карыйсың – күпме

акчасын түккән алар, шулай да баеганнар да баеганнар. Тагын ун-унбиш-егерме ел булса, бөтен Казанны сатып ала алган булырлар иде. Алар бит инде Татар бистәсендә генә түгел, Казанның уртасына кереп йортлар сала башлый. Сәүдәләре бөтен Рәсәй буенча бара. Урта Азия, Кытай белән сәүдә элемтәләре урнаштырып, Рәсәй базарының 50 % безнең татарлар кулына күчә. Шуңа күрә без һаман мескен булыр идек, дип әйтеп булмый. Революция, әйе, күп нәрсәне үзгәртте. Мәҗбүри рәвештә. Мәсәлән, республикалар оешуда Ленинның да, Сталинның да катнашы юк. Алар Федератив Рәсәйгә, республикаларга каршы була. Бәйсез республика сыйфатында иң беренче казакъларныкы оеша. Аннан гына – урысларныкы. Шуннан соң Украина, Белоруссия, Кавказ арты, Татарстан һәм башкалар, тегеләр кушканга түгел, халык таләбе белән барлыкка килә. Бераздан Сталинның реакциясе башлана. Шул ук вакытта ил үзгәрә. Элек бит Рәсәйнең үзәге – метрополия һәм аның янында провинцияләр була. Ә хәзер инде алар тигезләшә. Күп кенә халыклар моннан файда күрә. Мәсәлән, кыргызлар. Чикләре Кытай, Әфганстан белән тоташканга, алар өчен Рәсәй уңайлы булды. Республикаларны тигезләүне тизләтүгә күпме акча китте. Бу халыклар үсеш кичерде, ләкин безгә ул артык файда бирмәде. Без, әлбәттә, уңай якларны да эзлибез, табарга тырышабыз. Ә, бәлки, революция булмаса, безнең үсеш тагын да тизрәк булыр иде. Мәскәү университетындагы бер профессор: «Революция булмаса, Рәсәй, бәлки, Татарстан дип аталыр иде», – дип әйтә. Андый курку, чыннан да, булгандыр ахрысы.

**Индус Таһиров:**

– Октябрьдән соңгы икътисад төрле вакытта төрлечә үзгәрә килде. Шәхси милек бетте. Гражданнар сугышыннан соң җимерелеп, таркалып беткән икътисадка җан керә башлады. Халкыбызның канын эчү, бигрәк тә авылны, крестьяннарны талау, җәберләү рәвешендә индустриализация үткәрелде һәм, нигездә, хәрби икътисад барлыкка килде. Бөек Ватан сугышыннан соң, янә халыкны шундый ук авырлыкларга дучар итеп, шактый җимерелгән һәм имгәнгән икътисад аякка баскан кебек булды.

Ләкин ил тиздән нефть, газ, гомумән, чимал сатуга гына җайлашып яши башлый. Һәм инде үзгәртеп кору дигән заманга килеп җиткәндә, ул тирән кризиста була. Ельцин властька утыргач, олигархлар халык милкен үзара бүлешә. Икътисад яңа кризиска керә. Һәм әле бүгенге көнгә кадәр ул кризистан чыга алганыбыз юк.

Тик Татарстан гына аннан чыгуның мисалларын тудыра тора. Ләкин, ни кызганыч, аның артыннан барырга омтылучылар юк дәрәҗәсендә.

**Илдус Заһидуллин:**

– СССР таркалгач, илдәге халык хуҗалыгы зур югалтуларга дучар булды. Төбәкләр (республика, өлкәләр) арасындагы кооперация һәм хезмәт бүленеше, гомумән, хуҗалык итү моделе җимерелде, союздаш республикалардагы бик күп заводлар, әзерләгән белгечләр бер көндә «чит илнеке»нә әверелде. Социалистик һәм капиталистик илләр ярышында, хосусый милеккә, аерым шәхеснең инициативасына корылган җитештерү моделенең өстенлеге расланды. Безгә, иҗтимагый мөнәсәбәтләрне, менталитетны үзгәртү өчен, әле күп эшлисе бар, күп нәрсәләр буыннар алмашу аркылы гына хәл ителер, мөгаен. Кызганычка каршы, Русия һаман да алдынгы дәүләтләр өчен чимал чыганагы булып кала бирә, илнең икътисади тотрыклылыгын дөньяда нефть һәм газ сату бәяләре билгели. Тыюлар керткәнгә кадәр, чит илләрдән артта калган технологияләр сатып алып, җитештерүне үстерергә тырышалар иде. Хәзер аларын да алу мөмкинлеге юк. Бүгенгә кадәр хөкүмәтнең ил икътисады үсеше планы булмау хафага сала.

Русиядә патриотик тәрбия һәм халыкта патриотик хисләр көчәя бара. Бу күренеш бигрәк тә, Кырым Русиянеке булгач, күзгә ташлана башлады. Хәзер Мәскәү яшьләре арасында шундый фикерләр ишетергә мөмкин. Алар: «Татар-монгол игосы булмаган, чөнки бөек халыкның буйсынып яшәве мөмкин түгел», – дип сөйли.

Сәяси тотрыклылык булса, халыкара масштабта изоляция көчәя барган шартларда Русиядә икътисад үсеше башланыр дип уйлыйсы килә.

**Илфак Ибраһимов:**

*– Әлбәттә безнең өчен «казанышларның – казанышы» булып 1920 елда үз дәүләтчелегебезнең тернәкләнүе – Автономияле Республика төзелүе исәпләнде. Чыннан да, дәүләтчелек идеме ул? Бүгенге хәлебез, сәяси күзлектән караганда, ничек, кемнәр без?*

**Рафаэль Хәкимов:**

– Республикаларны оештыру ул Столыпин башлаган эшнең дәвамы иде: Татарстан-Башкортстанга бүлеп, Кавказда борынгы халыкларны уйлап чыгарып, «Ода письменное», диеп, аларга республикалар биреп. Сталин, әлбәттә, республикаларны бетерә ала иде, көче бар иде, ул бит халыкларны депортацияләп, күчереп йөртте. Ләкин ул да республикаларның исемнәрен булса да калдырды. Бүген кайберәүләр губерналарга әйләндерү хакында сөйли, алар бу сүзләрен уйламыйча әйтә. Сталин аларны әллә кайчан губернага әйләндерер иде, ләкин ул әлеге адымга бармый, чикне узмый. Калганы аңлашыла, Солтангалиев әйткәнчә, СССР уңышлы булмады, таралды. Ә бүген «без – федератив», дигәндә – бу матур исем генә. Каядыр әз-мәз, бик тырышсаң табып була инде аның җимешләрен. Мәсәлән, федеративлык тышкы эшләрдә әле калды. Чит илләр бирегә килә, үзебезнекеләр йөри. Бу бик тикшерелә инде, шулай да андый мөмкинлек бераз бар. Бу – федеративлыкның бер җимеше. Суверенитет елларында без үзебез фикерләргә өйрәндек. Мөстәкыйль буын туды. Калганы өчен яңадан көрәшергә кирәк.

**Индус Таһиров:**

– Әгәр дә яңа союз договоры барлыкка килгән булса, без Россияне сөйләшүләр барышында мөстәкыйль рәвештә кул куярга күндерер идек. СССР таркалмаса, без – Союздаш республика сыйфатында, таркалса, бәйсез дәүләт булыр идек. Ләкин, ни кызганыч, татарга менә шундый авыр язмыш гел килә тора.

Октябрь революциясен һичничек тә бертөсле генә бәяләп булмый. Чөнки аның уңай һәм тискәре яклары бергә үрелеп бара. Аларның кайберләренә, бигрәк тә рус булмаган халыкларга кагылганнарына тукталуны кирәк саныйм. Революция аларның дәүләтчелекләрен торгызуга юл ачты. Республикалар оешып, СССР таркалгач, союздаш дип аталганнары бәйсез дәүләтләргә әверелде.

Безнең халкыбызга да, зур авырлыклар белән булса да, дәүләтчелекне торгызу мөмкинлекләре барлыкка килде. 1920 елның 27 маенда автономияле Татарстан Республикасын төзү карары кабул ителде. Дөрес, аны Мирсәет Солтангалиев, Кәшшаф Мохтәров кебек милләтпәрвәрләрнең, үз-үзләрен аямыйча, союздаш республикага әверелдерергә тырышулары уңышсызлыкка дучар ителде. Тик шулай булуына да карамастан, әгәр дә, хокуклары кысылган рәвештә булса да, әлеге республика барлыкка килмәсә, аны суверенлаштыру мөмкинлеге тумас иде. Республикабызның суверенлыгы игълан ителде һәм гамәлгә керде. Көрәш әле тәмамланмаган, ул дәвам итә.

**Илдус Заһидуллин:**

– 1917 елгы революциягә кадәр кануннар хосусый милекнең кагылгысызлыгына нигезләнгән иде. Рус булмаган халыкларга мәдәни һәм рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен, дәүләт тарафыннан бер сум да бирелмәде. Әйтик, татарларда бу максатларга байлар, мәхәллә халкы үз чыгымнарын тотты. Ә милләтнең матди ресурслары чикле иде. Совет хакимияте хосусый милекне юкка чыгарды, халыкларның милли мәнфәгатьләрен территориаль бердәмлекләр – милли республикалар аша дәүләт бюджеты хисабына тормышка ашыра башлады. Бер яктан, зур уңышларга ирешелде: татарларның милли урта мәктәбе, яңа югары сәнгать юнәлешләре барлыкка килде һ.б. Икенче яктан, ТАССР территориясендә татарларның дүрттән бере генә яшәү сәбәпле, Бөек Ватан сугышы алдыннан чит

төбәкләрдә милли мәдәният һәм мәгариф өчен дәүләт чыгымнары киметелде, соңрак тәмам туктады, ассимиляция көчәя башлады.

2020 елда республикабыз ТАССР оешуының 100 еллыгын билгеләп үтәчәк. Бүгенге Татарстан – шул ТАССРның дәвамы. Суверенитет елларында яңа Татарстан турында сүзләр булмады түгел. Бүген Мәскәү тарафыннан федератив мөнәсәбәтләрне актив рәвештә «сүтү» тормышка ашырылганда, ТАССР тарихы, аның тәҗрибәсенең хәзерге вазгыять өчен бик мөһим икәнлеге калку күренде. Чөнки ТАССРны оештыру 1917-1920 елларда татар әйдәманнарының милли дәүләтчелек өчен тырышуларына большевикларның җавабы иде, ул исә Русия составында татарларның үз хокуклары өчен көрәшенә, милли азатлык хәрәкәтенә алып чыга, аннан инде урта гасыр дәүләтчелек традицияләре күренә.

Кызганычка каршы, Русиядә гражданлык җәмгыяте юк. Аның иң мөһим шартларының берсе булып кануннарның үтәлеше тора. Милли республикаларның статусы турында дәүләт Конституциясендә төгәл язылган. Кызганычка каршы, ул һәрвакытта да сакланмый. Юкса әлеге сорау бирелмәгән булыр иде. Бер сүз белән әйткәндә, гражданлык җәмгыятенең формалашуында федератив мөнәсәбәтләрнең ныгуы яки йомшавы мөһим роль уйный. Күптән түгел «Бизнес-онлайн»да Русия Президенты администрациясендә эшләгән Глеб Павловский белән әңгәмә басылды. Аны укыгач, без эчке сәясәттәге бик күп нәрсәне белмибез икән дигән фикер кала.

**Ленар Гобәйдуллин:**

– Халкыбыз 1552 елда бәйсезлеген югалтканнан бирле, һәрвакыт дәүләтчелек, азатлык идеяләре белән янган. Мәгълүм ки, Октябрь революциясе һәм Гражданнар сугышы елларында большевикларның бәйсезлек турындагы вәгъдәләре ялган була. Илне чын мәгънәсендә федератив мөнәсәбәткә коручы Идел-Урал штаты, Татар-Башкорт Республикалары төзү турындагы идеяләр чәлпәрәмә килеп, 1920 елда татар халкының бер өлеше генә яшәгән җирдә автономияле республика төзелә. ТАССРда Кәшшаф Мохтәров ХКС рәисе итеп сайлап куелганнан соң гына, тарихчы Рәмзи Вәлиев язуынча, 1921 елның 25 июнендә рәсми рәвештә республикада икетеллелек игълан ителә, татар һәм рус телләре дәүләт теле статусын ала. Моның өстенә, 1552 елда Казан һәм Идел-Чулман буйларыннан куылган татарларны тиз арада башкала янына, зур елга-юллар тирәсенә кайтару, татар яшьләрен югары уку йортларына тарту, дәүләт оешмаларына җәлеп итү кебек гамәлләр кылына. Татарстанда нәкъ менә шул вакытта Академүзәк төзелә, татар халкының тарихы яңадан языла башлый, рус кешеләре дә татар телен өйрәнергә керешә, күпсанлы фәнни-популяр әдәбият татар теленә тәрҗемә ителә. Нәкъ тә 1921-1923 елларда Кәшшаф Мохтәров хакимияттә булган вакытны чын мәгънәсендә суверен дәүләтчелек чоры, дип атарга мөмкин булыр иде. Соңыннан хокуклар кысылганнан кысыла, республика гап-гади автономиягә әйләнеп кала. Бу еллардагы тарихи вазгыять белән танышканда, ирексездән, 1990 елларны искә төшерәсең...

**Илфак Ибраһимов:**

*– Октябрь революциясенең төп казанышы – федерализм – дәүләт төзелеше формасы буларак, исеме җисеменә туры киләме? Федерализмның чагылышы булып Үзәк белән килешү дә яңартылмады... Татарстан Рәсәйнең «дәүләт тимерчелеге» булуын дәвам итә. Әлбәттә... Спорт башкаласы да шул ул...*

**Индус Таһиров:**

– Кайвакыт большевикларны Россияне федератив дәүләт итеп игълан итүдә гаеплиләр. Ләкин Учредительное собраниенең үзенең большевиклар тарафыннан куылу сәгатенә кадәр Россияне федератив дәүләт дип игълан иткәнлегенә игътибар бирелми.

Большевиклар исә федерациягә күчү карарын тик чарасызлыктан вакытлы гамәл рәвешендә генә кабул итә. Моның шулай икәнлеген аңлау өчен, Сталинның 1917

елның мартында язылган һәм 1924 елда өстәмәләр белән кабат бастырылган «Против федерации» исемле мәкаләсен уку да җитә. Анда федерация юлына басуның мәҗбүри вакытлы чара, инде тарала башлаган илне саклап калуга гына юнәлтелгәнлегә ярылып ята. Дөрес, Ленин үзенең соңгы көннәрендә федерация вакытлы чара түгел, ә илнең яшәү рәвеше икәнлегенә инана. Ләкин Сталин элеккеге фикерендә кала һәм, Ленин үлгәннән соң, акрынлап федерациянең җисемен җуеп, исемен генә калдыру юлына баса. Ә бит Мирсәет Солтангалиев 1924 елда ук, әгәр дә шушы сәясәт дәвам итсә, бүгенге СССР рәвешендәге Россиянең гомере кыска булыр, ул таркалачак, ди. Шулай булды да. Сталинның дәвамчылары әлеге башлангычны ахырына кадәр җиткерә. 1991 елның декабрендә СССР юкка чыкты.

Бүгенге Россияне дә шушы юлдан алып баралар. Россия тик кәгазьдә генә федерация. Ул – унитар, власть вертикале белән яши торган дәүләт. Аның нинди рәвештә федератив дәүләт икәнлеген тик Мәскәүнең 2007 елда Татарстан белән төзегән Шартнамәсеннән генә абайлап була иде. Хәзер ул да гамәлдән чыкты.

Әлеге Шартнамә Татарстан өчен бернинди икътисади өстенлекләр дә бирми. Ул – тик тарихта һәм бүгенге көндә үсә барган татар факторын тану билгесе генә иде. Күрәсең, бүген бу факторның, Татарстанның уңышларыннан көнләшүчеләр бардыр. Бар, бар! Һәм аларның саны кимеми. Ләкин татарлар, кем әйтмешли, тарихта чыныккан, эшсөяр халык. Безнең уңышлар Татарстанда гына түгел, татар яшәгән башка җирләрдә дә арта торачак. Татарстан Россиягә исән-имин калу юлларын күрсәтә тора. Аны алга алып баручы, башкаларны үз артыннан әйдәүче көч – ул нининдидер рәвештә язылган яки язылмаган Шартнамәләр түгел, ә татар канына сеңгән дәүләти көч һәм бетмәс-төкәнмәс куәт.

**Илдус Заһидуллин:**

– В.И.Ленин, элекке империя халыкларына үзбилгеләнү хокукы вәгъдә итеп кенә, таркалып киткән илне кабат җыя алды. Федерация – совет дәүләте төзелгән заманда яңа хакимият белән төрле милләт лидерлары арасындагы килешү иде. Аның нигезенә төрле гасырларда Русия составына кергән халыкларның яңа шартларда, яңа форматта үзләренең милли һәм мәдәни ихтыяҗларын тормышка ашыру фикере салынган. СССР таркалгач, Федерация составында калган халыкларның күпчелеге, Кавказ халыкларыннан кала, урта гасырларда бергә тупланган булган. Бу халыкларның, татарлардан аермалы буларак, урта гасырларда милли дәүләтчелек традициясе булмаган. Әлеге үзенчәлек хокуклар өчен көрәшкә тәэсир итми калмый.

СССР заманында милли республикалар хокуклары ягыннан берничә төркемгә бүленә иде. Союздаш, автономияле республикалар, милли өлкәләр һ.б. Федералистик мөнәсәбәтләр унбиш союздаш республика арасында күзәтелгәндер, мөгаен. Хәер, коммунистлар партиясе күзәтүе астында аларда да хилафлыклар юк түгел иде. Шул союздаш республикаларның берсе – чынлыкта иң зурысы һәм көчлесе булган РСФСРда мөнәсәбәтләр бик көчле үзәкләштерелгән иде. ТАССРның үз конституциясе булса да, чынлыкта барлык мәсьәләләр Мәскәү белән килештерелә иде. Менә шул Бөек Ватан сугышына кадәр үк калыплашкан, үзәккә буйсынуга корылган мөнәсәбәтләрне, СССР таркалгач, Русия Федерациясендә Татарстан суверенитет елларында үзгәртә башлаган иде. Үз конституциясен кабул итеп, федераль үзәк белән вәкаләтләрне бүлешү хакында килешү төзеп. Кызганычка каршы, бүген ул казанышларны югалта барабыз. Мәскәү Федерацияне, ачыктан-ачык әйткәндә, «сүтә». Әйтик, һәр субъектның халкының үз җитәкчесен үзе сайлап кую хокукы бозыла.

**Илфак Ибраһимов:**

*– Бүген элеккеге СССР дәүләтләреннән бүленеп чыккан ил-дәүләтләр арасында үзара бәйләнешләр барса да, телләр сакланышы – мәгариф өлкәсендә олы каршылыклар килеп чыкты. Украина-Россия буенча гына түгел... Әнә Казакъстанда да латин графикасына күчәләр. Рәсәйнең үзендә милли телләрне фән буларак укыту мөмкинлеге ни дәрәҗәгә төште? Бу мәсьәләдә нинди чишелешләр булыр?*

**Рафаэль Хәкимов:**

– Тел турында күп сөйләнде. Сөйлибез дә сөйлибез. Беренчедән, без декларация кабул иткәндә, анда бөтен сәясәтнең нигезенә яткан ике төп мәсьәлә бар иде. Берсен, «татар теле рус теле белән тигез булырга тиеш», дип, татарлар куйды. Икенче мәсьәләне, «Мәскәү белән Шартнамә булырга тиеш», дип, руслар тәкъдим итте. Бүгенге сәясәтнең нигезендә дә шул ята. Бу мәсьәләләргә кагылмасак, яхшы булыр иде, әмма барып чыкмый. Латин графикасын кире кактылар. Үзебезнекеләр дә әллә ни тырышмады. Латин графикасына килгәндә, минем фикер ул бер, ә эти, татар телен бик яхшы белүче һәм өч графикада да эшләгән, иҗат иткән кеше буларак, «безгә – татарга иң уңайлысы латин», дип әйтә иде. Ул фикергә таянып, барыбер шуңа кайтабыз инде. Кызганычка каршы, хәзер Шартнамә дә юк, телне дә кире кагалар.

Әлбәттә, хафаландыра. 90нчы елларда, бүгенге көн белән чагыштырсак, җиңел түгел иде. Әмма, аяк терәп, вазифабызны үтәмичә кайтмый идек. Без эшләгәндә, Мәскәүдән фәкать вәкаләтләребезне, хокукларыбызны танытып кайта идек. Уртак тел таптык.

Бер яктан, безнең татар халкы төрле оешмаларга, бюрократиягә ышанды. Бюрократиянең ни эшкә кирәген аңлау мөһим. Үз мәнфәгатеңне онытсаң, нигә аны Мәскәү танырга тиеш. Сәясәттә син яхшы, ләббәйкә булып, килешүгә ирешмисең. Үз мәнфәгатьләреңне яклый башлагач кына, сине таныйлар.

**Илфак Ибраһимов:**

*– Татар телен саклап калуга ышаныч бармы?*

**Рафаэль Хәкимов:**

– Ышаныч бар, ышаныч нәрсәдә?! Татар халкына әйтсәң, ул, дәүләт эшләргә тиеш, ди. Бу совет чорыннан шулай калган. Ә мин әлеге мәсьәләгә киңрәк карыйм. Глобализация процессы бара. Ул урысны да басып китә. Урыс глобализациясе булу мөмкин түгел. Андый нәрсә, гомумән, юк. Англо-саксонныкы бар, инглиз теле әле ул калып өчен гадирәк. Шундый тел белән Америка мәнфәгатьләре басып бара. Игътибар итик, Шотландия, Уэльс, Ирландия Британиянең үзәгендә утыра. Алар үз телен инде оныткан иде. Мәсәлән, Шотландиядә туган телендә сөйләшүче ике-өч авыл гына калган иде, Уэльста бераз күбрәк. Ирландиядә ирланд телен белә торганнар ике процент калган иде. Алар хәзер үз телләрен кайтаруга ныклап керește. Уэльс – Төньяк Ирландия – бу яктан иң алда. Һәм уңышлы эш итәләр. Ун-унбиш ел элек миңа аларның бер сәясәтчесе үз уңышларының серен, телевидение, радио ничек эшләргә тиешлеген аңлаткан иде. Анда син инглизме, шотландмы, барыбер мәктәптә алар телендә укырга тиеш. Шуңа күрә өмет бар, чөнки әлеге күренеш Европада да башланды инде. Каталония әкренләп үз теленә кайта. Бүген нәрсә булса да, алар үз фикерен әйтте. Аларның эшләре бүген барып чыкмаса, иртәгә барып чыгачак. Андый юнәлеш тә бар.

**Индус Таһиров:**

– СССР таркалгач, мөстәкыйль дәүләтләргә әверелгән элеккеге союздаш республикалар зур тырышлык белән телләрен гамәлләштерү юлына басты. Аларның күбесендә үз телләре бердәнбер дәүләт теленә әверелде. Кайберләрендә, мәсәлән, Украинада, әлеге хәл тирәсендә шактый зур низаглар барлыкка килде.

Татарстан үзенең дәүләт суверенлыгы Декларациясен кабул иткән көннәрдә шулай ук тел турындагы бәхәсләр туды. Бу документның төп вариантында татар теле бердәнбер дәүләт теле итеп күрсәтелгән иде. Ләкин, аңлашу барлыкка килеп, кабул ителгән Декларациядә татар һәм рус телләре тигез хокуклы дәүләт телләре рәвешендә язылды. Һәм бу Конституциядә ныгытылды.

Шулай булуга да карамастан, Россия Конституциясендә дә республикалар үз дәүләт телләрен билгеләргә хаклы дип язылган булса да, илдә бу хактагы низагларның туктаганы юк.

Россия Президенты В.В.Путин күптән түгел Йошкар-Олада булып үткән киңәшмәдәге чыгышында: «Рус булмаган телләрне көчләп укытырга кирәкми», – диде. Моңа тулы аңлатма бирмәгәнлектән, Башкортстан Җитәкчесе Рөстәм Хәмитов, республика мәктәпләрендә башкорт теле укытылмаска тиеш, дигән карар кабул итте. Бу республикада зур ризасызлыклар тудырды.

Татарстан Язучылары, Путин исеменә хат кабул итеп, Президентның рус телен генә түгел, татар телен саклау да аның конституцион бурычы икәнлеген ассызыклады. Анда мондый сүзләр бар: «Сезне Россия Федерациясе республикалары телләренең яшәвен тәэмин итүдә Конституция һәм законнарда каралган хокуклардан бөтен тулылыгында файдалану мөмкинлеген калдырырга чакырабыз». Чыннан да, Путин бит руслар Президенты гына түгел, русларны гына, аларның телләрен генә якларга тиеш түгел. Ул илдәге барлык халыкларның исән-имин яшәвенә гарант булырга тиеш. Язучылар үзләренең хатында аның игътибарын нәкъ менә шуңа юнәлтте.

Чынында телнең иң ышанычлы сакчысы тик халкыбыз үзе генә икәнлеген онытмыйк.

**Илдус Заһидуллин:**

– Милли мәдәният, милли мәгариф, алфавит, туган тел мәсьәләсе Русия империясендә дә, СССРда да сәяси фактор иде. Бүгенге Русиядә дә бу «традиция» дәвам итә.

**Ленар Гобәйдуллин:**

– Латин графикасына күчми калуыбыз, бәлки, хәерлегә генәдер. Графика – язма мирасның коды, аның ачкычы. 1920 елларда гарәп имлясыннан ваз кичү халкыбызны меңьеллык әдәби мирастан аерды. 1990 елларда латин графикасына күчү дә 70 еллык совет чоры әдәби мирасыннан аерган булыр иде, шуның өстенә юньләп татарча белмәгәннәр бу язудагы мәгълүматны укып торыр идеме икән? Хәзерге компьютер программалары – онлайн-транслитерлар кириллицада язылган текстны берничә секунд эчендә башка графикага аударып бирүен истә тотсак, латинга рәсми рәвештә күчүнең зарурлыгы үзеннән-үзе юкка чыга.

Соңгы вакытта берничә тел белүнең зарурлыгы, аның кирәклеге, телләр белгәннең илләр гизүе турында «акыллы фикерләр» еш әйтелә. Әмма бер нәрсәне оныттылар: урыс кешесе татар телен белеп нәрсә ота? Татарстанда яшәгән урыска татар телен белү кирәкме? Ул аны мәҗбүри өйрәнерә тиешме?

Татар телен белү кирәклеге хакында акыл сатканчы, иң әүвәл, аңа ихтыяҗны булдырырга кирәк. Әйтик, Дәүләт Советы һәм башка идарә органнарында чыгышларның кимендә нигә яртысын татарча гына сөйләмәскә, дәүләт эшенә фәкать ике телне дә белгән кешеләрне алырга, эш кәгазьләрен татарча язарга, урамда, кибетләрдә татар телле мохит тудырырга. Телне укытуны мәҗбүри итүдән бигрәк, урта кул түрәләргә, дәүләт хезмәткәрләренә аны белүне таләп итәргә кирәк, элмә такталар һәм башка мәгълүмат чыганакларын икетелле итү шарт. Менә шуннан соң гына башка милләт кешесе, дөрестән дә, миңа татар теле кирәк була, дип өйрәнер иде. Югыйсә кулланылыштан төшеп калган телне, башка милләт кешесенең түгел, татарның үзенең дә өйрәнәсе килмәс.

Икенчедән, шәһәрдәге татар баласына, башка предметлар рус телендә укытылуын истә тотсак, атнага 5-6 сәгать туган тел дә аз. Эш бит санда түгел, сыйфатта. Иң мөһиме – укыту методикасы камил булсын. Чит телләрне берничә айда да өйрәнүне вәгъдә итә торган методикалар бар, укучы өчен стимул, мотивация генә кирәк. Югыйсә, ун ел мәктәптә укып, туган телен ипилек-тозлык та белмәгән үз татарларыбыз да бихисап. Хәер, телне укыту методикасына килгәндә, урыс телен укыту да татар теленекеннән әллә ни аерылмый бугай.

Тел ул – дәүләтчелек символы. Дәүләт теле икән, аны уку да мәҗбүри булырга тиеш. Әмма телебезгә, татар теленә ихтыяҗ һәм кызыксыну тудырмыйбыз икән, аны башка халыклар беркайчан да өйрәнмәячәк. Җырлый-җырлый, кунакларга

йөри-йөри, татар телен бетерәчәкбез, ә аның артыннан дәүләт тә, милләт тә юкка чыгачак...

Моннан нәкъ йөз ел элек Россиядә зур вакыйга – Беренче Бөтенроссия мөселман съезды уза. Корылтайның «Мәдәният вә мәгариф эшләре хакында»гы бүлекчәсендәге карарда: «Ибтидаи (башлангыч) мәктәпләрдә уку теле һәр кабиләнең үз ана телендә булыр. Урта мәктәпләрдә гомуми төрек телен дәрес итеп укыту мәҗбүри булыр. Гали (югары) мәктәпләрдә уку теле төрек-татар кабиләләре өчен гомуми булган төрек теле булыр», – дип язылган. Әгәр дә бу карарлар шул чорда ук гамәлгә ашса, аңа революция комачауламаса, бөтенләй башка вазгыятьтә яшәр идек. Мәгълүм ки, татар теле халыкара аралашу, сәүдә, дипломатия теле булып, башка төрки телләр аеруча Урта Азиягә чыгу өчен ачкыч булып торган. Дөньяда Урта Азия халыкларының, казакъ, бигрәк тә үзбәкләрнең саны елдан-ел артып бара, алар Россиягә дә бик теләп үтеп керә. Киләчәктә дөнья алар кулына калырга да мөмкин, шул очракта, бәлки, татар теленә дә ихтыяҗ булыр.

**Илфак Ибраһимов:**

*– Октябрь революциясенең иң олы казанышлары булып Икенче Бөтендөнья сугышында СССРның җиңеп чыгуы аерып күрсәтелде. СССР – тынычлык терәге иде. Баксаң, СССР һәм Рәсәй, үз иминлеген тәэмин итү өчен, туктаусыз коралланырга мәҗбүр... Үз иминлеген саклап калу өчен, хәтта чит континентларда «сугыш чукмарлары»н, «террорчылар»ны бастырырга дучар. Бу хәлләр илне тәмам көчсезләндереп, халыкның яшәү дәрәҗәсен киметеп, социаль киеренкелек китереп чыгарса, яңа түнтәрелешләргә сәбәпче булмасмы?*

**Индус Таһиров:**

– Октябрь революциясен СССРның Икенче Бөтендөнья сугышында җиңеп чыгуына төп сәбәп итеп карау дөрес түгел. Әлбәттә, аның хәрби экономика булдыруда йогынтысы булмады түгел, булды. Ләкин бу инде, әйткәнемчә, халыкның кан-яше белән башкарылды. СССР революциянең беренче көннәреннән үк сугышка әзерләнә килде. Бүгенге Россия дә нindидер рәвештә шул эшне дәвам итә.

Ләкин, СССР никадәр генә әзерләнгән булса да, дошман Мәскәү капкасына кадәр килеп җитте, Ленинградка, Сталинградка куркыныч тудырды. Сугышның беренче көнендә үк дошман авиациясе, аэродромнарны бомбага тотып, 1200 самолётны юк итте. Танк һәм башка сугыш кораллары да шундый ук югалтуларга дучар булдылар.

Сугыш елларында ил үзенең 20 миллионнан артык кешесен югалтты. Берничә армия камалышта калды, миллионлаган солдат һәм офицер әсирлеккә төште. Уңышсызлыкларның сәбәбе – җитәкчелектә, бигрәк тә Сталинда. Ә менә ике фронтка сугыш алып барган Германия сугышта нибары 9,5 миллион кешесен генә югалта. Җиңүнең төп сәбәбе – халык. Моны һичничек тә онытырга ярамый.

СССР сугышка кадәр дә, аннан соң да тынычлык терәге була алмады. Бүгенге Россия дә андый терәк булудан ерак тора.

**Илфак Ибраһимов:**

*– Социал-демократия, сәясәт буларак, бүген ни дәрәҗәдә актуаль?*

**Индус Таһиров:**

– Социал-демократиягә бер төрле бәя биреп булмый. Россия социал-демократлары, большевик һәм меньшевиклар тарих күгеннән юкка чыктылар. Алар алга сөргән идеаллар чәлпәрәмә килде. Көнбатыш илләрендә алар пыскып булса да яшәп килә, заман таләпләренә буйсынып, сәяси тормышка үз өлешләрен кертә тора.

Ә менә үзләрен социал-демократлар дип санаган «Справедливая Россия»

вәкилләре социал һәм милли гаделлек идеалларыннан бик ерак тора, гамәлләре дә властька яраклашкан оппозиция булудан гына гыйбарәт. Алар Татарстан белән Россия арасындагы Шартнамәгә һәрвакыт каршы була килде. Шартнамәне озайтмауда да аларның куллары уйнады.

Гомумән, социал-демократиянең җыры җырланды. Бүген аңа берәү дә мохтаҗ түгел.

**Рафаэль Хәкимов:**

– Әлеге мәсьәлә беренче Госдумада ук куела. Аны мөселманнар да, Балтыйк буе депутатлары да революциягә хәтле үк күтәрә, ягъни революция буламы-юкмы, мәсьәлә туган була. Шуңа күрә, алдарак Ленин турында искәртелгәнчә, ул заманның бөтен көчле партияләре социализмны яклый. Патшаны кайтарырга, дигән акларны яклаучылар да була. Керенский киткәч, власть, гомумән, калмый. «Власть урамда аунап ята», дигән төшенчә яши ул вакытта. Аны кемдер үз кулына алырга тиеш була. Большевиклар алар күпчелекне тәшкил итми, сектага тиңләнелгән кечкенә генә бер партия хасил итәләр. Ләкин алар яхшы оешкан һәм көчле прагматик була. Әлеге вазгыятьтә без Ленинның уңай ягын нидә күрәбез соң? Ул, әүвәл Федерациягә каршы чыкса да, соңрак аның уңай якларын таба. Эсерлардан «Җир – халыкка» шигарен алган кебек, халык нәрсә теләсә, шуны барлык партияләрдән «чүпләгән», сизгер булган. «Бүген әле иртәрәк, берсекөнгә соң булыр. Революцияне иртәгә башлыйбыз!» – дип, вакытны да төгәл сайлаган. Шул мизгелне табып, ситуацияне үз кулыңа алу – бу гениальлек. Теориядә андый нәрсә язылмый.

**Илфак Ибраһимов:**

*– Дөнья үсеше барышында Татарстанны, татар халкын ниләр көтә? Тагын чирек гасырдан илебездәге вазгыятьне сез ничек күзаллыйсыз?*

**Индус Таһиров:**

– Татарлар – утны-суны кичкән, тарихта чыныккан халык.

Билгеле ки, большевиклар властька интернационализм байрагы астында килә. Милләтләрне бетерүне, аларны диннәреннән яздыруны төп максатларының берсе итеп билгели. Шуның нәтиҗәсендә, татар тормышыннан аны 1552 елдан соңгы фаҗигале елларда коткарып һәм саклап калган Ислам китә. Мәчетләр ябыла, муллалар куыла, дингә турылыклы калучыларга көн бетә. Ә бу исә татарның исәниминлегенә куркыныч тудыра, катнаш никахлар арта, милләтебезнең руслашуына юл ачыла.

Киң колач алган әлеге процесс тик СССР таркалгач кына кими. Ләкин әле һич кенә дә бетте дияргә урын юк. Динебез үз урынына кайту юнәлешендә. Акрынлап ата-бабаларыбызның безгә васыяти рәвештә калдырган иманыбызга кайту юлына чыктык. Тик әле барысы да шәп, дип әйтеп булмый. Чөнки дин нигезләрен җимерү җиңел булган булса да, аны аякка бастыру хезмәте авырдан-авыр. Әйтергә кирәк, бу эш шактый уңышлы бара.

Дөнья үсешендә Татарстанның роле, гомумән, татар факторы, бернигә дә карамастан, арткannан-арта барачак. Татарның дәүләтчелеге аякка басачак. Татар халкын тулы хокуклы яшәү көтә.

Чирек гасыр эчендә Россия үзе дә, зур үзгәрешләр кичереп, чын мәгънәсендәге демократик федератив дәүләткә әвереләчәк. Без моның шулай булуын телибез, чөнки аңа альтернатива – тик таркалу гына.

**Ленар Гобәйдуллин:**

– Бүгенге дөньяда бик кызыклы үзгәрешләр бара, аларның кая килеп чыгачагы Казаннан күренми.

Бүгенге көндә хакимияткә дә, илебез халыкларына да көчле дәүләт кирәк, шушы фикер җәмгыятебезне берләштерә дип уйлыйм. Татарлар өчен дә бу мөһим. Чөнки суверенитет елларында республикабыз хакимияте, бирелгән мөмкинлекләрдән файдаланып, Татарстанны икътисади яктан чын мәгънәсендә алдынгы республика

итү юлында халык баглаган өметне аклый алмады, суверенитет идеясенә хилафлык китерде, аннары чигенә-чигенә, ахыр чиктә халыкның ышанычын югалтты. Шуңа күрә тагын кризис чокырына төшмәскә иде.

**Рафаэль Хәкимов:**

– Без яшибез әле. Икътисад бүгенге көндә безнең таяныч. Суверенлык дигәндә, аны аңларга кирәк. 90нчы елларда аның бер мәгънәсе бар иде. Бераздан бөтен дөньяда суверенлык төшенчәсе нык үзгәрде. Рәсәйдә генә ул һаман XVIII гасырдан торып фикер йөртәләр, уйланалар. Мәсәлән, Кыргызстанны карасаң, ул суверен, ул ООНда утыра. Икътисадын алсаң – Татарстан белән чагыштырып буламы, юкмы? Казакъстанга килсәк, Путин бер әйткән иде бит, аның элек дәүләте булмады, дип. Ул – хафалана башлады, Алтын Урда – безнең дәүләт, диеп, Казакъ ханлыгын искә төшереп, һәм шундук бөтен хәрби көчен ныгытырга тотынды. Татарстанга килеп, нәрсә белән булыша аласыз, дип. Мөстәкыйльлек әле икътисадтан да тора. Татарстан, Аллага шөкер, үсеп бара. Европага һәм Азиягә чыгара торган юллар булса, тагын да көчәер идек. Безнең икътисад бөтен Рәсәйгә тәэсир итә. Күршеләр белән чагыштырганда, бүген, әлбәттә, башка регионнарны үзенә тарта.

Татарның бер начар, бер яхшы ягы бар. Заманында Франциядә бер илле татар җыелды да оешырга уйлады, талашып бетеп, ике партиягә бүленде һәм ике Сабантуй уздырды. Татар кая җыелса да – күмәкләшә, аннан сүзгә килеп бүленә һәм, нәтиҗәдә, һәркайсы үзенчә «сабантуй уздыра». Урыста юк бит ул. Урыс, Европадамы, Америкадамы, ничектер югала. Татар өчен үсәргә территориаль чикләр комачауламый. Бигрәк тә интернет заманында.

Без китаплар чыгарабыз, радио, телевидение эшли. Үткән ел Татарстанның алты районында социологик тикшерү уздырдык. Татар яшьләре белән сораштыру үткәрдек. Нәтиҗә, кызганыч: яшьләр газета-журнал, китап укымый, телевизор күбесенең өендә юк, булганы да аны карамый, караса да, анда сөйләнгән мәгълүматка ышанмый. Барысы да интернет, социаль челтәрләр белән мавыга, гаджетлар куллана. Шуңа күрә безнең ел әйләнәсенә чыгарылган иллеләп яхшы китап яшьләр тарафыннан укылмый дигән сүз. Без өч телдә «Татар тарихы» дигән 16 минутлык ролик чыгардык. Бүгенге көндә аны ярты миллион кеше карады. Көнгә ике мең кеше карый. Аны ютюбка керткәнгә әле өч ай да узмады. Күпчелек бу роликны яшьләр карый: 60 % 25 яшькә хәтле яшьләр. Кайсы илләрнең роликны ни дәрәҗәдә үз итүен дә анализладык. Мисалга, Азәрбайҗан хуплый, Германия һәм Белоруссия каршы. Шул якка авышмасак, без яшьләрне югалтабыз.

**Индус Таһиров:**

– Кайбер татарлар телен оныткан булса да, аның эчке дөньясында бар ул татарлык. Шуны саклау – безнең максат.

**Илфак Ибраһимов:**

– *«Түгәрәк өстәл»дә катнашуыгыз һәм тулы җавапларыгыз өчен зур рәхмәт!*

*Миләүшә Закирова – 1989 елның 26 августында Казанда туа. 2006 елда 68нче татар-рус гимназиясен көмеш медаль белән тәмамлый. Уку вакытында татар теле, әдәбияты буенча олимпиадаларда катнашып, татар әдәбиятыннан республика күләмендә алдынгы урыннарны яулый. 2006-2011 елларда КДУның (хәзерге КФУ) социология бүлеген кызыл диплом белән тәмамлый. Университетта алман телен дә өйрәнә, аспирантурага керә. Аспирантурада укыган вакытта төрле социологик тикшеренүләрдә, конференцияләрдә катнаша. Шигырьләрендә – фәлсәфи фикерләү, тормыш турында уйланулар, яшь кешенең үз-үзен эзләү тематикасы.*



Миләүшә
Закирова

# КҮПСЕНМӘСЕН КҮКЛӘР ГЕНӘ...

***

Миллионлы шәһәремдә
Миллион йөз чагыла.
Шул йөзләрнең барчасыннан
Берсе бик якын миңа.

Меңәрләгән машиналар
Тыз да быз чабып тора.
Җанга уелган санлысын
Күзләрем табып тора.

Йөзәрләгән таш биналар
Чатлары, почмаклары...
Һәркайсының бар күңелдә
Сакланырдай чаклары.

Бихисап исем-дәшүләр –
Ишетүем сак минем.
Берсен-бердәнберен генә
Күңелемдә саклыймын.

Миллионнан да, дистәдән дә
Табыла эзләгәне…
«Яратам!» – дип дәшсен иде
Өметем өзмәгәне...

***

Без –
Аллаһ тарафыннан
Бер тамчыдан шытым биргән
Кечкенәдән кечкенәрәк
Адәм бөртекләре –
Бәндәләр генә...
Безгә хаталану, ялгышу хас.
Безгә
Вак нәрсәләргә кубып борчылу,
Белми торып сәбәбен дә,
Соралмаганда бәя бирү,
Искәрми әдәп, әхлак таләбен дә,
Үзебезгә үзебезнең
Игътибар үзәге булу хас.

Кайчак
Тезгенне нык тоталмыйбыз,
Хис ташкынын тыялмыйбыз,
Ашыгып-кабаланып абынабыз,
Алдын-артын күрми атлыгабыз,
Әйтегезче,
Кайсы бабабыздан бу мирас?

Юкса,
Аллаһ Тәгалә каршында
Кечкенти генә кешеләрбез...
Әгәр үзебезгә үзебез
Хаклык күзеннән карарга
Өйрәнсәк,
Бәлки, бераз зураербыз?

***

Белмим
Бүтәннәр ничек яшәгәнен,
Аларның кайда, ничек йөргәнен,
Нинди уй, тойгы кичергәнен,
Бары сизенәм генә...

Дөньяда
Нинди мәхшәр, мәсхәрәләр булганын,
Цунамилар купканын,
Кешелек тарган шатлык-кайгыларын
Мин белмим әлегә...

Почмаклар,
Юллар чатында ни көткәнен,
Төнге йолдызлар ни дип күз кысканын,
Ачы җилләр нигә елавын,
Яфракларның тын пышылдавын –
Аптырамагыз белмәвемә.

Анык беләм, шөкер:
Үткәнемә кайтырга һич теләмәгәнемне,
Беләм тик синең белән бүгеннән
Бәхетледән дә бәхетле икәнемне!..
Күпсенмәсен күкләр генә...

***

Бар да кирәк бу тормышта:
Акыл үстерер өчен,
Гыйбрәтле хәл алу өчен,
Тәкатең артсын өчен,
Сын-рухың ныгысын өчен –
Бар да кирәк бу тормышта.

Көтелмәгән очрашу.
Кинәт кавышу.
Бер-берен табышу.
Кирәкме?
Кирәк!

Туктаусыз гәпләшү.
Эчкерсез сөйләшү.
Күңел ачып көлешү.
Кирәкме?
Кирәк!

Нужа чигү.
Ачы яшьләр түгү.
Билләр бөгү.
Кирәкме?
Кирәк!

Ялгышу, хаталану,
Абынып егылу,
Аннан кабат торып,
Яңа юллар ачу.
Кирәкме?
Кирәк!

Саташу.
Югалып калу.
Адашу.
Ә соңрак
Аңына килү.
Кирәкме?
Кирәк!

Каядыр ашыгу.
Каядыр соңга калу.
Каядыр иртәрәк булу.
Кирәкме?
Кирәк!

Бар да кирәк бу тормышта:
Акыл үстерер өчен,
Гыйбрәтле хәл алу өчен,
Тәкатең артсын өчен,
Сын-рухың ныгысын өчен –
Бар да кирәк бу тормышта.

Кирәкми тик
Акылыңны җую.
Яшәешнең ямен кире кагу,
Зарарлы шөгыльгә алыну,
Хыянәт упкынына чуму –
Кирәкми берүк.

***

Иркәләп, сыйпап,
Сөеп, назлап,
Күңелемнең кайсы кылларын
Тибрәттең син?
Тәнемнең кайсы авазларын
Таныдың син?

Көлеп, елап,
Күккә ашып,
Йөрдем мин
Җир өстеннән,

Йөздем мин
Күл өстеннән.

Көйдем, яндым,
Бардым, таптым.
Югалтуның ни икәнен
Тагын татыдым.


Эзләндем, хафаландым,
Сабыр иткәч, аңладым:
Табышымның җимешен,
Тормышымның җисемен.



*СССР Язучыларының V съезды делегатлары һәм кунаклары Кремльнең Георгий залында. Сулдан уңга В.Синев, Г.Рәхим, И.Юзеев, Г.Ахунов, З.Нури, Ш.Рәкыйпов, Р.Фәйзуллин, М.Вәлиев (КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре), И.Гази, С.Хәким, Р.Харис, Г.Бәширов, Р.Мостафин. 1971 ел.*



*Казанга Чыңгыз Айтматов килгәч. Сулдан уңга: Гариф Ахунов, Рәшит Гарипов һәм Чыңгыз Айтматов. 1972 ел.*



*Язучы, публицист, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Ф.Хөсни исемендәге әдәби премия лауреаты Равил Вәлиев. Күптән түгел аңа 75 яшь тулды.*



*Үткән гасыр аксакаллары. Сулдан уңга: Әмирхан Еники, Гомәр Бәширов, Шәйхи Маннур. 80 нче еллар.*

*Сәхифәне* **Равил ФӘЙЗУЛЛИН** *әзерләде.*

# КҮҢЕЛЕМ ЯКТЫРТКЫЧЫ



Кояш Тимбикова. Исем-фамилиясе генә дә ни тора бит, андый бүтән юктыр, мөгаен. «Азат хатын» журналының иң күп таралган еллары турында сүз чыкса, гадәттә, иң беренче итеп аның исемен атыйлар. Аңа өстәп – Диләрә Зөбәерова, иң соңыннан – Мәдинә Маликова.

Безне «журналның өч йолдызы» дип атаучылар да булды. Минем карашымча, Кояш арабыздан иң яктысы гына түгел, иң бәхетлесе дә иде. Укытучы гаиләсендә туган, яхшы укыган, университетка бик җиңел кергән, диплом алгач ук, журналга әдәби хезмәткәр булып эшкә урнашкан. Моннан да зур бәхетнең булуы мөмкинме? Хатын-кыз журналист өчен иң уңайлы, иң күренекле эш урыны иде бу. Монда иҗат өчен бөтен мөмкинлекләр бар иде. Язмаларың йөз меңнәрчә укучыларга барып ирешә.

Кояштан аермалы буларак, мин бу редакциягә авырлык беләнрәк, соңарыбрак килдем: институтны тәмамлагач, «Чаян» журналы редакциясендә корректор булып утырырга, аннары ике ел «Азат хатын»да килешү буенча эшләп йөрергә туры килде. Кояшның исеме ул чорда, чыннан да, йолдыз булып балкый иде инде. Яшькә миннән кечерәк булса да, мин аңа башымны чөеп, дигәндәй, үрелеп һәм сокланып карый идем.

Бергә эшли башлагач, без якынаеп, дуслашып киттек. Бик яхшы хәтеремдә, Кояшның Фатыйма Ильская турындагы «Ник сагынам икән?» дигән очеркы басылып чыккач, редакторыбыз Асия Фәридовна Хәсәнова аны барыбыз өчен дә үрнәк итеп куйган иде. Без ярыша-ярыша каләмнәребезне чарладык, мәкаләләр белән генә чикләнмичә, хикәяләр яздык, аннары, батыраеп, күләмлерәк әсәрләргә – повестьларга тотындык. Өлкән язучылар безне үсендереп торды, китапларыбыз басылып чыкты. Өчебез дә Язучылар берлегенә кабул ителдек.

Журналда эш җитәрлек. Хикәя-повестьлар язу «өйгә кайткач»ка кала иде. Кояш кырык ел рухланып, очынып иҗат итте. Аның «Сөлге булсын бүләгем», «Шикәр Гайшә», «Таяныч», «Ут» һәм башка бик күп хикәяләрен, «Тәңкәле тау», «Кышкы талпыну», «Табылдык хатлар сере» кебек повестьларын укучылар яратып кабул итте. Ихлас күңелдән, оста каләм белән язылганнар иде шул алар. Аның дистәдән артык китабы басылып чыкты, әсәрләре рус, украин, белорус, үзбәк, кыргыз, латыш һәм башка телләргә тәрҗемә ителде. Балалар өчен дә язды ул, аның сүзләренә язылган җырлар сәхнәләрдән, радиодан яңгырады. Әле тагын матур әсәрләре белән безне куандырган булыр иде, кызганыч, гомере иртәрәк өзелде, алтмыш алты яшендә ул безнең арабыздан китте...

Ә әсәрләре яши, күпләрнең күңелен җылыта. Бигрәк тә туган ягында – Чистай районында аның истәлеген кадерләп саклыйлар. Туган авылы Наратлы Елгада музее бар. Мәктәпләрдә әсәрләре өйрәнелә. Ел саен Чистай шәһәрендә Россиянең һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Хөсәен Ямашев исемендәге премия лауреаты Кояш Тимбикованың иҗатына багышлап кичәләр уздырыла, яшь талантларга аның исемендәге премияләр бирелә. Әсәрләре укылган вакытта язучы яши, диләр. Кояш Тимбикова татар әдәбияты тарихына якты сәхифә язып калдырды, шул ук вакытта ул бүген дә исән, заман язучылары белән бер рәттә кебек.

Ә минем өчен ул – газиз кеше. Бүтән андый дустым булмады һәм инде булмас та. Без озак еллар икебез бер бүлмәдә утырып эшләдек. Кояшның шәхси тормышы үз вакытында җайга салынган: студент чакта ук Рейн Ганиев белән танышып, яратышып, гаилә корганнар, матур гына яшәп яталар иде. Минем баштан исә төрле хәлләр узды: ирем белән бозылыштык, аерылышуга кадәр барып җиттек. Андый чакта якын дустың, сердәшең булу бик кирәк бит ул. Мин тормыш хәлләрен китаплардан укыганнан чыгып бәялим, халыкча әйткәндә, «күңел күктә, арт сан чүптә» (халык аны үтемлерәк итеп

әйтә). Кояш исә бу дөньяга ачык күз белән карый, кемнең кемлеген таный, яшәеш әвәрәләрен аңлый иде. Аның бик күп сүзләре минем хәтеремә гомерлеккә уелып калды. «Син аннан ул булдыра алмаганны таләп итәсең», – дигән иде ул ирем турында. Аның бу сүзләре мине уйга калдырды: чыннан да шулай булган икән бит. «Син зур эшләрне ерып чыгасың, ә вак мәсьәләләрдә абынасың», – дигән иде Кояш икенче бервакыт: «Беренче күргән кешегә ышанып бетмә, эч серләреңне түкмә, – дигән иде. – Соңыннан аның начар якларын күреп көенергә туры килмәс, киресенчә, яхшы якларын күреп сөенерсең». Хак иде шул аның сүзләре! Акыл иясе иде минем дустым Кояш. Һәм игелек иясе. «Яхшылык эшлә дә суга сал», – ди торган иде ул. Ягъни, кылган яхшылыгыңа игелек белән җавап бирерләр, дип көтеп йөрмә, савабын да өмет итмә. Булдыра алганыңны эшлә дә оныт. Мин моны аңламый идем: әҗере дә, савабы да булмагач, нәрсә өчен әле кырык эшеңне кырык якка ташлап, кеше гамен кайгыртып йөрергә? Соңыннан гына аңладым: Кояш мәрхәмәтле иде, игелек кылудан тәм таба иде.

Безнең редакциягә көн саен бик күп хатлар килә иде. Хатын-кызлардан гына түгел, ир-атлардан да. Әлбәттә инде без аларга җавапларны күңелләрен китмәслек итеп язарга тырыша идек. Бу эштә Кояш аеруча өлгер булды – хат кулга керүгә, җавабын яза. Төрмәдә утыручы бер адәмгә бу бик ошап китте, күрәсең, ул Кояшның җавабына җавап язды, тагын ниндидер сораулар бирде... Кыскасы, хат алыша башлады болар. «Андагы кешегә юанычкирәк шул», – ди иде Кояш. Еллар буе дәвам итте бу. Ниһаять, теге адәм тиздән иреккә чыгачагын хәбәр итте: «Рөхсәт итсәң, туры синең янга кайтыр идем», – дип тә өстәгән иде хатында. «Бик әйбәт булыр, – дип җавап бирде моңа Кояш. – Ирем зур акыл иясе, файдалы киңәшләрен бирер». Аңарчы ире барлыгын язарга ничектер бик җай чыкмаган икән. Килгән теге адәм, Рейнның акыллы сүзләрен тыңлаган, күңеле хушланган, каен тузыннан ясалган бик матур ваза белән кружкалар бүләк иткән. Кояш аларны шкафының киштәсендә саклый иде.

Берзаман шагыйрә Саҗидә Сөләйманова авырып китте. Кояш, аның хәлен җиңеләйтергә тырышып, бик күп көч куйды: хастаханәгә тәмле ризыклар пешереп илтү кирәкме, керләрен юып илтүме, даруларын табып бирүме – һәммәсен эшләде ул. Ә бит болай караганда, Саҗидә аңа кардәш тә, якын дус та түгел, безнең журналның редколлегия әгъзасы гына иде.

Кояшның әнисе Сания апа гомеренең соңгы елларын нәкъ менә шушы кызы тәрбиясендә, аның фатирында үткәрде – дүрт бала арасыннан аны сайлады. Абыйсы Азат – Ватан сугышы ветераны, хатыны вафат булып, үзе каты авырып киткәч, шулай ук Кояш янына күченде, аның кулында булды.

Кояшның шәхсән миңа кылган яхшылыкларын санап бетергесез. Бергә командировкаларда йөргәндә, авыр юллар узганда, мин һәрвакыт аның ышыгында булдым. Без бакча кишәрлекләрен дә янәшәдән алган идек. Берзаман кечкенә улыбыз салкын күлгә төшкән, аңарчы да тамагы авыртып йөри иде, нишләргә дә белмибез. Шунда бер чиләк кайнар су күтәреп Кояш килеп керде. «Аягын тыгып утырсын», – ди. Әйтмәгән дә идек, каян күргән, каян башына килгән, кай арада суын җылытып өлгергән диген!


Ә бервакыт мин бик зур ыгы-зыгыга эләктем: редакция фатирымны дөрес бирмәгән, дип таптылар һәм мине балам белән урамга куып чыгару эшенә керештеләр. Бу эшнең башында республиканың иң зур түрәләреннән берсе тора иде. Аңа каршы чыгу һич мөмкин түгел иде кебек. Ә менә Кояш тапты чарасын. Кайсыдыр районга командировкага баргач, ул Татарстан Югары Советы Президиумы Рәисе Салих Батыев белән танышып, сөйләшеп йөргән икән. Тотты да кабул итүен үтенеп шалтыратты бу аңа. Казан Кремленә бөтен редакция белән бардык. Батыев хәлемә керде, миңа каршы эшне туктатты. Хәзерге көнгә кадәр мин Кояш саклап калган торак мәйданында яшим.

Бу дөньяда бернәрсә дә үзгәрешсез тормый, шул исәптән дуслык та. Араларның бик җылы чаклары булган кебек, суынып киткән вакытлары да була. Кояшны хатын-кыз язучы өчен иң дәрәҗәле урынга – «Казан утлары» журналына җаваплы сәркатип итеп эшкә чакырдылар. Ә мин, яшь бала анасы булып, гаилә мәшәкатьләренә чумдым. Очрашулар сирәгәйде, серләшү мөмкинлекләре кимеде. Аның үлеме дә минем өчен башка таш төшкәндәй һич көтмәгәндә булды...

Бер танышым, Кояшны искә алгач: «Елмаюы бик матур иде», – диде һәм үзе дә елмаеп җибәрде. Аны искә алган саен, минем дә күңелем яктырып китә.

**Мәдинә МАЛИКОВА**

*Зиннур Насыйбуллин 1937 елның 12 ноябрендә Башкортстанның хәзерге Нуриман районы Кече Теңкәш авылында колхозчы гаиләсендә туган. 1956-1958 елларда Совет армиясендә хезмәт итә. 1964-1966 елларда – Башкорт дәүләт университеты студенты. 1967 елда университетның читтән торып уку бүлегенә күчә, башта Башкортстанның район газеталарында әдәби хезмәткәр, аннары Уфада Башкортстан радиокомитетында редактор булып эшли. 1969 елда Казанга килә һәм – Казан радиокомитетында редактор хезмәтен башкара.*



*Шагыйрьнең сугыш вакытына туры килгән авыр балачак һәм яшьлек мәхәббәте темаларына багышланган лирик шигырьләре «Тәлгәш», «Гамьнәр илендә» исемле җыентыкларына тупланган. Ул 1979 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы. 1986 елның 8 гыйнварында вафат була.*

Зиннур
Насыйбуллин

# МОҢНАР БЕЛӘН ШУҢА ЧИГЕЛГӘН

## Туган тел

Синдә – шатлык җиңеллеге,
Кайгылар авырлыгы,
Ата-бабам батырлыгы,
Аналар сабырлыгы.

Синдә – күңелләр киңлеге,
Туган җирем ямьнәре;
Синдә – илем иркенлеге,
Синдә – дөнья гамьнәре.

Югалтмыйсың, туган телем,
Сине югалтканны да,
Син алып чыктың дөньяга
Синнән баш тартканны да.

Сиңа тел тидергәннең дә
Телен син ачкан идең,
Ана булып, бишегенең
Янына баскан идең;
Сиңа кырын караганның
Күзен син ачкан идең.

Рухыбыздан табылган тел,
Тагылган тел түгел син,
Тар юлларда тигәнәктәй
Сарылган тел түгел син.

Көлү теле, елау теле
Уртак, диярләр. Беләм.
Ләкин татарча елыйм мин,
Татар телендә көләм.

## Гамьнәр илендә

Сәяхәтләр кылып хозурлану,
Илләр гизү насыйп булмады;
Җаным гына һаман юлда булды,
Эзләнүдән аһым тынмады.

Бу тормышны күпме яратсам да,
Бернине дә җиңел бирмәде.
Тапмый калмый ләкин ир-егетнең:
«Табам!» – диеп җилкән киергәне.

Шатлыкларым булса, һәр бөртеген
Табып кайттым Кайгы иленнән.
Нәкышләре шуңа сагышлырак,
Моңнар белән шуңа чигелгән.

Сөюем бар – Югалтулар дигән
Упкын аша кирәк үтәргә.
Йөрәгендә сөю булган кеше
Юл газабын җиңел күтәрә.

Уңышларым булса, менеп алдым
Эзләнүләр, Еллар тавыннан.
Ышанычым минем шул юллардан
Җәяү килгән чакта табылган.

Тынгысызлык һаман алга дәшә.
Ил хәстәрен салып иңемә,
Ваемсызлык иленә тукталмыйча,
Килеп кердем Гамьнәр иленә.

## Шик

Гомер буе сине уйладым мин,
Гомер буе сиңа гашыйкмын.
Гомер буе сине эзләдем мин,
Гомер буе сиңа ашыктым.

Һәрнәрсәне синең белән башлап,
Синең исем белән башкардым.
Синдер, диеп, сине сөям, диеп,
«Син»ен сөйдем ялгыш башканың.

Урау иде сиңа барыр юлым,
Җиңел юллар булды – китмәдем:
Сайладым мин, әкияттәге кебек,
Иң авырын – сиңа илткәнен.

Көч җитмәсне син дип күтәрдем мин,
Егылганда, син дип калкындым.
Син дип җиңдем җиде каршылыкны,
Уртасыннан үттем ялкынның.

Син, дидем мин, куәт кирәк булса,
Өметемне өзгән көнемдә.

Һәм, ниһаять, хәлсез юлчы кебек
Торам синең ишек төбеңдә.

Тик ачасы гына...
Ләкин мине
Ышанычым тагын ташлады.
Ачармын да... очратмаммы соң мин
Сине түгел, тагын башканы?

***

Һәр агачның җирдә тарихы бар,
Үткәне бар, килер көне бар;
Кошлар гынамыни сайрый белә,
Һәр яфракның өне-теле бар.

Һәрбер чәчәк сөя, сөелә дә,
Тууына җиргә сөенә.
Яшел шатлык булып туган яфрак
Сары сагыш булып сибелә.

Һәрбер сынган ботак ыңгыраша,
Һәр тапталган үлән сызлана.
Һәрбер чишмә көлә челтерәтеп,
Әйтерсең лә наян кыз бала.

...Табигатьтә наз да, куәт тә бар,
Тик кешесез ятим барыбер;
Шуңа күрә зәңгәр күлләр күзе
Өмет белән безгә карыйдыр.

## Яшәү өчен!

Бу гомерем өчен мин муеннан
Бурычлыдыр сиңа, ихтимал,
И табигать, нигә бу кадәр үк
Аяусыз соң синең ихтыяр?

Ничә миллиард еллык хезмәтеңнең,
И табигать, кая кадере?
Кеше өчен шушы туфрак – ана,
Шушы туфрак – аның кабере...

Җан өргәнсең безгә, аң биргәнсең,
Җир йөзенә хаким иткәнсең;
Тик дөньяга килгән һәр кешеңне
Үлемгә дә хөкем иткәнсең.

Тик һәр гомер – мәңгелеккә тамчы,
Ташлар тишеп килә тамасым.
Үлемсезлек бирмәсәң дә,
фәкать
Үлем өчен тудырмагансың.

Язгы ташкын булып, ташып, тулып,
Яшәү көче кайный күңелдә;
Аңым, җаным, эшем – яшәү өчен,
Тәнем генә калыр үлемгә.

# ГАЛИМӘ АЧКАН ДӨНЬЯЛАР



Кеше аңы, күзаллавы шулайдыр, күрәсең: ераграк тарихка мөрәҗәгать итәргә, күптән үткән хәлләрне хәтердә тергезергә, бездән гасырлар аерып торган күренекле шәхесләрне зурларга яратабыз. Бәлки, бу замана вакыйгаларының һәм кешеләренең әле хәтеребездә булуы белән бәйледер. Бәлки, Тукай әйткәнчә, чын бәяне куяр өчен, вакыт сынавын узу мәҗбүридер...

Ничек кенә булмасын, бу сыйфат безне бай тарихыбыз, элгәреләр тәҗрибәсе, үткәннәрнең кадерле ядкарьләре һәм кыйммәтләре белән тоташтыра, акыллы һәм зәвыклы, хисле һәм намуслы – Кеше булуыбызны искәртә!

Әмма бер үк вакытта үз замандашларыбыз, безнең белән бер үк һаваны сулап, бер үк урамнарда йөрүчеләр, аларның бәһаләп бетергесез эш-гамәлләре күләгәдәрәк кала. Хезмәтләренә бәя бирү, ачышларын күрсәтү, шәхесләрен зурлау тиешле дәрәҗәдә дә булып бетми... Шуңа күрә юбилейлар-бәйрәмнәр вакытында булса да тормыш-яшәешебезнең төрле өлкәләрендә яңа юллар ачкан, фикер офыкларын киңәйткән кешеләр хакында иркенрәк сөйлисе, аларның казанышларын барлыйсы килә.

Бу көннәрдә 85 яшен тутыручы хөрмәтле Резеда Кадыйр кызы Ганиева да шундыйлардан. Университет профессоры, күп шәкертләрнең акыллы һәм ярдәмчел остазы, олы галимә... Татар әдәбияты белемендә үзенең хезмәтләре белән яңа киңлекләргә юл ачкан фикер иясе!

Каюм Насыйриның якташы, Шырдан авылы кызы Резеда 1958 елда Казан дәүләт университетын тәмамлый. Мәскәү университетының СССР халыклары әдәбияты кафедрасында кандидатлык диссертациясе әзерли. 1963 елдан төбәгебезнең күренекле уку йорты – Казан университетында студентларга белем бирә башлый. Гомерен шәрык мәдәниятен өйрәнүгә багышлый.

Соңгы фикердә ялгышлык юк! Чыннан да, Резеда Кадыйровна шәрык мәдәнияте дигән очсыз-кырыйсыз өлкә буенча тирән белемле һәм мәгълүматлы белгеч, галимә булып таныла. Студентларга гарәп, төрек, фарсы, төрекмән, үзбәк, казакъ, азәрбайҗан һ.б. әдәбиятлар тарихын, шул әдәбиятларның классик язучылары иҗаты буенча белем бирә. Исламга кадәрге, мәҗүси чорлардан алып мөселман халыклары сәнгатен хәзерге көннәргә җиткереп тоташтыра – мең елдан артыкка сузылган тарихны иңләп ала. Тирән белеме, мәгълүматлылыгы, хисле-көйле сөйләү рәвеше белән бик күпләрне шушы сихри дөньяга алып керә, фәнгә тарта.

Күп халыкларның иҗади фикерләвен, фәлсәфәсен, дөньяга карашын, тарихын һәм мәдәниятен яхшы белгән галимә шул фонда, шул мирас яктылыгында шәрык әдәбиятларының татар әдәбияты белән бәйләнешләре мәсьәләсен махсус, тирәнтен өйрәнә. Нәтиҗәдә, шәрык, төрки-татар әдәбиятларындагы үсеш-үзгәреш, алгарыш-барышны бербөтен итеп карау мөмкинлеге туа. Р.К.Ганиева татар халкының үз тарихында ике тапкыр яңарыш, Ренессанс чорын кичерүе хакында тәгълимат тәкъдим итә. Беренчесе – Урта гасырларда, Болгар, Алтын Урда дәүләтләре чәчәк аткан чорда, икенчесе XIX-XX гасырлар чигендә, Ш.Мәрҗаниләр, К.Насыйрилар башлаган мәгърифәтчелек хәрәкәтеннән күтәрелә.

Шушы тәгълимат нигезендә галимә фәнни һәм педагогик эшчәнлегендә татар әдәбиятының тулы тарихын колачлап ала. Алай гына да түгел, аның тарафыннан шәркый яңарыш Европадагы Ренессанс белән тоташтырыла, фәндә шәркый әдәбиятларга карата озак еллар хөкем сөргән европоцентрик ялгыш карашларны кире кагуга һәм бу әдәбиятлардагы фәлсәфи байлык-тирәнлекне, эстетик нәфислекне, иҗади алымнар төрлелеген бөтенлекле система итеп карауга юл ачыла. Үз чиратында, татар әдәбиятындагы рухи-иҗади күтәрелеш үзбәк, азәрбайҗан, казакъ, уйгыр, төрекмән һ.б. халыклар әдәбиятларындагы, Алтай, Үзәк Азия, Каспий һ.б. тирәлекләрдәге мәдәниятләр белән бер үремтәдә тикшерелә, ягъни уртак шәркый Ренессансның татар, уйгыр, төрек һ.б. вариантлары турында сүз алып барыла. Мондый киңлек, масштаблылык галимәгә татар әдәбиятын дөнья мәдәнияте югарылыгында карау, бер үк вакытта милли мәдәниятебезнең шушы контекстта асыл сыйфатларын, хасиятләрен бөртекләп барлау мөмкинлеге бирә.

Урта гасырларда Гаребтә генә түгел, Шәрыкта да әдәбият-сәнгать, мәдәният гаять көчле күтәрелеш чорын кичерә диюче галимә Йосыф Баласагунлының «Котадгу белек», Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» кебек җәүһәрләрнең нәкъ менә шушы яңарыш хәрәкәтенең шаһитләре булуын ассызыклый. Аларны Европа Ренессансының гүзәл үрнәкләре белән тигез куеп бәяли. 1970-1980 еллар әдәбият белеме фәне өчен стандарт булмаган мондый караш милли мәдәниятнең югары дәрәҗәсен билгеләүгә, ассызыклауга хезмәт итә.

Р.К.Ганиеваның «Проблемы творческих методов в тюркоязычных литературах» (1976), «Төрки әдәбиятларда иҗат методы мәсьәләләре» (1979), «Восточный Ренессанс и поэт Кул Гали» (1988) кебек эзләнүләре шәркый романтизм күренешен, дини-суфичыл фәлсәфә һәм күзаллауларны урта гасырлар төрки, татар әдәбиятлары тарихына кайтарган, урнаштырган беренче хезмәтләрдән була. Аларда Урта гасырлар татар әдәбиятында матурлык категориясе, акыл һәм мәхәббәт, тән һәм рух проблемасы, антропоцентризм, Илаһият фәлсәфәсе, бигрәк тә бераллалык (әт-Тәүхид) фәнни проблема югарылыгында үзәккә куела. Озак вакытлар гуманитар фәннәр караш түгәрәгеннән читтә калдырылып килгән суфичылык татар мәдәниятенә зур йогынты ясаган фикри һәм эстетик күренеш буларак аерып чыгарыла. Галимә тарафыннан Кол Галидән башланган традицияләрнең Мөхәммәдьяр, Мәүла Колый, Габдерәхим Утыз Имәни һ.б. иҗатларында дәвам иттерелеше күзәтелә.

Күп еллар буе шушы юнәлештә алып барган тикшеренүләренең нәтиҗәсе итеп, 1992 елда Р.К.Ганиева «Шәркый ренессанс һәм төрки әдәбиятларда аның традицияләре» дигән темага докторлык диссертациясен уңышлы яклый. Хезмәт фәндәге урта гасырлар төрки-татар әдәбиятларына карашны үзгәртүгә юл ача: аларның үз, Европа әдәбиятларыннан аермалы иҗади фикерләү юлы булуын, шул юлда гаять зур сәнгати югарылыкка ирешүләрен дәлилли. «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә тәкъдим ителгән сурәтлелекне, төсләр, саннар, символларны да колачлаган үзенчәлекле образлар системасын, фәлсәфи-эстетик карашларны анализлау бу юнәлештә эшләгән галимнәрнең фикер-карашларын үстереп, поэмага яңача якын килү мөмкинлеге бирә. Сәнгатьтә канунчылык төрки әдәбиятлар өчен чикләү түгел, бәлки, киресенчә, традицион нигездә яңалыкны күрсәтүнең иң катлаулы һәм нечкә мөмкинлекләрен эзләргә мәҗбүр иткән иҗат принцибы итеп карала. Шул ук вакытта канунның үзгәреше эзеннән барыла. Әйтик, кануни алым – характерларда һәм детальләрдәге нечкәлек, ым-ишарәләр ярдәмендә сурәт тудыру, ягъни нюанслылык Кол Гали әсәрендә ничек кулланылганлык һәм аннан соңгы әдәбиятта (хәтта совет әдәбиятында, М.Гафури, М.Җәлил, Х.Туфан иҗатларында) нинди үзгәрешләр кичереп күчә баруы тикшерелә. Шул рәвешле, шәркый традицияләрнең бүгенге милли әдәбиятыбызга кадәр килеп җитүе исбатлана һәм шушы озын юл тулысынча иңләп күзәтелә.

Әлбәттә, галимәнең бу юнәлештәге ачышларының барысын да сөйләп бетерү мөмкин түгел. Шулай да алар арасында гуманитар фәннәр үсешенә зур йогынты ясаган аерым берләрен бәяләү мәгъкуль. Мәсәлән, Р.К.Ганиева – төрки әдәбиятларда һәм татар әдәбиятында шәркый романтизм методының кулланылыш даирәсен билгеләп, гасырлар дәвамында туа торган йөзләгән әдәби күренешләр мисалында тирәнтен анализлаган,

методның әйдәп баручы урынын кабат фәнни әйләнешкә кайтарган әдәбиятчылардан. Ул шәркый романтизмның татар әдәбиятында XIX гасыр ахырына кадәр яшәвен һәм әдәби барышны әйдәп баруын, мәгърифәтчелек хәрәкәте белән мәйданга чыккан яңа дөньяви әдәбиятка олы тәэсир итүен, аннары Европа тибындагы романтизм һәм реализм формалашуга җирлек булып хезмәт итүен күрсәтә. Бу фикерләрнең әдәбият белемендә барлык иҗат итү рәвешен реализм дигән баш астына урнаштырып, романтизмны буржуаз метод буларак кире кагу тәэсиреннән котылу омтылышлары гына ясала башлаган бер вакытта әйтелүен дә аерып искәртергә кирәк. Әлеге идеяләр татар әдәбияты тарихын үз традицияләре һәм заман алып килгән яңалыклар белән тәңгәл үсеш-үзгәреш кичерә торган, нинди генә сәяси-иҗтимагый шартларда да үз эчке закончалыкларын югалтмаган һәм башка мәдәниятләрдән калышмыйча үсеп барган бөтенлекле система итеп күзаллау ныгу-урнашуга хезмәт итә.

Беренче милли яңарыш казанышларын галимә XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар дөньясындагы рухи-мәдәни, сәяси-иҗтимагый күтәрелеш белән чагыштыра. Г.Тукай, С.Рәмиев, Н.Думави, Ф.Әмирхан, Г.Исхакый, Г.Ибраһимов иҗатлары белән янәшә Мирза Шәфи Вазих, Абай Кунанбаев, Н.Нариманов һ.б. төрки язучылар әсәрләренә мөрәҗәгать итә. Шушы материалда XX гасыр башында кайбер төрки әдәбиятларда, шул исәптән татар әдәбиятында да зур алгарыш, сикереш ясалганлык дәлилләнә. Шуның сәбәпләре, алшартлары, төп вәкилләре, аларның эшчәнлеге һәм иҗатлары, алгарыш нәтиҗәсендә барлыкка килгән өр-яңа күренешләр, гомумән, галимә гыйльми тикшеренүләренә хас булганча, колачлап алына.

Р.К.Ганиева XX гасыр башы татар әдәбияты белән әле аспирант вакытта ук шөгыльләнә башлый. 1964 елда якланган кандидатлык диссертациясе Г.Тукай иҗатында сатира мәсьәләсенә багышланган була. Бөек шагыйребез иҗатына югары бәя биреп, галимә сатираның Тукайда дөньяга караш һәм әдәбиятның максатын аңлау рәвеше дә, шул ук вакытта иҗади фикерләү һәм әдәби алымнар системасы да булуын исбатлый. Мондый зур фикерне дәлилләү өчен, татар әдәбиятында урта гасырларда, XIX гасыр әдипләре иҗатында тәнкыйди башлангычның үзенчәлекләре ачыклана. Шул вакытта ук татар мәдәниятендә үзенчәлекле көлү формалары, чаралары барлыкка килү билгеләнә. Тукай иҗатындагы юмористик, сатирик әсәрләр (алар шагыйрь иҗатының яртысыннан артыгын алып тора) җентекле тикшерелеп, алардагы фикер тирәнлеге, алымнар төрлелеге, жанрлар байлыгы күзәтелә.

Беренче хезмәтеннән соң Тукай иҗаты Р.К.Ганиеваның гомерлек темасына әйләнә, дисәк, ялгыш булмас. Галимә «Тукайның иҗат методы» (1972), «Наследие Тукая и тюркские литературы» (1979), «Габдулла Тукайның башлангыч чор иҗатында Шәрык һәм Гареб традицияләре» (2002), «Габдулла Тукай в контексте мировой литературы» (2006), «Габдулла Тукай иҗатында төрек мотивлары» кебек күпсанлы хезмәтләрендә бу иҗатны дөнья әдәби-мәдәни багланышлары, гарәп, фарсы, Европа һәм рус, төрки (башкорт, кыргыз, казакъ, үзбәк, төрекмән, каракалпак, комык) әдәбиятлар контекстында тикшерә. Тукай иҗатын нигез итеп алып, төрки әдәбиятларда иҗат методларының дүрт төре формалашуны дәлилли: татар һәм азәрбайҗан әдәбиятларында Европа тибындагы романтизм һәм реализмның тигез үсеш алуы; казакъ, үзбәк, комык әдәбиятларында мәгърифәтчелек реализмының өстенлекле булуы; чуваш әдәбиятында романтизм һәм мәгърифәтчелек, тәнкыйди реализмның синтезы күзәтелү; кыргыз, төрекмән әдәбиятларында фольклор традицияләренең саклануы шундыйлардан.

«Тукай иҗатын өйрәнү юлында» (2002) дип исемләнгән күләмле мәкаләдә галимә Тукай феномены, аны барлыкка китергән шартлар хакында уйлана. Шагыйрь иҗатын ул бөтен төрки-татар иҗади фикерләве тарихына шушы тарихның өзелмәвен тәэмин иткән кыйммәтле каптырма рәвешендә урнаштыра: «Тукай шигъриятенең тамырлары бик тә тирәнгә – татар халкының фольклорына, борынгы төрки дәвергә, мөселман мәдәниятенең Яңарыш сәхифәләрен ачып җибәргән изге Коръәнгә, Алланың барлыгын һәм берлеген таныган, югары әхлак кагыйдәләренә өндәгән дини-суфичыл әдәбиятка, кешенең акылын һәм хисләрен олылаган дөньяви эчтәлекле Ренессанс әсәрләренә, аларның гасырлар дәвамында чарланып килгән сәнгатьчә фикерләү кануннарына барып тоташа. Элгәргедән – төрки нигездән һәм Шәрыктан килгән тамырларның нык булуы,

аны Ауропа һәм рус әдәбиятлары йогынтысында яңа хасиятләр белән баетып җибәрү Тукайга XX гасыр башындагы татар Яңарыш әдәбиятының нигез ташларын салу, аны чын мәгънәсендә милли әдәбият итеп үстереп җибәрү өчен зур иҗади мөмкинлекләр ачты». Менә шундый киң контекстта Тукай – милли шагыйрь, халык шагыйре, татар дөньяви әдәбиятына нигез салучыларның берсе буларак бәяләнә.

2002 елда Р.К.Ганиеваның «Шагыйрьнең рухи дөньясы» исемле хезмәте дөнья күрә. Анда Тукайның 24 әсәренә XXI гасыр фәне югарылыгында анализ ясалып, аларда шагыйрьнең ислам диненә, суфичылыкка, төрки традицияләргә мөнәсәбәтләре дә калку билгеләнә. Тукай әсәрләре мисалында XX йөз башының күренекле язучылары иҗатын комплекслы, заманча бәяләү методикасы тәкъдим ителә.

Галимә бу юнәлештә эзләнүләрен бүген дә дәвам итә. 2016 елда дөнья күргән Габдулла Тукай энциклопедиясенең бик күп материаллары, бу фәнни теманың иң аз өйрәнелгән, иң четерекле мәсьәләләре турында язмалар аның тарафыннан әзерләнүен аерып әйтергә кирәк.

XX йөз башының күренекле фикер ияләре һәм иҗатчыларыннан Гаяз Исхакыйны кайтаруга да зур өлеш керткән шәхесләрдән ул. Аның югары уку йортлары студентлары өчен «Гаяз Исхакый иҗаты» (1998; 2005) исеме белән дөнья күргән программасы инкыйлабтан соң өзелеп калган гыйльми бәяне бүгенге көн белән ялгаучы, әдипнең исеме әйтелә генә башлаган бер чорда Исхакыйның милли-азатлык хәрәкәте вәкиле буларак дөньяга карашларын һәм иҗат баскычларын бербөтен итеп өйрәнүгә юл күрсәткән беренче хезмәтләрдән булды. Бу шәхеснең тормыш юлын, эшчәнлеген, инкыйлабка кадәрге әдәбият галимнәренең дә фикерләрен исәпкә алып, дүрт: мәгърифәтчелек (1897-1904); «таңчылык», социалистлык (1905-1910); милләтчелек (1910-1918) һәм мөһаҗирлек (1919-1954) дәверләренә бүлеп, галимә аларны берләштерүче үзәк төсендә милләт өчен җан атуын билгели. Әмма халкын бәхеткә илтә торган чара-ысулларны Исхакый төрле баскычта төрлечә күзаллый дигән нәтиҗәгә килә. Шушы дүрт чорга караган төп әдәби әсәрләренә анализ аша, әдипнең гаять бай иҗат дөньясын татар укучысына җиткерә. Алга таба, шул исәптән бүген – инде Исхакый иҗаты турында күп диссертацияләр яклангавннан, монографияләр басылганнан соң да, татар әдәбият белемендә әдипнең мирасы әлеге концепция нигезендә, хронологик баскычлар кысаларында өйрәнелә һәм үстерелә.

Р.К.Ганиева Гаяз Исхакыйның аерым әсәрләренә, үзенең һәм шәрык, һәм гареб әдәбиятыннан тирән белемен, мәгълүматларын файдаланып, комплекслы анализ ясый. Шундыйлардан, әйтик, әдипнең беренче һәм хәзерге көнгә кадәр тиешле бәясен алмаган әсәре «Тәгаллемдә – сәгадәт, яки Гыйлем үгрәнүдә – рәхәт гомер» хикәясе мисалында, аның басылып чыкканнан алып бүгенге көнгә кадәрге историографиясе, шәрехләнү рәвеше, аңа әдипнең үзенең һәм XX йөз башының күренекле тәнкыйтьче-галимнәренең карашлары, хикәянең татар әдәбияты тарихындагы һәм язучы иҗатындагы урыны, хәтта бүгенге укучыга тәкъдим ителеше дә тулы бер монографик тикшеренү рәвешен ала. Галимә хикәянең гыйлемне идеаллаштыру максаты куеп язылуын күрсәтә һәм аның идеясе ягыннан мөселман фәлсәфәсенә, шәрык әдәбиятына, Йосыф Баласагунлыларның «Котадгу белек»ләренә барып тоташуын ассызыклый. Шушы яссылыкта әсәрнең идея эчтәлегенә җентекле күзәтү ясала. Хикәянең төп герое Хәлимнең «милләтенә, халкына, кауменә» хезмәт итү теләге белән яшәвенә игътибар юнәлтә, әсәрдәге надан аталар, укымышлы аналар һәм белемгә омтылучы балалар конфликтын аерып чыгара, Хәлим идеалларының әсәр авторының ул чордагы идеаллары белән аваздашлыгын әйтә. Әсәрдәге ислам фәлсәфәсе белән тәңгәл фикерләр, шулай ук мәгърифәтчелек әдәбиятына хас алымнар күзәтелә. Галимә, шулай ук, кеше психологиясен табигать белән янәшәлектә сурәтләү, ягъни психологик параллелизм, эмоциональлекне көчәйтү чарасы буларак диалог-сөйләшү, монологлар, хатлар алмашу кебек алымнарны әсәрдә уңышлы кулланылган һәм алга таба язучы иҗатының асыл хасиятләре булып китәчәк сыйфатлар дәрәҗәсенә куя.

Хикәягә тулы, комплекслы анализ ясау белән чикләнмичә, Р.К.Ганиева тарафыннан аның төп тексты әсәрнең 1996 елда басылган кирил язуындагы журнал варианты һәм 15 томлыгына кертелгән варианты белән чагыштырыла. Бу гаять авыр һәм катлаулы

эшне башкарып, галимә текстның тәкъдим ителешендә калган хаталарны берәмтекләп күрсәтә, аларның дөрес вариантлары ничек булырга тиешлекне ачыклый. Шул рәвешле, бер хикәя мисалында һәм әдәбият галиме, һәм текстолог буларак чыгыш ясый.

Р.К.Ганиева тарафыннан Г.Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» повесте тулы анализланып, әсәрнең антиутопия жанр төренә каравы, төрки-татар әдәбиятлары тарихында беренче шундый әсәр булуы дәлилләнә. Бу әсәр мисалында да галимә аның идея-эчтәлек ягын, катлаулы сюжет-композициясе бирелешен, сурәтлелек байлыгын тикшерә, андагы ислам фәлсәфәсе дә, дин әһелләренә мөнәсәбәт тә, әдәбият, сәнгать, музыкага караш та, үткәнне идеаллаштыру максаты да, повестьның гомумән татар әдәбиятына ясаган искиткеч зур йогынтысы да ачыклана. Р.К.Ганиева аны «татар әдәбиятының үсеш юлларын билгеләүче программ әсәр», дип атый.

Башкарак характерлы әсәрләреннән, Г.Исхакыйның «Очрашу, яки Гөлгыйзар» повестенда Коръән өйрәтмәләренең тәэсире француз философы Бергсонның интуиция һәм Дарвинның табигый сайланыш тәгълиматлары, Ж.Ж.Руссо идеяләре белән үрелеп китү кебек моментлар игътибарга алына. «Алдым-бирдем», «Тартышу», «Мөгаллим» драмаларында, «Теләнче кыз» романында социалистик идеяләр бирелеше, «Тормышмы бу?» романында психологизм һәм лиризм алымнары аерып алып тикшерелә. Аеруча җентекле күзәтелгән «Зөләйха» трагедиясе, «Мөгаллимә» драмасы анализлары Исхакый иҗатына гына түгел, татар әдәбияты тарихындагы үзгәрешләргә дә яңача якын килүе белән хуплауга һәм мактауга лаек.

Р.К.Ганиева Исхакыйның Төркиядәге тормышы, мөһаҗирлек иҗаты белән дә махсус шөгыльләнә, бу юлда күп кенә фактик һәм аналитик материалларның мәдәниятебез тарихына кайтуына ярдәм итә.

Тукай кебек үк, галимәнең кабат-кабат әйләнеп кайтып, яңадан-яңа яклары белән укучыга, фәнни әйләнешкә, мәдәни хәзинәбезгә кайтара торган тагын бер шәхесе – Нәҗип Думави. Аның турында мәгълүматларны, иҗатын халыкка җиткерү белән Р.К.Ганиева 1983 елдан бирле шөгыльләнә: монографияләр, зур хезмәтләр, саллы мәкаләләр яза, әсәрләрен табып, гарәп графикасыннан кирилга күчерә, анализлый. Нәтиҗәдә, Думави – тирән белемле әдип-философ, дигән олы бәяне, бай әдәби-публицистик иҗаты татар әдәбияты-мәдәнияте тарихында лаеклы урынны ала.

XX йөз башы мәдәниятендә Р.К.Ганиева өйрәнгән, бәяләгән иҗатлар тулы бер плеяда хасил итә: С.Сүнчәләй, С.Рәмиев, Ш.Бабич, Ф.Туйкин, Г.Монасыйп һ.б. Алар арасында галимәгә аерата якын, аны кабат-кабат мөрәҗәгать итәргә, иҗатларының төрле сыйфатларын барларга мәҗбүр иткән әдипләр дип Ф.Әмирханны, Ш.Камалны, Г.Ибраһимовны күрсәтергә кирәк. Ф.Әмирхан шәхесенә, әйтик, галимә, Тукай кебек үк, аны формалаштыруда катнашкан бик күп факторларны анализлап якын килә. Нәтиҗәдә, әдипнең үзенең дә, гаиләсенең дә тулы культурологик рәсеме хасил була. Галимә фикеренчә, Ф.Әмирханның төп идеалы озак гомерләр дәвамында феодаль торгынлыкта яшәгән татар кешесен «хакыйкый европеец», абруйлы репутациягә ия шәхес итеп тәрбияләү була. Иҗатын исә шушы максатка буйсынган, XX йөз башы татар яңарышы хәрәкәтенең асыл сыйфатларын аеруча калку гәүдәләндергән дип саный. Язучының «Урталыкта» романына, «Тигезсезләр» психологик драмасына, «Фәтхулла хәзрәт» повестена яңача якын килүдә яки аның иҗатында романтизм методының әйдәп баруын билгеләүдә, «Хәят»ның саф романтизм үрнәге булуын дәлилләүдә, әдипнең модернизм юлында эзләнүләре чагылыш тапкан әсәрләренә («Татар кызы» һ.б.) мөнәсәбәттә дә Р.К.Ганиева хәлиткеч сүзне-бәяне әйтә. Шул рәвешле, XX йөз башы татар әдәбиятының төп юнәлешләрен, тенденцияләрен, таҗ әсәрләрен ачыклау ягыннан бүгенге әдәбият белеме фәнендә галимә тәкъдим иткән концепция урнашкан, яши һәм үстерелә дә.

Һәм бу концепция татар әдәбият белемен үстерүдә катнашып кына калмый, бәлки, гомумән, тюркология, төрки дөньяны өйрәнү масштабларына чыгып китә. Мәсәлән, галимәнең «Традиции Восточного Ренессанса в тюркских литературах Средневековья и Нового времени» *(Казань: изд-во «Фән» АН РТ, 2014. – 272 с.)* китабына туплап бирелгән гыйльми хезмәтләре арасында чуваш шагыйре Михаиль Сеспель һәм татар романтизм шигъриятенә, азәрбайҗан һәм татар әдәбиятларында Әфләтун

мәхәббәте концепциясенә, азәрбайҗан шагыйре Мирза Шәфи Вазих иҗатына, Абай иҗатында яңарыш традицияләренә, төрекмән классигы Мәхтүмколый һәм Мәүла Колый иҗатларында дини-мистик мотивларга, Мулла Панах Вагыйф лирикасына багышланганнары да бар. XX гасыр башы төрки әдәбиятларда иҗат методлары мәсьәләсенә махсус тукталып, шактый сандагы әдәби әсәрләрне өйрәнеп, галимә күп халыклар әдәбияты үрнәкләренең бер уртак олы юлга кушылган сукмаклар булуын ассызыклый.

Р.К.Ганиева – татар әдәбияты белемендә милли әдәбиятыбызның меңьеллык тарихын иҗат методлары, яңа күренешләр ягыннан колачлап, тулы бер күзаллау булдырган галимә. Реализм, романтизм, модернизм, хәтта постмодернизм юнәлешләре, аларның төрле агымнары, үзара мөнәсәбәтләре, кайсы язучылар иҗатларында, әсәрләрендә башлап күренүе, кайсы иҗатчылар тарафыннан үстерелүе мәсьәләләрендә, аның хезмәтләре юл ярып барды. Г.Исхакый, Ф.Әмирхан, Ш.Камал кебек классик язучылар иҗатлары мисалында яңа алымнарның милли әдәбиятыбызны баетуы, аның үсеш күрсәткечләреннән берсе булуы, татар әдәбиятының гареб һәм шәрык мәдәнияте хасиятләрен бер үремтәдә файдалану сыйфатлары аның хезмәтләрендә күп кенә мисалларда ачыклана һәм әдәби анализ үрнәкләрендә дәлилләнә.

Р.К.Ганиева – үз фәнни тикшеренүләре юнәлешендә – шәрык мәдәниятендә яңарыш хәрәкәте, әдәбиятта иҗат методлары, яңа күренешләр һәм әдәбиятара багланышлар өлкәсендә үз фәнни мәктәбен булдырган остаз. Аның җитәкчелегендә әзерләнгән докторлык һәм кандидатлык диссертацияләренең тематик киңлеге генә дә галимәнең никадәр колачлы тикшеренүләр алып баруы турында сөйли. Алар арасында урта гасыр татар әдәбиятында ислам фәлсәфәсенең чагылышы да, XX йөз башы татар әдәбият белемендә гарәп әдәбияты мәсьәләләре дә, Г.Тукай иҗатында дини мотивларны өйрәнү дә, Г.Исхакый, Х.Кайбышев, Г.Ибраһимов, Ф.Туйкин, С.Сүнчәләй һ.б. күп авторлар мирасы да бар. Ул укучылары белән бергәләп моңа кадәр өйрәнелмәгән катлаулы темаларга алынырга ярата, шул материалда яңа күзәтүләр ясап, шулай ук киләчәккә эшләү юллары сызып, аларны уңышлы башкарып та чыгалар.

Гомерен фәнгә багышлаган Резеда Кадыйр кызының, милләткә хезмәт итүне алга куеп, үзенең тикшеренүләр объектларын тирәнтен белеп һәм яратып эшләве күпсанлы ачышларга, гыйльми табышларга, казанышларга китерә. Ул алып барган тикшеренүләр мәйданы гаять киң, масштаблы булып, әдәбият белемендә генә түгел, мәдәниятләр тарихында да концептуаль, алга таба үстереләчәк зур фикер-тәгълиматлар таләп итүен, галимәнең үзенең исә фидакарьләрчә фән дөньясында янып яшәве белән башкаларны да үзенә җәлеп итү, ияртү, илһамландыру сәләтен, коллегаларының уңышларына ихластан куана белүен, укучыларына һәм фикердәшләренә теләсә кайсы ситуациядә ярдәмгә килергә әзер икәнлеген аңа хас сыйфатлар буларак аерып күрсәтергә кирәк.

Фәндә генә түгел, тормышта да киң күңелле, кунакчыл, ярдәмчел шәхес ул. Аспирантлары өчен генә түгел, диплом, курс эшләре әзерләүче студентлар өчен дә Резеда Кадыйровна һәм Зөфәр Зәйниевичларның ишеге һәрвакыт ачык булу, тәмле өчпочмак һәм пәрәмәчләр өстәлгә куелу хакында әдәбият фәне белән шөгыльләнүче һәркем белә: яки бу кунакчыл гаиләдә булган, яки шул хакта сөйләүләрне күп тапкырлар ишеткән. Әлеге ике зур галимне, Резеда апа белән Зөфәр абыйны, аларның фәндә яулаган биеклекләрен аерып карау да дөрес үк булмас иде. Көчле текстолог, тукайчы-галим Зөфәр Зәйниевич фәндә дә, тормышта да Резеда Кадыйровнаның таянычы да, фикердәше дә. Чын галимнәр, милләтебезнең асыл затлары гаиләсендә үскән уллары Булатның дөнья фәнендә уңышлары да Татарстанда мәгълүм, югары бәяләнә.

Бүгенге матур юбилей көннәрендә Татарстан фәнни җәмәгатьчелеге исеменнән Резеда Кадыйровнага сәламәтлек, күңел көрлеге, яңа сөенечләр һәм фәнни ачышлар телибез.

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,**
*филология фәннәре докторы, профессор*

# РУХИЯТ ЮГАРЫЛЫГЫНА ЧАКЫРУ

## ЛИРОН ХӘМИДУЛЛИНГА 85 ЯШЬ



Төрле әсәрләр җыелмасы буларак күзалланган матур әдәбият саф-төгәл жанрлар кысасында иҗат итүдән генә тормый. Аның гади укучы шәйләп бетерә алмаслык катлаулы хуҗалыгы бер-берсеннән аерылгысыз мөнәсәбәтләргә сулыш өргән бихисап вазифаны берләштерә. Сәнгать дөньясы тикмәгә генә зур мәйдандагы һөнәрханәгә тиңләнми. Биредә һәркем үзенчә хезмәт күрсәтә, һәркайсы үзара ярдәм кылырга тырыша. Мәдәни тормышның барлык тармакларын колачлап кайгырту нәтиҗәсендә генә рухи кыйммәтләрне ишәйтергә, тәгаенрәк әйткәндә, халыкның алга китеш дәрәҗәсен ачык чагылдырган әдәбиятны заманча югарылыкта тотарга мөмкин. Моның өчен исә сүз сәнгате үсешенә комплекслы караш, санап бетергесез мөһим бурычларны эзлекле төстә үтәү сорала.

Әдәби хәрәкәтнең табигыйлегенә ирешүгә күпләр дәвамлы өлеш керткән. Әйтик, Кол Галинең үлемсез «Кыйссаи Йосыф» поэмасын өйрәнү эшен башларга Габдерәхим Утыз Имәни кебек шагыйрьнең калкып чыгуы кирәк булган. Исеменә муафыйк юнәлештә ярларына тулып агуны дәгъвалаган милли әдәбиятыбыз, әйе, иҗадиятка кагылышлы әһәмиятле мәсьәләләрне күтәрерлек күпкырлы талантларга мохтаҗ иде. Шөкер, тора-бара андыйларга кытлык сизелмәде. Узган гасырда Габдулла Тукай, Галимҗан Ибраһимов, Гаяз Исхакыйлар язучылык чикләрен гамәли киңәйтүнең классик үрнәген калдырып китте. Ошбу исемлек озыная барды. Каләмен әүвәл хикәя һәм шигырьләр язып чыныктырган Гали Рәхим, Газиз Гобәйдуллин белән берлектә, моңарчы күрелмәгән «Татар әдәбияты тарихы» томлыкларын әзерләп бастырырга алына. Автордашының шөһрәт казанган тарих галиме, җәмәгать эшлеклесе булуы да гыйбрәтле. Үрнәк саналырдай мисаллар байтак.

Хәтерлим, Казан дәүләт университетында укыган елларда КПСС тарихы кафедрасы мөдире, профессор Рәфикъ Нәфыйков, әдәбият белеменә якынаеп, Габдулла Тукай тормышының әлегә ачылып бетмәгән якларын өйрәнү юнәлешендә ихластан канатланып йөрде. Әдәби үсешнең тулылыгын тәэмин итәр өчен мондый галимнәрнең дә тырышлыгы зарур иде. Әлеге олуг максатлар юлында татар китабы аша тарихыбызга яңадан-яңа сәхифәләр өстәгән Әбрар Кәримуллин, «әдәбият бакчасы»нда гаять бирелеп эшләгән Миркасыйм Госманов ише академикларның кирәклеге дә бәхәс уятмый. Әгәр язма мирасыбызның олылыгы вакыт тарафыннан расланган икән, уртак казанышта өстәмә вазифаларга алынган затларның хезмәте зур. Шулай килеп чыга, элгәрләрдән башланган шушы игелекле традицияне дәвам иттерү танылган әдибебез Лирон Хәмидуллин тәкъдиренә дә йөкләнгән. Бу җаваплы миссияне ул бик уңышлы башкарып килә.

Әдәбият белеме өлкәсендә ныклап шөгыльләнер өчен шәхес табигатенә язучылык сәләте салыну кирәк. Тик насыйп кылынган талант кына фикерләү офыкларын киңәйтергә мөмкинлек бирә. Сүз дә юк, мондый вазифага керешү күпне таләп итә. Тәҗрибәле каләм әһелләре искәрткәнчә, иң элек гасырларны колачлаган үз әдәбиятыңны турылыклы төстә сөю шарт, ә аннары инде әдәбиятчы исемен барысыннан да өстен санау лазем. Бу җәһәттән Лирон Хәмидуллин иҗатка кемнәргәдер сукырларча ияреп, балаларча беркатлы көнләшү дулкынында килгән очраклы кеше түгел. Гадәттә, мин дә язучы булам дигән һавалы кемсәләр үзләрен раслауда әллә ни уңышка ирешә алмый.

Икеләнүсез расланганча, бәләкәй Лиронның кальбенә сәмави сәләт салынган. Аның каләмгә соңлабрак тотынуы да алдагы эшчәнлеккә түл-мая туплауга, гомерлеккә сайланачак иҗат юнәлешен әзерлекле рәвештә билгеләү омтылышына бәйле. Әлбәттә, әдәбиятка төбәлгән тормыш баскычларының шулай башланып китүендә язмыш ханымның кырыс төзәтмәләрен исәптән чыгарырга ярамый.

Әтисе Хәйдәр Ленинград камалышын өзү өчен барган аяусыз бәрелештә һәлак булгач, ун яшьлек Лиронның балачак хыяллары тулы күңелен яшәү гаме биләп ала. Малай үзеннән-үзе төпкә җигелеп тартырга, ураулы юлларны узарга мәҗбүр ителә. Колхозда вакытлыча эшләү зуррак максатка этәрә. Әнисе белән энесе, һичшиксез, аңа таянырга тиеш. Ул Актүбә тимер юл транспорты техникумына укырга керә, Пионерлар йортында радиотүгәрәк оештырып, алгыр студент өйгә аз-маз акча да алып кайта. Озаккарак сузылган белем алу барышында исә армия хезмәте сынауларын үтәргә дә өлгерә. Техникумны тоташ бишле билгеләренә генә тәмамлаган егетне Ташкент тимер юл транспорты институтына барырга димлиләр. Әмма һәрдаим ярдәмгә мохтаҗ гаилә хәлләре аның әлеге матур ниятенә «вето» сала. Дипломлы белгеч Лирон Хәмидуллин тимер юлда бригадир булып эшли башлый, шулай ук Бөтенсоюз политехника институтында читтән торып укуын дәвам иттерә. Кешеләргә җайлы хәрәкәт мөмкинлеге тудыруга бәйле хезмәт аны Орскидан Казанга күченеп килгәч тә ычкындырмый. Ул башкалабызның транспорт идарәсендә инженер, баш инженер һәм партком секретарена йөкләнгән җаваплы вазифаларны башкара, әдәби мохиткә кереп, республика көндәлек матбугатының төрле басмаларында хикәя, повесть һәм очеркларын язып чыгарырга да вакыт таба. СССР Язучылар берлеге Әдәбият фондының Татарстан бүлеге директоры булып эшли башлагач, моңарчы читтәрәк торган Лирон Хәмидуллин каләм әһелләре даирәсендә үз кешегә әйләнә. Киң җәмәгатьчелек аның оештыру сәләтен дә, язучылык талантын да озак көттермичә таный.

Үзенең вөҗүден күзәнәккәчә биләп алган максатка тугры калучы затлар, гадәттә, тормыш агышына төзәтмәләр керткән сынаулардан ниндидер файда табуга ирешә. Гомер мәктәбенең мондый гаҗәеп хикмәтләре Лирон Хәмидуллин иҗатында да күзәтелә. Ничек кенә сәер яңгырамасын, әсәрнең нигезенә ятачак теманы язучы түгел, ә тема үзе язучыны сайлап ала. Беркадәр шәрехләбрәк әйткәндә, ул тормыш тәҗрибәсе утырымнарыннан үзеннән-үзе үсеп чыгарга тиеш. Шактый еллар транспорт тармагында хезмәт куйган әдипнең җанына аеруча якын темага тартылуы бик табигый. Диңгезне күрмәгән рәссамга маринистлык таҗы кидерелми. Каләм осталары искәртергә ратканча, белеп язуга ни җитә! Минсенергә яратмаучы Лирон Хәмидуллин исә безнең әдәбиятка моңарчы нечкәләп сурәтләнмәгән яңа геройлар алып килде. Тәүге җыентыгының «Юлда» дип аталуы да авторның тематикасын алдан ук сиздертеп куя. Тәнкыйтьче Фәрваз Миңнуллин аның иҗатындагы бу мөһим хасияткә беренчеләрдән булып игътибар юнәлтте һәм шушы хакта «Затлылык» дигән китабында да үзенчә басым ясап үтәргә онытмады. Лирон Хәмидуллинның үзенчәлеге нидән гыйбарәт соң? Әлеге гап-гади сорауга болайрак җавап бирелә: «Иң элек... прозабызның тематик чикләрен киңәйтүдә... Ул байтак гомер юл караучылар, тимер юл эшчеләре арасында яши... Күп кенә хикәяләре һәм «Дала иртәсе» исемле повесте шул авыр һәм тынгысыз хезмәт кешеләренә багышланган. Үзе сурәтләгән кешеләрнең эшен, тормышын әйбәт белү аның әсәрләрендәге ышандыру көчен арттыра. Ышандыручанлык һәм тормышчанлык өстенә, аның язганнарында тел белән сөйләп-аңлатып бирүе кыен булган, әмма укучыны иләсләндерә, аның күңелен нечкәртә һәм сафландыра торган үзгә бер моң, күтәренкелек, эчке көй бар».

Тарихи биеклекләр яулаган халыкның әдәбияты, төп миссиясеннән тыш, башка максатларга да исәп тота. Бер йолдызлык икенчесе белән нурларын бүлешкән шикелле, сүз сәнгатьләре дә бер-берсен баетышып яшәргә тиеш. Моның нәтиҗәле юлларыннан берсе милли тәрҗемәләр алмашудан гыйбарәт. Гомумән, дөнья әдәбияты хәзинәсендәге гүзәл үрнәкләрне без нәкъ менә шушы эшчәнлек аша беләбез. Безнең кавем тәрҗеманлыкка элек-электән үк өстенлекле игътибар биргән, хәтта әлеге вазифага ныклап алынучы мирзалар да булган. Язма казанышларыбызны ишәйткән төрле буын классиклары да бу әһәмиятле юнәлешне дәвам итәргә мөмкинлек тапкан. «Ят-чит телдәге изге фикерне тәрҗемә Биш вакытта биш намаз күк керде инде

фарзыма...» Күрәбез, «Буш вакыт» шигырендә ишарә кылып үткәнчә, Габдулла Тукай да башка милләт язучыларының әсәрләрен татар теленә сәнгатьчә күчерүне мәҗбүри гадәтенә әверелдергән, алай гына түгел, үзенең иҗатын тәртипкә салырга вакыт җиткерә алмаган шагыйрь тәрҗемә мәктәбен бөтенләй яңа баскычка күтәргән. Янә кабатлап әйтәсе килә: мәдәни кыйммәтләрне уртаклашу гаять дәрәҗәдә мөһим, чөнки мондый багланышлар халыкларны үзара якынайта. Ниһаясез төрки дөньяда гизүче йолдыздай сәфәр чыккан уртак әдәби сюжетлар да бар, димәк, даими нигезгә корылган рухи элемтәләр кардәш әдәбиятлар үсешендә зарури шарт булып тора.

Күркәм традиция рәвешен алган әлеге ихтыяҗ Лирон Хәмидуллинны кайчан үзенә җәлеп иткән? СССР Язучылар берлеге карамагындагы Әдәбият фондында эшли башлагачмы? Совет чорында әледән-әле үткәрелеп килгән милләтара әдәбият көннәрендә катнашу, бәлки, тәҗрибә тупларга өлгергән иҗатчыны тәрҗемә белән чын-чынлап шөгыльләнергә этәргәндер?! Минемчә, мондый уй-ният аңа шактый ерактан килә. Әле Актүбә техникумында укыган елларда ук ул казакъ әдәбиятының тәэссоратлы йогынтысына эләгә. Пионерлар йортында түгәрәк алып барганда да, аңа этник мохитне өйрәнергә форсат ачыла. Якынлыгы сизелеп торган казакъ телен егет отыры күңеленә сеңдерә башлый. Хәер, Оренбург өлкәсенең Яңа Сергиевка районы Искеавыл мәктәбендә белем алган чакта да ул аң-зиһен күзәнәкләренә киләчәктә һичшиксез кирәге чыгачак төрле мәгълүмат тупларга омтыла. «Китап җене» кагылган малай тарихи әдәбиятка өстенлек бирә. Якынрак чорлар да аны бердәй кызыксындыра. Аерым күренекле шәхесләр турында укып-ишетеп белү яшь хәтердә инде озаккача уелып кала. Мәгърифәт учакларының берсе булып саналган әлеге атаклы төбәктә, әнә, нинди генә милләт балалары олуг максатларга хезмәт итмәгән! Мәдәни багланышларның алдын халыкларны бәрәкәтле нәтиҗәләргә китерүен Лирон Хәмидуллин гомере дәвамында тирәнрәк аңлый бара. Мондый үзара мөнәсәбәтләр бетмәс-төкәнмәс мөмкинлекләргә ия. Шушы җирлектә язучының эчке инануы да, бу мәсьәләгә карашы да ныгый төшә. «Яшьрәк чакта вакыт кадерен белмисең...» дип исемләнгән әңгәмәдә ул яшь каләмдәше Ләбиб Леронга төпле фикерен ап-ачык итеп белдерә: «Бер әдәбият та үз-үзенә бикләнеп кенә яшәми. Башкалар белән көндәлек аралашу һәркемгә зарур булган кебек, әдәбиятлар да үзара бәйләнеш тотмыйча зур уңышка ирешә алмый».

Күренә ки, Лирон Хәмидуллин тәрҗемә эшенә зур әзерлек белән килде. Әдәби иҗат серләрен өйрәнү исә аның каләменә тотрыклы ышаныч биргән. Чыннан да, үзеңнең рухиятеңә муафыйк өслүптә яза белү әлеге дә баягы мөтәрҗимлектә өстенлек санала. Мондый җаваплы вазифага керешү алдыннан да ул икеләнү халәтенә кертерлек хисләр кичермәгәндер. Очраклы әсәрне безнең телгә «аударырга» алыну Лирон Хәмидуллинның холык-фигыленә бөтенләй туры килми. Аның хәстәрләп билгеләнгән юнәлешләре, күңеле кушкан максатлары бар. Язучының казакъ әдәбияты әсәрләрен тәрҗемә итә башлавы шушындый мөһим эзлеклелеккә тугрылык күрсәтү белән аңлатыла. Бик табигый ласа: ул әлеге халыкның телен дә нечкәләп өйрәнгән, яшәү рәвеше турында да байтак мәгълүмат белә. Бу уңайдан Лирон Хәмидуллин үзе боларга тагын бер этәргечне өсти. «Борынгы төрки дөнья мине элек-электән кызыксындыра, – ди ул. – Татарда төркиләр тарихын чагылдырган әсәрләргә юл ябык булган елларда казакълар бу өлкәдә алдарак бара иде. Шул сәбәпле мин әүвәл казакъ әдәбиятына мөрәҗәгать иттем».

Гадәттә, эчке әзерлек үзен барыбер аклый, максатчан иҗтиһат, һичшиксез, уңышка китерә. Җиңнәре сызганулы Лирон Хәмидуллин казакъ әдипләре Әнвәр Әлимҗановның повестьларыннан торган «Отрар хатирәсе» китабын (1974), Сайын Моратбәковның хикәя һәм повестьлары тупланган «Әрем исе» җыентыгын (1986) татарчага тәрҗемә итеп чыгара. Шулай ук Абайның «Хикмәтле сүз»ен үзебезнең телгә күчерә һәм акынның бер томлыгын (1981) төзеп бастыруда катнаша. Аның тәрҗеманлык тырышлыгы белән казакъ язучыларының повестьлары да («Җәйләүдә», 1993), казакъ халык әкиятләре дә («Сыбызгы сере», 1996) аерым басмаларда дөнья күрә. Кардәш халыклар турында ихлас кайгыртучы чын мәдәни илчегә әверелеп киткән Лирон Хәмидуллин «Ак дөя» исемендә чыккан чәчмә әсәрләр җыелмасын (1979) әзерләүгә дә зур өлеш кертә.

Борынгы римлылар искәрткәнчә, бер үк эшкә ике кеше алынса, ахырда бер үк нәтиҗә

килеп чыкмас. Мактанырга да мөмкиндер, безнең татар әдәбияты тәрҗемә әһелләреннән унды. Узган гасырның 60-70 нче елларында аларның эшчәнлеге аеруча көчәйде. Әлеге юнәлештә күзәтелгән яңарыш, әлбәттә, осталар плеядасы оешуга бәйле. Әмма тәрҗемә үрнәге ничек кенә югары кимәлдә башкарылмасын, укучылар кулына кергән әсәрләрнең сыйфаты барыбер төрлечә була. Монысы каләм ияләренең язу рәвешеннән, интеллектның башка байтак хасиятеннән киләдер. Артык тирәнгә төшеп тормыйм. Бу җәһәттән Лирон Хәмидуллинның да сыйфатка әверелердәй кайбер өстенлекләре бар. Аның иҗат осталыгы турында әйтеп үттем инде, берничә телне сөйләшерлек дәрәҗәдә белүе дә мәгълүм. Шулар өстенә ул бик тыныч холыклы. Сабыр төбе – сары алтын. Дөрес мәсләккә юнәлтелгән әлеге халәт теләсә нинди өлкәдә казанышка китерә. Иктыматлап эшләү дә шуннан башлангыч аладыр. Алдында йөзгә тармакланган хисапсыз бурыч торган чакта мондый сыйфатларның кирәклеген бигрәк тә ачык тоясың. Ә Лирон Хәмидуллин фигылендә боларның барысы да бар. Ашыкканда да кабаланып эшләмәс, иҗатын өзлексез конвейерга кормас. Ул яхшы мәгънәсендәге үҗәтлеген дә күрсәткәли, кайвакыт вак-төяк нәрсәләргә дә игътибар бирә. Үз дигәненә ничек тә ирешә, соңыннан тулысынча хаклы булып чыга. Кара әле, Корней Чуковский дөрес әйткән: «Башка телгә күчерелгән хезмәттә тәрҗемәченең автопортреты чагылыш таба». Хак сүзләр, Лирон Хәмидуллин тарафыннан күңел биреп башкарылган эшләрдә дә аның югарыда ассызыклап үтелгән сыйфатларын абайламыйча мөмкин түгел. Әдипнең тәрҗемә өлкәсендәге һәрбер уңышы менә шундый табигый зәмингә нигезләнгән. Тәҗрибә туплаган затларга, кагыйдә буларак, өстәмә бурычлар йөкләнә. Үзенең күнекмәләре белән үрнәк күрсәтә алу дәрәҗәсенә ирешкән каләм әһеленең яшьләр өчен мастер-класслар үткәрүе, Татарстан Язучылар берлегенең тәрҗемәчеләр секциясен ун еллап җитәкләве Лирон Хәмидуллинның ышаныч казануы турында сөйли. Тыйнак олпатлыкны үтә таләпчән каләмдәшләре дә, аерым алганда, осталар остазы Рәис Даутов та таный. «Җаваплылык хисе» исемле мәкаләдә мәтрның мөнәсәбәте аермачык белдерелгән: «Аның тәрҗемәләре, теге яки бу милли язучының рухи дөньясын, образлар иҗат итүдәге шәхси үзенчәлекләрен мөмкин кадәр тәңгәллектә саклап, үз ана телебезнең табигый кануннарына буйсындырылып, саф татарча рәвештә эшләнә».

Үзеннән-үзе аңлашылганча, милләтара әдәби багланышларда хәрәкәт ике яклап оештырылса гына, һәр халык өчен дә файдалы нәтиҗәләр көтәргә мөмкин. Бу очракта татар-казакъ хезмәттәшлеге уңышлы проект булып чыкты. Әдәби элемтәләрне яңа биеклеккә күтәрүдә Лирон Хәмидуллин үзенчә башлап йөрде. Чагыштырмача кыска вакыт аралыгында Алма-Ата нәшрияты язучыларыбызның дистәләрчә китабын, шул исәптән 1979 елда «Татар повестери» дигән тупламны чыгарды. Бетмәс-төкәнмәс сабырлык аша ирешелгән күпкырлы куә газиз әдәбиятыбыз казанышларын дөньяга танытуда файдаланыла. Татар әдипләренең хикәяләрен русча («Пробуждение», 1978), үзбәкчә («Йиллар ва йуллар», 1981), каракалпакча («Татар гүрриңлери», 1981) махсус басмалар рәвешендә җыйнап-төзеп бастыру, шундый ук жанрдагы әсәрләрдән мадьяр телендә аерым җыентык әзерләү Лирон Хәмидуллинның гаять мәшәкатьле тәрҗемә эшенә җаны-тәне белән бирелгәнлеге хакында сөйли.

Инде беркадәр әйтеп үтелгәнчә, Лирон Хәмидуллин үзбәк, каракалпак, башкорт, белорус әдәбиятлары белән тәрҗемә алмашуда да шушы халыкларның мәдәни алгарышын күзалларга ярдәм итәрлек игелекле гамәлләр кылырга өлгерде. Мәсәлән, Әсгать Мохтарның «Чинар» (1976), Василь Быковның «Һәйкәл» (1984), Яныбай Хамматовның «Бөртекләп җыела алтын» (1996) китаплары шундый хезмәтләр җөмләсенә керә. Болар янына Александр Капустинның «Беренче җиңүләр»ен (1995) дә өстәргә мөмкин. Әлеге затлы җыентыкларда төрле милләт язучыларының саллы-саллы романнары һәм повестьлары тәкъдим ителә. Сүз уңаеннан искәртеп узыйм, югарыда телгә алынган «Беренче җиңүләр» повесте Казан тумасы майор Фёдор Баталовка багышланган. Советлар Союзы Герое исеме аңа беренчеләрдән булып, төгәлрәк әйткәндә, әле 1941 елның 9 августында ук бирелгән.

Сокланмый мөмкин түгел, шуның ише җитди китаплар чыгарган арада Лирон Хәмидуллин көндәлек матбугатта Мохтар Ауэзов, Теләпбиргән Каипбиргәнов, Сырбай Мәүләнов, Мохтар Мәгауин кебек кардәш әдипләрнең әсәрләрен тәрҗемәләп

бастырырга да, башка милләт язучыларының татар әдәбиятына кагылышлы хезмәтләрен үзебезнең укучылар хөкеменә тапшырырга яки алдан уйлаган тәртиптә әзерләнгән берәр яңа җыентыкка төпле кереш язарга да җаен таба. Ә инде аның Урта Азия әдәбиятлары турында аерым тематик мәкаләләренә килгәндә, әтрафлылык ягыннан аларның һәркайсы җитди энциклопедик белешмәләргә кирәрлек кызыклы мәгълүматлардан тора. Кайчандыр Лирон Хәмидуллиннан файда күргән затлар аны тикмәгә генә «аяклы китапханә»гә тиңләмидер. Күпләр гаҗәпләнеп сөйләгәнчә, үзең белеп бетермәгән катлаулы сорау белән мөрәҗәгать итсәң, ул күпчелек очракта аңа шундук нигезле җавап бирер. Кайбер чакта исә өеңә телефоннан шалтыратырга вәгъдә куяр, беркадәр вакыт үткәч, гыйлемеңне теләсә нинди реферат яза алырлык дәрәҗәгә җиткерер. Ул инде күптәннән шундый, шулай булып кала да. Газета һәм журнал редакцияләрендә берничә дистә ел дәвамында эшләп, махсус мәсьәләләргә багышланган мәкаләләр яздыруны оештыру тәҗрибәмнән чыгып әйтәм: безнең милләтара әдәби багланышларны гамәли үстерүдә Лирон Хәмидуллинга торырлык шәхесләр сирәктер.

Иҗат дөньясында саф тәнкыйть вазифасына кермәгән, әмма мөһимлеген югалтмаган бурычлар да хәтсез. Алар сөйләп үтелгән мәдәни багланышларны ныгытырлык гамәл кылудан, әлегә тиешенчә өйрәнелмәгән фактлардан хакыйкать коелмасы эретеп алудан, чуарлык хөкем сөргән әдәбият елъязмасына нигезле төзәтмәләр кертүдән, мәшһүр затларның тормыш юлындагы кайбер томанлы урыннарны ачыклаудан, моңарчы чишелмәгән башка җитди мәсьәләләргә игътибар юнәлтүдән гыйбарәт. Кыскасы, шәрехчесен көткән нәрсәләр тормышыбызда санап бетергесез. Еш кына күренекле әдипләрнең тәфтишләп язылган гыйбрәтле биографияләре дә күп белергә омтылучы кешедә чиксез канәгатьләнү хисләре тудырырга мөмкин. Француз язучысы Анатоль Франс әлеге сүзләрне хуплагандай әйткәнчә: «Әдәбият турындагы очерклар – тарих язуның иң үтемле формаларыннан берсе. Зурдан кубып фикер йөртсәк, аларда чын тарих – кеше рухының тарихы чагылыш таба. Мондый жанрда уңышлы эшләү өчен сирәк очрый торган сәләт һәм югары культура кирәк».

Бу уңайдан кабатлап расларга туры килә: безнең Лирон Хәмидуллин нәкъ менә шушы өлкәдә күркәм нәтиҗәләргә ирешә, димәк, аның рухи-әхлакый сыйфатлары әлеге вазифаны яхшы итеп башкарырга җирлек тудыра. Әйе, мондый белгечлекне данлаучылар чагыштырмача әллә ни күп түгел, әмма имгәтелгән дөреслек үзен яклаучыларны барыбер эзләп таба. Әйтик, аяныч язмышлы Дәрдемәндкә багышланган хезмәтләр шулай кистереп әйтергә нигез бирә.

Оят булса да, искә төшереп үтәм. Совет хакимияте чорында «рәнҗетелергә уңайлы» Дәрдемәндкә «буржуаз шагыйрь» дигән хаксыз ярлык тагылды, милләтнең мөбарәк тәсбихендәге мәрҗәнне гәүдәләндергән зат нигезсез рәвештә тыелган иҗатчылар исемлегенә кертелде. Безнең җәмгыятьтә череп беткән бай ничек инде шагыйрь санала алсын! Татар авылындагы мәктәп китапханәләренең сыгылып торган киштәсендә бөтен дөнья әдәбияты үрнәкләрен табарга мөмкин иде. Дәрдемәнднең исә аерым китабы түгел, уку барышында исеме дә яңгырамады. Атаклы Һёте дә алай фәкыйрь яшәмәгән. Ә менә аның шигырен миңа немец теле дәресендә хәтта күңелдән чатнатып сөйләрлек дәрәҗәдә өйрәнергә туры килде... Югыйсә миллионерлыкта гаепләнгән Мөхәммәтзакир Рәмиев (Дәрдемәнд) ил-көнгә күпме игелек күрсәтергә өлгергән: абыйсы Мөхәммәтшакир белән бергә Оренбургта «Вакыт» газетасын, аннары шунда ук «Шура» журналын чыгара башлый; туган ягында мәчет һәм мәдрәсәләр төзетә, аларда дәреслекләр, башка кирәкле әсбаплар булдыра; гаиләләре яшәп алган Юлык авылында һәркемне җәлеп итәрлек китапханә салдыра; үзләренең хисабына берничә студентны чит мәмләкәтләрдә укытуны оештыра... Берничә дистә ел дәвамында шагыйрен югалтып торган халык хәзер Дәрдемәнднең җәмәгать эшлеклесе булуын да яхшы белә. Саный китсәң, ул мондый хезмәттә дә күп вазифалар башкарган икән: 1 нче Дәүләт Думасы депутаты, Оренбург шәһәр управасы, Конституцион-демократик партиясенең Оренбург бюросы, мөселман хәйриячелек оешмасы әгъзасы, «Иттифакъ әл-мөслимин» фиркасен төзүдә катнашучыларның берсе... Күпләргә мәгълүм булганча, Октябрь инкыйлабыннан соң Рәмиевләр егермеләп алтын приискасын, шулай ук

«Вакыт» басмаханәсен дәүләт карамагына тапшыра. Рухи байлыкларын да. Дәрдемәнд хакимияткәниндидер каршылык күрсәтергә дә, чит илгә китәргә дә омтылыш ясамаган. Менә шундый олуг шәхесебез онытылуга дучар ителсен әле! Аның хәтта дәфен кылынган кабере югалган, чөнки бу урында завод бинасы төзелгән. Гаҗәпкә калырлык, тормышта бөтен ирешкәнен халыкка биргән зат өч аршын җиргә дә лаек түгелмени?!

Дөреслек ясалма бозуларга бирешми. Гаять үзенчәлекле әдәби мирас калдырган шагыйрь Дәрдемәнднең исеме, ниһаять, хакыйкый хокукларны киңәйткән яңа җәмгыять шартларында тәмам акланды. Әмма әдипнең тәрҗемәи хәлен ныклап тулыландырырга кирәк иде. Анда билгесезлек алмашлыклары күптән-күп булып чыкты. Нигә татарда кабересезләр арта? Җәлилчеләр фаҗигасе бәгырьне телгәли. Насыйп гүрләренә керә алмаучылар якынрак заманда да булгалады. Миллионер чынлап ачтан үлгәнме? Дәрдемәндкә кагылышлы имеш-мимешләр дә күзне томаларлык күләмдә күбәйгән. Гомумән, аның гомер ахыры елларында мәгълүмати өзеклек шәйләнә иде. Аңлашыла ки, классик шагыйребез язмышына бәйле рәвештә килеп туган әлеге кыен сорауларга уңайлы өстәл янында филологик фикерләүләр аша гына җавап табып булмый. Моның өчен тир түгү, кара эш башкару сорала. Ә Лирон Хәмидуллин көннәрдән бер көн нәкъ менә шундый вазифага алынды да. Хәер, ошбу эзләнүләр юнәлешен сайлауда һичнинди дә очраклылык юктыр. Ул Орскида Дәрдемәндкә баглы тарихи урыннар белән танышканда ук, бик еракка төбәлгән егетлек уйларыннан үзенчә төен ясап куя.

Гомеренең байтак өлешен юлга бәйле хезмәткә багышлаган кеше гавам тормышында сыналган тәҗрибәнең фикри сөземтәсен яхшы беләдер: күп йөргән күп ишетә. Дәрдемәнд эзләре буйлап озын сәфәргә чыгып киткән Лирон Хәмидуллин Җиргән, Юлык, Балкан, Требия, Фершампенуаз авылларында, Баймак шәһәрендә була. Хәзерге Башкортстан белән Чиләбе өлкәсенә кергән әлеге кала-салаларда олырак буын вәкилләреннән Рәмиевләргә кагылышлы истәлекләр язып ала. Фотосурәтләр дә туплана. Уфа һәм Оренбург архивларында казгану көтелгәннән дә яхшырак нәтиҗәләр бирә. Биограф вазифасына керешкән тикшеренүчебез шагыйрьнең Уфада һәм Мәскәүдә яшәүче оныклары белән дә күзгә-күз очраша, дөньяга сибелгән башка кайбер туганнарыннан дәвамлы хатлар аша үзе теләгән тарихи мәгълүматларны туплауга ирешә. Шулай бөртекләп җыелган материалларда Дәрдемәнд тормышының билгесез саналган сәхифәләре дә, аның хатыны, уллары һәм кызларының язмышы да ачык шәйләнә башлый. Болар хакында тизрәк киң җәмәгатьчелеккә хәбәр итәргә ашыккандай, Лирон Хәмидуллин көндәлек матбугатта дистәләрчә мәкалә бастырып чыгарды. Аның «Офыктагы рәшәләр» исемле калын китабы (1990) менә шундый җентекле өйрәнү нәтиҗәсендә туа. Ул берничә буын хәтереннән юылган шагыйрь турында күп нәрсәләрне ачыклый, димәк, бердәнбер җыентык белән генә чикләнеп калу бөтенләй дөрес булмас иде. Әлеге эзләнүләрен аерым юнәлешләрдән торган проект итеп күзаллаган әдип 2003 елда «Дәрдемәнд» дип исемләнгән үзенчәлекле фотоальбом бастырып чыгара. Һәм аннары «Күренекле татар шәхесләре» сериясеннән рус телендә «Дэрдменд» (2010), шулай ук «Поэт, издатель, меценат» (2016) дигән китаплар дөнья күрә. Шушы өлкәдә белгеч булып танылган Лирон Хәмидуллин «Бертуган Рәмиевләр» басмасын әзерләүдә дә турыдан-туры катнаша. «Шәхесләребез» сериясеннән 2002 елда укучылар кулына кергән әлеге җыентыкта язучының Рәмиевләр шәҗәрәсенә һәм башка мәсьәләләргә багышланган ике мәкаләсе урнаштырыла. Сирәк фотосурәтләрне барлауда да ул маһиранә булышлык күрсәтә. Шагыйрь тормышына бәйле кайбер өстәмә мәгълүматлар аның башка хезмәтләрендә дә, әйтик, «Ак төннәр хәтере» исемле очерк, эссе, хатирәләр мәҗмугасында да бирелә... Инде җавабын күпләр белгән шундый сорау бирәсе килә: татар халкының затлы улы Дәрдемәнднең биографиясен гыйльми торгызуда Лирон Хәмидуллиннан да зуррак өлеш кертүче тагын бармы? Бу сөаль уңаеннан могтәбәр әдәбият галиме Мөхәммәт Гайнуллинны искә алып үтмәү, аның шагыйрь иҗатын барлауда башлангыч адым ясавын олыламау гөнаһ саналыр иде. Ә Лирон Хәмидуллинның нәтиҗәле эзләнүләрен икенче югарылык рәвешендә күрәм мин.

Һәрдаим акыл чослыгын таләп иткән шахматта берничә йөрешне алдан уйлап уйнаучылар була. Лирон Хәмидуллин – шундыйлар рәтендә. Әлеге дә баягы Дәрдемәнднең мозаик сурәтендәге җитешмәгән кисәкләрне эзләп йөргән чакта ул

якын елларда үтәлергә тиешле башка мөһим бурычларны да күздә тоткан. Гадәттә, аерым максатчан тикшеренүләр барышында бүтәнрәк материалларга да юлыгасың. Зирәклеге йөзенә чыккан Лирон Хәмидуллин да озын сәфәрләрендә берничә китаплык мәгълүмат туплый. Татарның мәдәни мәркәзләреннән саналучы Оренбург яклары рухи ядкарьләргә шулкадәр бай ки, бу очракта дөреслеге ачык сизелеп торган мантыйкый фараз да күңелгә килә: менә шундый гаять үзенчәлекле төбәктә яшәп алу Лирон Хәмидуллинга галимлек вазифасына җигелергә этәргеч биргәндер. Баксаң, ул шул ук Орск өязенең Күкшел авылында дөньяга килгән Мирхәйдәр Фәйзинең тормыш юлын өйрәнүне дә игътибар үзәгендә тоткан. Дәрдемәнднекенә охшаш гомер тукталышлары: Оренбург, Орск, Баймак шәһәрләре, Юнәй, Юлык, Темәс, Түбә авыллары... Йөргән аякка йөрем иярә. Югарыда беркадәр гөман кылып әйтелгәннәргә чираттагы дәлил рәвешендә «Галиябану туган якларда» исемле хезмәт укучы хөкеменә тапшырыла. Баеп торган мәгълүмати картотека булдырган Лирон Хәмидуллинның башка мәкаләләрендә дә мәшһүр драматург Мирхәйдәр Фәйзинең әдәби-гыйльми портретына өстәмә шәрехләрне очратырга мөмкин.

Һәрбер милли әдәбиятның иҗадият кануннарына баглы нигезе мәдәни алгарышка илткән бәрәкәтле гасырлар дәвамында салына. Аны ныгытуга аерым каләм әһелләре дә, бигрәк тә классиклар үз осталыклары белән кабатланмас өлеш керткән. Гомумән, яхшы китап рухи яшәешебезнең бер мөһим өлешен гәүдәләндерә, алардан башка мәдәниятнең җирлеген дә тулысынча күзаллап булмый. Мондый әдипләр турында без бик җентекләп белергә тиеш. Югыйсә әдәбиятка килгән яшьләрнең байтагы элгәрләр традициясенә таянуны, әзерләнгән нигезгә «бина кору»ны аңлап та бетерми шикелле. Сүз сәнгатенең үткәненә битараф караш иҗатта үз-үзеңә тышау кидерүгә тиң. Бу җәһәттән күренекле язучыларның биографиясен төрле яклап өйрәнү әдәби барышның менә шундый максатларына да хезмәт итә. Үзара аерылгысыз бәйләнештә торган әлеге мәсьәләләргә Лирон Хәмидуллин да өстенлекле әһәмият бирә. Аның Габдерәхим Утыз Имәни, Әбелмәних Каргалый, Һибәтулла Салихов иҗатын өйрәнүчеләргә ярдәм итәрлек мәгълүматлар табуы, Галимҗан Ибраһимов, Муса Җәлил һәм башка әдипләргә багышланган махсус тикшеренмәләре әнә шул хакта сөйли. «Амирхан Еники» исеме белән русча китап рәвешендә чыккан документаль бәян да (2013) бу юнәлештә эзләнүләр алып баручының билгеле бер тәртипне төгәл саклавын күрсәтә.

Ерак гасырлардан бирле яшәеш дөреслеге сагында торган әдәбият галимлек эшчәнлегендә дә дөреслек тарафдары булуны таләп итә. Вәләкин хаклыкка ачыктан-ачык яла ягуны хәтерләткән әһәмиятсез расламалар аң-хәтер күзәнәкләренең инде байтак өлешен томалап алырга өлгергән. Аларны җиз иләк аша үткәрү, ягъни орлыкны кибәктән аеру сорала. Мондый чистарту эшен тулаем вакыт вазифасына гына кертергә ярамый, әдәбият кануннарын тайпылышсыз үтәү дә уңай нәтиҗәләргә китерергә мөмкин. Тарихи фактлар ташкынының ни-нәрсә икәнен бик яхшы белгән Лирон Хәмидуллин рухи-мәдәни тормыш елъязмасы эзлеклелеген торгызуда нәкъ менә шундый кагыйдәгә таяна. Гыйльми тикшеренүдә гадел хөкемче булып калу өчен, акыл ияләре киңәш иткәнчә, кайчакта ватанчылык хисләренә артык бирелмәү дә файдалы. Бу хакта нигә шулай басым ясап әйтәм әле? Сөйләгәннәрдән аңлашылганча, Лирон Хәмидуллинның күп кенә документаль әсәрләре туган-үскән ягына турыдан-туры бәйле, әмма ул хәтта атаклы авылдашы турында язганда да күпертүләргә бармый. Газиз якташларының истәлеген кәгазьгә төшергәндә дә, әдип алардан ниндидер филантроп ясарга тырышмый. Объектив чынбарлыкка хилафлык кылу яңа хаталар ясауга этәрә.

Хәйран калырлык, Лирон Хәмидуллинның Оренбург өлкәсендәге Каргалы бистәсендә тикшеренүләр алып баруы әллә никадәр хәтер мәгъдәннәренә кояш нуры йөгертергә мөмкинлек ача. Нәтиҗәдә, Габдерәхим Утыз Имәнинең тәрҗемәи хәленә яңа өстәмәләр кертерлек, шагыйрьнең тормышына бәйле кайбер фаразларны чынга әйләндерерлек мәгълүматлар табыла. Белгәнебезчә, татар шигъриятенең социаль мәсьәләләрне яктырту ягына борылуы аның төрле жанрдагы әсәрләрендә аеруча ачык күренә. Бездә халыкчан тел-өслүп булдыруда да ул сизелерлек өлеш кертергә өлгергән. Мондый шәхеснең үзе укыган мәдрәсәдә яшьли мөгаллимлек итүе дә, хәләл җефете белән бергә ишле гаилә йөген тартуы да, Бохара, Герат, Кабул, Балх ише шәһәрләрдә

белемен күтәрүе дә, аның дустанә аралашып яшәгән даирәсе дә зур кызыксыну уята. Аң өчен барысы да игътибарга лаек, ул вакны да эреләү тылсымына ия. Азык кына тәкъдим ит. Оренбург губернасындагы Каргалы кемнәрне генә хәтерләми! Бактың исә, Габдерәхим Утыз Имәнине укыткан мөдәррисләр Салават Юлаевка да белем биргән. Шушы ук бистәдә дөньяга килгән Әбелмәних Каргалый... шагыйрь Габдессәлам ибн Ураиның оныгы икән бит. Соңгысы Каргалы мәдрәсәсенең химаячесе һәм ахун булган, милли каһарманыбыз Батырша белән якын бәйләнештә торган. Менә нинди атаклы бистә, язмыш юллары кисешкән урын! Монда Салават белән Батырша дини белем генә алмаган, йөрәкләрендә менә-менә дөрләп китәр гыйсъянчылык утын да йөрткән. Шагыйрь Һибәтулла Салихов та Каргалы мәдрәсәсендә укып, соңыннан биредә өлкән укытучы дәрәҗәсенә кадәр күтәрелгән. Боларның бөтенесе турында тәфсилле мәгълүматны Лирон Хәмидуллин эзләнүләрендә табарга мөмкин. Мондый кызыклы фактларның күпчелек өлеше инде фәнни әйләнешкә дә керде.

Үткәннәргә кагылышлы хезмәтләр башлыча ни-нәрсәгә нигезләнергә тиеш – моны яңа эрага кадәр үк әйтеп калдырганнар: тарих философиясе мисаллардан тора. Күренекле шәхесләрнең тормыш юлын өйрәнүчеләр дә бу искәртүне тирәнтен аңлап эш итәдер. Нинди дә булса нәтиҗәне ныгытырга булышырдай дәлилләр Лирон Хәмидуллинның тулыланып торган җыелмасында да байтак. Әйтик, Галимҗан Ибраһимовның беренче җәмәгате Мәстүрә тәкъдир каләме язганнарны ничек үткән? Фактлар барысын да хаклык кушканча ачыклый. Шул ук Лирон Хәмидуллин олуг затның Өммегөлсем һәм Хәдичә исемле хатыннары белән очрашып та, алар сөйләгәнне язучының әдәби репутациясен тулыландырырга ярдәм итәрдәй истәлек рәвешендә теркәп калдыруны кирәк тапкан... Мондый раслама да бик гыйбрәтле бит: вәисиләрнең Гражданнар сугышы елларында оештырылган «илаһи полк»ы хәтта әдибебез Афзал Шамовны да үзенә тарткан. Кызыксыну уята торган очраклар, уйланырга этәргеч биргән фаразлар... «Вовеки нельзя дружбу разбить...» дип аталган мәкаләсендә исә («Татарский мир» газетасы, 3 нче сан, 2016) автор Максим Горькийның «мордва тамырлары»н беркадәр ачып күрсәтә. Зиһен баетырлык мисаллар китерүне озаклап дәвам итәргә мөмкин.

Әдәби хәрәкәттә катнашучылар даирәсе язучылар белән генә чикләнми. Бездә каләм әһелләре элек-электән төрле сәнгать эшлеклеләре белән хезмәттәшлек кылган, иҗтимагый яшәешнең үзгә өлкәләрендәге һөнәр ияләре белән тыгыз бәйләнештә торган. Гомумән, зур халыкның күпьяклы мәдәни алгарышын шушындый бәгланыштан башка күзаллап булмый. Әдәбият тормышының үзәгендә кайнаган шәхесләрне өйрәнүче Лирон Хәмидуллин да төрле чорларны колачлаган эзләнүләрендә мондый чынбарлык күренешләренә әледән-әле юлыккандыр. Хәер, авторның документаль әсәрләре аларны ап-ачык күрсәтә. Димәк, алга карап фикер йөртә белгән тикшеренүче әдипләр турында гына түгел, бүтән зыялы затларыбыз хакында да материал туплауны максат итеп куйган. Татарның концертлар биргән тәүге музыкантларыннан берсе Фәйзулла Туишев аның ихлас кайгыртулы игътибарыннан ничек читтә калсын инде?! Дан казанган әлеге гармунчы – Лирон Хәмидуллинның авылдашы бит. Бөтенсоюз смотры лауреаты, ТАССРның халык артисты... Ул – җырлар һәм инструменталь пьесалар авторы да. Уйлавымча, шушындый шәхеснең гомер юлы тасвирламасын эшләүне язучы үзенең фарыз бурычы итеп санагандыр. Хәзерге Ульян өлкәсенең Яңа Малыклы районы Иске Төгәлбуга авылы булачак тарихчы Җәмил Гыйльмановны да олы дөньяга фатихалап озаткан. Музыкант, галим, язучы... Бер чишмә суын эчеп үскән егетләр туган туфрак хакын һәрвакыт югары тота. Шулар арасыннан Лирон Хәмидуллин исә изге йөкләмәсен бүгенгәчә үтәп килә: милләт олугларын барлый, якташларын да онытмый.

Дистәләрчә ел дәвамында аң-зиһеннән юыла килгән сәясәтче һәм җәмәгать эшлеклесе Йосыф Акчура, шөкер, күпне кичергән татар халкының күренекле шәхесләрен берләштергән галереяда үзенең лаеклы урынын алды. Әлбәттә, Лирон Хәмидуллинның төпченүле эзләнүләреннән башка аның портреты тулы булмас иде. Тарих галиме, филолог, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе Габделбари Батталга карата да, төгәлрәк әйткәндә, халык улының хәтергә кайтуы турында да шундыйрак

сүзләрне кабатларга туры килә. Язучының «Онытылган якын исем» дигән хезмәте Татар энциклопедиясе мәкаләсен эшләгәндә дә файдаланылган. Аумакайлык инерциясе буенча хаксызга сүгелгән журналист, нашир, җырчы һәм көйләр авторы Камил Мотыйгый да, җәмәгать эшлеклесе, педагог һәм публицист Шакир Мөхәммәдьяров та Лирон Хәмидуллин тикшеренмәләрендә өстәмә шәрехләү тапты. Өстәвенә соңгысы Орскида туган. Петербург университетының юридик факультетында укыганда, ул пайтәхеткә килгән Габдулла Тукайны медицина профессоры Александр Польгә күрсәтә, «пәйгамбәр кыяфәтле» шушы табибның үлем карары шикелле кабул ителгән күңелсез диагноз куюына ирексездән шаһит була. Бөек шагыйрьне гомер дәвамында олылаган затны ничек инде эзтабар каләме читләтеп үтсен?! Әгәр өйрәнелгән шәхесләр хакындагы мәкаләләр алфавит тәртибендә тезелеп төпләнсә, бердәнбер автор тарафыннан эшләнгән үзенчәлекле белешмә барлыкка килер иде.

Еш кына зарланырга яратабыз. Гыйбарәсе дә тиз табыла. Янәсе, ике эш аеруча кыен: махсус сүзлек төзү һәм грамматика дәреслеген әзерләү. Зарый кылмыйк, бездә әлеге авыр хезмәтнең тәҗрибә туплаган осталары бар. Дөрес, алар күп түгел. Әмма без әле булганнарын да уртак бурычларны үтәүгә тарта белмибез. Саллы белешмә-кулланмалар нигезенә ятарлык фәнни-документаль китаплар да, киң әйләнешкә кертүне көткән чыганаклар да хәтсез. Татарстан Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе институты төзелү дә (1994) бу хәзинәнең иксез-чиксез мөмкинлекләрен тиз арада ачып күрсәтте. Милли әһәмияткә ия учреждение тип-тигез урында калкып чыкмый. Ә Лирон Хәмидуллин кебек белгечләрнең әлеге институтка чакырылуы шәкли мантыйк кагыйдәләренә бөтен яктан да җавап бирә. Өлкән фәнни хезмәткәр вазифасындагы әдип биредә сигез еллап эшли, гамәлгә куелган энциклопедияләрнең татар телендәге үрнәген әзерләп чыгаруда катнаша, «Татар энциклопедиясе сүзлеге»ндә һәм томнарда утыздан артык мәкаләсен урнаштыра. Безнең өчен күнегелеп бетмәгән әлеге йөкне тартуда аңа галимлеге генә түгел, шулай ук язучылык маһирлеге дә, тәрҗемәчелек тәҗрибәсе дә көч өстәп торгандыр. Ә моңарчы Татарстан китап нәшриятында эшләгән чакта (1985-1993) ул остазлар күзәтчелегендә чын мөхәррирлек мәктәбен уза. Редактор Лирон Хәмидуллин кулыннан үткән йөз иллеләп китап арасында аннан эрудит булуны таләп иткән аерым басмалар да байтак... Әйе, галәми киңлектәге сүзлек төзү иң авыр эшләрдән санала. Мондый четерекле хезмәтне башкару өчен, барлык сәләтеңне үлчәү тәлинкәсенә салу, күңел кушуы буенча сайлап алынган максатка бөтен гомереңне багышлау кирәк. Безнең Лирон Хәмидуллин шундыйлар төркеменә керә. Аның төрле баскычлардан торган нәтиҗәле эшчәнлеге, һичшиксез, энциклопедист затлар үтәгән җаваплы вазифага тиң.

*Өзелмәде, яши безнең юл:*
*Дәвам булып шоңкарлар килә.*
(«Вакуум юк безнең сафларда...»)

Шагыйрь Хәсән Туфан әсәреннән алынган әлеге өземтә, мөгаен, каләмдәше Лирон Хәмидуллин күңелендә канәгатьләнү хисләре уятадыр. Үзенең беренче китабын «Юлда» дип атаган язучы ничек инде алмаш булырлык варислар хакында уйланмасын?! Менә шундый дәвамчылар арасында үз малаеңны күрү милләт хадиме өчен икеләтә бәхет галәмәте бит! Шушы урында Туфан Миңнуллинның «Син кемнәрнең баласы?» дигән мәкаләсе, дөресрәге, әдипнең гадәти сүзләр белән белдереп үтелгән фаразы искә төшә. Ул яшь тарихчы Булат Хәмидуллин турында язып, зур өметләр багланган егеткә хәерле юл теләп: «Киләчәктә, Алла боерса, аның исеме хөрмәт һәм ихтирамга лаек татар зыялылары исемлегендә булыр» («Татарстан яшьләре» газетасы, 31 октябрь, 2000). Хикмәти Хода, шулай булды да! Хәтерлим, 2016 елны гаммәви мәгълүмат чараларында Татарстанның фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт премиясен дәгъвалаучылар игълан ителде; анда күрсәтелгән берничә дистә галим янәшәсендә тарихи хезмәтләре белән танылган Булат Хәмидуллин да бар иде. Әүлияларча күзалланган «зыялылар исемлеге». Олуг максатларына урау юллар аша килгән Лирон абый чиксез сөенгәндер – аның дәвамчысын гәүдәләндергән улына Президент Указы нигезендә югары бүләк

бирелде. Бәяләү сүзләре генә дә әнә ничек горур яңгырый: «Борынгы заманнардан татарлар тарихы»ның 7 томлык академик басмасын әзерләп чыгаруда катнашканы өчен... Димәк, сайланган юлның өзелмәве варислар казанышында раслана. Аталы-уллы Хәмидуллиннарның уртак китаплар бастыруы да шул нәтиҗәле дәвамчанлыкны ачык итеп күрсәтә.

Борынгы тәрбия мәктәбе үк шундый гыйбрәтле нәтиҗәгә килгән: өмет белән баккан улың киңәшеңне тотармы-юкмы, әмма ул синең үрнәгеңә барыбер ияречәк. Гомумән, балалар ялыктыргыч үгет-нәсихәткә түгел, беренче нәүбәттә үрнәккә тансык. Ә Хәмидуллиннар гаиләсендә ияртә алучылар бар. Аларның кызы Зөһрә дә үз әти-әнисенә бик лаек. Казан дәүләт университетын тәмамлагач та, ул җаваплы вазифалар башкарырга алына. Хәзер инде Булат белән Зөһрәнең уллары, әби-бабасын сөендереп, җай гына кул арасына керә башлады. Гаделлек саклап әйткәндә, бу гаиләдәге тәрбиянең уңышлы куелышында Дания ханымның өлеше аеруча зур. Янә искәртеп узасы килә: ананың акыллылык күрсәтүе төче-мөче вәгазьләүдән өстен. Шәхеснең үз-үзен зирәкләрчә тотышы алмаш буынны сүзсез тәрбияли. Аны безнең даирә шундый итеп белә. Ул насыйп ирен дә «Лирон абый» дип йөртә. Әлеге сәеррәк мөгамәләдә нәзакәтле хөрмәт бардыр. Әмма минем озак еллар дәвамында күзәтүемнән тагын да гаҗәбрәк нәтиҗә килеп чыга. Монысы бөтенләй башка вазифаны аңлата. Чынлыкта Дания ханым инде менә ярты гасыр «Лирон абыйсын» үзенең... өченче баласы итеп карый. Әйе, теләсә нинди иҗат әһеле гаиләдә җылы кайгыртучанлыкка мохтаҗ. Әлбәттә, әдипнең таянычы булу җиңел генә бирелми. Мондый миссия өчен дә зур талант көче кирәк. Әзерлек тә сорала. Күпләр шаһит, Дания Ибраһим кызы озак еллар Язучылар берлеге карамагындагы оешмаларда эшләде, каләм ияләренең эчке тормышындагы хәлләр белән һәрдаим хәбәрдар булырга тырышты. Яңа әдәби әсәрләрне укып баруы да аның зыялы зат икәнлеген раслап тора. Язучы хатыннарының классик үрнәге. Һәрьяклап уңган Дания ханымны әнә шулай бәяләргә мөмкин.

Ерак сәфәргә чыккан һәрбер кәрванның дөрес юнәлешне күрсәтүче юламаны булган. Иксез-чиксез әдәбият дөньясын танып белүдә дә күп вазифаларны башкара алырдай белекләләр кирәк. Алар элгәрге әдипләр белән элемтәләрне дә торгыза, ихтыяҗ чыкканда, фәнгә дә башаяк кереп китә, кайбер очракта гыйльми арадашчы ролен дә үти, милли мәдәниятебез мәсьәләләре буенча киңәшләр дә бирә... Күренгәнчә, Лирон Хәмидуллин кебек затларга йөкләнгән бурычлар гадәти белгечлек таныклыгы сәхифәсенә генә сыймый. Татар халкы яулаган рухи биеклекне һәрдаим тәкъдир итеп тору сорала. Асылыбызны гәүдәләндергән мондый югарылыкка төрле яклап күтәрелергә мөмкин. Әмма урау сукмаклар кыйммәтле вакытны ашый. Күпне белгән юламаннар ярдәме максатка ирешүне мотлак җиңеләйтә. Шушы уңайдан академик Миркасыйм Госмановның сурәтләмәгә тәңгәл сүзләре хәтердә яңара. «Тыйнак табигатьле каләмдәшебез» дип исемләнгән мәкаләдә Лирон Хәмидуллин образы үзенчәлекле төстә ачыла: «Ул һәр очрашкан саен сине кысыграк күзләрен тагын да кыса төшеп, күзлеген төзәтә-төзәтә, якты чырай белән елмаеп каршылар. Карашында аның «Кирәгем булса – әзермен...» дигән кебегрәк сораулы чалым да чагыла сыман».

Ышанып әйтергә мөмкин, Лирон Хәмидуллинның әзер торуы беркемдә дә шик уятмыйдыр. Ул галимнәргә дә, үзенең каләмдәшләренә дә, укучыларына да кирәк. Аның булышлык күрсәтергә ашкынуы халкыбыз өчен бик мөһим.

**Зиннур МАНСУРОВ**

**Редакциядән:**

*Каләмдәшебез, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, ТР Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенең Г.Исхакый исемендәге премиясе лауреаты Лирон Хәмидуллин бу көннәрдә 85 яшьлек юбилеен билгеләп үтә. Шушы ук көннәрдә аларның Дания ханым белән бергә яши башлаганлыгына да 50 ел тула. Икесенә дә ныклы сәламәтлек, олы бәхет һәм күңел тынычлыгы теләп калабыз.*

## АНТ ЭЧКӘНДӘГЕ ЫСЫЛДАУЛАР...

– Йә, ни үзгәрде соң? – диде кемдер. – Әйтегез әле, барсы да элеккечә калды түгелме соң? Ләкин аны ишетүче булмады. Ул көнне дә, аннан соңгы көннәрдә дә.

– Берни дә үзгәрмәде. Ә бит: "Барысының да Астын-Өскә китерәбез", – дигәннәр иде.

– Өстен-Аска китерделәр китерүен, әмма үзләре Астан-Өскә күтәрелә алмадылар. Хәтта Астан-Өскә күтәрелү бик үк кыен да түгел икән. Күтәрелгәннән соң шунда калу гына бик кыен икән.

– Берни дә үзгәрмәде бит?! – диде тагын теге гаҗәпләнүле аваз.

– Нәрсә үзгәрергә тиеш иде соң? – дип сорады икенчесе.

– Өстен-Аска китергәч, без Өстә калырга тиеш идек... Өстәге Аста калды калуын... Астагысы һаман Өскә үрмәли алмый...

– Өскә күтәрелмәсә, сиңа ни зыян? Бүтән кайгың булмаса, кычытмаган җиреңне кашып йөрмә, – диде аңа бер таныш кебегрәге.

– Әйттем исә кайттым. Миңа ни? Өстен-Аска китердегез ни дә, Астын-Өскә китердегез ни. Миңа тегеләй дә, болай да бер файдасы да юк.

– Файдасы юк, имеш. Астын-Өскә, әй, түгел лә, Өстен-Аска китерик, Өстен-Аска китерик, дип иң исәрләнеп йөрүче син идең түгелме соң? Бөтен Астагыларны Өскә өндәүче дә, Өскә менә калса, шунда һәркайсыгызны оҗмахта яшәтәм, дип, тау-тау вәгъдәләр бирүче дә Син идең бит. Моның өчен ниндидер искиткеч шәп ысулың барлыгын, бары тик әүвәл Өстен-Аска китерергә кирәклеген тукыган, калганын шул супер ысул хәл итәчәк дип лаф орган син түгелме?

– Мин андый проектның барын Сезгә әйтмәдем, күрсәтмәдем. Өстәгеләрдән дә Өстәгеләргә әйттем... Алар – Өстәгеләрдән дә Өстәгерәкләр:

– Астагыларда эшебез юк, үзегезне үзегез карагыз, – диделәр...

...Ә Өстәгене Аска төшерүебез әйбәт булды. Чөнки ул үзе Өсне-Аска төшермичә генә Асны-Өскә күтәрмәкче иде... Ул Асны Өскә күтәрү ягында булган...

– Үзен Өстән-Аска төшермичә генәме?

– Әйе. Әмма Өстен-Аска китерергә теләүчеләр моңа риза булмады.

– Ни өчен?

– Чөнки Өстен-Аска китерүчеләр: "Без Өстен-Аска китерәчәкбез!" – дип ант эчкәннәр иде...

– Ни сөйлисең Син, хәзер антын тотучы бармы?

– Ант тотучысы булмаса, ант эчүчесе бар. Эчкән авыз белән эчмәгән авыз бер булмас, ди торган иде Өстен-Аска китерүче, ант эчеп астына итүче остазыбыз.

– Гаҗәп...

– Ни-нәрсәсе гаҗәп?!

– Өстен-Аска китергәчтен, бернәрсә дә үзгәрмәве гаҗәп?..

– Өстен-Аска китерү үзе үзгәреш түгелмени, и, наданым? Үзгәреш кирәк идемени сиңа?.. Үзгәреш булмаса, үзең үзгәрәсең инде... Башка ысул юк... И, наданым.

– Өстен-Аска китергәч тә, берни үзгәрмәгәч, кызык түгел... Астын-Өскә китерү кирәк булгандыр да, бәлки...

– Үзгәрешләр булды, Син аны әлегә сизмисең генә, наданым...

– Үзем сизмәгәч, нинди үзгәреш була соң ул?

– Менә, үзгәреш булмаганын һәм без булганда мәңге булмаячагын сизә башлагансың бит... Димәк, үзгәрәсең. Димәк – үсәсең. Акылың үсә, наданым!..

– Әйдәгез, шуның өчен салганын күтәреп куйыйк. Ант итмичә генә.

– Тутырып сал тустаганым, көтмә кабат кыстаганым.

– Ант итмәгәч, күтәреп булмый.

– Ә үзең Астын-Өскә күтәрик тә, Астын-Өскә күтәрик, дисең, йөз ел бер сүз сөйлисең.

– Тсс – ишетмәсеннәр... Өр-яңа ысулым бар!..

**Мөхәммәт МИРЗА**

## КОЛХОЗ КАССИРЫ КӘҮСӘРИЯ ҺӘМ БАНКОМАТ

1987 ел. Советлар Союзы чоры. Кассир Кәүсәрия «Сбербанк»ка колхозчылар өчен хезмәт хакы алырга киткән дигән хәбәр яшен тизлегендә авыл өстенә таралды. Озак та үтми йөзләрендә шатлык нуры балкыган колхозчылар берәм-берәм хуҗалык идарәсе каршына җыела башлады. Бу вакытта Кәүсәрия алар өчен колхоз рәисеннән дә, баш бухгалтердан да өстен, зур абруйлы шәхес булып тоелды. Төркем-төркем баскан колхозчыларның авызында сүз гел кассир һәм хезмәт хакы турында барды:

– Ходай җиңеллек бирсен инде үзенә, үткән айдагыча банктан буш кайтмаса ярар иде, Кәүсәребез, – дигән өметләр багладылар аңа.

Шундый уйларга чуалып, беренче булырга тырышып, әрсезрәкләр кассаның каршында бер-берсен этә-төртә чират ала башлады. Берәр сәгать чамасы үткәннән соң, ниһаять:

– Акча килде, акча килде, кассирга яшел юл, юл бирегез касс-сир-га! – дигән шатлыклы тавышлар көчле бер лозунг кебек яңгырады. Юлда хәлдән тайган Кәүсәр, халык төркемен ерып, кулындагы акча тулы зур сумкасы белән көчкә үз бүлмәсенә кереп югалды, һәм шактый тынлык урнашты. Колхозчыларның кайберләре, озаксынып:

– Сеңел, ач инде, ач тәрәзәңне, эш хакыбызны көтә-көтә ялыктык бит инде. Эх, кайчан бездә тәртип булыр икән?! – дип кычкырындылар. Тавышлар көчәйгәннән-көчәя барды, һәм шушы зарланулардан соң тылсымлы касса тәрәзәсе, матур әкияттәгедәй, шыгырдап ачылып китте. Хезмәт хакы алырга килүчеләр рәхәтләнеп сулап куйдылар…

Аннан соң и тотынды, и тотынды этеш-төртеш, әйтерсең лә кассаны штурмлау башланды. Моның нәтиҗәсендә, дулкын-дулкын булып тибрәлгән халык өермәсе эченнән, беренче булып эш хакын алучылар тиз арада бөке сыман читкә очып чыктылар. Бу мизгелдә алардан да бәхетлерәк кеше юк иде.

Касса тәрәзәсе төбендә берәүләр: «Ник безгә эш хакын әз язганнар?» – дигәч, кассир аларны аңлатмалар алырга дип икенче катка, баш бухгалтерга җибәрде. Тегеләр аннан төшкәнче, алган чиратларыннан җиллләр искән иде инде.

Чиратлылар һөҗүме дәвам итте, тавышлар кызганнан-кыза барды. Эш хакы алучылар арасында ыгы-зыгы, ризасылык тагын да купты: «Кәүсәр, Кәүсәр, зинһар, мине, мине беренче җибәр! – дигән ялварулар ишетелде. – Чык, кит аннан, бас чиратка, колхозда өч көн генә эшлисең…»

Бүре, Төлке, Саескан, Кәҗә дигән кушаматлар, үртәүләр яңгырап торды коридорда.

Хезмәт хакы алырга килүчеләр арасында чигелдәк кадәрле кечкенә генә бер апа, бу хәлне күзәткәннән соң: «Ыланнар, мин булдыралмыймын, бу тамаша эченә кереп акчамны алалмыймын, мине монда кысып үтерүләре ихтимал», – дип, өенә үк кайтып китте.

«Кассирыбыз Кәүсәргә Ходай сабырлык бирсен, ничек бу хәлгә түзә икән, мескен», – дип кызганучылар да булды.

Колхоз кассасы янындагы тамаша биш сәгать чамасы дәвам итте. Чират куәте тора-бара сүнгәннән-сүнде һәм төнге сәгать унда, ниһаять, колхозчылар, тулаем хезмәт хакы алып, өйләренә таралды. Ул кичне хәлдән тайган Кәүсәр: «Шөкер, тагын бер айга котылдым болардан», – дип, көч-хәл белән өенә кайтып китте.

…2017 ел. Ул көннәрдән соң утыз ел сизелми дә үтеп киткән. Мин кассир Кәүсәрияне «Пятёрочка» кибетендә очраттым. Ул һаман шул ук эштә кешеләргә хезмәт хакы бирә. Юк… Юк… Кәүсәрия дигәннән, бу ул түгел, бу аның образы – хәзерге заман таләпләренә туры китереп ясалган могҗизалы дүрт читле тартма – Банкомат кына. Элеккеге заман белән бүгенге көнне чагыштырып алдым.

Банкомат ул үз эшен, үз вазифасын бик төгәл башкара. Аның тәрәзәсендә «Баланс карты», «Какими купюрами выдать», «Другая сумма», дигән язулар чыга, һәм бер-берсен белмәгән кешеләр, үзара аралашмыйча, сүз кушмыйча гына акчаларын алалар да салкын гына китеп баралар. Кушамат кычкыру дигән нәрсә дә юк монда.

Элек, хезмәт хакы алган көннәрдә, касса төбендә булса да күрешә торган идек. Үзара бердәмлек, табигый җылылык, бер-береңә ярдәмчеллек сыйфатлары яши иде. Ә хәзер, банкоматлар, җансыз тартмалар күбәйгән саен, көннән-көн араларыбыз ерагая.

**Рөстәм АРИФУЛЛИН**
*Ульян өлкәсе, Иске Кулаткы*

# Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## ТАТАРСТАН КОНСТИТУЦИЯСЕНӘ – 25 ЕЛ

Казанда, С.Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында Тататрстан Республикасы Конституциясеннең 25 еллыгына багышланган тантаналы җыелыш булды. Анда ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, ТР Премьер-министры Алексей Песошин, ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, ТР Дәүләт Советы депутатлары, министрлыклар, ведомстволар җитәкчеләре, шәһәр, район хакимияте башлыклары һ.б. катнашты. Р. Миңнеханов үзенең чыгышында ТР Конституциясенең җәмгыятьтә тынычлыкны, тотрыклылыкны, милләтара татулыкны тәэмин итүдә, тарихи, милли һәм рухи традицияләрне, мәдәниятне, телләрне саклауда һәм үстерүдә зур роль уйнавын әйтте.

## ТР ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ СЕССИЯСЕ

ТР Дәүләт Советының 33нче утырышы булды. Аның көн тәртибендә татар теле мәсьәләсе билгеләнмәсә дә, бүгенге вазгыятьтә зур шау-шу куптарган бу теманы депутатлар күтәрми кала алмадылар. Утырышта ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Дәүләт Советының мәгариф, фән, мәдәният һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев, Бөтендөнья татар конгрессы рәисе Ринат Закиров, ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова, ТР прокуроры Илдус Нәфыйков, депутат Николай Рыбушкин һ.б. чыгыш ясады. «Без артык тирәнгә кереп киттек, туксанынчы елларга ук әйләнеп кайттык. Милләтләр арасындагы мөнәсәбәтләрдә берниндн проблема булмаганда, ничек шулай итеп җәмгыятьне бүлгәләрлек хәл китереп чыгарырга була», – диде Р.Миңнеханов. М.Шәймиев бу мәсьәләнең уку елы барышында кузгатылуына гаҗәпләнүен белдерде. «25 ел буе эшләдек, ә хәзер уку елы барышында җимерергә керешикме», – диде ул. Утырышны ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин алып барды. ТР Дәүләт Советының 33нче утырышы рәсми рәвештә ябылмады. Ул дәвам иттереләчәк һәм махсус тел мәсьәләсенә багышланачак. Республика прокуратурасы белән Мәгариф һәм фән министрлыгы үз аңлатмаларын бирәчәк.

## ПАРЛАМЕНТ ДӘРЕСЛӘРЕ

Татарстан Республикасының Дәүләт Советы бинасында тарих, хокук һәм җәмгыять белеме укытучылары өчен ачык ишекләр көне һәм махсус семинар узды. Әлеге чара Татарстан мәктәпләрендә үтәчәк Парламент дәресләре уңаеннан оештырылды. Быел бу дәресләр Татарстан Конституциясенең 25 еллыгына багышлана. Укытучылар белән очрашу вакытында Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Парламент дәресләренең гражданлык активлыгын формалаштыруда, укучыларда кануннарга карата дөрес мөнәсәбәт булдыруда әһәмиятен ассызыклады. Ул мәктәптән үк балаларда законлылык мәсьәләләренә кызыксыну уяту мөһимлеге турында сөйләде. Парламент рәисе хокук һәм җәмгыять белеме укытучыларының хокук һәм бурычларга бәйле төрледән-төрле сорауларга җавап бирергә әзер булырга тиешлеген билгеләп китте. Моның практик әһәмияте дә бар. Хәзер законнарны камил белеп үскән буын тиздән Татарстанда кабул ителгән «Стратегия-2030» программасын тормышка ашырырга тиеш булачак. Ф.Мөхәммәтшин Татарстан Конституциясен республиканың үсешен тәэмин итә, җәмгыятьтә тотрыклылык саклый торган документ дип атады. Россия законнары белән тәңгәлләштерү аркасында үзгәрешләр кертелсә дә, аның бик күп өлеше сакланып калуын телгә алды.

Семинарда Татарстан Конституциясенең тарихы, әһәмияте турындагы төп доклад белән Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты рәисе Шакир Яһудин чыгыш ясады. Ул? Татарстан белән федераль үзәк арасындагы шартнамәгә кул куелмау мәсьәләсен искә алып, Россия киләчәктә барыбер үз төбәкләре белән килешү нигезендә эш йөртәчәк әле дигән өмет белдерде.

## И ТУГАН ТЕЛ...

Татарстан Республикасы Язучылар берлеге Россия Федерациясе Президенты Владимир Путинга мөрәҗәгать белән чыкты. Ул Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең киңәйтелгән утырышында кабул ителде. «Дәүләт теле статусындагы татар телен мәктәп программасындагы мәҗбүри предметлар исемлегеннән төшереп калдыру татар язуын, әдәбиятын,

тулаем бөтен татар мәдәниятен инкыйразга – юкка чыгуга дучар итәчәк. Өстәвенә Президент күрсәтмәләрен гамәлгә ашыру башка халык вәкилләрен мәктәп предметы булган татар теленә генә түгел, шушы телдә сөйләшүчеләргә дә кимсетеп карауга этәрәчәк, республикадагы милләтара мөнәсәбәтләрнең ныклы нигезен какшатачак», дигән юллар да бар әлеге мөрәҗәгатьтә.

***

23-24 октябрьдә Махачкала шәһәрендә милли мәгариф проблемаларына һәм телләрне өйрәнү мәсьәләсенә багышланган Бөтенроссия киңәшмәсе булды. Россия Дәүләт Думасының мәгариф һәм фән комитеты оештырган бу мәртәбәле җыенда Дәүләт Думасы депутатлары, Федерация Советы әгъзалары, Россия мәгариф һәм фән министрлыгы, Рособрнадзор җитәкчеләре, милли республикалар һәм өлкәләрдән килгән вәкилләр катнашты. Татарстан Дәүләт Советының Мәдәният, мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе, Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиев пленар утырышта ясаган чыгышында республика мәктәпләрендә дәүләт телләрен һәм туган телләрне укыту өлкәсендә туган проблемалар һәм аларны хәл итү юллары турында сөйләде. Башка милли республика депутатлары милли мәгариф өлкәсендә Татарстан алып барган сәясәтне хуплауларын һәм соңгы вакытта килеп чыккан мәсьәләләрне бергәләп хәл итәргә кирәклеген әйттеләр.

Шул ук көннәрдә Разил Вәлиев Дагыстанның халык шагыйре Шәет-Ханум Алишева җитәкчелегендә кумык язучылары белән очрашып, тугандаш татар һәм кумык әдәби-мәдәни бәйләнешләре, киләчәккә планнар турында фикер алышты.

***

Финляндиядәге ислам татар җәмгыяте чакыруы буенча, шагыйрь һәм депутат Разил Вәлиев Хельсинки шәһәрендә дин һәм туган тел бергәлегенә багышланган «түгәрәк өстәл»дә катнашты.

Суоми илендәге милләттәшләребез, гасырлар буена чит илдә яшәп тә, диннәрен һәм туган телләрен саклап кала алулары турында горурланып сөйләделәр. Аларның сорауларына җавап биреп, Разил Вәлиев Россиядә һәм Татарстанда милли мәгариф, милли мәктәп тирәсендә соңгы арада туган катлаулы вазгыять, туган тел язмышы турында тәфсилле мәгълүмат бирде, бу проблеманы хәл итү юллары турында үзенең фикерләре белән уртаклашты. Соңыннан Хельсинкиның «Татар милли йорты»нда Разил Вәлиев иҗатына багышланган әдәби-музыкаль кичә булды.

***

25-27 октябрьдә Самара өлкәсендә Татар мәгарифе көннәре үткәрелде. Анда Татарстаннан республиканың мәгариф һәм фән министры урынбасары Т.Алишев җитәкчелегендә зур делегация катнашты. Татар мәгарифе көннәре өлкәнең Камышлы, Похвистнево районнарының Балыклы, Степановка, Иске Ярмәк, Байтуган, Гали авылы мәктәпләре, мәктәпкәчә балалар учреждениеләре эше тәҗрибәсе белән танышудан башланды. Милли мәгарифебезне үстерүдә зур өлеш керткән Зыя Ярмәки, Сәләй Вагыйзов, күренекле шагыйрьләр Әнвәр Давыдов, Рөстәм Мингалимнәрнең ватаннарында үткәрелгән әлеге чара кич белән Камышлы мәдәният йортында районның барлык мәгариф активистлары катнашында очрашу белән дәвам итте. ТР мәгариф һәм фән министрлыгының төбәкләр белән хезмәттәшлек итү идарәсе җитәкчесе Г.Мусина, Камышлы муниципаль районы башлыгы Р.Баһаутдиновлар бүгенге көн шартларында милли мәгарифне саклап калу һәм үстерү чаралары турында сөйләделәр.Беренче көнне очрашулар Камышлы районы мәктәпләре укучылары һәм Казаннан килгән сәнгать осталары М.Галиев, А.Габдинов, М.Мирза, Д.Бәдретдиновлар катнашында зур концерт белән тәгәлләнде.

Икенче көнне Самара каласында узган пленар утырышта ТР мәгариф һәм фән министры урынбасары Т.Алишев Татарстан милли мәгариф системасы һәм Россия Федерациясе төбәкләре белән хезмәттәшлек турында доклад белән чыкты. Утырышта Самара өлкәсенең мәгариф министры урынбасары М.Татаринцев, «Татар теле» милли җәмәгать оешмасы рәисе И.Гомәров, Татарстаннан килгән белгечләр К.Фәтхуллова, Г.Галиева, Р.Шәрифуллин, Самарадан «Яктылык» мәктәбе хезмәткәрләре Л.Сабиров, А.Әпсәләмова, Ф.Гыйләҗева, С.Нуруллина, Ф.Фәйзуллиннар катнашты.

## МӘРҖАНИНЕҢ 200 ЕЛЛЫГЫНА

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов 2018 елда республикада фәлсәфәче, тарихчы, мәгърифәтче, дин эшлеклесе Шиһабетдин Мәрҗанинең тууына 200 ел тулу уңаеннан бәйрәм чаралары уздыру турында Указ игълан итте. Әлеге Указ нигезендә оештыру комитеты төзелде. Аны ТР мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттахов җитәкли.

## ГУМИЛЁВКА – ЧӘЧӘКЛӘР

Казанда язучылар, галимнәр тууына 105 ел тулу уңаеннан Лев Гумилёв бюстына чәчәкләр салдылар. Чәчәк салу тантанасында ТР Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе һәм

төбәкне өйрәнү институты директоры Искәндәр Гыйләҗев, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов һ.б. чыгыш ясады.

## МОХТАР АУЭЗОВНЫҢ ТУУЫНА 120 ЕЛ

Казакъстанның Семей (Семипалат) каласында әдип Мохтар Ауэзовның тууына 120 ел тулуны зурлап билгеләп үттеләр. Бу уңайдан Шәкәрим исемендәге Семей дәүләт университетында халыкара фәнни-гамәли конференция булып узды. Аның пленар утырышында Казаннан галим Хатыйп Миңнегулов «М.Ауэзов һәм татарлар» дигән темага доклад ясады. Юбилей кунаклары (алар арасында галим, җәмәгать эшлеклесе Морад Ауэзов та бар иде) М.Ауэзов һәйкәленә чәчәкләр салды, әдипнең туган җәйләвенә барды, андагы һәм Семей каласындагы музейларында булды, педагогика көллияте укытучылары һәм студентлары белән очрашты.

## САҖИДӘ СӨЛӘЙМАНОВА ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЛАРЫ

Әлмәт Татар дәүләт драма театрында Саҗидә Сөләйманова премиясе лауреатларын бүләкләү тантанасы булды. Быел ул 12нче тапкыр үткәрелде. «Бу эшне 2006 елда ул вакытта Татарстан Язучылар берлеге җитәкчесе Илфак Ибраһимов белән башлап җибәргән идек», – диде «Татнефть» компаниясе генераль директоры урынбасары Рөстәм Мөхәммәдиев. Быел олуг бүләккә «Илкәй батыр» китабы өчен Галимҗан Гыйльманов, «Күңел тәрәзәләрем» китабы өчен Рәзинә Мөхияр, «Авось, Небось и Кабы» китабы өчен Лев Кожевников лаек булды. Кызыксындыру премияләре Зинаида Захаровага («Нурлы җиһан» китабы өчен), Фәнәвис Дәүләтбаевка («Әйтер сүзем бар» шигырьләр җыентыгы өчен), Фәнил Гыйләҗевка («Ризасызлык»шигырьләр җыентыгы өчен) тапшырылды. Лауреатларны «Татнефть» компаниясе генераль директоры урынбасары Рөстәм Мөхәммәдиев, Әлмәт районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Светлана Лаптева, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов котлады. Тантанада С.Сөләйманова стипендиясен алачак 10 яшь иҗатчыны да котладылар. Бәйрәмгә кунак булып Татарстанның халык язучылары Марсель Галиев, Гәрәй Рәхим, язучылар Ләбиб Лерон, Эльмира Шәрифуллина, С.Сөләймanованың улы Әнвар Маликов та (җәмәгате Асия ханым белән) килгән иде.

## ЮБИЛЕЙЛАР

Габдулла Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачы театрында драматург, прозаик, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Фатих Хөсни исемендәге әдәби премия лауреаты Рәдиф Сәгъдигә 60 яшь тулу уңаеннан юбилярның «Гашыйклар утравы» спектакле күрсәтелде. Тамаша алдыннан бәйрәмдарны Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, Яшь тамашачы театрының баш режиссёры Ренат Әюпов, Г.Камал театры артисты Әсхәт Хисмәт, Г.Кариев театры артисткасы Рәмзия Закирҗанова, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон, шушы басманың бүлек мөхәррире Марат Закир һ.б. котлады.

***

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең зур уку залында язучы-прозаик, юмор остасы, автор-башкаручы, режиссёр Алмаз Хәмзинга 70 яшь тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичә үткәрелде. Юбилярны Милли китапханәнең генераль директоры Сөембикә Җиһаншина, аның урынбасары Ирек Һадиев, каләмдәшләре Равил Фәйзуллин, Тәлгат Галиуллин, Камил Кәримов, Рәмис Аймәт, Риман Гыйлемханов, җырчы Рафаэль Сәхәбиев котлады. Кичә Алмаз Хәмзинның зур чыгышы белән тәмамланды.

***

Чаллыдагы «Энергетик» мәдәният сараенда шагыйрә Әлфия Ситдыйкованың юбилей кичәсе булып узды. Юбилярны Чаллы шәһәр хакиме башлыгы Рамил Хәлимов, Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Рәмис Аймәт, Язучылар берлегенең Чаллы бүлеге җитәкчесе Факил Сафин, «Мәдәни җомга» газетасы баш мөхәррире Вахит Имамов, каләмдәшләре Фоат Садриев, Айдар Хәлим, Мөҗәһит Әхмәтҗанов, Чаллы татар дәүләт драма театры вәкилләре, Актаныштан якташлары һ.б. котлады.

## ТАТАР ШИГЪРИЯТЕ – ЯКУТ ТЕЛЕНДӘ

Якут-Саханың «Медиа-холдинг Якутия» нәшриятында татар поэзия антологиясе (төзүчесе – Ленар Шәех) басылып чыкты. Әдәбият галиме Фоат Галимуллинның кереш мәкаләсе белән ачылган бу китапта 16 шагыйрьнең шигырьләре урын алган.

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: роман Н.ЯГУДИНА «Конные казаки», повесть Р.ГАЛИУЛЛИНА «Адран», рассказы-миниатюры Г.ВАСИЛОВОЙ; стихи Р.НИЗАМИ, Р.РАХМАНИ, Ф.МУСЛИМОВОЙ; рубаи Ф.ДАВЛЕТБАЕВА.*
*«Новые имена»: стихи М.ЗАКИРОВОЙ.*
*«Круглый стол» с участием И.ТАГИРОВА, Р.ХАКИМОВА, И.ЗАГИДУЛЛИНА, Л.ГУБАЙДУЛЛИНА. Подготовил И.ИБРАГИМОВ.*
*«100-я страница»: Г.МУХАМЕТШИН. «Татарская грусть».*
*«80 лет со дня рождения К.Тимбиковой»: статья М.МАЛИКОВОЙ «Осветитель души».*
*«80 лет со дня рождения З.Насибуллина»: стихи поэта.*
*«Наши юбиляры»: Статьи – Д.ЗАГИДУЛЛИНОЙ, посвящённая 85-летию Р.Ганиевой, З.МАНСУРОВА, посвящённая 85-летию Л.Хамидуллина.*
*«Юмор-сатира»: юморески М.МИРЗЫ, Р.АРИФУЛЛИНА.*
*Из фотоархива журнала.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: «Казанский пейзаж с мечетью Марджани». Картина Закира Батраева; Казань. Парк Урицкого.*

## IN THIS ISSUE:

*«Prose and poetry»: novel by N.YAGUDIN «Mounted Cossacks», novel by R.GALIULLIN «Adran», narrative miniatures by G.VASILOVA; poems by R.NIZAMI, R.RAKHMANI, F.MUSLIMOVA; rubaiyat by F.DAVLETBAEV.*
*«New names»: poems by M.ZAKIROVA.*
*«Round table» with the participation of I.TAGIROV, R.KHAKIMOV, I.ZAGIDULLIN, L.GUBAIDULLIN. Prepared by I.IBRAGIMOV.*
*«100th page»: G.MUKHAMETSHIN. «Tatar sadness.»*
*«80th anniversary of K.Timbikova»: article by M.MALIKOVA «The soul light».*
*«80th anniversary of Z.Nasibullin»: poems by the poet.*
*«Our jubilees»: articles by D.ZAGIDULLINA dedicated to the 85th anniversary of R.Ganieva, Z.MANSUROV dedicated to the 85th anniversary of L.KHAMIDULLIN.*
*«Humor-satire»: humoresque by M.MIRZA, R.ARIFULLIN.*
*From the photo archive of the magazine.*
*Diary of social and cultural life.*
*On our covers: «Kazan landscape with the Mardjani mosque». Picture by Zakir Batraev; Kazan. Uritsky park.*

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Казан пейзажы. Мәрҗани мәчете». *Закир Батраев картинасы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* Казан. Урицкий паркы.
*Фото «2gis.ru» сайтыннан алынды.*